ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

8.2010



# ТАТАРСТАН СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНИТЕТЫ ТУРЫНДА ДЕКЛАРАЦИЯ

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы Югары Советы,

—республиканың күпмилләтле халкы язмышы өчен тарихи җаваплылыкны аңлап;

—Россия Федерациясендә һәм Совет Социалистик Республикалар Союзында яшәүче барлык халыкларның суверен хокукларына ихтирам белдереп;

—автономияле республика статусының аның күпмилләтле халкының киләчәктә сәяси, экономик, социаль һәм рухи үсеше мәнфәгатьләренә туры килмәвен күрсәтеп үтеп;

—татар милләтенең, республикада яшәүче бөтен халыкның үзбилгеләнүгә булган аерылгысыз хокукын тормышка ашырып;

—демократик хокукый дәүләт төзергә омтылып,

1. Татарстанның дәүләт суверенитетын игълан итә һәм аны **Татарстан Совет Социалистик Республикасы—Татарстан Республикасы** итеп үзгәртә.

2. Татарстан ССР территориясендәге җир һәм аның байлыклары, башка табигый байлыклар һәм башка ресурслар бары тик аның халкының милке булып тора.

3. Татарстан ССР үз территориясендә яшәүче барлык гражданнарга, нинди милләттән булуларына, социаль чыгышлары, диннәре, политик инанулары нинди булуга һәм башка аерымлыкларга карамастан, кешегә тигез хокуклар һәм ирекләр гарантияли, Татарстан ССРда татар һәм рус телләренең дәүләт теле сыйфатында тигез хокуклы кулланылуы, башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнә.

4. Киләчәктә Конституциядә, башка хокукый норматив актларда, дәүләт тормышында дәүләтнең рәсми исемен **«Татарстан Совет Социалистик Республикасы» (Татарстан ССР яки Татарстан Республикасы)** дип кулланырга.

Республика дәүләт властеның югары органын—**«Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы»** дип, ә ул кабул итә торган актларны—**Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы актлары** дип исемләргә.

5. Бу Декларация Татарстан ССР Конституциясен эшләү, Татарстан ССР законнарын үстерү өчен, Татарстан ССРның Союз договорын, РСФСР һәм башка республикалар белән договорлар әзерләүдә һәм төзүдә катнашуы өчен, Татарстан ССР дәүләт төзелешенең аеруча мөһим мәсьәләләрен һәм аның ССР Союзы, РСФСР һәм башка республикалар белән мөнәсәбәтләрен аның халкы тикшерүенә чыгару өчен нигез булып тора.

Татарстан ССР Конституциясе һәм законнары Татарстан ССРның бөтен территориясендә өстенлекле.

6. Татарстан ССРның яңа Конституциясен, башка законнарны һәм норматив актларны кабул иткәнгә кадәр Татарстан ССР территориясендә Татарстан ССРның, РСФСР һәм ССР Союзының Татарстан ССРның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә каршы килми торган законнары һәм закон актлары гамәлдә булуны дәвам иттерә.

Бу Декларация аны кабул итү вакытыннан көченә керә.

Татарстан Совет Социалистик Республикасы
Югары Советы рәисе — М. ШӘЙМИЕВ.

Казан, 1990 ел, 30 август.

**Казан утлары**

**Qazan utları**

2010

# 8

**(1054)**

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*
*Казан, Академия ур., 2*

татмедиа

БАШ МӨХӘРРИР

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

ИДАРӘ:

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Роберт МИҢНУЛЛИН. Татар киңлекләрендә. *Шигырьләр.* ........ 5
Альберт ХӘСӘНОВ. Данәгәл. *Роман. (Дәвамы)* ........ 10
Нур ӘХМӘДИЕВ. Шәм кабызам. *Шигырьләр.* ........ 45
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Карурман аша.... *Хыялый кыйсса.* ........ 49
Айрат СУФИЯНОВ. Тормыш йөрәгенә—чәчәк... *Шигырьләр.* ........ 73
ИДЕЛБИКӘ. Гомер симфониясе. *Шигырьләр.* ........ 76

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Мулла. *Ике пәрдәле драма* ........ 79

Туфан Миңнуллин фотоархивыннан. ........ 104

**ТАТАРСТАННЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНИТЕТЫ ИГЪЛАН ИТЕЛҮГӘ 20 ЕЛ**

Рабит БАТУЛЛА. Азатлыкка таба. ........ 106

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Әдәбиятыбыз тарихы төрек телендә. ........ 118

**ФӘН**

Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. Үлемсез «Кыйссаи Йосыф». ........ 121
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ........ 129
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ........ 132

**Г. ТУКАЙНЫҢ 125 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП**

Бөеклек баскычлары ........ 134

**МӘҖИТ ГАФУРИНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Татарның бөек бер моңчысы. ........ 137

**ХӘТЕР**

Фирдәвес ХУҖИН. Күкләр шаһит. *Документаль бәян.* ........ 147

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Госман ГОМӘР. Шигырь—тәмәке түгел! ........ 174

«Казан утлары»—интернетта ........ 176
Безнең календарь. ........ 178

**АК ҖИЛКӘН**

Дания НУРУЛЛИНА. Бәләкәй Дания. ........ 179

«Казан утлары» архивыннан. ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман А. ХАСАНОВА «Данагюль» (прод.); фантастическая повесть А. ТИМЕРГАЛИНА «Сквозь терний...»; стихи Р. МИННУЛЛИНА, Н. АХМАДИЕВА, А. СУФИЯНОВА, ИДЕЛЬБИКИ.
«Драматургия»: Т. МИННУЛЛИН. «Мулла».
«К 20-летию объявления суверенитета Республики Татарстан»: Р. БАТУЛЛА. «Путь к свободе».
«Литературная критика»: А. АХМАДУЛЛИН. «История татарской литературы на турецком языке».
«Наука»: Н. ХИСАМОВ. «Незабвенный «Кыйссаи-Юсуф»; Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.)
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«К 125-летию Г. Тукая»: хронология жизни поэта.
«К 130-летию М. Гафури»: статья Х. МИННЕГУЛОВА.
«Память»: Ф. ХУЗИН. «И небо тому свидетель».
«Белый парус»: Д. НУРУЛЛИНА. «Маленькая Дания».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: памятник М. Вахитову в г. Казани; ученый-писатель Искандер ГИЛЯЗОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and Poetry»: novel by A. KHASANOV «Danagyul» (continuation); fantastic story by A. TIMERGALIN «Through thorns...»; poems by R. MINNULLIN, N. AHMADIEV, A. SUFIYANOV, IDELBIKA.
«Dramaturgy» T. MINNULLIN. «Mullah».
«To the 20th anniversary of Sovereignty of the Republic of Tatarstan»: R. BATULLA. «Path to freedom.»
«Literary Criticism»: A. AHMADULLIN. «History of Tatar literature in Turkish language».
«Science»: N. KHISAMOV. «Unforgettable «Kyyssai-Yusuf»;
F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«For 125th anniversary of G. Tukay»: chronology of poet's life.
«To 130th anniversary of M. Gafuri»: article by H. MINNEGULOV.
«Memory»: F. HUZIN. «And sky is witness».
«White Sail»: D. NURULLINA. «Little Denmark».
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: monument to M. Vakhitov in Kazan; scientist Iskander GILYAZOV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 2.08.2010, график буенча 2.08.2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–1044. Тираж 4150.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2010 ел.



Роберт
Миңнуллин

# ТАТАР КИҢЛЕКЛӘРЕНДӘ

## Монда без дә бар әле!

**Без яшибез бер Рәсәйдә,
Кайныйбыз бер Казанда.
Алыш-биреш дәвам итә
Рәсәй дигән базарда...**

**Моннан ары татарларны,
Белмим, кем дип атарсыз?!
Әмма Рәсәй дигән дәүләт
Була алмый татарсыз!**

**Юк безнең башка илебез,
Безнең башка җиребез.
Шушында аккан каныбыз,
Монда тамган тиребез...**

**Шушы илгә, шушы җиргә
Береккән кендегебез.
Ерак-ерак тарихлардан
Күренә кемлегебез...**

**Бетереп булмый татарны—
Тарихны бозып кына,
Үтереп булмый татарны—
Тарихтан сызып кына...**

**Татардан котылалмыйсың,
Татарны куалмыйсың,
Бу татарны тырышсаң да
Беркая куялмыйсың!**

Роберт МИҢНУЛЛИН (1948) – *Татарстанның халык шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе; күпсанлы китаплар (шул исәптән, 7 томлык «Сайланма әсәрләр») авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Хакыйкатьне белер өчен
Тарихны актарыгыз!—
Бу илгә, бу җиргә безнең
Бар, бар, бар хакларыбыз!

Тарихтагы кара эзләр
Без калдырган эз түгел.
Без килмешәк түгел монда.
Килмешәкләр—без түгел.

Без яшибез Рәсәй дигән
Татар киңлекләрендә:
Күрдек тиңлекләрен дә без,
Күрдек кимлекләрен дә...

Татар илбасар да түгел,
Юлбасар да, баскын да...
Безнең бу үз урыныбыз
Якты кояш астында.

Тик кемгәдер, кемнәргәдер
Дөнья һаман тар әле...
Сез алай бик кәпрәймәгез:
Монда без дә бар әле!

## Үзгәрүен үзгәрдек...

Безне хәзер тыеп булмый
Авызлык белән генә.
Буйсындырып булмый безне
Явызлык белән генә.

Җиңеп булмый безне терсәк
Йә беләк белән генә.
Җиңеп була безне хәзер
Ак теләк белән генә.

Безне яулап алып була
Мәхәббәт белән генә.
Теләктәшлек, дуслык белән,
Мәрхәмәт белән генә!

Заман үзгә, Казан үзгә,—
Үзебез дә үзгәрдек...
Тезләндек без, ләкин торып
Басар өчен тезләндек!

Ә моннан соң, белмим әле,
Түзәрбезме тезләнми?!
Без күптән үзгәрдек инде...
Мәскәү генә үзгәрми.

## Күңелләрдә...

Бу татарда акыл төштән соң шул,
Килә безгә акыл соң гына:

Азатлыкны шаулап, яулап алдык,
Кайтарабыз кире шым гына.

Тын гына да, шым гына да түгел,
Кайтарабыз астыртын гына.

Күңелләрдә хәзер берни дә юк,
Күңелләрдә хәзер шом гына.

Элеккегә кайтып барышыбыз
Сиздермичә генә, тын гына.

Күңелләрдә ачы моң гына шул...
Күңел сыкрый акыртын гына.

## Тукай белән сөйләшү

Ниләр уйлыйсың икән син, Тукай?—
Безнең өчен сызланасыңмы?
Безнең белән горурланасыңмы?
Әллә безне кызганасыңмы?

Ә без һаман синнән калган татар—
Үзгәрмәгәнбездер тамчы да.
Үзгәрмәбездер дә... Хәзер инде
Ярдәм итмәс синең камчы да!

Үз көнебезне без күрер-күрмәс,
Телебезне дә яклар-якламас.
Без һаман шул үләр-үлмәс инде,
Без һаман шул йоклар-йокламас...

Мәскәү абзыебыз әле һаман
Якабыздан тоткан ныгытып...
Үзебезнең татар икәнне дә
Җибәрәбез кайчак онытып.

Кыскан саен кычкырырга кирәк!..
Кычкырмыйбыз—тамак карлыккан.
Без дәшмәскә өйрәнгәнбез инде...
Татарлыктандыр ул, тарлыктан.

Йодырыкларыбыз төйнәлсә дә,
Коерыкларыбыз кысылган.
Әйтерсең лә, койрык кысарга да
Кемдер тарафыннан кушылган.

Мактанырга булдырабыз! Имеш,
Заманында дөнья тотканбыз.
Тотканбыздыр... Ләкин ни өчендер
Телебезне генә йотканбыз.

Телсез дә бит елап-көлеп була,
Утырып була көйләр көйләшеп.
Телсез татар ул иң әйбәт татар,
Аның белән була сөйләшеп.

Телсез татар—иң абруйлы татар!
Телсезләрне була тыңлатып.
Без сүзсез дә аңлый торган халык...
Нәрсә торам әле аңлатып?!

Безнең хәлләр шушындыйрак инде.
Кайтып керсәң әгәр тегеннән,
Язар идең, Тукай, акылыңнан,
Язар идең туган телеңнән.

Язар идең телдән, киек кошлар
Мәхрүм булган кебек канаттан...

Бу хәлләрне күрсәң, оятыңнан
Үләр идең, Тукай, кабаттан.

Син булса да әйт сүзеңне, Тукай,
Татар теле әле тереме?
Юк, кирәкми, телсезләргә, зинһар,
Әрәм итмә газиз телеңне...

Ни дисәң дә, без шул татар инде,
Нинди генә хисләр кичермә!..
Кичер безне, Тукай, кичералсаң,
Кичер безне...
Хәер, кичермә!

## Без шагыйрьләр милләтеннән

*Удмуртиянең халык язучысы*
*Вячеслав Ар-Сергига*

Синең белән без татарча
Сөйләшәбез. Күңелле!
Татарчаң әлләни түгел,—
Син дә татар түгелме?

Хәер, нигә аптырарга?—
Син дә бераз төркисең.
Ә син мине ни өчендер
Удмурт диеп үртисең.

Татарның исемендә үк
ТАТАР да бар, АР да бар.
Алай дисәң, татарларның
Каннарында бар да бар...

Тик без ныграк аңлашабыз
Шагыйрьләрнең телендә.
Тиз аңлыйбыз ни ятканын
Шагыйрьнең тел төбендә.

Шагыйрь дөньясын булмыйдыр
Ни буйлап та, ни иңләп...
Шагыйрьләрнең үз телләре,
Алар үзе бер милләт.

Шагыйрьләрне булмыйдыр ул
Беркем белән дә тиңләп.
Без шагыйрьләр милләтеннән,
Без, димәк, бөек милләт!

## Фәнис Яруллин

Бик күкрәк какмыйк әле без:
«Без барсыннан өстен!»—дип.
Фәнис Яруллин янында
Без күбебез мескен бит.

Без тап-таза, тик булдыксыз...
Күрергә соң ни чара?

**Фәнис Яруллин янында**
**Күбебез ник бичара?..**

**Зарланабыз, зар елыйбыз...**
**Чыңлап тора колаклар.**
**Фәнис Яруллин янында**
**Без, әлбәттә, елаклар.**

**Без, нигәдер, ялкау халык...**
**Язмаса, бетә шагыйрь.**
**Фәнис Яруллин янында**
**Күбебез—мөтәшагыйрь.**

**Бездә дә бар ул егетлек,**
**Бездә дә бар ул иман...**
**Зар еламыйк, ә оялыйк**
**Без Фәнис Яруллиннан!**

## Кебек...

**Мин барсын да аңлыйм кебек...**
**Аңламыймын да кебек.**
**Мин сезне бер дә алдамыйм...**
**Алдалыймын да кебек.**

**Сугыш яралары үткән...**
**Үзе үтмәгән кебек.**
**Илдә сугыш беткән кебек...**
**Үзе бетмәгән кебек.**

**Солдат улларыбыз үлә...**
**Үлмәгәннәр дә кебек.**
**Шуны бар да белеп тора...**
**Белмәгәннәр дә кебек.**

**Болар бар да дәрес безгә...**
**Дәрес тә түгел кебек.**
**Мин дөресен язам кебек...**
**Дөрес тә түгел кебек.**

**Дәүләтебез бар да кебек...**
**Нигәдер юк та кебек.**
**Эшләребез хутта кебек...**
**Без ач та, тук та кебек.**

**Телебезнең хәле яман...**
**Яман да түгел кебек.**
**Гәзит, экран тулы ялган...**
**Ялган да түгел кебек.**

**Бу илдә бер тәртип тә юк...**
**Чүт-чүт тәртип тә кебек.**
**Бу шигырем тәнкыйть түгел...**
**Чүт-чүт тәнкыйть тә кебек.**

*2009—2010*

Альберт Хәсәнов

# ДАНӘГӨЛ

РОМАН

***

—Таһир улым, безнекеләр инде күптән аякта,—дип, салкынча верандада, әнисенең мамыклы канаты астына чумган бәбкәдәй йоклаган Таһирны иртән Фәйрүзә апа кереп уятты.—Дингез ярына баргач үз киемнәренне сал, югыйсә пычратырсың. Менә боларны киярсен,—дип, балык тотканда чыланмый торган иплерәк киемнәр керткән. Таһир киенеп тышка чыкканда, Ногайбәк ага юлга аласы әйберләрне машинага төяп тә куйган. Данәгөл дә үзенә килешеп торган калфак-капюшонлы зәңгәр курткадан, аяк өсте җил кузгатып әтисенә булышып йөри.

—О-о, Адмирал! Хәерле иртә!—диде ул.—Тәмле төшләренне су буена баргач сөйләрсең. Әтием, син безне кайсы якка алып барырга уйлыйсың? Ташбака култыгынамы? Узган юлы көн җиләс булса да, анда бик шәп каптырганыек бит. Әйдә, шунда тотыйк компасны.

—Тәгаен, кызым, шунда барырбыз. Ул култыкны нишләптер үзем дә килештерәм. Анда балык әрсезрәк шул. Барырга да ерак түгел.

—Ә минем буяуларны, мольбертны, өчаякны алмыйбызмени? Ике рамга киергән киндерләрем дә әзер.

—Алары бүген ниемә хаҗәт инде, кызым? Бүген син кунагыңның көен көйлә. Аның күнелен күр. Шулай ич, Таһир, улым?!—Ногайбәк ага Таһирга күз кысты.

—Мин бит алай көйсез кунак түгел,—дип кенә әйтә алды Таһир.—Урын бар бит. Рамнарга киергән киндерләрне дә алыйк, сыешырбыз.

—Ничек инде алмыйбыз ди? Мин бит маринист. Дингезгә чык та, буяуларыңны алма. Дингез патшасы Нептун әфәнденең мине бөтенләй аңламавы бар. Хәтта үпкәләве мөмкин. Дингезнең иң серле күренешләрен полотнога төшерү кулымнан килми башласа? Ә бит мин киләсе ел Парижда Авангард маринистларның Европа күргәзмәсендә катнашырга ниятлим. Кимендә өч полотно белән! Эскизларны байтак ясадым инде.

—Монысы бер!—дип бармагын бөкте Данәгөл.—«Совет хәрби

*Ахыры. Башы узган санда.*

дингез флоты матросы Таһир Туктамышев Франция ярларында» дигән исем астында, дулкыннар чабышкан дингез ярына бастырып, кадерле кунагыбызның да сынын мәңгеләштерергә исәбем бар. Мин портрет остасы түгел түгелен. Маэстрогыз төсләргә бай пейзажлар ясарга ярата. Әмма көн кояшлы булса, болытлар комачауламаса, кунагыбыз риза булса, нигә әле рәсем сәнгате дөньясына бүгенге Совет Гераклы сынын бүләк итмәскә! Шулай бит, Адмирал әфәнде?

—Маэстро, сез мине унайсыз хәлгә куясыз бит. Ә чынында исә бу тәгъдимегезгә чат сөял ике кулым белән риза, Данәгөл туташ. Талантлы рәссамның матур рамга киергән киндеренә эләгү—ул бит чал тарих битенә эләгү, мәңгелеккә атлау!

Шөһрәт ага борын эченнән генә сыкранып та алды:

—Дүрт урынлы «Пежо»ны бу кызый йөк машинасына тинлиме? Мольберт, өчаяк, киндер тарттырган рамнар, кармак таяклары, спиннинглар, кашык-чүмеч-казан! Бер атнага бармыйбыз лабаса. Ярар, ярар, барын да ал инде алайса. Әллә чегән таборы яна жиргә күченәме, дип юлда инспекторлар туктатса, үзең акланырсың.

Таһир шундый нәтиҗә ясарга өлгерде. Ногайбәк ага сукранса, сукрана, әмма бердәнбер кызының бер теләгенә да каршы килми. Чөнки Данәгөлне ул колларча буйсынып ярата бугай. Ә чынлап торып, эчкерсез ярату хисе адәм баласы җилкәсенә төшә торган йөкләрнең иң авыры түгел микән әле?! Яратасың икән, теләсәң, теләмәсәң дә, ташламаларны бихисап ташларга әзерләнә. Ярату хисе синнән аларны күп таләп итә. Аның каравы... Аның каравы—син бәхетле! Синең эчендә ярату хисе балкый. Бер минутка да тынмый, сыекланмый.

—Адмирал!—Данәгөл шап итеп Таһирның җилкәсенә кулын куйды.—Бу исем миңа бик ошый. Ә синең килеш-килбәтең килә. Бүгеннән үк коеп куйган адмирал син. Сиңа шулай дип дәшүемә, шәт, үпкәләмисеңдер?

—О-о! Әйттең сүз, кызым. Менә миңа «адмирал» дип дәшсеннәрие әле!—дип күтәреп алды Ногайбәк ага.—Мин ул затны ничек кенә кочып үпкән булырыем...

—Ишеттеңме, Таһир? Адмирал әфәнде!—Данәгөл Таһир алдына басты, яңагын куйды. Бармагы белән төртеп, кайсы тарафларны әп итеп алырга мөмкин икәнен күрсәтте. Таһир кыймыйчарак кына Данәгөлнең сул як бит уртасыннан үпте. Егетләрчә түгел инде. Беренче сыйныф мәктәп баласы кыюлыгы дәрәҗәсендә генә. Әмма артыгын да кыланырга ярамый. Хуҗа кунакның тыйнагын ярата. «Кунак булсаң, тыйнак бул»,—сүзе дә шуннан бит.

—Алайса, хөрмәтле Адмирал әфәнде, син утыр алга, əти янына. Ә мин артка кунаклыйм. Кузгалдык!—дип, Таһирның җилкәсенә янәдән шап итеп сугып алды.—Үпкәли күрмә тагын. Үзебезчә, Марсель егетләречә дуслык тәгъдим итү генә,—дип елмаеп алды Данәгөл.

Яр буйлап сузылган тигез асфальт юл белән байтак кына баргач, Ногайбәк ага машинасын кинәттән сулга борды. Вак ташлы сөзәк тар сукмактан дингез буена төштеләр, кечерәк кенә алачык алдында туктадылар. Алачык алдында яткан куш йодрык хәтле генә көчекнең чән-чән килүенә, аннан төссез беретын кыңгыр салган, төребкәсен капкан, җирән сакаллы, ярым бөкре бер карт чыкты.

«Йә, гозерегез нидән гыйбарәт?»—дигән төсле ул, кырык-карык йөткереп алды. Машинаны аңа сакларга калдырдылар. Вакытлыча файдаланып тору өчен иркен, сигез кеше сыешлы моторлы көймә алдылар. Таһир көймәгә кереп басу белән, чын моряк булуын раслап, баш бармагын иренена тидереп юешләде дә, аны баш очына күтәреп, як-якка боргалады.

—Зюйд-Ост! Диңгез өсте бүген утюг белән бастыргандай тын булачак,—диде.

—Яхшы хәбәр китерүчеләргә борынгы мисырлылар нинди бүләк биргәннәр әле? Кәрван башы дәрәҗәсе түгелме? Димәк, шул чорлар өчен бу исем бик дәрәҗәле һәм акчалы булгандыр,—диде Данәгөл.

Ә Ногайбәк ага исә:

—Рәхмәт матур фаразың өчен! Безгә нәкъ менә шундый, калкавычны борчымый торган тын диңгез өсте кирәк тә инде,—дип кармакларны көйләргә кереште.

—Адмирал, күрәсеңме, ә-ә-нә-ә-ә теге иң түрдәге утрауны? Якорьне әнә шунда кереп салырбыз. Ул минем бик яраткан утравым. Мин аны Карлыгачлар пансионаты дип йөртәм. Әнә теге, безгә йөзе белән төбәлгән, диңгезгә менә ишеләм, менә ишеләм дип торган текә кыяларда аларның оялары исәпсез-хисапсыз. Белмим ни өчендер, әле бала чагымнан ук бик яратам мин бу оялчан матур кошларны. Үзләре дә кешегә тартылучаннар. Менә күрерсең әле, утрауга аяк басуыбыз белән баш очыбызда очып уйный башларлар. Әмма берәрсен тотармын, учыма алып сөярмен, димә. Тоттырмыйлар. Әмма берәрсен тотып, матур кошкаем, кил учыма утыр, ял ит, эч сереңне шатлык-сөенечеңне, моң-зарыңны сөйлә, дип әйтәсем бик тә килә. Ирек, бәйсезлек сөюче, үз-үзләрен тотышлары белән сокландыра, яраттыра торган кошлар ул карлыгачлар. Ә яшәү рәвешләре һаман кешеләр тирәсендә.

Ногайбәк ага исә осталык белән движок каешын бер генә тартты. Моторы, араннан ишек алдына чыгарып бастырган айгыр кебек, шундук «кешнәп» җибәрде дә, көймәне дер селкетеп эшли башлады. Әйе, мондый чакта кеше дигәнең бөтенләй сәер якларын да күрсәтеп куя. Ногайбәк ага куен кесәсеннән озынча тартма алды. Аны ипләп кенә ачып, ни-нәрсә ала дип көтсәң, бик пөхтә итеп чытырдавык кәгазьгә төргән Гавана сигарасы чыгарды. Аны башта борын төбенә төртеп, уйнатып, бик тәмләп, озаклап иснәп торды. Йөзе соң, йөзе! Күкнең җиденче катына менеп баскан диярсең.

—Мондый чакларны, Таһир, мин үземне карт диңгез бүресе, Урта диңгез пиратларының атаманы төрек башкисәре Мостафа кебек хис итәм,—дип, күз кысып алды, сигараны кабызды. Аны тирән итеп ике-өч тапкыр суырды:

—Һа-ай! Хуш исе генә ни тора! Сизәсез булыр?

—Яшең алты дистәне тутыра, ә малайлыгың һаман чыгып бетә алмый, әтием,—диде Данәгөл.—Тын кысылу чире бит синдә. Сигараның мондый кырыс төтене тын юлларыңа ярамый. Аннары буылып йөткерә башларсың...

—Бөтен хикмәт тә, кызым, малайлыгым чыгып бетмәүдә. Малайлыгың чыгып бетсә,—беттем диген инде. Малайлык бетү белән дөньяның кызыгы да бетә. Малайлык хисе аша адәм баласында әйләнә-тирәлекне өйрәнү, танышу, үзләштерү, бар нәрсә белән кызыксыну процессы бара. Бу дәрт бетсә, чыннан да, организмда, күңелдә сүнү, чигенү башланачак. Ә син дөрес әйттең, кызым. Миндә малайлык дәрте житәрлек әле. Болай булгач, яшибез, димәк! Кхм, кхм,—дип Ногайбәк ага учына йөткереп куйды. Канәгатьлек, тормыштан канәгать булу хисе белән яшәп, оныкларым булыр дип өмет итәм әле Ходайдан. Аларны да балыкка алып йөрермен.

Көймә артын ак күбекләр белән тутырган моторның газын арттыруга, агай:

—Алмачуар, әйдә, алга!—диде.

Баркас, кояш чыгып килгәндә тып-тын булып яткан диңгез өстен икегә ярып, алга ыргылды. Данәгөл «Карлыгачлар пансионаты» дип атаган,

беренче күрешкә үк ипле, ышык күренгән утрауга тиз килеп життеләр.

—Көне буена болай тын тормас. Дингезнең холкы көйсез хатын-кызныкыннан болай. Якорьны без утрауның жилдән ышыгырак ягына салыйк. Кармакларны барлагыз. Сала башласагыз да була,—дип ашыктырды агай. Иртән торсаң, ит пешә, соңга калсаң бит пешә. Таһир, улым, ишеткәнең бар идеме бу мәкальне?

—Булмыйча!

—Менә без дә иртәнге чиртү вакытына кыл сәгате суккан моментка килеп життек. Болай барганда, Алла боерса, чүплибез бүген кефальне.

Таһир кармагын салырга да өлгермәде, калкавычы юкка да чыкты. Егет кармагын суырырга ашыкты. Суырса, буп-буш.

—Скумбрия шаяра!—дип ым какты Данәгөл.—Калкавычны умырып алып төшеп китте дип кенә суырырга ашыкма. Кармагыңа киерткән жимеңне читеннән генә эләктереп, башта аның бер уйнаклап алганын көт. Шулай шаяртырга ярата.—Данәгөл шунда: «Һо-оп!» дип кармагын тартты, көймә төбенә, беләк буе булыр, бер балык килеп тә төште.—Әйттем бит скумбрия дип. Кило-мазар ук булмаса да, сигез йөз граммнар булыр.

Данәгөл артыннан Таһир да бик оста чүпли башлады. Дүрт йөз-биш йөз грамлы скумбрияләр белән чиләкләре тиз арада тулды. Кефаль күренмәде. Аның икенче көтүе килгәнне көтәсе булды. Аңа карап кармаклары буш тормады. Кармакны салышка, калкавычны сугымга симерткәндәй симез «дингез үгезләре» аска өстери.

—Болары, Адмирал, әлләни эре булмасалар да, киптерергә әйбәт. Телеңне йотардай тәмле булалар. Кичтән тозлап бауга элсәң, шул ук көнне өлгерәләр дә. Сыйлармын үзеңне,—дип, Данәгөл «дингез үгезләрен» икенче савытка жыеп барды.

—Кипкән балыкка тәкатьсез мин. Телемне йотмасам инде,—дип, Таһир шөбһә белдерде.

—Ә балык шулпасына мөнәсәбәтең ничек?—диде Данәгөл. Таһир күп мәгънәле итеп:

—Диңгезче бул да, ничә ел дингездә йөз дә... Анысы... Без ризыкның бер төреннән дә йөз чөермибез,—диде ул.

Иртәнге уннар тирәсендә дингез төбе буйлап кемдер кыңгырау шалтыратып узды диярсең. Ник бер кармак чиертсен, ник бер калкавыч дерт итеп алсын. Жимнәрне дә алыштырып карадылар. Данәгөл аптыраган кыяфәттә:

—Болар соң әллә безгә: «тоткан балыгыгыз житеп торыр, бераз ял итегез»,—диделәрме? —дип, су өстендә кармагын уйнатты.

Моңарчы «тус-тус» сигарасын суырып, дәшми-сөйләшми генә балык чүпләгән Ногайбәк ага шап иттереп маңгаена сугып алды:

—Абау-абау! Аh, каhәр! Зиhен таркаулыгы чире йоктымы соң миңа? Бөтенләй истән чыгарганмын бит, балалар. Бүген төш алларыннан коры йөк белән йөрүче грек пароходы килергә тиеш иде бит. Капитаны Папандополус әфәнде—күптәнге дустым. Мина hич кичекмәстән портта булырга кирәк. Очтым мин, очтым,—дип, ике кулын ике якка жәеп, канат итеп, агай кабаланып-ашыгып китеп тә барды. Балык шулпасы өлгергәнне дә көтмәде. Яшьләргә берүк борчылмаска, рәхәтләнеп ял итәргә, кояшта кызынырга, су керергә киңәш итте.

—Бер дә борчылмагыз, кичен үзем килеп алырмын,—диде.

Икәү генә калгач, Данәгөл Таһирга утрауны күрсәтергә булды. Кулга-кул тотынышып, алар аны әйләнеп чыктылар. Бу утрау чыннан да карлыгачлар патшалыгы икән бит. Аларның оялары акбур-известьняктан торган текә кыя битенә, кемдер махсус борау белән бораулап чыккандай, бер сызыкка, бер

тасмага тезелгән тигез интервал белән, бернечә рәт этаж-этаж бу ояларны карлыгачлар әйтерсең үзләренең Югары Советларында раслап, генплан буенча һәм баш архитекторның ныклы күзәтүе астында төзегәннәр. Бу кадәр тәртипкә һәм төгәллеккә башкача ирешеп тә булмастыр. Данәгөлдән һәм Таһирдан бер дә шикләнми-нитми генә, әллә үз итеп инде, аларның баш очыннан гына очып киткәлиләр.

—Адмирал, син килгән ерак Татарстаныбызда шушы матур кошларга багышланган матур җырлар да бардыр инде,—диде Данәгөл.—Берәрсен җырлап күрсәтсәң, мин аны отып калыр идем.

—Карлыгачлар турында юк бугай, әй. Бездә җырларда күбрәк сандугачларны телгә алалар. Әле беренче класста укыган чакта ук, җыр дәресендә менә бу җырларны җырладык:

—Сандугачка жим ашатам,
Жим ашатам кулымнан.
Безне беркем аера алмас
Коммунизм юлыннан.

Сандугач баласын юа,
Гөл тамчылары белән.
Яшәсен Совет власте
Юлбашчылары белән.

Сандугачлар сайрашалар
Безнең урман буенда.
Ленин бабай васыятьләре
Һәрчак минем уемда.

—Нигә? Матур, тәрбияви көчкә ия җырлар бит,—дип куйды Данәгөл.— Син яраткан әлеге кошкайларның исеме телгә алынган җырны да беләм икән:

—Яратам мин карлыгачның
Тәрәзәгә кунганын.
Без кызларның яратабыз
Ударница булганын.

—Мондый җырларны кичен клубка чыккач, түгәрәккә басып, кызлар белән биешкәндә җырлый идек.

Таһир ике-өч чуер таш алып, аларны учында сикертеп торды:

—Җырның җыртыгы юк, диләр бездә. Хәтер сандыгында менә мондый җыр да сакланган:

—Сандугачлар югары,
Карлыгачлар юк әле.
Бу дөньяда безнең кебек
Пар килгәннәр юк әле.

Таһир Данәгөлгә, шушы сүз дөресме, дигәндәй сораулы караш белән текәлде.

—Ә мондый җырларны кайчан, кайда җырлый идегез?—диде Данәгөл.— Соңгысы бигрәк тә матур. Мин аны отып калырга телим.

—Ә мин, Данәгөл, матурым, аны сиңа багышлап җырладым...

Таһир аягына ботинкаларын киде, биленә капчык бәйләде.

—Син кая болай?—диде Данәгөл.

—Әнә шул матур кошкайларның берәрсен тотып сина бирергә телим. Учыма утыртып иркәлисем килә, дигәниең бит.

—Мондый матур теләгең өчен рәхмәт. Кирәкми, Адмирал. Борчымыйк. Куркытмыйк аларны!

—Ул чакта, кадерле туташым, мин балык пешерергә керешәм. Безнең крейсер егетләре еш кына:

—Хороша уха из петуха!—дисәләр дә, балык шулпасыннан да баш тартмыйлар. Ә мин үзем төп очколарны жиренә житкереп пешергән балык шулпасына бирәм,—дип әйтте дә, дулкыннар ярга бәргән йомычкаларны кочагына жыеп, Таһир учак кабызды.

Данәгөл исә, киндер тарттырган зур гына рамны өчаякка беркетте, кулына мольберт алып, аны әйләндереп, андагы һәр буяуга таләпчәнлек белән карап алды. Аннары кинәттән генә:

—Адмирал, рәссамнарны жәмгыять өчен кирәкле затлар дип танйсызмы? Безнең һөнәргә гомумән ничек карыйсыз?—дип сорап куйды, ничектер үзеннән үзе туган сорау сыман итеп кенә.

Данәгөл Таһирның дөньяга карашын, гыйлем, гакыл дәрәжәсен үз бизмәненә салып, үлчәп карамак булдымы? Мондый хиреслек һәркемгә табигый. Кайчак шулай урамда очраклы гына очрашканда да яңа танышыңнан әллә нәрсәләр сораштырып бетерәсең. Бик табигый халәт бу. Адәми затта бөтен гомере буена үзенә рухи якыннарны эзләү инстинкты яши. Данәгөл, бу юлы пушкасын туп-туры төбәп:

—Адмирал, син исеме дөнья күләм танылган берәр рәссамны беләсенме?—диде. Үзе үк ярдәмгә килеп:

—Илья Репинны, минем табынган кумирым Иван Айвазовскийны, әлбәттә, белә булырсың. Чөнки алар Рәсәй рәссамнары бит. Ә менә сезнең совет мәктәпләрендә талантларын бөтен дөнья жәмәгатьчелеге таныган, шедеврлары иң атаклы музей залларын бизәгән осталарның тормыш юллары, ижатлары белән таныштыралармы? Әгәр дә алар программага кертелмәгән булса, яшьләргә белем берьяклы гына бирелә булып чыга түгелме?

Данәгөлнең бу сорауларыннан соң Таһир эчке бер канәгатьләнү белән елмаеп куйды. Тормыш дигәнең әнә ничек бит ул, шайтан. Франциягә дуслык визиты белән барачак крейсерда матрослар өчен уздырылган курсларның менә ничәнче тапкыр кирәге чыгып куйды бит, әй. Ул чакта алар өчен лекцияләр укыган чал кашлы, пенснәле картшэофессор Мәскәүдәге Третьяков галереясе, Ленинградтагы Эрмитаж, Парижлагы Лувр музейлары турында бик кызыклы альбомнар ачып, диафильмнар күрсәтеп бәйнә-бәйнә сөйләгән иде.

Таһир, бер тезенә тезләнеп, дөньяда бер ләззәт татып, тотен исни-исни учакка коры йомычкалар өсти. Өчаяк өстендә утырган чуенда, тирә-юньгә хуш ис таратып, балык шулпасы кайный. Ничек сагындырган учак төтене! Малай чагында Ашыт елгасы ярларында да, техникумда укыган елларында да күпме якты, күпме кабызды инде ул мондый черт-черт учакларны, һич көтмәгәндә генә ул тәмам кыюланып китте:

—«Күбрәк, күбрәк, бар сәдәфләрегезне дә төбенә чаклы ычкындырып ачыгыз изүегезне! Ни өчен, шайтан алгыры, сез миңа тулып пешкән грушадай күкрәгегезне күрсәтергә теләмисез? Сезнең миңа күкрәгегезне күрсәтергә карышуыгыз—зур жинаять!»—дип әйтергә яратканмы әле Франциянең бөек рәссамы, хатын-кызларның шәрә тәненә гимн жырлаган Огюст Ренуар?

Профессор Писаревский безнең алда һәр лекциясен шулай, Огюст

Ренуар сүзләре белән башлап җибәрер иде. Башта безнең егетләр рәхәтләнеп бер көлешеп алалар. Аннары инде карт профессорның бер сүзен җилгә очырмый, лекциясен колакларын торгызып тыңлыйлар. Ә минем үземә Анри Тулуз-Лотрек иҗаты якын. Бәлкем, бөтен тормыш юлы, искитмәле иҗаты трагизмнан торгангадыр, профессор Писаревский да:

—Анри Тулуз-Лотрек писал без устали и пил без устали,—дип кабатларга ярата иде. Ә бит нинди талант иясе булган. Париж бульварлары кызларының күз иярмәслек тизлек белән зыр әйләнеп, биюләрен дөньядагы барлык төс-буяуларны да рәхәтләнеп кулланып, шунда ук картонга, киндергә төшергән ул.

Данәгөл мондый җавапны көтмәгән иде. Таһирның рәсем сәнгате һәм аның осталары турында шактый хәбәрдар булуына әллә гаҗәпләнеп, әллә сөенеп:

—О-о-о!—дип сузды. Кулына җыйган чыбык кисәкләрен черт-черт сындырып, учакка салды.

—Иван Крамскойның «Билгесез»е алдында туктап, ана сокланып тормаган ир-егет юктыр ул,—дип дәвам итте Таһир.—Әгәр мин үзем рәссам булсаммы?!

—Йә, йә, әгәр син рәссам булсаң?—диде Данәгөл ана төбәлеп.

—Беләсеңме, мадемуазель, туташкаем Данәгөл? Әгәр менә мин сурәтче булсаммы?! Рәсем сәнгате шедеврлары арасында бик күпләрне «ah!» иттергән «Неизвестная» исеме белән йөргән ул полотноның тагын бер вариантын мин сездән күчереп язган булырыем.

—О-о, Адмирал! Бу юлы сез планканы бик югары, үрелсәң, буй җитмәслек биеклеккә куйдыгыз түгелме?—диде Данәгөл матур елмаеп.—Комплимент әйтә беләсез икән. Сез мине күккә чөйдегез бит. Хатын—кыз затының кайсысы гына үзен күккә чөйгәнне яратмый икән? Монысы өчен Эйфель манарасы зурлыгындагы рәхмәт сиңа. Әйе, комплиментыңны килештердем. Шул ук вакытта синнән, Адмирал, гафу үтенми дә булдыра алмыйм.

—Ни өчен?—дип бүлдерде аны Таһир.

—Соңыннан гына сизеп алдым, дорфарак биргән сорауларым өчен. Кораблары ярда ташлап киткән, йә кабактан вакытында чыга алмыйча үзләре аерылып калган матросларны кечкенәдән күп күреп үстем. Корабларының тәмам уңган, җил ашаган җилкәннәре төсле киндердән теккән киемле япон матросларын да, йөзләре җиз лэгән төсле ялтыраган сап-сары кытайларны да, антрацит күмере төсле кап-кара тәнле африканнарны да, күп эчүдән борыннары кызыл чөгендердәй кып-кызыл Канада морякларын да. Барысының башында бер борчу-хәсрәт: коры җиргә аяк басу белән берәр кыска итәкне элэктерү дә, өч-дүрт тәүлеккә берәр кабакка кереп чуму... Шуңа күрә аларның гыйлем-акыл дәрәҗәләре турында мин бик тискәре фикердә. Сиңа да баягы берничә соравымны шул җирлектәрәк биргәнием. Адмирал, мин тез чүгеп үкенәм.

—Таптыгыз үкенерлек нәрсә!—дип куйды Таһир. Аның Данәгөлне кочып аласы килде.—Без бит Бөек Совет иле вәкилләре. Бу турыда кайда гына булсак та онытырга хакыбыз юк. Кирәк чакта үзебезнең кем икәнебезне таныта да белергә тиешбез. Безнең холкыбызда бөтенләй башка әхлак...

Данәгөл кинәттән генә сүзне икенче җирлеккә күчерде.

—Адмирал, туган авылыгызда хезмәт срогыңны тутырып кайтуыңны өзелеп көтеп торучы кара кашың, нечкә билең, әлбәттә, бардыр инде? Ничек булмасын? Син бит әнә нинди күркәм егет. Булмаса... кызганыч...

—Хәзерге акылым булса, калдырмаган булыр идемме? Авылда чакта да, техникумда укыганда да, дус егетем Исмәгыйль әйтмешли, бер кашык су белән йотып җибәрешле Чибәркәйләрнең чуты юк иде. Күк йөзе йолдызлы

кичләрне араларыннан иң чибәрен озата кайткан чаклар да булды. Алай гынамы? Үзебезнең техникумда Миләүшә исемле бер мишәр кызы бар иде. Агрономнар бүлегендә укыды. Менә шул чибәрнен-чибәре чем-кара каш, шомырт күз Миләүшәне бүлешеп, канга батып сугышып та йөргәниек әле.

—Чынлапмы? Адмирал, син дә сугышып йөрдеңме?

—Мин кемнән ким? Үлчәүгә салсаң, минем йодрык кайбер егетләрнекеннән авыррак та булгандыр әле,—Таһир учын йодрыклап, йөзенә якынайтты.

—Кем җинде соң? Миләүшә кемгә булды?

—Мишәр кызы төлкедән дә хәйләкәррәк булып чыкты ул. Группа егетләрен чимә-чи канга батырып сугыштырып йөрде дә, техникумны да тәмамлап тормады. Үз авыллары егете, авиация училищесын тәмамлаган лейтенантка ябышып чыкты. Ерак Көнчыгышка китеп тә барды. Ә мин, ангырабаш: «Таһир, синең хезмәтеңне тутырып, авылыбызга дингезчеләрнең матур формасын киеп кайтканыңны бер егеткә дә карамый көтәм»,—дип крейсерыбызга сагынычлы хатлар язып торырлык ышанычлы бер яр булдырырга ничектер өлгерә алмадым. Ә хәзер терсәкне тешләрдәй булып үкенәм. Терсәк якын да, теш җитми. Юкса безнең авылда кызларның айһай чибәрләре бар. Кыз урлауны совет власте декретлары белән үк тыйды. Ә егетләр күзләре төшкән Чибәркәйне барыбер урлый бирәләр.

—Ә ник?

—Әгәр син урламасаң, өлгермәсәң, авызыңны ачып каласың, икенче егет урлый.

—Палеолит, неолит заманыннан калган кыргыйлык түгелме соң бу?

—Анысын кем тикшереп торган. Урлап алып киткән кызларның берсенең дә әнисе-әтисе каршына кире борылып кайтканы булмады әле. Яшиләр, ал тутырып балалар үстерәләр. Урлап өзгән җимеш тәмлерәк була, күрәсең.

—Әтием өзелеп-өзелеп сагынып искә алган Ватаныбыз халкының яшәү, көнкүреш шартларын, гореф-гадәтләрен мин бит бөтенләй белмим. Синең авызыңнан чыккан һәр сүз минем өчен яңалык, Таһир. Ә кызларны ничек, нинди транспорт белән урлыйлар?

—Һәрхәлдә, самолет белән түгел. Элегрәк атка салып, чана, арба белән урлап киткәннәр. Хәзер мотоцикл белән уңайрак. Үзеңнең мотоциклың булмаса, ул кичкә иптәш егетеңнән сорап торасың. Күзең төшкән кызыңны күрше авылга урлап качарга булсаң. Ә үз авылыңа гына, югары очка, йә аргы якка булса, велосипед белән генә. Алдыңа утыртасың да, сиптерәсең генә.

—Ә мәхәббәт? Адәми зат кичерә торган иң бөек хис?

Таһир иңбашларын җыерды. Ни әйтергә дә аптырап, беркавым сүзсез торды. Аннары гына, бу кадәресен дә әйтимме, юкмы икән дип торганнан соң:

—Мәхәббәт булмаса, синең пытыр-патыр, шытыр-шатыр мотоциклың артына үзләре менеп атланмый бит инде алар,—дип куйды.—Аларны бит бәрәү дә кулын-аягын бәйләп, авызына чүпрәк мукләп урламый. Бу тантаналы акт ике якның да ризалыгы белән башкарыла. Безнең татар авыллары, бүген дә халкыбыз гасырлар буе туплаган, үзен аклаган традицияләр белән яши. Аларны сакларга тырыша. Күпчелек әниләр бездә җиткән кызларына «тиз бозыла торган товар» дип карыйлар. Шушындый мөмкинлекләр була торып та, берәрсенең башын әйләндереп китәргә башым җитмәде шул. «Татар акылы төштән соң» диләр. «Татарга акыл тау төшкәч керә», дигән варианты да бар.

—Ничек «тау төшкәч» керә?

—Арбаны аударгач!—диде Таһир.

—Бәлкем мин тулы мәгънәсен аңлап та җиткермим булыр. Бу мәкальнең ике варианты да безнең татар халкын мактамый түгелме соң?

—Мин чыгарган мәкаль түгел,—диде Таһир.—Халык үзе уйлап тапкан. Әмма үз-үзенә бераз көлеп, тәнкыйть белән карый алган халык өметле, үз халык түгел микән?

—Бәлкем, бәлкем,—дип килеште Данәгөл.

—Безнең карабтагы кайбер украин, аеруча молдован егетләре берьюлы дүрт-биш кыздан мәхәббәт хатлары алалар. Ярдан крейсерга хат ташучы матрос Саша Кузнецов, палубага аяк басу белән, хатларны «Коханый Опанас!», «Коханый Дмитро!» дип кычкырып таратып йөри. Ягъни «Сөекле Опанас!», «Сөекле Дмитро!» Әлеге үткен егетләр, хезмәт срогыбыз тулгач, бу чибәркәйләрнең кайсысы кочагына кайтасы булыр, дип бүгеннән үк баш ваталар.

—Әллә шундыйлар да бармы?—дип гаҗәпкә калып сорады Данәгөл.—Менә ышан икән егетләргә!

Таһирның күңелен кинәттән генә сагыну хисе басты. Ул янәдән авыллары турында сөйләп китте.

—О-о, мадемуазель Данәгөл! Безнең авылның кызларын күрсәң, аларга син үзең дә гашыйк булыр идең. Барысының калын толымнары тезгә җитешләләр. Билләрен әйткән дә юк, балдак киертешләләр! Авыл башындагы Биш чишмәдән кыр казлары кебек тезелешеп кайталар кичләрен судан. Башларында, кич утырып матур үрнәкләр белән үзләре чиккән ап-ак батист яулыклар. Алларына япкан ап-ак батист алъяпкычларының итәкләренә дә матур чәчәкләр чиккәннәр. Чиләк-көянтәләре дә өр-янадан, барысы да бизәүле, буяулы. Мотоциклга утыртып урлаганчы, егетләр аларны башта су юлында күзлиләр әле. Холыкларын, күз карашларын, аяк атлауларын өйрәнәләр. Кызлар сиңа карамаган да төсле, башларын аска игәннәр. Шулай сак атламасалар, чиләкләре чайкалуы бар. Синең яныңнан узганда алар чак кына елмаялар.

—Әкрен атла, әкрен атла,
Безнең турыдан үткәнче.
Карап калыйм әле, дустым,
Ике күзем туйганчы,

—дип җырлыйлар бездә. Мөлдерәмә су белән тулы чиләк көянтәсен асып судан кайтучы кызларга багышлап инде. Их, шуларның хет берсенә: «Сеңелкәем, баргач та тулы адресымны салырмын, карточкаңны да салсаң, почта расхутларын да үзем түләрмен. Миңа хат кына язып тор»,—дип сораган булсам. «Татар акылы төштән соң»—шушы була инде ул.

***

Тәмле балык шулпасының хуш исе бөтен яр буен басты. Таһир, саклык белән генә, казанны өчаяктан алды. Шулпасын кашык очына гына элеп алып, өф-өф итеп, озаклап суытып, аны Данәгөлгә татып карарга тәгъдим итте.

—А-а, телеңне йотарлык!—диде Данәгөл.—Әгәр шушы минуттан сүзсез калсам, белеп тор, телемне йоткан булырмын. Беренче ярдәмгә ашык.

Таһир казанны янәдән өчаяк өстенә куйды. Ногайбәк аганың килеп җиткәнен көтәргә булдылар. Бергә ашасалар, шулпа тагын да тәмлерәк тоелыр, диделәр.

Данәгөл бишташ уйнарга теләгән кыз баладай, бик тә бирелеп, дулкыннар

әледән-әле ярга бәреп торган вак чуерташлар арасыннан иң матурларын сайлап учына жыя башлады.

—Шушы ташлар арасыннан уртасы тишегән табасы иде. Андый ташны бәхет китерә диләр. Аны соңыннан күкрәккә тагып йөртәләр.

—Бәхетле булу өчен шушы бер таш кисәге генә житсә, хәзер табабыз аны. Дингез ярын бульдозер урынына сөреп чыгып булса да,—диде Таһир, Данәгөлне жинелчә генә кочагына алып.—Андый кодрәте булгач, хәзер мин бөтен дингез ярын бульдозер урынына сөреп тә чыгам. Нужәли тапмабыз икән!? Тапсак, бәхет ташы безгә зыян итмәс иде...

Әлеге могжизаи көчкә ия ташны алар башта кулга-кул тотынышып, житәкләшеп эзләделәр.

—Бәхет аяк астында ятмый, диләр, дөрес, ахры...—диде Таһир. Алар кулларын ычкындырышып икесе ике якка таба атладылар. Бераздан Данәгөлнең шатлыклы тавышы ишетелде.

—Менә бит! Менә бит, таптым! Нәкь без эзләгәне!

Әлеге уртасы тишек чуерташны тотып, ул Таһир янына килде:

—Адмирал, без бәхетле, димәк!

—Ә ни өчен без бәхетсез булырга тиеш?!

—Мин аны затлы чылбырга киертеп түшемә тагып йөрермен. Бәлки ул үзенә бер ырым гынадыр. Ә менә күпме чуерташ арасыннан эзләп тапкач, барыбер сөенеч. Тапмаган булсам, күңелдә шөбһәле уйлар туган булыр иде. Кеше дигәнең шундый бит, юктан гына аның күңеле күтәрелә, бер дә юктан гына тәмам сыгылып төшә. Ә бу таш, Адмирал, өмет ташы. Аңарда кеше күңелендә якты өметләр уяту кодрәте бар. Тормышның хәтта иң кыен чакларында да, тукта, Данәгөл туташ, бирешмә, менә синең түшеңдә бәхет китерә торган амулет бар бит әле, дип үз-үзеңне юатырга терәк булачак. Шулай бит, Адмирал?

Таһир аны ике кулыннан тотып, күзләренә карады. Килешүен раслап баш какты. Ә Данәгөл кинәттән генә:

—Адмирал, рәссамнар турындагы әңгәмәбез икебез өчен дә бик файдалы булды бит әле. Крамскойның «Неизвестная»сына кагылышлы фикерең йөрәгемә аеруча хуш килде. Шаяртмаган булсаң,—диде ул елмаеп.—Ә менә иртәгесе көнгә билгеләнгән планга кичекмәстән төзәтмәләр кертергә туры киләчәк.

—Аңламадым,—диде Таһир.

—Сине бездә тулы, бай эчтәлекле программа белән кунак итү буенча билгеләнгән чараларга яна өстәмәләр кертү кирәклекне әйтәм.—Сине, Адмирал, рәсем сәнгатен бөтен нечкәлекләре белән аңлаган кунагыбызны, Франциянең иң зур мактанычы булган Луврга алып бармасам... мин гөнаһлы булачакмын. Кем алдындадыр гөнаһлы булып яшәү,адәм баласы өчен мөгаен иң кыеныдыр. Андый бәхетсезне мин нәкъ күкрәк уртасына зур кара тап төшкән ак күлмәк кигән кешегә ошатам.

—Лувр?..—дип куйды Таһир, хәтта бераз әсәрләнеп.—Лувр Парижда бит ул...

—Әйе, аны урыныннан кузгаткан кеше юк. Булса соң? Тимер канатлы кошлар очып житмәстәй аралар юк бит хәзер. Марсель-Париж арасы реактив лайнерлар өчен ике сәгатьлек юл.

—Луврда Леонардо да Винчи! Аның «Моно Лиза»сы! Аны үз күзең белән күрү бик сирәкләргә генә татый булыр. Безнең крейсерга, шампан эчемлекләре чыгара торган компаниянең вәкилләре килгәннәрие. Визит ахырынарак махсус килеп, бөтен экипажга Луврны күрсәтеп кайтырга ышандырып киткәннәрие. Әйе, алар да дөньяда тиңе булмаган Лувр музее Франциянең генә горурлыгы, мактанычы түгел, ә бөтен кешелек дөньясы,

галәмнең сәнгать байлыгы галереясе, дип сөйләгәннәрие.

—Алай булгач, Адмирал, мин синең алда икеләтә-өчләтә бурычлы. Иртәгә Парижга очабыз! Ә хәзер шушы утрауның иң истә калырлык жиренә барып бас әле. Миңа да синең портретыңа керешергә вакыттыр бит инде. Югыйсә, мин бу буяуларымны, пумалаларымны, рамга тарттырган киндерләрне нәрсәгә генә алдым? Көн төшне узып бара, ә мин әлегә кулыма пумала да алмадым. Моның өчен мине җавапка тартырга вакыт. Борынгы Грециядә, әле безнең эрага кадәр, Апеллес атлы сурәтче яшәгән. Ул: «Нулла диез синэ линэа!»—дип әйтә торган булган. Ягъни «Бер көн дә бушка узмасын, һич югында бер сызык сызып куй!»—дигән ул. Аның даһиларча бу кисәтүе минем дә яшәү рәвешем. Чын рәссамның бер көн дә кулына пумаласын алмый калырга хакы юк. Сәнгать, гомумән иҗат вәкилләренең яшәү рәвеше агымга каршы ишкәк ишүченеке белән бер. Ишүдән туктау белән агым сине артка этәрә. Бу кадәресе дә минем сүзем генә түгел. Аны безгә һәр лекциясендә композиция укытучыбыз кабатлый иде. Мин бит сурәт төшерү сәнгатенең Лион Югары мәктәбен тәмамлаган профессиональ рәссам. Барып чыкса, Адмирал, Луврга куярлык итеп эшләргә кирәк булыр портретыңны. Миңа да бер тетрәнеп алырга вакыт. Ә астына: «Совет хәрби крейсеры «Сергей Киров» матросы Таһир Туктамышев»,—дип язып куярбызмы?

—Бик купшы килеп чыкмасмы?

—Нигә купшы килеп чыксын ди? Гадәттә ничек бар, шулай язалар инде. Мона Лиза икән «Мона Лиза», дип, Император Бонопарт Наполеон икән «Император Бонопарт Наполеон», дип. Портрет астына язу анысы соңгы этап.

—Данәгөл, кадерлем, натурщик булырга мин бик теләп риза,—диде Таһир.—Ә нигә туп-турыдан Луврга ук куярга? Безнең дуслыгыбызның мәңгелек истәлеге итеп мин ул портретны карабыма алып кайтырмын, үзебезнең кубрикка эләрмен.

—Ул чакта без аны ике нөсхәдә ясарбыз. Шулай бит? Ә нигә аптырап торырга? Кирәксә, ун нөсхә дә ясыйбыз аны!

—Бер рәссам да үзенең шедеврларын модельләрсез, натурщицаларсыз тудырмаган. Минем укыганым бар. Күп маэстролар үзләренең натурщицаларына башларын җуеп гашыйк булганнар. Ә мин бик аңлыйм аларны. Сиңа илһам биреп, дөнья музейларын бизәрлек әсәрләр тудырырга дәртләндергән, һәрчак янында булган изге затларга ничек инде гашыйк булмыйсың?—диде Таһир.

Данәгөл аны ярты юлда бүлдереп һәм авыз чите белән генә елмаеп:

—Андый «мәшәкать» безнең башка да төшмәгәе дип борчылмыйсыңдыр бит?—диде, Таһирның җавабын көтмәде, йөзенә җитдилек өстәп сүзен дәвам итте:—Адмирал, ихлас күңелдән әйтәм, син чыннан да мин уйлаганга караганда күпкә киң карашлы егет булып чыктың бит, әй. Синең белән аралашу миңа үзе бер ләззәт. Бу үзе минем өчен зур бәхет. Әйтәм бит, моңарчы мин һәр матросны исерекбаш, дебошир, юлында очраган теләсә кайсы итәк артыннан телен асылындырып чабучы дип кенә белә идем.

Бу юлы Таһир да күкрәгенә җиңелчә генә сугып куюны кирәк дип тапты:

—Хөрмәтле мадемуазель, совет матросларына моннан соң эшегез төшкәндә планканы иң биек ноктасына куйсагыз да ялгышмассыз.

Икесе дә рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр. Таһир пакеттан алып, диңгезче формасын киде. Бескозыркасын башына кимәкче иде. Аны тегеләй кыңгыр, болай кыңгыр салып карады. Аннары аны сул култык астына кыстырып, дулкыннарның кыяның иң текә җиренә килеп бәрелеп як-якка су чәчрәгән жиренәрәк килеп басты. Горур кыяфәт алды.

—Хөрмәтле маэстро! Мин үземнен шушы кырыс һәм горур кыяфәттәге сүрәтем белән иң атаклы музейларның да залларын бизәргә әзер!—диде.

—Коеп куйган Аполлон!—диде Данәгөл.—Монда рәссамга эш тә калмаган. Фотога төшереп ал да туп-туры музейга гына йөгер.

Көн бүген бик матур булды. Хәзер инде төш авышып бара. Данәгөл үзенә килешле пляж костюмыннан. Зур бөҗралы кара күзлекләрен маңгаена күтәреп куйган. Кыяфәтендә эшлеклелек, тәвәккәллек. Шушы килеш-килбәте дингез уртасында утырган әлеге бәләкәй генә утрауны үзенә бер тулыландыру белән бизи иде. Моны хәтта дингез өстеннән балык чүпләгән акчарлаклар, бер бетмәс үз эшләре белән мәшгуль карлыгачлар да раслыйлар төсле. Бу чибәр апаларының шулай бирегә килеп чыккалавына гүя алар да бик шатлар. Буяуларын таратып салган тартмасы өстенә иелгән Данәгөлнең өстеннән генә очалар, канат очлары белән кагылып-кагылып китәрдәй булып уйныйлар. Карамаска ни тырышса да, Таһир үзе дә еш кына аңа текәлә. Булганнан артыгын өмет итәргә аның хакы юк. Аларның ике арасындагы мөгамәләләре шушы көн ярымнар вакыт эчендә дустанә, якын булырга өлгерсә дә, чик дигән нәрсә бар. Хәрби дингез карабы матросына, присяга кабул иткән егеткә бу турыда кисәтеп торасы юк. «Стоп кран!» дигән төшенчә дә бар бит әле бу буталчык дөньяда. Шул чикне бозучы—диверсант, җинаятьче! Их, булса икән менә шушында җиде кат җир астына, мөгаренен үзенә таба сузылган юл—Данәгөлне ул ике дә уйлап тормыйча урлап качар иде. Аларның Салкын Аланнарындагы төсле мотоциклга атландырып түгел, ә кайнар кочагына кадерләп төреп. Әмма күңеленә салган тышавы әлегә аны нык тота. Чөнки бу тарафлардан күп булса егерме-утыз чакрымнарда рейдта аның крейсеры тора. Дүрт тәүлектән соң аның анда кайтып басасы бар. Әлеге тышау аңа: «Таһир, онытма һәм онытма! Сиңа бирелгән дүрт тәүлек иртәнге томан кебек очачак. Ә аннары нәрсә?!» дип тукып кына тора. Алары шулай-й-й. Әмма Данәгөл белән аралашкан, бер һаваны сулаган саен, хатын-кыз затында моңарчы ул күрмәгән, игътибар да итмәгән, егет күңелен ымсендерә торган төсмерләр күрә. Күрә шул, күзен йомса да күрә. Ишетә, җаны белән тоя. «Данәгөлкәй әллә дөньяның бер чибәреме? Җаныма якын мондый гүзәлкәйне моңарчы мин бер дә күрмәдем, очратмадым бит!» дигән уйлар аның башына инде кат-кат килде. Аның күңеленә әллә мәхәббәт кошы кундымы? Вакытсызрак йөрмиме? Ләкин аны куып җибәрешле дә түгел хәзер. Таһир күреп тора, ул утырган мәхәббәт арбасы зур тизлек белән алга таба тәгәри. Аны хәзер туктатып, ничек тә тотып калып та булмас төсле. Ике яшь йөрәкнең транзисторлары, аларның әле капитан Соболь каютасында очрашкан минутларыннан бирле үк шулай бер ешлыкта эшли. Язмышның теләгеме бу, әллә усал бер шаярырга ниятләвеме?

—Берьюлы ике эскиз сызгалап алырга исәбем,—дип, Данәгөл каршына ике өчаяк куйды. Кәефе күтәренке аның. Борын эченнән нindидер көй көйли. Французчадыр дип уйлаган иде. Татарча бит! Таһир үз колагына үзе ышанмый торды. «Сак-Сок»ны көйли бит Данәгөл!

—Адмирал, «Сак-Сок» көен ишеткәнең бар идеме?—дип сорады кыз.

—Ишетмичә! Йон эрләгәндә, безгә йон оеклар бәйләгәндә аны әбием һәр кичне көйли торганые.

—Минем дә әнием шушы көйне көйләргә дә, җырларга да ярата.

Рамнарга тарттырган ак киндерләрнең әле берсенә, әле икенчесенә Данәгөл байтак ара нindидер сызыклар сызды. Сыза-сыза да, аннары кулындагы йомшак фланеле белән аларны боза, юкка чыгара. Шунда ул кулындагы кара күмер карандашны бар көченә кизәнеп диңгезгә ыргытты.

—Шедевр тудырырга керешкәнием бит, Адмирал,—диде ул елмаеп.—Ә

илһам әллә кайда йөри. Парахутка соңарганмы, әллә безнең поездга өлгерә алмаганмы? Сызам, сызам, ә мин дигәнчә чыкмый. Ярар, грек рәссамы Апеллес кушканны булса да барыбер үтәдем—бер сызык булса да сыздым. Булмый бүген берни чыгарып. Күзең каты, Адмирал. Ә булмагач, нигә көчәнергә? Адмирал, сикер минем арттан.

Шулай диде дә, йөгереп килеп утрауның ин текә ярыннан дингезгә чумды. Дингез Таһир өчен дә ят мохит түгел. Ул да Данәгөл артыннан сикерде. Данәгөл дингез уртасында уйнаган дельфиннардан бер дә ким түгел, каерып-каерып колач салып эчкә таба йөзде. Таһир: «Житеп торыр, кире борылыйк!» дигәнче.

Ярга тәмам арып чыгып комга сузылдылар. Таһир Данәгөлнең нәни йодрыгын үзенең амбар йозагы хәтле учларына алды. Данәгөл:

—Бу таш соң минем баш астына махсус шуышканмы?—дип, баш астыннан куш йодрык хәтле чуерташ алды. Иплерәк, йомшаграк урын эзләгәндәй, башта кулы белән капшап, башын Таһирнын күкрәгенә салды.

—О-о, Адмирал, синең йөрәгең ничек көчле тибә! Мондый йөрәк белән син тагын йөз ел яшисең әле. Нинди зур һәм көчле ул!

—Нигә алай дисең, Данәгөл? Нәрсәдән чыгып?

—Чөнки менә бит синең йодрыкларың нинди зурлар. Минем укыганым бар, һәркемнең йөрәге аның йодрыгы кадәр була икән. Ә менә минем йодрык—күгәрчен күкәе хәтле генә. Аннан нинди кыюлыклар, нинди батырлыклар көтәсең? Зур сынаулар, көтмәгән кыенлыклар алдында калса, аларга түзә алыр микән? Хәер, миннән нинди батырлыклар көтәргә мөмкин? Гәүдәңне йөртсә, бик житкән инде.—Данәгөл үз сүзләреннән үзе үк кычкырып көлеп куйды.—Менә, Адмирал, колагынны куеп тыңлап кара, тибүе дә синекедәй, сандалга чүкеч белән суккандай түгел, усак яфрагына янгыр тамчысы төшкәндәй лепер-лепер генә.

—Нигә алай дисең? Матурым! Синең йөрәгең дә менә дигән—«ЧТЗ» тракторы моторыннан ким түгел.

—Ә «ЧТЗ» нәрсә ул?

—«ЧТЗ»мы?! Бездә аны белмәгән, ихтирам итмәгән кеше юктыр. Бик әйбәт, бик көчле, жир сөрергә бик иплe трактор ул. Әле техникумга кергәнче үк шушы трактор белән мин үзебезнең «Коммунизмга» колхозының кырларын күп тапкырлар аркылыга-буйга сөрдем. Икмәк чәчтем. Лобогрейка тагып борчак чаптым. Хезмәт срогымны исән-сау тутырып кайтсам, янәдән берәр «ЧТЗ»га утырырмын әле. Кем белә? Бу тракторны Чиләбе трактор заводы эшләп чыгара. Бездә Чиләбе дигән шәһәр бар. Кыскартып кына «ЧТЗ» дип йөртәләр. Синең йөрәгең дә, матурым, нәкъ менә шушы көчле тракторның моторы төсле тибә.

Таһир Данәгөлнең күзенә төбәлде. Бу минутта кочагындагы зат аңа шул хәтле үз һәм кадерле тоелды. Аның өстенә иелеп, иренен Данәгөл иренәнә тидерде. Бераз каушап китте. Янагына чалтыратуны көтепме, башын читкәрәк күчерде. Шулчак Данәгөл үзе кочып алды.

—Таһир, Адмирал, син миңа язмыш үзе биргән бүләк,—дип пышылдады ул.—Сөям мин сине. Тик...

—Миңа да сине язмыш бүләк итте, карлыгачым... «Тик...» димә инде. Минем күңелемне болай да бик буталчык, хәтта шөбһәле уйлар ботарлый. Кинәттән генә «жу-у», «жу-у» итеп куйган минутлар кичерәм.

Аннан соң әле алар тагын озаклап су керделәр. Кат-кат жылытып балык шулпасы ашадылар. Кулга-кул тотынышып утрауны янәдән кат-кат урадылар. Икесенең дә йөрәгендә бер-берсенә әйтергә кыймаган шөбһә—тиздән, бик тиздән аерылу сәгате сугачак. Аннан котылыр чара бармы? Алар исә берсеннән башка икенчесе бер сәгать, бер минут та аерым яши

алмастай гашыйкларга әверелделәр бугай. Таһир белән Зөһрә, Фәрхад белән Ширин, Ромео белән Джульетта—алар әсәр каһарманнары. Ә Таһир белән Данәгөл—тере затлар. Алар алдында—усал тешле чынбарлык.

Озын җәйге көннең ничек узганын сизмәделәр дә. Өстенә көтмәгәндә ишелгән бу бәхеттән Таһир тәмам исерде. Дингез ана хәзер тубыктан. Крейсерлары шунда рейдта чайкала бирсен. Бәлкем, ана Данәгөлнең әтисе Ногайбәк агадан кызының кулын сораргадыр? Көт, тоттырырлар, бар... Булмаганны. Тиле баш түгел бит ул. Аяк астында басып торыр җире булмаган бер килмешәк матроска бердәнбер кызын бирер ди. Данәгөлнең кулын сорарга монда Марсельнең үзендә бер дигән егетләр беткән ди. Яраттым Данәгөлне, аннан башка яши алмыйм, дисә? Аның бит җилкәсендә әнә нинди «бөкресе» бар—аны рейдта чайкалган карабы, крейсеры көтә. Көтсә инде! Көтәр, көтәр дә, китәр. Ногайбәк агай әгәр кызымны бирәм дисә, Данәгөл дә ризалашса, калырга да булырые... Башсызлык бит бу! Башсызлык! Башыңны җуеп яратканда, бәлкем, башсызлыкны да кабул итәргә, хәтта кичерергә дә кирәктер. Алдагысын Алла хәл итсен. Таһир күңелендә әлегә шундыйрак уйлар бөтерелде.

Шактый сонарып булса да, Ногайбәк ага аларны алырга килде. Килмәсә дә аптырап калмаслар иде. Икәүләп брезент палатка куйдылар. Дингез ярында учак ягып төн куну үзе бер дөнья. Күпләргә гомер буе тәтеми. Таһир палатка төбенә төне буе ягып чыгарлык күп итеп коры йомычкалар җыеп куйды.

—Мин балык шулпасын салкын килеш күтәреп эчәргә яратам,—дип, Ногайбәк ага мактый-мактый шулпа эчте.—Кызым, мин иртәгә Марсельдә булмам. Эш белән Лионга барып киләсем бар. Ә син кунагыбызга фермабызны күрсәтерсең.

—Без иртәгә Парижга барып килергә булдык,—диде Данәгөл. Ногайбәк ага казаннан балык калҗасы чүпләгән кашыгын читкә куйды:

—Бик хуп, кызым, бик хуп, андый кинәшне бирергә сезгә үзем дә җыенып тора идем. Һәр мөэмин-мөселман гомерендә бер булса да хаҗга барырга тиеш, ди китап. Ә югары цивилизациягә ия кеше бер генә тапкыр булса да Парижны күрергә тиеш. Аның каштаннарга күмелгән урамнарын.

—Ман-Мартор мәйданын, Эйфель манарасын, Сорбонна университетын, Виктор Гюгоның Квазимодасы яшәгән замокны,—дип куәтләде аны кызы.—Таһирыбыз рәсем сәнгате өлкәсендә шактый тирәннән сукалый. Без иртәгә Луврны карарга барабыз!

—Бик хуп, кызым, бик хуп!—дип кабатлады Ногайбәк ага.

Балыктан алар бер тамырдан үскән гөлләр, бер ояда борын төрткән кош балалары төсле бер-берләренә эчке якынлык тоеп, арып, әмма күтәренке күңел белән кайттылар. Рентген нурлары адәм баласының күңел төбендә ниләр ятканын да әйтеп бирә алса икән. Әгәр рентген нурлары шундый кодрәткә дә ия булса, аларның икесенең дә күңел төпләрендә алгы тәпиләре, белән башын каплап, йоклаганга, берни белмәгәнгә салышып, йоп-йомры шөбһә хисе ятканын ап-ачык күрсәтерие. Әмма бу турыда алар икесе дә бер-берсенә ләм-мим. Кыңгырауны поезд кузгалыр алдыннан гына да, чаңны бар көченә янгын чыккач та кага башларга була бит. Ә вакытның һәр минуты, һәр секунды аларның аерылышыр, кем белә, бәлки мәңгегә-мәңгегә бер-берләрен җуяр сәгатен якынайта. Таһирның куш йодрык хәтле, ә Данәгөлнең күгәрчен күкәе хәтле генә нәни йөрәкләре түзәрме бу сынауга?

Аларның балыктан кайтышларына Фәйрүзә апай өйләрен янә бер үзенчә бизәп, җыештырып, берсеннән-берсе тәмле ризыклар пешереп куйган. Тәмле хуш исләреннән генә башыңны җуярсың, бер мәлгә мәрткә китәрсең.

Үзе инде, үзе инде! Кая басканын, ничек шуып барганын сизми. Ногайбәк ага да тамагын үзенә нииндидер бер канәгатьләнү белән кыра. Бүлмәсенә кереп китәр алдыннан:

—Алайса, сез иртәгә Парижга барасыз. Бик хуп, бик хуп! Үзем дә ияргән булырыем, каһәр. Иртәгә безнең портка палубасына тере сарыклар төягән Аргентина карабы керәчәк. Испан телен белүче тылмачыбыз ялда. Улын өйләндерә. Димәк, миңа эшләргә туры киләчәк,—диде.

Данәгөл Таһирны верандага озата чыкты. Таһир аны кочып алды, өзелеп яратуын, ошбу дөньяда аннан башка бер минут та яшәргә теләмәвен шушы гамәленә салып аны суырып үпте. Үпте дә, күзләренә карады. Ике күздә дә бер-берләрен табу шатлыгы, алдагы көннәрге өчен кот очып шөбһәләнү, борчылу хисе иде.

Данәгөл чыгып киткәч, Таһир кочагына баш астына салган мендәрне алды. Мондый кечтә егет күзенә нинди йокы керсен? Күңеленең бер почмагында кемдер аңа:

—Үзең дә инде, Таһир! Пешмәгән нәрсә, арыш боламыгы! Куеныңа кергән кошны чыгармаска булган, яныңда калдырасы иде. Юкса тагын ике тәүлек ярымнан карабыма кайтасым бар, нибары илле алты сәгать кенә бит ул!—дип сыкранасың. Иртәгәсе көн өчен ишәк кайгырсын. Син бүгенге көн, бүгенге сәгатең белән яшә әле бер. Син бөек Пушкин әкиятләрен укып үскән егет түгелме соң? Аларның күбесе: «Утро вечера мудренее»—дип тәмамлана бит.

Шундый капма-каршы уй-кичерешләр эчендә ятканда, кулына кефирлы стакан тотып, янә Данәгөл керде. Янына килеп утырды. Таһир кулындагы кефирны ут капкан йөрәгенә су бөркегәндәй бер йотуда эчеп тә куйды. Данәгөлне нәни кулларыннан тотып, яңакларына китерде. Күзләрен йомган хәлдә берәм-берәмләп үбеп алды.

—О—о, Адмирал, иртән генә кырынган идең бит, сакалың нинди каты. Наждак кәгазе белән бер,—диде Данәгөл. Үзе дә Таһирга сарылды. Аның сакаллы битләренә үз яңакларын тидерде.

— Әллә син бик усал кешеме, Адмиралым? Усал кешеләрнең сакалы да каты була дип ишеткәнем бар.

—Сиңа мин, карлыгачым, ни дип кенә әйтим икән? Үз гомеремдә әле минем берәүгә дә усаллык эшләгәнем юк. Минем минерлар группасында Раяну атлы пешеберәк җитмәгән бер молдаван егете бар. Аның аркасында еш кына үземә дә эләгә. Ләкин аның «пешеп», тәмам җитлегеп җиткәнен кат-кат күңегүләр аша, күбесен сүз белән аңлатып, күтәргә тырышам.—Таһир Данәгөлне кочагына алды.—Шушы минуттан, кадерлем, мин сине беркая да җибәрмим! Син минеке!

— Таһир!... Җибәрә күр...Үземнең дә сине бөтереп-бөтереп сөясем, кочагымнан бер чыгармый иркәлисем килә. Ләкин... Аңлый булырсың, безнең бу бәхетебезнең сәгате-минуты санаулы. Җибәрә күр, лачыным, юкса мине гөнаһлы итәсең ... Минем бөтенләйгә калуым бар.

—Гафу ит, җибәрмим сине, кошчыгым. Башларыбызны шушы кечтә бер мендәргә салуыбызны тормыш үзе теләмәсә, безне болай очраштырмаган да булырые... Карышмыйк, иркәм, аның ихтыярына. Безгә биргән бу бәхете өчен аңа мәңге-мәңге рәхмәтле булыйк. Данәгөлем, бу дөньяда бердәнбер генә, бер данә генә гөлем, син минеке!...

***

Аулак веранданың калай түбәсенә лепер-лепер генә вак, җылы яңгыр явып торган әлеге тын кичтә Данәгөл Таһир куенында калды. Иртән алар, яшереп—нитеп тормыйча, әти-әниләренә бүгенге иртәдән аларның ир белән

хатын булулары турында әйттеләр. Ногайбәк аганың:

—Булдыргансың, хайван!!!—дип янагына чалтыратуын көтмәсә дә, Таһир нык унайсызланды. Данәгөл аларның бердәнберләре. Намуслары, ышанычлары, өметләре, таянычлары. Ә рейдта Таһирның карабы чайкала...

Яшьләрнен бергә сулыйсы минутлары күзгә күренеп, стенадагы зур сәгатьнең теле келт иткән саен кыскара. Әмма Ногайбәк ага да, Фәйрүзә апа да бу хәбәрне көткәндәй, хәтта мона сөенгәндәй каршы алдылар. Бу кадәресе Таһирга бераз шиклерәк тә тоелды. Икесе дә диванга утырып, яшьләрнең бу гамәленә хәер-фатиха бирделәр.

—Ир белән хатын булу—егет башына да, кыз башына да килә торган изге гамәл. Безнең хәер-фатиха белән генә түгел, Ходай үз фатихасын бирсен,—диде Ногайбәк ага.—Ул чакта Парижга очуны онытып торырга туры килер.—Ногайбәк ага ашыга-ашыга өс-башын киенде. Машина ачкычын барлады.—Мин хәзер кайтам,—диде.—Аш-суын, әнисе, әзер булсын!

Дөньяда зур бер диңгез портларының берсе, халкы өч миллионнан өстәге Марсель каласында мөселман динен тотучы гарәпләрнең, төрекләрнең, алжир, мароканнарның чуты юк. Мөселман булган җирдә ничек инде мәчет булмасын ди? Марсельдә алар хәтта берничә икән. Ногайбәк ага, әйткәнемчә, тиз әйләнде. Төшке ашка ук, ияк очында бер чеметем генә ак сакалы булган, җилсез көнне дә усак яфрагы төсле дерт-дерт калтырап торган бер картны алып кайткан. Шушы тирәләрдә туганны дога белән каршылап, үлгәнне үз динебезчә дога белән озатып, кирәк чагында никах мөнәсәбәтләрен дә шәригатьчә хәл кылып, муллалык вазифаларын башкаручы төрек карты икән. Кияү егете бүләк иткән чиккән камзулны, кыз атасы бүләге читек-кәвешне дә киеп алгач, әлеге төрек карты никах догаларын бик җиренә җиткереп укыды. Әллә төнлә йокысызлыктан интеккәнме, әллә башкаданмы, мулла бабай догасын өзеп, тирән-тирән итеп иснәп азапланды. Аңа кушылып, тирән итеп иснәп алудан Таһир үзен дә чак тыеп утырды. Әмма мулла бабай үзенә тиеш вазифаны шәригать кушканча, җиренә җиткереп очлап чыкты.

—Менә, балаларым, шушы минуттан сез галәм алдында да, Хак Тәгалә каршында да законлы ир белән хатын. Котлыйм сезне! —дип, Ногайбәк ага икесенең дә кулын кысты, кочагына алып сөйде, битләреннән үпте. Кулыннан кысып тәбрикләгән чагында Таһир бабасы Ногайбәк аганың күзендә тирән серләр, нииндидер сораулар, үкенечләр күрде. Аларны анализлап торыргамы соң? Таһир бәхет күгенең җиденче катында. Аның кочагында аның Данәгөле! Законлы, никахлы хатыны! Ә рейдта чайкалган кораб ник шунда чәнчелеп китми... Шунда кемдер ана:—Тукта, егетем, дөнья бу! Чапма балтаңны утырып тирбәлгән ботагыңа!—дип кисәткәндәй булды төсле.

—Чабам! Корабы гына түгел, чәнчелеп китсен дөньясы! Кочагымда сөйгән ярым. Диңгезләрнең Карасы гына түгел, Уртасы да, хәтта океаннары да миңа тулы мәгънәсендә тубыктан. Кочагымда сөйгән, бердәнбер ярым, йөрәк тибешем—Данәгөлем. Мин бәхетле!—дип үҗәтләнде Таһир. Үҗәтләнергә хаклы иде ул.

***

Шөһрәт Ногайбәк агалар яшәгән шәһәрчектән күп булса нибары унбиш-егерме минут барышлы җирдә агайның егермеләп сыердан гына торышлы фермасы бар икән. Таһир бер күз салу белән шуны төшенде: ферма хуҗаларга табышны нык бирел тора булыр. Чөнки җылы сулы диңгезнең

яшеллек сарган сөзәк ярларын күп санлы санаторийлар, профилакторийлар, балаларны туберкулездан дәвалау пансионатлары бизи. Әле яна гына сауган җылы, шифалы сөтне шул санаторийлардан махсус җыючылар килеп ала икән.

Таһир шуңа исе китеп, гаҗәпкә калды. Талчыбыктай нечкә билле Данәгөл, фермага килү белән, комбинезон, резин итекләр, перчаткалар киеп алды. Сөтле бикәләрне, һәркайсын әле «Оялган Сюзанна», әле «Шаян Глория», әле «Кара кашкай» дип үз исемнәре белән атап, шлангадан җылы су коеп, щетка белән ышкып-ышкып юарга кереште. Тегеләре дә, хуҗабикәләрен танып, бераз иркәләнеп, шлангтан аккан җылымса су астында рәхәтләнеп торалар. Су танауларына тиеп китткәндә прых-прых төчкереп тә куялар әле.

Ошбу җыйнак һәм бик төзек фермага үзе кебек үк телсез, хатыны белән урта яшьләрдән бер карыш кына өстәрәк, чал чәчле бер француз агае күз-колак булып, малларны ашатып-эчертеп, асларын карап тора икән. Данәгөл алар белән бик тату мөгамәләдә. Башта әле, килә килү белән телсезләр үзара аңлаша торган ымнар, шартлы билгеләр белән ишарәләп, дөм чукрак агайны эче катканчы бер көлдереп алды. Ферма караучы агай Таһирга ымлап, нидер сорады ахры.

—Бу матрос кемең, энеңме, абыеңмы?—дип сорагандыр инде,—диде Таһир.

—Шулай дип сораштыра.

—Кемең диден соң?

—Кемем, диим? Никахлы ирем дидем!

Таһир Данәгөлне кочагына ала төште. Чукрак агай, бер минут кына сабыр итәргә ымлап, әвеслек астына йөгерде.

—Бездә унынчы елларын эшлиләр инде. Леон агай гаиләсен эшкә алып, әтием унды. Бик булганнар алар,—диде Данәгөл.—Леон агайның белмәгән эше юк: электрик та, механик та. Ә хатыны Жанна апа—кече ветеринар.

Ул арада Леон агай әвеслек астыннан берәр литр сыеклык керешле ак фарфор крушка тотып чыкты. Аны Таһирга сузды. Леон агайны төшенмиерәк торган Таһирга Данәгөл аңлатты:

— Әле генә сепаратордан чыккан җылы сөт өсте—каймак,—ди. Диңгезләр кичеп йөргәндә мондый тәмле әйберләр бик еш эләкми торгандыр әле, ди. Эчеп җибәрергә куша. Сыйлансын, ди.

Таһир да кыстатып тормады. Җылы каймакның ни икәнен кечкенәдән белеп, татып үскән җан бит. Крушканы каплап та куйды. Каймакны мактап телен шапылдатты, юк мыекларын сыпырып куйды. Агай, дөм чукрак булса да, ачык йөзле, шат күнелле, уен-көлке яратучы зат иде ахры. Таһирның юк мыегын сыпырып куюыннан гөрселдәп көлеп җибәрде. Чукрак кешенең көлүе бераз сәеррәк. Колагы ишетмәгәч, ни дәрәҗәдәрәк кычкырып көләргә икәнен чамалый алмый бит ул. Әмма ихлас күңелдән кылынган гамәлнең кайсы да бизи кеше дигән затны. Кемнедер кыерсыту, кимсетү, җәберләү, талау максатында эшләнгән гамәл түгел бит.

Леон агай Таһирның җилкәсенә дусларча кагып та алды әле. Ике кулы белән дә ишарәләп нидер сөйли башлады.

—Кунып китегез, дип кыстый. Урыныбыз иркен. Кунак булырсыз, ди. Бүген безнең Франция футболчылары күрше Испания егетләре белән очрашалар икән. Шул матчны карарбыз, ди,—дип аңлатты Данәгөл Леон агайның ялкынлы ишарәләрен.

Булганлык, тырышлык—байлыкның, мул тормышның нигезе. Ногайбәк агайлар бай яшиләр. Мондый иркен, бай тормышны Таһирның моңарчы күргәне булмады. Каян килеп? Кара ипине дә крейсерга эләккәч кенә

туйганчы ашый башлады бит. Яшьлеге бик кыен, бик хәерче чорга туры килде шул. Сугыш туктаганга да әле күпме генә ел. Әмма бу байлыкларын Ногайбәкләр урлашып-алдашып түгел, ә тир түгеп, тырышлык белән тапканнарын үзе күреп тора бит. Аның күңелендә бу тату гаиләгә карата ихтирам хисе сәгать саен көчәя генә барды.

Ай, Алла?! Тагын ике тәүлектән аның крейсерына кайтасы бар. Нишләргә генә соң? Башны ташка орып карасаң да бер файдасы да чыкмас, һәй! Бу турыда иң яхшысы уйламау. Искә дә алмаска, бетте-китте! Данәгөлнең нәни йодрыкларын үз учыннан бер генә секундка да ычкындырмый. Бу дөньяга без бер-беребез өчен туганбыз, дип тукый ул үз-үзенә аның саен. Крейсерны да мине нәкъ менә Франциянең Леон култыгына, Марсель портына китерү өчен төзегәннәр. Ике илнең политиклары да, совет хәрби крейсерының Марсель портына дуслык визитын, ике яшь йөрәкне очраштыру өчен оештырганнар. Башка максатта булуы мөмкин түгел. Данәгөл Таһир кочагында. Аның кочагы, дөньяда иң ышанычлы төеннәрнең берсе, диңгезчеләр төене белән ябык. Һәм ул аны беркем алдында чишмәячәк.

***

Таһирга крейсер капитаны Соболь биргән биш тәүлек иртәнге чык булып очты. Бала чагыннан ук ул шундый булды. Кая да булса юлга чыгарга, пароходка төшәргә, йә кемне дә булса озатырга булса, ул беркайчан да будильник куеп тормады. Ни гаҗәп, кирәк сәгатендә ул кылт итеп уянып китә иде. Чөнки иң яхшы будильникның да абынып-сөртенеп куюы мөмкин. Үзеңә-үзең хуҗа булуга ни җитә!

Чистай авыл хуҗалыгы техникумында укыган чакларында да шулай булды. Егетләр төн уртасында торып берәр җиргә китәсе, пароходка төшәселәре булса, гел аңа ышаналар иде. Крейсерда да шулай. Каюталарында будильник булса да, аңа баш игән егет юк. Вахтага торырга егетләрне ул уята. Ә менә кочагына Данәгөл кергәч, Таһир үзен бөтенләй хәтерен, зиһенен җуйгандай хис итте. Ю-ук икән! 1нче ранг капитаны Соболь биргән вакыт берәмлеге эчендә генә ул үзен шулай иркен тоткан. Алда аңа мыскал да ташлама ясамаячак реаль чынбарлык. Бу чынбарлык аның алдына диңгез тигезлеге өстенә кинәттән генә төптән күтәрелгән су асты көймәсе төсле килеп басты. Стоп-кран хәрәкәткә килде. Шлагбаум ябылды. Командир биргән вакытның соңгы өлешләре ком сәгатеннән коелган ком төсле, күзгә күренеп югала. Алда соңгы кич. Иртәгә ул крейсерда булырга тиеш. Абау, нишләргә?! Данәгөленнән аерыла, диңгезчеләр арасында иң ышанычлы саналган, еш кына үзләре дә кулланган төрле юанлыктагы арканнарны бәйләү өчен кулланылган «морской узел», ягъни «диңгезчеләр төене» белән бәйләнгән кочагын ача алырмы?

Үзенә бер эш табып, Таһир бөтен өс-башын үтүкләргә керешә. Үз-үзен кая куярга белмәгән бу минутларда хет бер юаныч булсын, дип инде. Аһ-ух килеп, сыкрап, ыңгырашып кына хәл үзгәрсә икән. Болай да күе томан баскан әлеге иртә күгенә яңгыр болытлары да дәшсенме?

Данәгөлдән теш порошогы сорап алды, көзгедән дә шома итеп, бил каешын ялтыратты. Уйламаганда, көтмәгәндә юлыннан бәхетенең сызган шырпы хәтле генә кыска булуын ул менә хәзер генә аңлады. Менә хәзер генә... Бөтен трагедиясе белән. Үҗәт күңеле үзенекен тукый:—Юк! Юк! Никогда килешмим мин бу хәл белән! Ә килешми кая барасың? Ике рам арасына эләккән чебеннең тәрәзә пыяласын ватып ирекккә чыга алганы бармы соң? Терсәкне тешләп булса икән ул? Ә ни дип тешләргә аны?

Егет берсеннән-берсе каршылыклы уйларга чумып, керләре өстенә эченнән вулкан аткандай гөрс-гөрс су бөркеп, кулында үтүк биеткәндә,

аның янына, кыштыр-кыштыр килеп, Фәйрүзә апа кат-кат кереп чыкты. Йә тастымал тоткан, йә буш тәлинкә. Берсен төшереп ярды да бугай инде. Кайнар үтүкнең егет кулында чабыш атыдай уйнаклап йөргүен, киң балаклы кара сукно чалбарга алгы җөйне салганда авызыннан суны брандсбойдтан сиптергәндәй бөркеүен, аналарча яратып, килештереп карап тора. «Ай, Аллам», «ай, Аллам», дип бер туктаусыз бот чабуын белә. Кая барып төртелергә аптыраšта. Күзләрендә яшь. Ипле генә урын табып, рәхәтләнеп бер елап аласы иде бит ана. Юк бит өендә шундый ипле почмак.

—Ай, Аллам! Ай күрде, кояш алды булды бит инде сине улым, Таһир. Ай, Данәгөлем, Данәгөлем! Бердәнберебез. Менә ул нишләр инде? Аерылышуыгызны кичерә алырмы? Башына бәрмәсме инде, Ходаем? Һай, үземнең дә башым чатнауга һич түзәр хәлем юк.—Фәйрүзә апа кулындагы тастымалы белән күз яшьләрен сөртә, берсе артыннан берсе йөрәк даруларын каба.

—Йә Ходаем, йә бер Аллам. Таһир улымның башына акыллы кинәшенне индер. Ул нишләсен? Әле бит соң түгел. Соң булганчы, уң булсын дип, әллә башкачарак уйлап карыйсынмы, балам? Әллә, мин әйтәм...

—Ничек башкачарак? Башкачарак уйларга юллар киселгән. Иртәгә мин корабта булырга тиеш. Мин пыяла банкага япкан чебен хәлендә. Бернинди дә «әллә»ләрнең булуы мөмкин түгел. Аткан пуляны кире кайтарып булмаган төсле.

—И-и, балам, караб дисең. Качмый ла ул. Син менә безнең турыда уйла. Без инде картлар. Данәгөлебездән башка, улыбыз да, кызыбыз да юк. Бөтен юанычыбыз, өметебез—Данәгөл. Әлегә без исән-имин дә. Алда ни язгандыр бит. Күзебез күргәндә, колакларыбыз ишеткәндә, аякларыбыз йөреп торганда тырматырбыз инде. Бирешмәбез. Бирешми яшәп көн күрдек. Аяклар тотмый башласа нишләрбез? Ул чакта кем кулына калырбыз? Син, улым, Таһир, безне ташлый да, оныта да күрмә, инде... Синсез Данәгөлебез нишләр соң? Китсәң дә... Мәңгегә китмә...

Байтак сүзсез торганнан соң, Фәйрүзә апа ике кулын күкрәк авызына куйган. Йөзендә ялвару.

—Таһир, улым! Әгәр мин иртәгә карабыгызга барып, капитаныгыздан сине бездә бөтенләйгә калдыруын сорасам?... Аягына егылсам?... Син җитешмәгәннән генә карабыгыз батмастыр бит? Капитаныгыз алдына күчтәнәчләр белән барырмын, алдына тезләнермен?

—Ярамый!—диде Таһир.—Күңелегездә андый уй булса да, аны шушы минутта ук чыгарып ташлагыз. Ул бит сәүдә карабы түгел, ә хәрби крейсер! Һәр матрос катгый учетта... Гомумән... Без присяга биргән хәрбиләр. Присяганы Илгә, Ватанга, халкына мәңге тугры калу турында бирәләр.

***

Таһирның үз йөрәге дә меңгә телгәләнә. Тешләре кысылган. Ике кулы да йодрыкланган. Шулай итмәсә, бөтенләй сыгылып төшүе бар. Фәйрүзә апаны ул аның үзеннән күбрәк аңлый. Әмма нәрсә эшләсен соң? Ул бит хәрби дингезче! Еш кына тормыш үзе тудырган иң кыен, иң буталчык ситуацияләрдә дә, үз ориентирын табып, бер алган курсын югалтмыйча, иң кыен сынауларны җиңеп чыгып, иленә, халкына тугры калырга бөтен команда алдында ант иткән, присяга биргән зат. Бу камыт бер кигәч, кат-кат салышлы түгел. Командиры аңа ышанып биргән ялы тәмам. Җир шары шушы минутта икегә ярылса да, иртәгә ул карабта булырга тиеш. Матрос Таһир Туктамышевның кыска вакытлы ялдан тиешле срокта кайтып керүе турында склянка сугарга санаулы сәгатьләр генә калды. Тәүлегенә егерме дүрт сәгать тизлек белән әйләнгән Җир шарының күчәренә каен бастырык

тыксаң гына, бәлкем бу минутларны беразга тоткарлап булыр иде. Мөмкин булса әгәр, Таһир анысын да эшләр иде.

Кулында кайнар үтүк. Күз алдында, дөресрәге, тел очында рапорты:

—Иптәш 1нче ранг капитаны! 1нче статьялы матрос Таһир Туктамышев сез биргән кыска сроклы ялдан, ярдан кайтты. Үземә тиешле вазыйфаларны үти башларга рөхсәт итегез!

Әйе, Таһирны көтәләр карабында. Читкә тайпылыр чара юк. Мәсьәлә бер ысул белән генә чишелешле. Вариантлары юк. Реаль чынбарлык шул хәтле кырыс. Хәлне хәтта бераз гына җиңеләйтердәй чара да юк. Бу тату гаиләне бәхетсез итә түгелме соң ул? Шушы кыска вакыт эчендә аларның һәркайсын ихлас күңел белән яратырга өлгерде. Аларны яратмый мөмкин дә түгел. Эчкерсезлекләре тышка ашкан. Таһирны колач җәеп кабул иттеләр. Алар да тирән кайгыда. Әмма Таһир да нишләсен соң? Аларны, Данәгөлен калдырырга мәҗбүр. Карабка кайтмый мөмкин түгел. Юлына таш яуса да...

Аһ, Данәгөл! Данәгөл! Ул бит Таһирның никахлы хатыны. Аны нишләтергә? Кая куярга? Матур яулыкка төреп кенә, корабына алып кайта алмыйсың. Аерылып китә алырмы соң? Бу минутларны Таһир күз алдына китерә алмый. Данәгөлдән аерылса, Таһир кипкән камыш кебек булып саргаячак. Чын әгәр, әй! Данәгөлне үзе белән крейсерга алып кайтып караса? Ә? Кит инде-е! Тарихта булмаган хәл. Аңламаслар. Кертмәсләр. Теләсә кая куй, диярләр. Үзе дә кайтмый кала алмый. Тарихка монысы да сыймый. Аның кайтмый калуы халыкара зур вакыйгага әвереләчәк. Әверелсә соң? Анысы чәнчелеп китсен сәнә. Ана ышаныч белдереп әлеге ялга җибәргән командирына хыянәт итү була бит бу. Кешеләрдәге күп кимчелекләрне кичерергә була. Әмма хыянәтне?! Һичкайчан! Хыянәт ялгышлык белән түгел, ә уйлап эшләнә...

Бертуктаусыз гел шушы турыда гына уйланудан, вариантларны уйнатудан Таһирның миләре кыза башлый. Әмма нәтиҗә бер: Ул билгеләнгән вакытка карабка кайтырга тиеш.

***

Барысы да ут йоткан гаугалы көн узды. Гаугалы булмаска, аның һәр мизгеле, һәр секунды дап-доп килеп миләргә чаң сугып, колакта яңгырап торды. Кич җитте. Яшьләр, бергә булырга тырыштылар. Калган вакытның һәр минутын санап, янә фермага барып кайттылар. Данәгөл «Оялган Сюзанна», «Шаян Каролина», «Төньяк балкышлары»н бу юлы тагын да иркәләбрәк, җылымса су белән коендырды. Леон агай Таһирга яңа аерткан сөт өсте сузды. Яшьләрнең күңелендә зур борчу ятуын ул да тиз сизде. Телсез, дөм чукрак башы белән, әмма бик аңлаешлы ишарәләр ясап, аларны көлдерергә тырышмады. Аннары дингез буена төшеп мендәләр. Данәгөлнең йөзендә мәңге онытылмастай моңсу елмаю. Аерылгач, аның нәкъ менә шушы сурәтен, шушы карашын, шушы моңсу елмаюын йөртер инде Таһир күңел түрендә. Аерылгач? Тетрәткеч сүз. Телеңне әйләндереп әйтергә куркыныч.

Ногайбәк ага бүген эшеннән иртәрәк кайтты.

—Кичен, ара чыкса, өйдә генә карап чыгармын, дип алдым,—дип, китап шкафы башына калын гына күн папка куйды.—Көннең икенче яртысында зыңа чәй, кофе, аш тәмләткечләр төялгән һинд судносы килеп җитте. Капитаны, кап-кара мыеклы яшь кенә һинд егете, бер алдыма, бер артыма төште тәмам. Алып килгән тауарларын, алдан килешенгән бәяләрдән кыйбатракк бирмәк була. Һиндстанда быел ел башыннан корылык булуын, тауарларын үзе дә кыйбатрак бәягә алуын сәбәп итмәкче. Андый чакта

порт житәкчелеге тауар җибәрүчеләр белән элемтәгә керә. Узган җәйдә Һиндстанда чыннан да зур корылык булган. Чәй плантацияләре дә зур зыян күргән. Чәй җитештерүчеләр дә бәяләрне күтәргәннәр. Әлеге капитанның сүзләрен расладылар. Мәсьәлә аның файдасына хәл ителер төсле. Ни ара мильәр-чакырымнар узып портка килгән судноны кире бормабыз инде. Безнең Франция чәйне, гарәп илләре белән ярыша-ярыша, күп эчә. Инглизләр, әнә, кофе, дип, аһ итәләр. Хәер, чәйне дә яраталар.

Ә капитан егет күп нәрсәне миннән генә тора дип уйлыймы, миңа сырышты инде тәмам. Инглизчә теленнән ут очыра. Ә французча белми. Безнең порт чиновниклары, үзара, әлбәттә, французча сөйләшәләр. Мин исә, аларча сүгенерлек кенә булса да, һиндчә бераз сукалыйм. Унсигез ел эчендә һиндстан капитаннары белән дә эш йөртергә туры килде. Болай үзләре хәрәмгә катышмый, алдашмый торган, намуслы егетләр. Безнең портта аларны ихтирам итәләр.

Ногайбәк ага шулай озаклап порт хәлләрен сөйләсә дә, тел төбендә башка нәрсә бугай аның. Порт хәлләре хикәяте аның балыкка салган алдавычы түгелме икән? Саласы йомыркасын кәрҗингә төшерә генә алмыйча интеккән карт ана каздай, үзе бертуктаусыз тамагын кырды, керде, чыкты, өй борынча йөренде. Бу минутларда аның өе дә көчле давылга, штормга юлыккан караб кеби. Нәрсәгә кагылып кына китсә дә, шул ыңгыраша, шул шыгырдый. Моңарчы тыннарын да чыгармый ничәмә еллар шым яткан паркетлар, Шөһрәт агай кая килеп басса, шул төштә ыңгырашып алалар. Ачсаң да, япсаң да зал ишеге ямьсез шыгырдап куя. Аш өстәленең дә әллә бер аягы кыскарак инде? Нәрсә китереп куйсалар, шул тәлинкә чайкалып китә. Түшәмгә эленгән люстрага ни булган инде? Бүген ничектер бөтенләй тоныкяктырта.

Фәйрүзә апа да маңгаена яулыкны бүген тагын да калынрак ураган. Йөрәк даруы да халат кесәсендә генә. Еш кына: «Бүгеннән исән калмам ахры»,—дип ыңгырашып ала. Шушы кызганыч хәлендә дә сөйкемле ул. Йөзеннән изгелек бөркелә.

Утыз көн уразаның бер көн бәйрәме булмый калмый. Анысы бәхәссез. Гәрчә бу «ураза» утыз көнгә үк сузылмаса да. Ногайбәк ага кинәттән генә учын-учка сугып куйды. Иңбашларын уйнатып алды. Нәрсә соң әле ул хәтле? Башларыбызны гильотина пычагы астына салырга хөкем итмәделәр бит әле, димәкче булдымы. Барыбыз да исән-сау, өстәл тулы ризык!

—Әйдәгез, чәйгә утырыштык, сайбуллашу чәе булыр инде бу,—дип барысын өстәлгә чакырды. Утырыштылар. Фәйрүзә апаның татлы ризыкларыннан өстәл өсте сыгылып тора. Әмма аларга берәү дә үрелми. Чөнки әллә «бер аягы кыскарак» өстәл өстен кайгы, аерылышу сөреме баскан...

Ногайбәк ага, ни нәрсәнедер исенә төшергәндәй, янәдән учын-учка сугып алды. Сикереп торды да, тагын йөренеп килде.

—Мәет чыккан йортмы, диярсең. Бөтен өстәл өстен кайгы сөреме баскан. Син китә дип, Таһир улым, егылып үликме инде? Әлегә бит барыбыз исән-сау, әйе. Башыбызны да чабарга җыенмыйлар. Җәллад балтасын кайрамый лабаса. Болай булмый, җанкисәккәйләрем. Бу халәттән, кадерлеләрем, җәядән аткан ук тизлеге белән чыгарга кирәк безгә,—дип янә өстәл янына килеп, лып итеп урындыкка утырды. Учын-учка уып, кһым-кһым килеп тамагын кырды. Өстәлгә каяндыр гына шалт кына алып, бер шешә эчемлек чыгарып утыртты.

—Әлеге, бик үткен һиндстан капитаны күчтәнәче бу. «Дәһли утлары» дигән бик югары маркалы коньяк. Шушы коньякны бер-бер артлы өч чәркә томмый торып, улым, безне биләгән, тәмам сарган бу кара сөремне башкача

тарата алмабыз. Ханымнарга Сантьягоның үзеннән китергән бик тәмле Куба ромы ачам. Нәрсә сез, барыгыз да авызларыгызга су каптыгыз? Миннән үрнәк алып, һо-оп, затлы эчемлек кабыгыз. Менә булырсыз кеше!.

Ногайбәк ага, кыядан ташланырга җыенган кешедәй, үзен бәйсез тотты. Бер-бер артлы өч рюмканы каплаганнан соң, тукта, сикерергәме бу кыядан, әллә бераз сабыр итимме, дигән төсле шып тын калды. Затлы коньякның тылсымлы кодрәте күнеленең барча кылларын үзенә буйсындырганны, аларны колы иткәнне көтте. Күнел төбен бик тирән кичерешләр биләве аның да йөзенә чыккан, саргылт-яшел күзләрендә чагыла. Йөрәгенең нинди югары көчәнешле режимда эшләвен, чәнчә бармак юанлыгы булып бүрткән чигә тамырларының дерт-дерт тибеп торуы күрсәтә. Ниһаять, монарчы күнеленең ин түрендә һәркемнән яшереп, күз карасы кебек саклап, берәүгә дә ачмый килгән серен чишәргә, иреккә чыгарырга вакыт җитте, сәгате сукты, дип хәл итте, ахры. Башта, канатларын як-якка җәеп, бер киерелеп алды.

—Менә нәрсә!—дип, авызын ачар алдыннан, үзен психологик яктан хәстәрләп, сул йодрыгын учлап, дек-дек кенә бәреп өстәлдә биетеп алды. Шунсыз булмый. Авыз ачылса да телнең әйләнмәве мөмкин. Аннары борынын сыпырып, ак тастымал белән авыз читләрен сөртте.

—И-их, Таһир улым! Синең яшеңдә булсаммы? Таулар ишәр, таулар аударыр идем мин. Шул хәтле якын син минем күнелгә, чөнки бар ягың белән дә килгәнсең. Беләсеңме нәрсә? Китмә син бездән. Кал, улым!—диде жете яшькелт күзләрен Таһирга төбәп.—Тот та кал, ә? Бүген бер дигән егет булсаң, иртәгә ак сакаллы карт булырсың. Күреп торасың, Фәйрүзә апаң белән безгә тагын күпме генә яшисе калган. Гомер буе мыскаллап туплаган малыбызның барысы өелеп сезгә кала. Барысына син хуҗа булырсың. Кал, кал син улым?! Бу теләк минем күнелемдә күп еллар буе саклаган хыялым. Командирың каршына да шул өметне тормышка ашыру теләге белән бардым. Анысын эшли алдым. Сине үзебезгә кунакка сорап алдым.

Таһир дәшми. Дәшәрлек хәле дә юк бугай. Аның хәленә төшәргә дошманыңа язмасын.

—Үземне черегән байлардан санасам, шапырыну булыр иде,—дип дәвам итте.—Әмма хәерче, ярлы-ябагай да түгел. Картлык көнебезгә дип, банкларга сала барган франкларыбыз да, долларларыбыз да җитәрлек. Син, улым, тот та кал. Кал бездә! Үкенмәссең гомердә! Синдә—яшьлек, көч-кодрәт. Минем дә куен буш түгел. Миндә, улым, бай тормыш тәҗрибәсе. Монысы бүгенге көндә аеруча зур, кыйммәтле капитал. Күзем дә бик җете минем. Нәкъ диңгез киңлекләрендәге кебек. Тәҗрибәле капитан диңгез төбеннән башын калкытып утырган рифләрне ничек оста әйләнеп узса, мин дә шулай, тормыш сукмакларында туып торган сикәлтәләрне ничек әйләнеп узу мөмкинлеген бер күз салу белән үк чамалыйм.Әгәр инде икәүләп алынсакмы, улым Таһир?! Тормышның шыгыр-шыгыр тәгәрәгән көпчәгенә күпме байлык урарга өлгерәбез әле. Әмма барысы да сезгә, нәкъ менә сиңа булачак бит. Синең урыныңда үзем булсаммы, егетем?! Ник шунда чәнчелеп китми дөньясы, дияр идем. Ике дә уйлап тормыйча, калыр идем. Иректә кеше булып, байлык эчендә, муллыкның нәрсә икәнен үз җилкәңдә татып, рәхәтлектә яшәрсең. Син шуны бел, Таһир улым, син миңа бу дөньяда иң якын, иң туган кешем. Бердәнбер кызым Данәгөлне бирдем бит сиңа. Никах укыттык, хәзер инде икегезнең дә бәхетле булуыгызны телибез. Сүземә колак салсаң, аларны мыек очына чорный барсаң, пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп гомер итәрбез, ишек алдыбызны тутырып миңа оныклар бүләк итәрсез!—Э-эх, Таһир, улым! Аек акыл белән яшәгән кешегә череп баеп яшәргә дөньяда әллә нинди мөмкинлекләр бар бит. Менә үзебезнең портта ук. Әгәр төпле,

ышанычлы терәгем булса, үзебезнең портта ук чит ил дингезчеләре өчен көндезге кафе, кичке ресторан ачып җибәрерием. Шунда ук һотел, сауна, шунда ук бильярд клубы, казино. Менә кайда тау-тау акча, менә кайда саф табыш! Ә мондый эшкә бер ялгызым алынырдай яшьтән узып барам шул инде. Аркадаш, ышанычлы аркадаш кирәк мондый эшкә алыну өчен. Ә рөхсәт кәгазен, лицензияне префектурадан мин сиңа иртәгә үк алып кайтып тоттырам.

Таһир ни әйтергә дә аптырап телсез калып утыра. Ногайбәк ага, хәзер инде законлы бабасы, аларның крейсерына килеп, капитаннан аны менә нинди максатларны күздә тотып, сорап алган икән. Хәзер аны үтереп калырга кыстый. Ләкин бу адымны Таһир үлсә дә ясамаячак. Кала алмый ул. Бу мөмкин түгел. Ләкин Данәгөл, кочагында иркәләп туймаган кошчыгы белән аерылышу да аның өчен берьюлы йөз үлем кичерүгә тиң. Аерылышу гына тиз. Кавышулар сирәк була... Булса әле...

Шөһрәт ага башын артка ташлап, беравык уйланып торды. Коньяк шешәсен алып, янәдән рюмкаларны тутырды.

—Мин әйткән һәр сүземне бик чамалап сөйлим,—дип куйды. Менә бүген генә дә синең урыныңа үземне йөз тапкыр куеп карадым. Мондый бәхет адәм баласына гомердә бер генә килә. Шуны кулдан ычкындырсаң, тү-тү, гомерең буе үкенәчәксең. Аннары бердәнбер бәбкәсен тилгәннән урлаткан дивана ана каз кебек, бер максатсызга каң-каң каңгылдап яшәргә генә кала. Кайчакта безнең адәм баласына тәвәккәллек тә җитми. Ә син менә тәвәкәллә, кал! Кызыма гына түгел, бу тормышта миңа да ышанычлы терәк кирәк. Чабышка чыккан атларның кайсы алдан киләсен мин бер күз сирпү белән сизәм. Зур тормыш юлы үткәннәр алдында гына ачыла торган аның үз сере бар. Мин аны сиңа да ачармын. Ә крейсерың ничек килсә, шулай китәр. Син кайтмады дип кенә бүсере салынмас, кингстоннары тишелеп төпкә китмәс...

—И-и, Аллам, ярга киткән җиреннән бер матрос кайтмады, дип экипажыгызның исе китәр инде бик,—дип аны Фәйрүзә апа да хуплады.— Безнең Марсель портында, Таһир улым, мондый хәлләр бик еш булып тора бугай ул. Корабларыннан берәүләп тә, дүртәү-бишәүләп тә аерылып калгалыйлар. Аңа карап бер кораб та килгән җиренә китми калмый бугай. Шулай бит, әтисе?! Әйеме?

Данәгөл генә сүзгә катышмый. Кулындагы тастымалны бөтерә. Язмышның үзе бу! Аның алдында тәмам сыгылып төшеп, тез чүгү ни генә бирә? Өлешемә чыккан көмешем, бу аерылышу газапларын мин күтәрми тагын кем күтәрсен, дигәндәй тын гына утыра, тастымалны бөтерә. Моңсулык бөтен йөзен баскан. Шул ук вакытта бер төбәлеп карасаң, күзеңне алалмаслык матур. Баш артына җыеп бәйләгән толымнары үзенә килешеп тора. Хатын-кызларның маңгае шулай матур буладыр, дип Таһирның башына да китергәне юк иде. Данәгөлнең әлләни киң дә, тар да булмаган маңгае аның йөзен әнә ничек бизи. Аның сөйкемле күз карашын Таһирның гомердә онытасы юк. Данәгөлнең озын кара керфекләре әкиятләрдәге Сылубикәләрнең битләренә җил өрә торган веерларын хәтерләтә. Таһир аларның һәрберсен берәмләп-берәмләп үбеп чыгарга әзер. Бер чите белән генә елмая белгән уймак авызы, сусыл иреннәре аны чагыштыру таба алмастай гүзәл күрсәтәләр. Шулчак Таһир күңеленә авылда, кичке уеннарда, кызларга төрттереп җырлаган бер җыр искә төште.

Төшмә, дустым, су читенә, су чәчерәр битеңә.
Син сөймәсәң, мин дә сөймим, гөл үсмәгән битеңә,

—дип җырлар иде алар. Ә Данәгөлнең битенә нәкъ менә гөл үскән шул. Шуна күрә дә ул Данәгөл! Бер генә, данә генә гөл!

Ногайбәк ага Таһир янынарак күчеп утырды.

—Адәм баласының бәхетле булырга хакы бар. Бу турыда үзебезнең Француз философлары да язалар. Теләсәң, әнә битләрен дә ачып күрсәтәм. Ә синең бәхетең менә монда, шушы нигездә. Бүген менә минем алда шушындый сорау торсамы, улым? Мин ике дә уйламый, калыр идем. Ник чәнчелеп китми шунда дөньясы, дияр идем. Кочагында Данәгөл булганда! Иртәгәдән үк Карлыгачлар пансионатына балыкка йөрерсез. Ул арада мин барын да көйләрмен. Паспортын да юнәтермен. Гражданлыгын да җайлаштырырбыз.

—Таһир, улым, син бабаңны белмисең әле,—дип күкрәк сугып куйды Шөһрәт агай.—Мактана картлач, дип уйлый күрмә тагын. Анысы кешеләрдә мин иң сөймәгән сыйфат. Әмма кистереп әйтәм. Әгәр кирәк икән, мин сиңа, «менә бу чибәр егет—призедент Де-Гольнең туганнан туганы», дигән таныклык алып кайтып тоттырам.

—Бабаң шундый, шундый, әйттеме, эшли!—дип куәтләде аны Фәйрүзә апа.—Әйеме, әтисе?

—Эшнең дә җаның теләгәнен табарбыз. Син бит үзеңне минер, дидең. Шартлату осталарын, тәҗрибәле минерларны үзебезнең портка ук дүрт куллап алачаклар. Үзәк портның уң як өлешендә Гаваньне тирәнәйтү, причалларны киңәйтү эшләре башланды. Анда нәкъ менә минерлар кирәк инде.

Кеше дигәнең суга чумгач та шулай була бит. Пылт итеп өскә калка да, колач сала-сала йөзеп тә китә. Таһир белән дә шулай булды. Капитан Соболь аны җибәрде, ул машинага утырып китеп барды. Берни турында уйлап-нитеп, баш ватып тормады. Хәзер менә мираж качты, томан таралды. Егет алдына азау тешләрен ыржайтып реаль чынбарлык килеп басты. Димәк, Ногайбәк ага, үз гомерендә утны-суны кичкән бу хәйләкәр кеше, аны үзенә башта ук мәкерле уй белән, ничек тә монда калдыру нияте белән кунакка чакырган икән. Хәер, аны гаепләр сәбәп тә юк. Чит җирләрдә яшәсә дә, туган илен, туган халкын өзелеп сагынып яшәгән бу зирәк акыллы баш, бердәнбер кызының хәләле үз милләтеннән булуын теләгән. Моның соң ни гаебе бар? Калырга өндәвен дә аңларга була... Ногайбәк ага еш кына үзен Таһир урынына куеп караса, кияве дә үзен бабасы урынына кат-кат куеп, уй-фикер йөртеп күп тапкырлар карады.

Таһир утырган җиреннән торып, Данәгөлне кочагына алды. Данәгөл—песи баласы, атлет гәүдәле совет матросы Таһир Туктамышевның кочагына сеңде дә бетте. Хуҗалар аннан җавап көтәләр. Таһир тирән итеп тын алды. Авыр сулап:

—Кичерә күрегез мине, кадерлеләрем, кала алмыйм!—диде.—Бу мөмкин түгел. Мин хәрби диңгезче. Илем, халкыма присяга бирдем. Мондый хыянәтне эшләсәм, мин үземне-үзем күралмаячакмын. Мине командирым ышанып җибәрде. Мондый ышанычка хыянәт итү өчен миңа кем булырга кирәк соң? Кайберәүләр бәлкем булдырырлар да, ә мин юк! Бер хыянәт үз артыннан мең хыянәтне ияртә. Мондый юлга баскач, ничек яшәмәк кирәк соң? Сезгә бу сүзләрне ишеттерүгә караганда, ике тегермән ташын берьюлы каршыдагы әнә теге тауга тәгәрәтү миңа мең өлеш җиңелрәк булыры иде. Әмма әйтмичә дә булдыра алмыйм, кадерлеләрем. Бер тоташтан таш яуса да, җир урталай икегә ярылса да, мин карабыма кайтырга тиеш. Шушы адымны бернинди карусыз-нисез эшләргә мәҗбүр итүче ниндидер көч, кодрәт бар минем өстемдә. Бу көчкә каршы мин кыл кыймылдатырлык та каршылык күрсәтә алмыйм...

Таһирның бу сүзләреннән соң, Ногайбәк ага шап иттереп ике ботына сугып куйды.

—Һәй-й, улым, улым! Присяга да, присяга, дисен. Дивана баш булмасаң, дип әйтәм инде, присяга бирсәң соң инде! Тот та боз присяганны!— Ногайбәк агай йодрыгын-йодрыкка уып, бәрә-бәрә, ул присяганы ничек бозарга икәнен дә күрсәтте. Идәнгә тураклап ташланган присяганы, янәсе, ике аягы белән таптап та алды.

—Иленнең, халкынның иң тирән серләрен аның кан дошманнарына ачмыйсың сәна,—дип дәвам итте ул бераз тынычлана төшеп.—Әгәр инде тулы бер флотның флагман карабында хезмәт иткән хәрби буларак, ул серләрне күбрәк беләсең икән, авызыңны йозакта тот. Крейсерың синнән башка да бик әйбәт йөзәр, сайга утырмас. Ничек килсә, шулай шома гына китәр. Ә син кал! Ә син, балам, мина киявем генә түгел, үзем жан биреп, алдыма утыртып, үчти-үчти итеп үстергән улымнан да кадерле жан булырсың. Тик син кал гына. Ка-а-ал, улым! Акылыңа кил. Ике күзеңне киңрәк ачып, башыңны як-ягына боргалабрак кара әле бу фани дөньяга. Бердәнберебезгә, Данәгөлебезгә тиңдәй парны без моннан да тапкан булыр идек. Э-э, улым! Тапмас идекме?! Тиле кеше әйтмешли, чыгып бер сызгыр гына. Шундук чиратка басачаклар.

—Чиратка басмасалар да...—дип кушылып китте Фәйрүзә апа.—Без бит кызыбызның тормыш иптәше үз өммәтебездән булуын теләдек. Гаиләбезгә кушыласы, нигезебезне таркатмый ыруыбызны дәвам итәчәк затның кан кардәшебез, жан кардәшебез булуын теләдек, улым Биктаһир. Һәр кылган догабызда Ходайдан шуны сорадык,—чигәсен уып утырган жирдән, Фәйрүзә апа ике кулын да йөзе алдына китерде, авыз эченнән генә янә бер дога укып алды:—Йә, Ходаем, ошбу догамны да изге сәгатьтә укылган итеп кабул ит.

Ногайбәк ага кинәттән генә:

—Ә Жак кая соң әле безнең?—дип сорап куйды.—Бу арада бер дә күренми. Машинасын да кычкыртып узып китми. Бик чибәр, бик әдәпле күрше егетебез ул безнең. Данәгөл белән уйнап үстеләр, мәктәпкә дә бергә йөрделәр. Әтисенең автомобильләр төзәтә торган кечерәк кенә мастерское бар.

Жак шунда механик. Машинаңа бер генә күз салып ала, кайда дефект булуын шундук әйтеп бирә. Хәл белергә керсә дә, һәрчак Данәгөлгә чәчәк бәйләме тотып, ә безгә нинди дә булса күчтәнәч тотып керә. Эш аның үтә дә итагатьле егет булуында гына микән? Мин шуны сизәм. Жак та бер дә максатсыз гына безне шулай «кулына иярләндерми» торгандыр. Ул да инде күптәннән Данәгөлнең кулын сорарга йөри төсле тоела мина.

—Кичә генә әнисен күрдем,—диде Фәйрүзә апа.—Алар бит мастерскойларын кинәйтергә жыеналар. Шуңа яңа жиһазлар кайтартырга Германиягә китте, дидеме әнисе. Кайтса, кереп житәр әле. Бик әйбәт, бик ышанычлы күршебез. . . Хәлебезне һәрчак белеп, сорашып кына тора.

***

Чикләвек агачыннан мең сыр төшереп ясалган затлы тартма эчендәге, Швейцариянең үзендә, затлы, бай залларны бизәү өчен эшләнгән зур стена сәгате, үз кадерен белеп кенә, әмма барысын сискәндереп, дан-дон итеп жиде тапкыр сугып алды. Кичке жиде тулды. Барысы тып-тын калдылар. Стена сәгатенең әлеге дан-доннары әйтерсең кыямәт көне житәсен хәбәр иттеләр. Кыямәт көне үк житмәсә дә Таһирның бу гаилә кочагында нибары уники сәгатьләр яшисе калган. Жыена башларга да вакыт түгелме? Иртәгә, иртәнге жидедә ул карабында булырга тиеш. Шул сәгатькә кайтып басмаса, бер матросны ярга, кыска сроклы гына ялга жибәргән жирдән кайтмавы турында

тревога булачак. Вакытында тиешле чаралар күрү өчен эзләргә керешәчәкләр. Ул бит сина колхоз базары түгел. Анда гына суган сатучы Мәчтүрә киленнен, итек басучы Галәветдин абзыйның, тозлы гөмбә сатып көн итүче Пелагея түтәйнең бүген рәтләрдә күренүен, йә нишләптер күренмәвен, барын-югын искә алган кеше дә юк. Ә Крей-се-ер!!! Крейсер ватанына, иле-халкына мәңге тугры хезмәт итәргә байрак алдына тезләнеп, аны үбеп, тантаналы ант биргән, бөтен яшәү рәвешләре ныклы дисциплинага корылган менгә якын ир-егеттән торган корыч йодрык. Бу йодрыкны тәшкил итүчеләр кешелекнен әлегә аз өйрәнелгән, әмма бөтенләй башка камырдан басылган һәм бөтенләй башка технология белән жан өрелгән затлары. Монын шулай икәнен раслау өчен «Варяг» крейсеры егетләрен, аларнын тиндәшсез батырлыкларын искә төшерү дә житә... Флот традицияләрне нык саклый.

Хужаларынын холык-фигылен, шуннан, стенадан торып, озак еллар буе күзәтергә күнеккән үзсүзле швейцар сәгате дә, өйдәге чамадан тыш хәлне, хужаларнын киеренке халәтен сизә идеме? Сизә булыр, шайтан. Өй жиһазлары шулай алар. Соңыннан кемдер аларга акыл әләме соң? Тора-бара өй жиһазлары хужаларынын кәефен анларлык, кайгы-шатлыгын уртаклашырдай, киңәш бирердәй, юатырдай затларга әвереләләр. Алай гынамы? Тора-бара өй жиһазларында хужаларына, ә хужаларында бер күнеккән, тәмам үз иткән өй жиһазларына карата эчкерсез мәхәббәт хисе туа. Шунда ук тагын унны алып кайтырга мөмкинлеге булса да, сервант башыннан төшеп ватылган бәллүр вазасын юксынып елап утырган хужабикәләр азмени? Базарда яналары күпме кирәк, ә эш балтасын жуйган, йә урлаткан агай ничек уына.

Юк, бу стена сәгате алган көннән үк бик үзсүзле булды. Ник бер секундка соңарсын, ник бер минутка алга китсен? Вакытында герен күтәр, вакытында төшер. Менә хәзер дә, миңа дисә, ник шунда дөньясының асты-өскә килми, мин үз вазыйфамны гына беләм, ә башкасында мыскал эшем юк, дигәндәй, алай да авыр сулап, шалдыр-р-р итеп чылбырын кыскартып алды да, акча санаган төгәллек белән, док-док-док итеп секундларны санавын дәвам итте. Анын моңарчы өйне бизәгән док-деге суккан секунды саен шөбхәлерәк ишетелә башлады. Бу док-доклар Ногайбәк агага аеруча ачу китергеч тәэсир иттеләр.

—Бер суга башласаң, тиле баш, очы да ахыры да юк, туктый белмисен. Каян килеп кичке жиде житсен әле? Ә син, тиле күке, жиде тапкыр доңдан килден. Синен бер генә данын да башка тимер чүкеч белән органнан бер дә ким түгел. Ярар, дустым, бүген синен безгә кирәген шул хәтле генә. Бераз ял итеп ал әле!—дип, барып сәгатьне туктатты.

—Күптән кирәгие, күптән,—дип хуплады аны Фәйрүзә апа да.—Шундый чакта бераз тынып торса да чарыгы күгәрмәс.

Ногайбәк ага, идәннең нәкь менә шыгырдаган паркетларын эзләгәндәй, нәкь шундыйлары өстенә генә басып, йөренә башлады.

—Нервыга тиеп ни дип шыгырдыйлар!

—Аларны жәйгәнебезгә ничә ел инде, әтисе?.. Бераз коргаксый төшкәннәрдер.

Ногайбәк ага янәдән лып итеп Таһир каршына килеп утырды. Янәдән йодрыгын йодрыкка бәреп-бәреп:

—Әгәр инде бер-берегезне ошатмаган, килештермәгән булсагыз, бер хәл. Сүз дә кузгатып тормаган булыр идек. Күреп торабыз лабаса, бер-берегезне өзелеп яратасыз. Аерылышсагыз сагынуга ничек түзәрсез? Сагыну—коточкыч халәт бит ул. Аңа берниндн дәва юк. Сары яфрак итеп саргайта ул сине, корыган агач кебек киптерә. Безнен таможня службасында «Наполеон» атлы бер бик матур ата мәчебез бар иде. Бик эре гәүдәле, уйчан, акыллы йөзле песи иде. Документларын көйләп йөргәндә күзенә чалынган

ахры. Наполеонны грек пароходы шпикеры күреп алган.

—Суднобызны күселәр басты, шуларны бераз тыймасмы,—дип, бездән рөхсәт сорап, шул песине үз карабына алган иде. Шпикер белән китәргә Наполеон ул чакта ук карышкан иде. Кочагыннан сикереп төшеп качарга маташкач, шпикер аны сумкасына салып алып китте.

Бу турыда без шул минутта ук оныткан идек. Наполеон таможняга ике ел үткәч кайтып керде. Безне сагынуга түзмәгән. Аның кыланышын күрсәгез. Таможнядагы һәр бүлмәгә кереп, һәркем белән мыраулап исәнләшеп, аягына чорналып иркәләнеп йөреп чыкты. Ул грек судносы белән Наполеон кайларда, кайсы илләрдә генә булмагандыр. Ә барыбер кайткан. Чөнки ана сагыну хисе көч биргән.

—Егет башына мондый сөю бер генә килә,—дип дәвам итте Ногайбәк ага.—Акылына кил, улым, тот та кал. Бәхетеңне очкан кошларга бирмә! Әнә Наполеоннан гыйбрәт ал.

Чал чәчле, киң җилкәле, горур кыяфәтле, мәһабәт килеш-килбәтле Ногайбәк агай кинәттән тезләренә чүкте. Кыйбла якка карап, ике кулын күккә төбәде. Йа, Ходаем, бер Аллам! Күрәсенме, таныйсынмы? Кыюсыз, күндәм бер колың Шәһрәт Ногайбәк бит мин. Моңарчы мәрхәмәтеңнән мәхрүм итмәдең. Аны гомеребез буена сизеп, тоеп, рәхмәтле булып яшәдек. Бу юлы да ташлама. Минем никахлы киявем булган шушы алтын егет башына да үз акылларыңны өстәсәнче,—дип ялварырга кереште.—Берлегеңне таныган, гомере буе сиңа табынган, бер гөнаһсыз бәндәң сорый моны синнән. Кодрәтең киң һәм чиксез, бер Аллам, ярдәменне кичекми индерә күр.

Хак Тәгаләнең Ногайбәк ага ялваруларыннан башка да мәшәкатьләре муеннан чагы булдымы, бу юлы ярдәмгә ашыкмады. Аның каравы агай һөҗүмен көчәйтте.

Тезләнеп ялварудан гына эш чыкмасын күрде Шәһрәт агай. «Билемне тотты, билемнән каптырды»,—дип ыңгырашып, аякларына торып басты. Чүбе-мазар булмаса да, тезләрен какты. Әмма чигенергә исәбе юк. Һөҗүмне башкачарак җирлектә дәвам итте.

—Кал, улым, кал, дип күпме тукыйбыз. Юк, китәм, ди генә. Карышкач та карышыр икән. Бүген генә шундыймы син, Таһир, әллә тумыштан ук киребеткән бала идеңме? Аh, Алла, кеше сүзен колагына да элми торган нинди тискәре җан син? Көнбатышның байлыкка, муллыкка чумган чагы. Базарларда җаның ни тели, шул бар. Марсель портына бер дигән көн-күреш тауарлары, өс-баш, затлы ризыклар төяп көн саен килеп торган караблар йөк бушатырга амбарлар, пакгаузлар көтеп чират торалар. Ә бу егетебез һаман кайтам, ди. Газеталар бер дә булмаганны язмаслар. Ә мин аларны берсен-бер калдырмый укып барам. Анда бит сезнең ипи-тозга да чират икән. Кер сабынын да талонга гына бирәләр, ди бит. Мунчадан соң алмашка дигән күлмәк-ыштанны да ГэПэУ чекистлары гына бирә, ди. Хатын-кызларыгыз театрларга да кирза итекләрдән киләләр икән. Юк, юк, газеталар бер дә булмаганны язмаслар.

Егет кеше башы белән кунак өстәле артында сәяси дебатлар оештырып утырмас бит инде Таһир.

—Әйе, сугыштан соң безнең ил чыннан да экономик кыенлыкларны кичерде. Әмма ипи-тозга чират юк. Сабынны да талонсыз, теләгәнчә бирәләр,—дип кенә әйтте. Хатын-кызларыбыз театрларга панбархат күлмәкләрдән, биек үкчәле, лакланган туфлиләрдән йөриләр.Ә чит илләрдән килгән туристлар Мәскәүнең парфюмерия кибетләрендә «Красная Москва» исемайларына чират торалар. Газеталар алар империалист хуҗалары кушканны язалар.

Таһирнын эчендә Везувий вулканы кайный. Ала да су кабып куя, ала да су каба. Бабасы Шөһрәт агайны да, Фәйрүзә апаны да, анын кочагында утырган Данәгөлне дә анлый. Ләкин нишләсен? Йә, нишләсен?! Һаман шул бер сүзне кабатларга мәҗбүр:

—Күреп торасыз, кадерлеләрем, мина да жинел түгел. Туйганчы бер кочарга да өлгермәгән ярымнан аерылам. Алда күрешәбезме, юкмы, билгесез!? Әмма кала алмыйм. Сездән аерылу мина да бик авыр. Өзелә, телгәләнә үзегем. Бу сүзләремне йөрәгем сыкрап, күнелем ачы күз яшьләре белән тулган хәлдә әйтәм. Туган ил ул шундый нәрсә, анын белән араңны өзәргә теләп, бер кизәнүдә мен кылын өзсән дә, тагын мене кала. Менә шулары тота, шулары жибәрми. Калдым, ди. Үзегез уйлап карагыз, шушындый алдакчы, хыянәтче, дезертир турында минем командирым ни уйлар? Ә бит мин аны бик ихтирам итәм, ирләрчә кырыс ярату белән яратам. Холкым-фигылем, акыллы гамәлләрем белән аңа охшарга тырышам. Андый кешегә хыянәт итү мөмкин түгел. Чөнки ул моны үзе кабул итмәячәк. Сыгылып төшсә төшәр, ә минем хыянәткә ышанмас.

Мин илебездәге алдынгы яшьләрне берләштергән, юлбашчыбыз бөек Ленин төзеп калдырган ВЛКСМ оешмасынын Севостополь хәрби округы конференциясе делегаты. Шушы конференциядә үзебезнең крейсер матрослары исеменнән чыгыш ясадым. Анда мине ВЛКСМнын өлкә комитеты әгъзасы итеп сайладылар. Хыянәтем турында анда ишетсәләр, ни диярләр?! Активист булып кыланып йөргән комсомолец Таһир Туктамышев, төлке тиресе ябынган бүре булган икән, диячәкләр. Ә карабтагы, үзем белән бергә дингезченең авыр хезмәтен тартучы хезмәттәшләрем минем турыда ни уйларлар? Комсомол булып йөргән иде, мәлгунь, чын дезертир булып чыкты, диячәкләр. Милләтем йөзенә таш атачаклар. Безнең крейсерда унлап милләт вәкиле хезмәт итә. Шулар арасында татар егете—дезертир! Ходаем, бу хурлыктан үзең сакла! Монын өчен мине бөтен татар халкы хөкем итәчәк, жирәнеп, лач итеп жиргә төкерәчәкләр. Командование тарафыннан да:

—Безнең теге татар егетебез, бик хәйләкәр жан булып чыкты бит. Мөгезне чыгарды тек чыгарды. Франциягә дуслык визиты белән барган жиреннән качып калды. Бу татарларга беркайчан ышанырга ярамый,—дип нәтиҗә ясарлар. Мыскыллап көлүчеләр, жирәнеп төкерүчеләр сансыз булачак!

Шундук әнигә хәбәр итәчәкләр. Ул бит минем гади бер авыл хатыны. Саулыгы да чамалы. Бу кайгылы хәбәрне ул ничек күтәрер? Күтәрә алырмы? Сенлем Зөһрәгә житкерәчәкләр. Анын бит авылда яшисе, кияүгә чыгасы бар. «Дезертир сенлесе! Черек капитализмнын байлыгына кызыгып, Франциядә калган хыянәтченең бертуган сенлесе!»—дип күзен ачырмаслар. Совет хәрби карабыннан качкан дезертирнын сенлесен кем кияүгә алсын? Анын рәнҗүе, кайнар күз яше, каргышы минем башка төшмичә, тагын кем башына төшсен? Ногайбәк ага сүзләреннән кайтып төшкәндәйрәк булды.

—Булмый икән инде, булмый. Булмагач, бер хәлен юк,—диде ул маңгаен уып. Бер мәлгә тирән уйга калды. Ватан—туган ил төшенчәсе чын ир-егетләр өчен коры сүз шулпасы гына түгел шул. Бер карасан, вак-төяк кенә кебек. Сине туган илең белән бәйләгән жепләр әллә ни калын да түгел. Әмма шуларнын барын бергә жыйсаң, бастырыктан юан аркан килеп чыга. Шуңа син балта чабып кара, әгәр шундук кулын корудан курыкмасаң. Анладым мин сине улым, тәмам анладым. Язмыш бу!. Аннан узмыш юк. Елашып утырмыйк. Саубуллашу хөрмәтенә тагын берәрне тотыйк.

Ногайбәк ага учын-учка уып алды.

—Синең белән, Таһиржан, улым, без менә монысын тотып карамадык бит әле. Менә бу коньягым тегеләреннән дә затлырак,—дип серванттан,

бөкесе ачылган тагын бер шешә алып килде. Монысы Зәм-Зәм суы!— Икесенә дә рюмкаларын тутырып «Зәм-Зәм суын» салды. Фужерларга салганда, Фәйрүзә апа урыныннан тора төшеп, нидер әйтмәкче булды. Шөһрәт ага аңа ым какты: «шып бул» янәсе.

—Сине туктатып кына вакыт агышын туктатып булса икән! Дак-док килеп атлый бир, даң-доннарыңны да суга тор,—дип, агай бая туктаткан сәгатен җибәреп килде. Янәдән учын учка уып алды. Ничектер кинәттән генә күнеле күтәрелеп киткәндәй тотты ул үзен.

—Улым, күтәрдек алайса берәрне. Аннары тәмләп чәй эчеп алырбыз. Фәйрүзә апаң тезгән ризыклардан өстәл сыгыла. Сыйлан рәхәтләнеп. Мәет чыккан йорттагы төсле утырабыз шунда. Тоттык берәрне!

Таһир, бик зур сер чишкәндәй, башта як-ягына каранып алды:

—Минем... башымда... менә мондый тәвәккәл вариант бар,—дип бармагын иреннәренә китерде. Шып булыгыз, тыңлагыз әле дигән ишарә иде бу.

Ногайбәк ага алай да:

—Башта берәрне тотарга булган инде,—дип канәгатьсезләнү белдереп, бераз сагая төшеп, рюмкасын өстәлгә утыртты.

—Йәле, улым, нинди вариант? Әгәр дә тормышка ашырырдай булсамы... Ике куллап....

—Мин Данәгөлне үзем белән крейсерга алырга булдым. Эчемдә биш көн барган кискен каршылыклы дебатлардан соң, бу карарымны күнелем бер тавыштан кабул итте һәм бу карарга нинди дә булса коррективалар кертү турында уйлыйсы да юк,—дип сөйләп китте ул.—Безгә кунакка килгән делегацияләр составында Данәгөлне крейсерга алып керү кыен булмаячак. Палубага күтәрелгәч, анда эш башка. Безнең минерлар трюмында кечерәк кенә бүлмә бар. Ул һәрчак буш. Кадерлемне беркемгә күрсәтми шунда төшереп урнаштырырмын. Урын-җир, чәйнек, савыт-саба төшереп куярмын. Иртә-кич ашарына-эчәренә кертеп торырмын. Вахтадан бушау белән янына ашыгырмын. Анда минем Данәгөлем яшәгәнне беркем белмәс. Берәрсе белсә дә, безнең егетләр сер саклый беләләр. Күп булса ике атнадан безнең визит тәмамланачак. Без кайтышлый ук Одессага, Ильичевка базасына ремонтка туктаячакбыз. Дизельләрне, кайбер коралларны яңага алыштыру көтелә. Ремонт эшләре кимендә өч-дүрт ай дәвам итәчәк.

Таһир җилле генә сөйләгән җирдән шып туктап куйды. Өйдәгеләр аның вариантын хуплыйлармы? Стена сәгате дә бу юлы секундларны «хуп, хуп, хуп»,—дип саный төсле тоелды аңа.

—Одессада квартира табу кыен түгел. Данәгөлне квартирага урнаштырырмын. Ремонт вакытында көн саен ярга чыгып йөрермен. Аннары инде миңа хезмәт итәргә дә күп калмый. Мин Данәгөлемне үзем белән крейсерга алырга булдым.

Кияүләренең бу вариантны барып чыгармы, юкмы икәнен күз алларына да китерми, әмма авызларын ачып тыңлаган Ногайбәк ага белән Фәйрүзә апа шып тын утыра бирделәр. Таһир, уң як кочагына сыенып утырган Данәгөлгә иелеп карагас, аның күзләреннән тәгәрәп-тәгәрәп яшь ага.

—Юк, юк, кадерлем. Бу вариантка мин риза түгел,—дигәндәй башын кире кагып селекте. Аннары ике күзен ике кулы белән каплап, сулкылдавын тыеп үз бүлмәсенә кереп китте.

—Саубуллашу киче берәүгә дә җиңел түгел. Әйдә, күтәрик берәрне,—дип кыстады кияүвен Ногайбәк ага, рюмкасын кулына ук тоттырды. Берне дә, икене дә тоттылар бугай. Шөһрәт ага үзе еш кына Фәйрүзә апага карап ала. Анисының тирән шөбхәгә төшүе йөзенә чыккан... Үзе «Аллага тапшырдык, Аллага тапшырдык»,—дип кабатлый. Йокы бүлмәсенә кияүләрен икәүләп

кертеп салдылар төсле. Бу кадәресе Таһир колагына да ягылдымы шунда?

Нидер пышылдаган Фәйрүзә апаны Ногайбәк ага:

—Әнисе, бер дә борчылма, бары да тәртиптә, нәкъ без дигәнчә булыр,—дип тынычландырды бугай әле.

***

...Таһир уянып китте дә, корт чаккан тизлек белән, сәгатен күзләренә китерде. Үзләренең Чистай сәгать заводында эшләнгән, карангыда да яхшы күренсен өчен циферблатлары фосфорга манылган «Командирский» сәгате. Армиягә киткәндә дус егетләре бүләк иткәннәрие. Циферблатка күз салу белән эче жу-у итеп китте. Ул бит, чү әле, чү, тәүлектән артык йоклаган. Бу верандага ничек кереп ятканын да хәтерләми. Коньякны да алай күп эчмәделәр бит. Ул бит күптән крейсерда булырга тиеш. Нишләп соң ул монда ята?

Таһир сикереп торып басуга, верандага, бөтен тулы йөзенә елмаеп, кояш булып балкып, Фәйрүзә апа килеп керде.

—Хәерле иртә, Таһир улым. Ай-һай! Йоклап та күрсәттен бер ичмасам. Тукта, бу баланы уятырга вакыт түгелме, дип ничәләр кердем янына. Нарасый балалардай татлы йоклавына сокланып, аяк очыма гына басып, уятмыйм тагын дип чыгып китәм. Йокласын, балакаем, йомшак түшәгемдә, дим.

Таһир торып баскан көенә, кинәттән башы әйләнеп китеп, янә караватына ауды. Башының чатнавына түзәр хәле юк. Бу нидән шулай? Башы нидән шулай чатный? Гомердә шулай озак йоклаганы юк иде анын. Чү?! Йоклата торган дару эчергәннәр түгелме соң аңа? Махсус! Карабына бармасын, сонарсын өчен түгелме? Йоклата торган дару! Коньякка кушып!

Таһир янәдән сикереп торып басты. Киемнәре кая соң? Кичтән баш очына гына салган иде төсле. Аларны кем алган инде тагын? Әллә яшереп үк куйганнармы?

—Кая минем зюйд-весткам? Чалбарым кая?

—Абау, улым! Менә шушында гына иде бит. Әллә тан алдыннан гына урлап чыкканнармы, Ходаем? Веранда ишеге төне буе ачык булды. Урлап чыгулары да ихтимал,—дип Фәйрүзә апа канатларын як-якка жәйде.— Совет матросларының формасыннан кем дә баш тартмас. Мөгаен урлап чыкканнардыр. Вәт бәла. Нишләрбез инде, Ходаем?

Таһир торып басуга верандага кояш булып елмаеп Ногайбәк ага килеп керде.

—Икебез дә чын йокы чүлмәкләребез икән бит, улым Таһир, ишкәнбез генә йокыны. Әмма харап булганбыз бит. Карабына кайтырга тиешле сәгатенә син нәкъ бер тәүлеккә сонардын. Анда юл ябык хәзер сина. Анда сине трибунал көтә. Яхшысы—барып күзләренә күренмәү. Кулларына эләксән, башкалар өчен гыйбрәт булсын, дип асарлар да куярлар. Халыкара хәлнең бик киеренке чоры бит. Марсель портына совет крейсеры дуслык визиты белән килде дип кенә, халыкара киеренкелек йомшарса икән. Һәр ике як лагерьның да, куеннарында таш йодрыкланган куллары кесәләрендә. Бер-берләренең маңгайларына тамызырга ипле жай чыкканны гына көтәләр, улым.

Берни булмаган сыман итеп, Ногайбәк ага борынын тартып алды.

—Карабка кайтмаганыңны бәлкем сизмәгәннәрдер дә. Крейсерын да якорен күптән күтәргәндер. Ят, улым. Хәзер тынычлап ял итсән дә була.

—Сез! Сез! Беләсезме кем сез?—дип буылды Таһир. Бу минутта ул Ногайбәк аганы чак кына бугазыннан буып алмады.—Сезне шундый мәкерле, әшәке, хыянәтче жан булыр, дип башыма да китермәгәнием. Сез бит потенциал жинаятьче! Мина сез йоклаткыч дару салган эчемлек биргәнсез. Әгәр шуны

сизгән булсаммы? Мин аны сезнең оятсыз йөзегезгә сипкән булырыем. Мине хәзер үк карабыма илтегез! Ишетәсезме, хәзер үк!

Веранда ишегенә Фәйрүзә апа белән Данәгөл кереп сөяльделәр. Ах, Данәгөл, Данәгөл! Таһирнын, атылган йолдыздай кыска мәхәббәте! Таһир килеп аны кочагына алды. Күңелен биләгән тиндәшсез сагышы анын йөзенә чыккан, гөл булып сулган...

—Әгәренки... Әгәренки.... Крейсерым киткән булса, мин анын артыннан диңгезгә ташланачакмын. Колач салып куа чыгачакмын.

Таһир әйтер сүз тапмый, иренен чәйни. Ике кулы да йодрыкланган.

—Әгәр хәзер үк карабыма илтеп куймыйсыз икән, беләсезме нишлим? Ни кылырга аптырап, икеләнеп калыр дип уйласагыз, ялгышасыз. Зинһар мәҗбүр итмәгез. Юкса, өегезне шартлатам, көлен күккә очырам. Минем өчен ул берни түгел. Минер икәнемне беләсез, бу йортны күккә күтәрү минем өчен бер шырпы сызу белән бер. Көтәм! Әгәр киемнәремне бирмәсәгез, шушы килеш, трусиктан гына чыгып чабам. Юк, башта өегезне шартлатам.

Ногайбәк ага ым какты.

—Менә сәнә алар...—дип Фәйрүзә апа киемнәрне кертте.—Таушалмасыннар дип үзем күрше бүлмәгә чыгарып куйганыем...

—Ярар, улым, кадерле киявем, тынычлан бераз,—диде Ногайбәк ага кулы белән ишарәләп.—Белдем, белдем, күнелем белән сиздем, сине ничек тә сындырып булмасын. Кичер син мине, берүк кичер. Шайтан котыртты бит, шайтан... Эчертеп йоклатып кара, карабына сонга калсын, калырга бәлкем шулай күндерерсең, дип котыртты. Булмады. Тынычлан, карабына хәзер илтәбез. Теләсәң нишләт улым, үземне синең хөкемеңә тапшырам... Мин гаепле... Кичерә алсаң, кичер.

Шунда ул, Таһирны бөтенләй коралсызландырып, елап җибәрде.

—Бар халәтем белән аңлыйм мин сине, комсомолец киявем, улым,—дип елады.—Шушы хәлләрдән соң, син миңа тагын да якын. Безне, ирләрне, бу сыйфатыбыз зур кыенлыклар алдына бастыра, хәтта хурлыкка төшерә, бәхетсез итә. Әмма биргән сүзеңне тоту, хыянәткә җирәнеп карау, чын ирләрне бизи, Олимпия биеклекләренә күтәрә торган иң изге сыйфатларның берсе. Алдагы гомереңдә дә шундый булып кал. Мин сокланам сиңа. Холкың, ихтыярың корычтай нык. Мәхәббәт тә җиңә алмады, байлыгыма да кызыкмадың. Биргән сүзеңә, антына тугры калдың. Соклангыч егет син, Таһир улым. Әмма бәхетсез. Берүк күңелеңә авыр алма, бәхетсез син. Әй-й-й, үкенерсең әле бездә калмавыңа. Бер генә түгел, мең-мең тапкырлар. Әмма соң булыр. Ны-ык, ай-й-й, нык үкенерсен. Ә хәзер башта ванна кер, юын, үзеңне тәртипкә китер. Аннары бергәләп саубуллашу чәе эчәрбез дә, Аллага тапшырып, юлга чыгарбыз... Берүк өемне генә шартлата күрмә,— диде ул елавыннан туктап, бераз гына елмая төшеп.

—Тагын алдарга ниятлисезме? Сезнең өстәлегездән мин ачка үлсәм дә тәгам ризык кабачак түгел. Не выйдет! Киемнәремне генә киям дә, бер минут та тоткарланмый юлга чыгам.

Ишеккә таба атлаган Ногайбәк ага кире борылды:

—Син минем өемне шартлатам дип янагач, диңгезгә чыккан карабыңны колач салып куарга җыенгач, үзең уйлап кара, синең чәеңә йоклаткыч салудан миңа нинди файда? Файда юк. Язмыштан кем уза алган? Матур гына итеп саубуллашу чәен эчәрбез, мәңгелек туганнар булып саубуллашырбыз. Кем белә, алда безгә күрешергә язгандырмы, язмагандырмы? Анысын Алла гына белә. Алай да өмет дигән нәрсә бар бит әле. Адәм баласын шушы өмет дигән нәрсә яшәтә. Син бер нәрсәне күңелеңә киртләп сеңдер, җир шарының менә шушы почмагында, Марсель каласының матур бер бистәсендә, сине өзелеп сөйгән ярың, аның әти-әнисе барын онытма. Сине

бу йортта өзлексез көтәчәкләр, кайчан гына килеп чыксаң да, сагынып каршы алачаклар. Бу турыда беркайчан исеннән чыгарма, улым. Бу теләк сина яшәргә көч, өмет бирсен!

Әтисе әлеге сүзләрне, теләкләрне бер җепкә тезгәндә, «әйтәсе сүзләребезне без инде әйтештек, вәгъдәләребезне бирдек»—дигәндәй, Данәгөл Таһирга төбәлеп, чак кына елмаеп, сүзсез утырды. Шәһрәт агай, каршыдагы сервантны ачып, аннан кечкенә бер тартма чыгарды. Аны Таһирга сузды.

—Матур бер истәлек булсын! Сакла!—диде. Тартма эчендә беренче классны кул сәгате. Швейцариянең иң атаклы фирмасында эшләнгән.

—Яле, кулына үзем тагыйм,—дип сәгатьне Данәгөл алды.—Сәгатьнең телләрен Париж вакыты белән куям...

—Баштарак бераз кыенрак булса да, моннан соң мин Париж вакыты белән яшәргә тырышырмын,—диде Таһир.—Рәхмәтем бу нигезгә чиксез.

Тагын нәрсә әйтә алсын соң инде хәрби хезмәттәге матрос?!. Бәйдәге эт белән бер бит...

Берәр сәгатьтән алар өчәүләп Марсельга таба юл алдылар. Фәйрүзә апаны да алмакчы иделәр. Кая ул! Аерылышу кайгысыннан ул бөтенләй авыруга сабышты. Ә Таһирның иптәш егетләренә дигән күчтәнәчләре ике кәрҗингә чак сыешты.

—Алмыйм, алмыйм. Бу кадәрле әйберне карабка кертмиләр. Ул бит хәрби крейсер,—дип Таһир карышмаса, күчтәнәчләрне тагын да төягән булырлары әле.

Портка җитәрәк өч-дүрт чакрымнар кала, Данәгөл машинаны туктатуны сорады. Диңгез яры буйлап, серпантин булып менәле-төшәле сузылган бетон трассаның иң биек ноктасы бу. Бу тарафлардан узгынчыларны үзенә чакыргандай ым кагып ниндидер үҗәт кыюлык белән диңгез эченә керергә кыюлык иткән биек гранит кыя каршында туктадылар.

—Минем бит яраткан кыям бу. Биредә еш булам. Диңгез күренешләрен ясарга идеаль иппе урын. Еш кына буяуларымны, планшетларымны да күтәреп килгәлим,—диде Данәгөл. Алар җитәкләшеп, кулга-кул тотышып, кыя очына таба атладылар. Аерылышу сәгатенең соңгы минутлары якынлашты. Шундый чакларда өзелеп сөюенне, вәгъдәләреннең мәңгелек булуын тагын да тирәнрәк, мәңге тутыкмаслык итеп ничек җиткерергә?

—О-о, моннан бөтен әйләнә-тирәгә, еракка-еракка искитмәле панорама ачыла икән!—дип сокланды Таһир, Данәгөлне кочкан хәлдә.—Иске Гавань нәкъ уч төбендәге төсле күренә.

Әйтәсе саубуллашу сүзләре әйтелгәндер дә инде. Аларның барын да әйтеп бетерү мөмкинме соң?.. Таһир бердәнберен, кара карлыгачын, нечкә билен бөтереп алып, янә һәм янә күкрәгенә кысты. Башын башка, маңгаен маңгайга, кашын кашка терәде. Икесе дә тынсыз, сулышсыз калдылар. Тик йөрәкләре генә дөк-дөк тибә.

—Эре кочагымда, карлыгачым! Барың белән син, сиң мина, бөтенләйгә сиң!—дип пышылдады ул.—Булса иде шушы минутларда пар канатың, очсаң иде сөйгән ярың белән күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләргә, йолдызларга, киң галәмнең иң түренә.

—Крейсерың ә-ә-ә-әнә!—диде Данәгөл Таһир кочагыннан арына төшеп. Тора. Китмәгән. Сине көтә,—бу сүзләрен ул йөрәк өзгеч сыкрау, ыңгырашу белән әйтте.—Кичә син тау батыры йокысы белән йоклаганда, кадерлем, мин бирегә ике тапкыр килеп киттем... Көтелмәгән тайфуннарга юлыкканда да, аның өстенә өерелеп-өерелеп цунамилар ябырылганда да, аның батмавын, үз ярына, киткән портына исән-сау кайтып якорь салуын теләдем. Чөнки ул синең карабың. Ул карабта минем бердәнберем. Ә бүген мин шушында калам. Крейсерыңа әтием илтер. Сине крейсерыңа илтәчәк

катерга утыртканда үземне тыеп тора алмам, бөтенләйгә сыгылып төшәрмен төсле. Ул хәлгә үк төшәсем килми. Ирләрен дингезгә озатучы хатыннар аны яхшыга юрамый.

—Сөйгәненнен, иреннен, бердәнбереннең исән-имин әйләнеп кайтуын теләсәң, суырып үп тә, елмаеп озат, диләр алар. Ә мин бу кыя башына моннан соң һәр көн килермен... Сине көтәрмен...

Таһир Туктамышев башына бу мәхәббәт уйламаган, көтмәгән җирдән генә тайфун, цунами булып ишелде. Әле кайчан гына җаны ничек тыныч иде. Ә хәзер менә үзен кая куярга белми. Ничек аерылсын соң? Ничек аны ташлап китсен? Йөрәге ярылырлык булып тибә.

—Крейсерыгыз бүген-иртәгә кузгалырмы, әллә ике-өч көн торырмы. Шушы кыя башында яулык изәп торган бер силуэт күрсәң, ул мин булырмын, Таһир. Крейсерыңның капитан күперчегенә күтәрел дә, син дә яулык изә. Мин дә сине төсмерләрмен, күрермен. Исән-имин икәненне белермен. Өзелеп юксынуыма дәва булыр...

Данәгөлнең өстендә кура җиләге төсендәрәк бик матур, җинел ефәк җилән. Башында чиста күк йөзедәй зәп-зәңгәр берет. Таһир аннан баш ярымга калку. Күбәләгең кочагына ала да аннары кая бастырырга, кая куярга белми. Мөмкин булса, куенына гына төреп тыгар иде күк күгәрченен.

—Таһир, акыллым, белеп тор, бу кыя башына мин һәркөн киләчәкмен. Безнең якларга янадан килеп, мине кабат үз кочагында кочканчы... Көтмәгәндә генә юлыккан саф бәхетебез бик кыска гомерле булды. Кал, дип тә әйтмәдем. Калмавына да үпкәләмим. Мин барын да аңлыйм. Син хәрби кеше. Антын бозучыларга мин үзем дә җирәнеп карыйм. Синнән шуны гына үтенәм. Син онытма мине. Ә мин сине мәңге-мәңге көтәчәкмен. Тормыш сине бик кыен хәлләргә төшереп сынаганда да, сыгылып төшмә, дөньяда сине өзелеп яраткан һәм сине өзелеп көткән бер җан—хатының, Данәгөлең, мин бар. Тагын нәрсә әйтим, бәгырем, ике күз алмам. Шушы сүзләрем сиңа юл догам булсын, сине һәрчак хәвеф-хәтәрләрдән сакласын. Мин сине мәңге-мәңге көтәчәкмен. Бәлкем хәрби хезмәтең тулгач килә алырсын. СССР хуҗалары үз кешеләрен чит илләргә бик җибәрмиләр бугай алар. Безнең Франциядә Россиядәге революциядән соңгы эзәрлекләүләрдән качып киткән бәхетсезләрнең чуты юк. СССР хуҗалары аларны кире кайтарырга да теләми кебек. Гәрчә араларында кайтырга теләүчеләр байтак булса да. Әмма икебез ике система гражданнары булсак та, бәхетле булырга безнең хакыбыз бар. Без бәхетле булудан кемгә зыян? Кемнең укасын коябыз, шулай бит, кадерлем?... Минутларның санаулы икәнен икесе дә җаннары, тәннәре белән сизәләр.

—Флотта хезмәтемне тутыру белән мин сине килеп алырмын. Барып кермәгән Ак йортым, шакымаган имән ишегемне калдырмам. Сине килеп алырга рөхсәтне алмый калмам!

Таһир Данәгөлнең үзенә бер якын, татлы хуш ис бөркегән толымнарын учына алды. Аларны күкрәк алдына китереп, үбеп-үбеп битен сыйпады.

—Килеп алсам, бу толымнарыңны әче катык белән юып үзем тарармын, үзем үрермен әле, кошчыгым.

Бу иртәдә дингез өсте тып-тын, йөгерек дулкыннар гына уйнаклый. Рейдта күренгән судноларның чуты юк: хәрби эсминецлар, сәүдә караблары, балыкчы шаландалары, баркаслар, җилкәннәрен салындырган мачталы спорт яхталары. Шулар арасында аерым акватория биләп, ерактан ук совет крейсеры «Сергей Киров» күренеп тора. Аның шулай айкалмый-чайкалмый, исән-имин торуы сөендерә дә, бераз чытайта да. Аның палубасына басу—аерылу. Шунда соң, баткан булса, йә Торпедо аткан булсалар, аерылу сәгате беразга булса да чигерелер иде...

—Ә мсье Сергей Кировны ни өчен үтергәннәр?—дип Данәгөл Таһирны уйларыннан бүлдерде.

—Бу сорауга бүген дә кисеп кенә җавап бирүче юк.

—Дошманнары күп булды микәнни?

—Безнең илнең үткән юлы нык сикәлтәле. Моңарчы беркем аяк басмаган кара урманнар аша узган хәвеф-хәтәрле еллары да булган. Аннары Бөек Ватан сугышы. Бу яуда без илле миллионнан артык халкыбызны югалттык. Бәлки шуна да, алда узачак юллары тагын да сикәлтәле булачакка без аны өзелеп яратабыздыр. Бөек совет халкы прогрессив кешелек дөньясының хыялы Коммунистик җәмгыять төзи...

Данәгөл, урамда озак вакытлар адашып йөреп, тәмам ачыгып, салкын янгырга чыланып, шунда кемдер күтәреп алган песи баласыдай тынсыз калып Таһир кочагына сеңде. Үзе аңа китәргә кирәклеккә ым кага, үзе җибәрми. Таһир кочагыннан башын гына чыгарып:

—Менә шушы кыя түбәсенә һәркөн килеп, иске Гаваньга кергән барлык карабларны яулык изәп каршылармын. Якты өмет белән. Кем белә, көннәрнең берендә, шуларның берсендә син килеп чыгарсың. Килерсең бит, Таһир?

Күтәргәме сине? Тәнемдә җаным бар чакта мин сине күтәчәкмен, җаным...

Аста, өзек-өзек итеп, машина кычкыртты. Таһир башыннан бескозыркасын салып, Данәгөлгә киертте. Аның башыннан зәңгәр беретын алып, дүрткә бөкләп, куенына тыкты. Соңгы тапкыр аны иреннәреннән үпте...

Машина тагын өзек-өзек сигнал бирде. Аерылышу минуты... кичектергесез сукты. Монда, кыя түбәсендә беркадәр җиләс. Данәгөл куеныннан ап-ак ефәк шарф чыгарды. Аны Таһир муенына салып:

—Минем истәлегем ит, керләндермә, саклый күр, бәгърем. Мине бик сагынганда аның белән серләш, аны коч,—диде.

Таһир арты белән чигенә-чигенә машина янына төште. Туйганчы бер кочарга, бар булган тән җылысын, күңел җылысын татырга өлгермәгән җан сөйгәнең белән билгесез срокларга аерылуны дошманына язмасын. Крейсер пушкаларының йөз егерме килограммлы снарядларын кулында уйнаткан егетнең тез буыннарына хәтле йомшады. Бөтенләй шәлперәеп китүдән куркып, сүзсез генә машинаның арт бүлегенә утырды. Ногайбәк ага аны портка, контроль-уздыру пункты төбендә торган кысыграк күзле, ач янаклы старшина егет алдына китереп төшерде. Фәйрүзә апаның, кияве белән бергә хезмәт иткән егетләргә дигән кәрҗин-кәрҗин күчтәнәчләрен әлеге егет алдына куйды.

Ногайбәк ага, сүзсез-нисез генә, Таһирны иннәреннән алды, күкрәгенә кочты. Көч, кодрәт менә кемдә икән ул! Кара дингез хәрби флоты матросының тыны кысылгандай булды. Текәлеп, нииндидер ялварулы өмет белән законлы киявенең күзләренә төбәлде.

—Бердәнбер кызымны, Данәгөлемне ихлас сөю белән кочтыңмы, комсомолец?

Таһир, берни аңламый, сүзсез тора.

—Бүтән әллә күрешәбез, улым, әллә юк... Әйт, ыруымны дәвам итәргә оныгым булырмы?

—Улым булырга тиеш!—диде Таһир икеләнмичә дә.—Ант итеп әйтәм, дөнья икегә ярылса да, улымны күрергә, аны үчти-үчти итеп күккә чөяргә мин бу җиргә кабат аяк басачакмын... Дөньясы икегә ярылса да... Дөньяның бер гүзәле, сезнең кызыгыз Данәгөл—минем никахлы хатыным, бердәнберем. Сез дә ага түгел, әтием сез минем. Минем улым туачак. Баламны саклый күрегез!

Таһир бу юлы үзе кочагына алды Ногайбәк аганы. Саубуллашты да, приста чайкалып торган кизү катер палубасына сикерде. Катер аны

крейсерына алып китте. Моңарчы бернигә бирешмичәрәк торган Ногайбәк ага, янәдән тезләренә тезләнде, кесәсеннән яулык чыгарып, Таһир күздән югалганчы аны болгап торды.

Тау башында таш тегермән,
Чи бодай тарта микән?
Егет үзе картаймаса,
Дөнья картайта икән...

Көтмәгәндә өстенә ишелгән бәхет, башына төшкән тирән сагыш турында командирына сөйләргә бик исәбе бар иде Таһирның. Олы, киң күңелле капитаныбыз мине аңлар, хәлемә керер, акыллы киңәшен бирер, дип уйлаган иде.

—Иптәш 1 нче ранг капитаны, 1нче статьлы матрос Таһир Туктамышев сез ярга җибәргән кыска сроклы ялдан кайтты!—диюенә, капитан Соболь аны бүлдереп:

—Кайтып та җиттегезме, Таһир?! Вот молодец! Хәзер үк үз вазифаларыгызны үтәргә керешегез!—диде.

—Есть!—диде Таһир, честь биреп...

Бу көнне крейсер үз палубасында, дөньяда иң дәрәҗәле һәм иң өлкән уку йортларының берсе Сорбонна университеты студентларын каршыларга, кунак итәргә тиеш иде. Студентлар гомер-гомергә шулай: алар үзләрен җәмгыятьнең иң алдынгы, иң прогрессив көчләренә санап, хәтта үзләре яшәгән чорга, аның тәртипләренә каршы оппозициядә булалар.Чөнки яшьлек җәмгыятьнең үзеннән дә яңалыклар таләп итә. Бу очрашу крейсер коллективына да зур җаваплылык йөкли. Мондый мәшәкатьле көндә хәрби караб командиры Собольдә кыска сроклы ялдан кайткан матрос Таһир Туктамышев кайгысымы? Аның ярдан тәүлек ярымга соңарып кайтуын белгән, сизгән, исәпкә алган кеше дә булмады, дип нәтиҗә ясарга өлгергән иде инде егет. Вәләкин... Алай булып чыкмады шул...

Французлар беренче классы совет хәрби карабы палубасына бераз шикләнебрәк аяк бассалар да, хуҗаларның эчкерсезлеген күреп, тоеп, соңыннан үзләре дә шалтырап ачылып китәләр. Шаяралар, автографлар алалар. Үзләре дә кунакка чакыралар. Совет хәрби морякларының бу визит белән килеп чыгуларын хуплыйлар. Гомерендә телен әйләндереп бер русча сүз әйтмәгән французлар да карабтан киткәндә:

—Дружба! Дружба!—дип кабатлый.

Әмма дошман көчләр дә, мыж килеп торган ярга япа-ялгызы киткән матросның кая китүен, кайчан кайтуын белеп, тикшереп торучылар да бар иде. Ничек булмасын ди инде?! Капитан-лейтенант Штанько карабтагы һәр матросның башында нинди уй-фикер барына кадәр белеп тора иде. «Личное дело матроса 1-ой статьи Туктамышева Т.» дигән папкага, аның крейсердан кайчан китүен һәм ничә сәгатькә соңарып кайтуын ул минуты-секундына кадәр теркәгән иде. Карабның арткы өлешендәге күзгә әллә ни чалынмый торган кечерәк кенә каютасына Таһирны дәшәргә әле вакыты түгел. Визит тәмамлангач, кайтыр юлга курс алгач та өлгереп була...

*Беренче китап тәмам*



Нур
Әхмәдиев

# ШӘМ КАБЫЗАМ

***

*Дөнья якты булсын дисәң,*
*үз өеңдә шәм кабыз.*
Ризаэддин Фәхреддин

**Чишмәләрнең җыры илһам бирә,**
**Кошлар сайравыннан моң алам.**
**Бәрәкәтле үткән көннәремә**
**Алтын тоткан төсле куанам.**

**Куанычтан кошка җимнәр сибәм,**
**Чүпләсеннәр, әрәм булмасын.**
**Игелекләр кылу—фарыз гамәл,**
**Без онытмыйк халык йоласын!**

**Күңелләре китек күпме җаннар**
**Нәүмиз, мохтаҗ җирдә—яхшыга.**
**Утырыплар уйлар уйлый калсаң,**
**Аяз көнне күздән яшь чыга.**

**—Борчуларың бармы?**
**Җиңеләйтик!—**
**Белешәләр дуслар хәлемне...**
**Дөнья якты булсын, шуңа күрә**
**Кабызам мин көн дә шәмемне.**

**Шәм кабызам, чырага ут эләм,**
**Бар дөньябыз нурга төренсен.**
**Исәннәргә яңа шатлык бирсен,**
**Хасталары чирдән терелсен.**

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946)—*шагыйрь, прозаик; күпсанлы китаплар («Аһәң», «Амбирак», «Абага чәчәге» һ. б., шул исәптән 4 томлык «Сайланма әсәрләр») авторы. Әлмәттә яши.*

Шәм яндырам һәрбер җырым белән,
Күңелләрдә кояш кабынсын.
Һәм кешеләр бары яктылыкка,
Яхшылыкка гына табынсын!

***

Бүген тагын күзне йокы алмый,
Сәбәбе дә юк бит югыйсә:
Нечкә билле ай елмая күктә,
Назлап кына талгын җил исә...

Йолдыз белән йолдыз күз кысыша,
Былбыл сайрый тәрәз төбендә:
Күпме гашыйк тәү кат аңлашкандыр
Җәйнең шушы сихри төнендә!

Әнкәсенең хәләл күкрәк сөтен
Күпме сабый тәмләп имгәндер...
И илаһи мизгел!
Шайтанилык
Бу минутта тәмам сүнгәндер.

Болар бар да гел сөенеч өсти,
Пәрдәләрен ача күңелнең...
Инде белдем: чиксез бәхетемнән
Йоклый алмыйм икән бүген мин!

## Бүгенгебез

Менә тагын үткәннәргә кайттым,
Төштә генә кайттым, өндә түгел.
Туксанынчы еллар бимазалый,
Әле ярый, шөкер, көн дә түгел.
Бик болгавыр көннәр уздырдык без,
Куллар чаптык, хәтта сызгырдык без.
Киләчәккә өмет белән карап,
Мәйданнарда канны кыздырдык без.
«Азатлык!» дип оран аз салмадык,
Йөзләр генә түгел, меңнәр идек.
Түрәләр дә йөрде арабызда,
Барыбыз да тигез, тиңнәр идек.
И айкалды дөнья, әй чайкалды,
Гамәлләрне Мәскәү ошатмады.
—Без—бәйсезләр!—диеп куансак та,
Дилбегәне бер дә бушатмады.

Алданганны соңлап аңладык без:
Кол хәлендә һаман көн күрәбез.
Мәскәү кушса гына җыр җырлыйбыз,
Тик Мәскәүчә генә йөткерәбез.
«Бәйсез» сүзе Мәскәү үтен сыта,
Кәгазьләрдән хәтта алдыралар.
Татарымны кабат илсез, телсез
Бер эш аты итеп калдыралар.
Үткәннәрне сагынырга ярый,
Тик яшәргә мәҗбүр чынбарлыкта.

Ә Хакыйкать ачыкламый калмас:
Кайда өтер кирәк, кайда нокта...

Дисбе урынына тезгән идем, юкса,
Уйлар тузды, фикер чияләнде...
Безнең хәлдә тагын ни көтәсең:
Якын тора йөрәк өянәге...

## Хакыйкать

*Адлер Тимергалинга*

Кешеләр гомере буена
Тырышкан Чынлыкны аңларга.
Аңлыймы—ачык тик Аллага,
Кирәкми үзеңне алдарга...

Хакыйкать—синнән бик еракта
Һәм якын—әйләнә-тирәңдә.
Чык булып ялтырый иртәнге
Энҗеләр сибелгән чирәмдә.

Хакыйкать—аналар сөтендә,
Нарасый сабыйлар күзендә.
Гасырлар буена чарланган
Иманлы дастаннар сүзендә.

Хакыйкать—әчсе суында,
Ташлары чаларган зиратта.
Кояшны сеңдергән икмәктә,
Хакыйкать тормый ул чиратта.

Хакыйкать—диңгезләр шавында,
Нурланып балкый ул күкләрдә...
Хакыйкать—син үзең икәне
Ачылмый кала тик күпләргә...

## Монафикъ

Халык әйтсә, биткә бәреп әйтә,
Халык акыллы ул, тапкыр, зирәк:
Тугры юлга өндәп йөрер өчен,
Үзеңә хак, чиста Иман кирәк.

Бушбугазга кытлык булганы юк,
Шайтанны да үзенә каратырлар:
Үткәннәрнең кыдрач парткомнары
Мәчетләрдә бүген ораторлар...—
Теле телгә йокмый вәгазь сөйли
Пәйгамбәрнең Үзе исеменнән...

Монафикъка тыныч карап булмый:
Тутык исе килә җисеменнән.
Җил уңаен тойган «сизгер» затлар,
(Кире кайта калса «тегe» заман)
Тәсбихләрен кабат чөйгә элеп,
«Коръән»нәрен утка ягар тәмам...

## Әсәй каргалары

И авылым каргалары!
Шундый сагындырдыгыз,
Сүнеп барган сагыш утын
Кабат кабындырдыгыз.

Кемнәрдер сезне яратмый,
Ә миңа сөйкемле сез:
Бала чактан бергә үскән
Дусларым шикелле сез.

Чикмәнегез шундый затлы—
Монахлар кызыгырлык...
Сезгә карап тору рәхәт,
Үзе бер зур хозурлык!

Бер гөнаһсыз димим сезне—
Чебиләр алгалыйсыз.
Нишлисең шулай яралгач—
Тумыштан карга бит сез!

Һавада чыр-чу киләсез,
Утырышасыздыр шул:
Дума депутатлары кебек,
Котырышасыздыр шул.

Сезнең дә бардыр арада
Берәр Зюгановыгыз.
Жириновскийдан да артык
Кайчак кылануыгыз.

Күңелсез түгел миңа һич
Авылымда сез барда...
Шәһәр каргасы каргамы,
Әсәй каргасы—карга!

***

Туган җир!
Аллар-гөлләргә
Сине мин алыштырмам.
Син—җырымның иң моңлысы,
Мәңгелек сагыш сыман.
Синнән оҗмахка керергә
Бер генә карыш сыман.

И туган җир!



Адлер
Тимергалин

# КАРУРМАН АША...

ХЫЯЛЫЙ КЫЙССА

*... яхшы атлар кирәк үтәргә*

Зал ягында борынгы сәгатьнең карлыккан, тутык тавыш белән унбер тапкыр озаклап-озаклап сукканы ишетелде. Соңгысын суккач та әле колак төбендә металл чыны зеңләп торды, һәм инде тутыктан арынган бу нәзек чың дулкыннары ике йөз яшьлек җиз сәгатьнең үзе кебек саргылт төтен булып талгын гына каядыр ерак-еракларга—үткән мизгелләргә, әллә соң киләчәккә табамы?—сузылып, нечкәрә, җуела бара иде.

Менә моңлы аваз һавада эреп тәмам юкка чыкты, өзелде, сүнде...

—Багалмам, бүгенгә җитәр... Сиңа күптән инде йокларга вакыт,—диде әнисе һәм китап укып яткан малайның кулындагы йомшак ялтыравык тышлы, ләкин саллы математик журналны, ачык килеш тотып, сак кына өстәлгә алып куйды.—Йокла, улым, әнә күзләрең дә кызарган...

Аннары ул малайның җиңел юрганын рәтләбрәк япты, яшь математикның тынлаусыз чәченнән сыйпады да, караватт янындагы яшькелт торшерны сүндерде.

Һәрвакыттагыча, әнкәсенең җылы, йомшак кулы малайга гипноз шикеллерәк тәэсир итте. Самими бәхете тулып ашканга, йоклап киткәч тә аның иреннәре елмая иде.

Чыннан да бәхетле иде ул. Гаиләдә бер бөртек бала булганга, аны, бәлки, артык иркәли дә торганнардыр, ләкин укуга һәм белем эстәүгә бирелгән малайны әти-әнисенең назы бозып өлгермәде, һәм ул дөнья рәхәтләренең азы белән дә канәгатьләнә торган бала булып үсте.

Кыскасы, ул вафасыз дөньяда җил-янгыр тимичә, мәрхәмәтсез урам тормышының камчысын да, тукмакларын да күрмичә, тәмсез сүзләрен ишетмичә, җылы оранжереяда, чәнечкесез гөлчәчәкләр һәм купшы пионнар

Адлер ТИМЕРГАЛИН (1931) — *язучы, фантаст, энциклопедист; «Пәһлеван кабере», «Ерак планетада», «Космостан кунаклар», «Таш алиһә», «Җиде юл чатында» һ. б. күп кенә китаплар авторы. Г. Исхакый исемендәге әдәби бүләк лауреаты. Казанда яши.*

арасында үскән самими һәм тыйнак малай иде. Дөрес булса, педагоглар андыйлардан көрәшче чыгуы икеле дигән булалар...

Хәер, тугыз яшендә инде малай шахмат буенча район мәктәпләре чемпионы булды, аннары кинәт кенә математика белән мавыгып китеп, шахмат уеныннан бизде. Дөрес, ташлап ук бетермәде, чөнки ул, бу уенның катлаулы математик һәм логик мәсьәлә булуын аңлап, аны бер читкә куеп, киләчәккә калдырып кына торды бугай. Шулай да малай, баш мие гимнастикасы өчен, көндәлек газитләрдәге төрле шахмат мәсьәләләрен чишмичә барыбер тынычланмый иде.

Малаебыз ниндидер төш күреп ята иде. Менә аның иреннәре дерелдәп куйды, кашы җыерылды... Аннары ул, ике кулын да юрган астыннан чыгарып, учлары белән битен һәм болай да йомык күзләрен тәрәзәдән төшеп торган салкын ай яктысыннан каплады...

Юк, малаебыз татлы төш күрми иде шикелле. Менә ул бәләкәй йодрыкларын буыннары агарганчы йомарлады, битләре, иреннәре тартышып куйды... Аннары ул күзләрен ачып, башын күтәрде дә, торып ук утырды.

Бу минутта аны әнисе күрә калса, һичшиксез, коты алыныр иде, чөнки баланың күзләре, ак төшкәндәй, тоныкпәрдә белән өртелгән һәм әйләнә-тирәне күрми, аңламый иде кебек. Ул һаман йокы кочагындамы әллә? Әллә инде лунатиклар кебек йокы аралаш торып йөри башлаганмы?

Малай бүлмәдә ут алып тормады. Караңгым агачлар өстендә түбәнтен генә күренгән ай яктысы аңа җитә иде, күрәсең.

Менә малай урындык аркасындагы чалбарына үрелеп, караватында утырган килеш, берьюлы ике балагына чумды, торып, кыска җиңле күлмәген, оекбашын, калын табанлы спорт ботинкасын киде. Өстәл өстендәге кечкенә рамкадан әтисе белән әнисенең үзе төшергән фотоларын кубарды да, кәгазьгә төреп, бөгәрләмичә генә түш кесәсенә урнаштырды, аннары, бераз уйлап торгач, калын математика журналы эченнән күрше дачада яшәүче Ниса исемле бер кызчыкның рәсемен дә алды. Ниса аңа һәрвакыт: «Әй син, вундеркинд!»—дип дәшә һәм, җае чыкса-чыкмаса да, үртәргә тырыша иде. Малай исә, күпме генә эзләмәсен, күрше кызына төртке кушамат таба алмыйча гаҗиз иде. «Алтынчәч»не кушамат дип булмый ич инде! Алай дигәч, кызый алтын толымын уң җилкәсеннән сул якка гына күчерә, үзе рәхәтләнеп көлә... Гыйлемдарга соңыннан бөтен мәктәпкә таралган «Малай-Нигалай?» дигән кушаматны да шушы күрше кызы таккан иде. Аннары Ниса ике көннең берендә күршеләренең почта ящигына берәр шахмат мәсьәләсе салып китә иде. Хәер, монысын Гыйлемдар белми дә калды бугай.

Электр фонаре белән кечкенә пәкегә чалбар кесәсендә урын табылды. Ай яктысында тоныкына ялтыраган мобиль телефон өстәл өстендә калды... Әйе, малайга телефонның кирәге чыкмаячак.

Бер катлы җәйге тәрәзә, тоткасына кагылу белән үк, ике якка ачылып китте. Малай, аякларын тышка салындырып, тәрәзә төбенә утырган килеш, нидер пышылдады, бәлки, йокы аралаш кына, әти-әнисеннән гафу үтенүе булгандыр.

Йомшак туфраклы клумбага сикереп төшкән иде, спорт ботинкасы дымык, көпшәк җиргә батты. Ул аны кагып-нитеп тормады, ком түшәгән аллеядан китмичә, куе үләннәрне ерып, дача коймасындагы үзе генә белгән тишеккә таба атлады, капка башындагы сизгер видеокүз объективына эләгәсе килмәгәндер, ахрысы.

Тиздән малай сирәк багана башларындагы зәңгәрсу лампалар яктырткан тар гына асфальт юлга чыкты. Вакыт соң булганга, юл буп-буш, дачаларына кайтасы кеше кайтып беткән инде.

Малай, минут та уйлап тормастан, сулга борылып, тимер юл станциясенә

бара торган шоссе белән янәшә велосипедчылар сукмагыннан эре-эре атлап китте.

Тимер-бетон панельләрдән генә укмаштырып төзелгән вокзал бинасы тып-тын, хәтта зал димәсәң хәтере калырлык, сыңар тәрәзәле кысан бүлмәдәге касса да ябык инде. Тимер юлчы формасы кигән дежур каравылчы өч-дүрт урындыкны бергә кушып, шул ятакта рәхәтләнеп йокы сүтә... Шулай да аның кырыенда яткан Акбае төн уртасында ялгыз йөргән малайга сәерсенде бугай, Гыйлемдар янына килеп, башын кыегайтып, аның күзләренә тутырып карады, аннары урынына кире кайтып, койрыгын җайлабрак салды да кабат мәрткә китте.

Төнге битараф дөньяның малайда бер эше дә юк иде сыман.

Чирек сәгать үтсә үткәндер, станция янына иң соңгы зәңгәр электричка килеп туктады. Үтәли күренеп торган буш вагоннардан сыңар җан иясе дә төшмәде. Койрыктагы вагонның ишекләре ике яктан да ачык, ахыргы станциягә ярты сәгатьлек кенә юл калганга, машинист ыктыматлыгын җуйган иде, ахрысы. Хәер, шәрран яра ачык вагон ишеге соңгы вакытларда янә баш калкыткан хулиганнар эшедер, бәлки.

Малай койрыктагы вагонга кереп утырды. Тәрәзәдән караган иде, вокзал ишек төбендә күзләрен уа-уа басып торган баягы дежур тимер юлчыны һәм аның Акбаен күрде. Аларны күргәч, малайның күңеле нигәдер нечкәреп китте, әйтерсең лә, ул якын танышларын соңгы тапкыр күрә, алар белән мәңгегә хушлаша иде... Хәер, бу сагыш хисе күңел төпкелендә тыпырчынып кына алды да, шундук сүнде. Малайны башка, мөһимрәк вакыйгалар көтә иде...

Ахыргы станциядә алгы вагоннардан берничә генә пассажир төште. Алар шундук вокзал бинасы каршында көтеп торган микроавтобус янына ашыктылар, ә малаебыз бөтенләй кире якка юл тотты.

Бераз баргач, шоссе юл кисәк кенә бетте, өзелеп калды. Анардан, икегә аерылып, инде чирәм үскән гади авыл юллары башлана иде. Малай, сихерләнгән шикелле, беркавым юл чатында басып торды, аннары, ниндидер боерыкка буйсынгандай, сулга борылып, ышанычлы адымнар белән юлын дәвам итте.

Озакмы баргандыр,—ул моны, әлбәттә, хәтерләми, ләкин күктәге йолдызлар тоныкланган иде инде, димәк, таң сызылырга да күп түгелдер.

Каршында чәнечкеле тимерчыбык киртә пәйда булгач, ул капыл туктарга мәҗбүр булды. Киртә бер офыктан икенчесенә кадәр сузыла (моңа күпме металл киткәндер?), анда биш метр саен баш сөяге сурәте төшкән сары калай эленеп тора иде. Электр фонаре белән яктыртып, малай андагы язуны да укыды: «Тыелган зона. Якын килү катгый тыела. Радиация!»

Малайның моңа исе китмәде. Иске атом электр станциясе тирәсендә тыелган зона барлыгын, бу зур мәйданлы зонаның чиге җәйге дачалардан егерме биш чакрымнарда гына булуын ул белә иде, әлбәттә. Заманында дөнья шаулаткан «Карачирәм авариясе»ннән соң үткән ярты гасыр эчендә радиоактив нурланыш бик нык кимегән һәм хәзер әйләнә-тирә табигатькә аның зыяны юк чамасында диләр. Тик тыюлык зона барыбер тагы илле елга калырга тиеш икән әле...

Малайга болары билгеле. Ләкин тутыкмас тимерчыбык киртәнең 1000 саны сугылган бетон баганасы төбендә, вак яфраклы зәһәр урман кычыткан арасында, бала үрмәләп кенә үтәрлек тишек барлыгын ул каян белде микән?

Тишектән үтү өчен шактый көч түгәргә, елан кебек шуышырга, боргаланырга туры килде. Алай да әле малайның җәйге курткасы, очлы тимерчыбыкка эләгеп, бер-ике җирдән ертылды кебек. Ә кычыткан чаккан кулның ачытуы, игътибар итмәсәң, сизелми иде.

Зона эчендә җир тигезле-тигезсез, чөнки сөреп үлән чәчкән булганнар, аннары кыргый куаклар китә... Арырак инде чын мәгънәсендә урман башлана, атом станциясендәге авариядән соң үткән еллар арасында монда

табигый юл белән каеннар, усак агачлары тишелеп үскән, алар элекке җиләк-җимеш бакчаларын басып киткән...

Малай, ниндидер җәнлек салган сукмак табып, шуннан китте.

Таң атарга күп тә калмый, күктә, баш очына кадәр, яктылык уйнап, дулкынланып алгандай итте дә янә күз бәйләнде. Бу яктылык электә азанчы мәзиннәрне дә саташтыра торган «шайтан таңы» гына иде әле. Аннары көнчыгыш тарафта чын, җылы яктылык сызылды.

Урман куелыгына кергәч, сукмак дип әйтерлек эзләр дә калмады. Менә шул чакта гына малай әйләнә-тирәсендәге тынлыкка игътибар итте.

Үле тынлык дигән нәрсә шушы инде.

Монда кошлар оя типми.

Сандугач сайрамый.

Монда кырмыска оясы да калмаган, түмгәкләре җир белән тигезләнеп беткән.

Монда үскән кыргый җиләк җирдә килеш чери.

Юеш черек исе килә...

Сул кул якта агачлар арасыннан йорт-каралтыларны шәйләп була иде. Кыйшайган ташландык йортлар. Ишек-тәрәзә уемнары ялмавыз шикелле ырҗаеп тора. Бер йортның җимерек түбәсенә әрсез куак үскән дә хәзер бер-ике зәгыйфь тамыры белән генә эләгеп калган.

Мондый төтенсез, үле авыллар бу зонада дистәләп.

Малай тукталып тормады. Аңлаешсыз бер көч аны һаман алга, алга әйдәкли иде.

Куелыкка кергәч, иртәнге салкын чык малайның тезбашларын чылатып бетерде һәм ул адымнарын тизләтте.

Инде кояш шактый күтәрелеп, агач өсләреннән күренә башлагач, ул җил аударган карт каен кәүсәсенә утырып хәл җыйды.

Малай сусаган иде. Ләкин ул монда үзенә эчәргә су табылмаячагын һәм түзәргә туры киләчәген белә иде. Ләкин озаккамы? Юк, озакка булмас. Малай үзен әйдәкләгән көчнең явыз түгеллегенә ышана иде бугай.

Төш вакытында ул бер түгәрәк аланлыкка барып чыкты. Кызыл, сары, зәңгәр чәчәкләргә күмелгән бу якты аланны күргәч ул, сискәнеп, туктап калды. Ничек гаҗәпләнмисең: монда һәр тарафта кошлар сайрый, үлән арасыннан вак чикерткәләрнең нәни кубыз чиерткәне ишетелә, йомшак җилдә яфраклар лепердәшә... Әнә, бер шәмәхә бөҗән, хуҗаларча җуылдап, чәчәктән чәчәккә кунып, биләмәсен тикшереп йөри.

Шунда бер ак күбәләк малайның иңбашына килеп кунды...

Малай артына борылып карады.

Анда берни күренми—ярым үле карурман юкка чыккан, аның урынында ниндидер аксыл төстәге иксез-чиксез бушлык, такыр чүл җәйрәп ята иде.

Кире борылды—күз алдында шул ук җәннәт бакчасыдай гүзәл аклан.

Якында гына яшь кәккүк тавышы ишетелде. Малай кәккүкнең ничә тапкыр кычкырганын авыз эченнән генә санарга керешә. «Кәк-күк» авазлары бер дистәгә тулгач, малай күпсенде шикелле, муен артын кашып куйды.

—Аптырама,—диде шунда кемдер.—Син ничәне теләсәң, шул тапкыр кычкырыр ул... Синең мәңге яшисең килә ич, шулай бит, Гыйлемдар?

Малайның янәшәсендә көмеш чәчләренә бөрчекле ак яулык өреткән ак күбәләктәй бер әби басып тора иде. Гыйлемдарның иңбашына килеп кунган баягы күбәләк шул булган, ахрысы.

—Сез... кем? Сез мине каян беләсез?—дип сорады малай, әбигә таба борылып.

—Ак әби дисәң дә ярый. Ә яшь чагымда Гөлгенә дип дәшәләр иде. Мин сине яралган көнеңнән үк беләм... Гыйлемдар исеме сиңа чат ябышып тора.

Дөрес, әтиен баштарак Галим исеме кушмакчы иде...

—Анысын да беләсезмени? Каян?

—Гыйлемдар улым, моны бер сүз белән генә аңлатып бирә алмамдыр... Боларга син үз вакытында, әкренләп төшенерсең...

Бу сүзләрнең мәгънәсен аңлау кыен түгел иде: Гыйлемдар биредә вакытлыча гына, бер көнгә генә килмәгән дигән сүз иде бу. Димәк, ул тоткын? Әсир?

—Бүгеннән бу дөнья безнең икебезнеке,—дип, малайның сүзсез сөаленә җавап бирде әби.

—Икебезнеке?

—Һәрхәлдә ул синеке дә, балам.

«Балам» дигән сүзне ул нәкъ әнкәсе кебек ягымлы, назлы итеп әйтте һәм, ирексездән, малайның күзләренә яшь килеп тыгылды.

—Бөтенесе дә әйбәт булыр, Гыйлемдар,—диде Ак әби, тыныч тавыш белән.—Әти-әниләрең исән-сау. Син—минем кунагым. Куышыма рәхим ит.

Куыш дигәне аланның нәкъ уртасында куаклар арасына корылган киез тирмә булып чыкты. Аның үзенә күрә тәрәзәләре һәм чаршау шикеллерәк ачыла торган ишеге бар, ишек төбенә аяк киемен сөртү өчен камыш палас җәелгән иде.

Тирмә иркен һәм якты гына булып чыкты. Кергәч тә сул якта гади юынгыч, аның янындагы урындыкта сулы чиләк тора. Арырак—аш-су әзерли торган «почмак». Утын ягыла торган чуен плитә, ишле-кушлы табак-савыт. Плитәнең калай морҗасы төннек тишегеннән чыга икән. Түрдә өстәл, кыяфәтләреннән үк какшау икәнлеге күренеп торган артлы урындыклар. Аннары фанер тумбочка, аның өстендә кадимгә каләрге аклы-каралы «Рекорд» телевизоры һәм ике җиз мөгезле антенна, стенага эленгән кара тәлинкә—бусы радиорепродуктор, ахрысы. Уң якта чардуган корылган никельле карават. Аның бәләкәй тимер тәгәрмәчләре паласка яртылаш батып кергән. Аккалай тасмалар белән шакмаклап бизәлгән яшел сандык. Ишек тирәсендәрәк сары лак белән буялган фанер гардероб... Ялтыравык амальгамасы купкан кызыллы-яшелле көзге... Көзге янында күгәреп беткән Бакыркош, тик аның күзләре генә пыяладай ялтырый. Ә бусы—бүрәнә ярыгына кулын кыстырган уенчык Шүрәле бугай...

Хәер, Шүрәле һич тә уенчык түгел, кайчагында ул, тәмам җанланып һәм зураеп, өстәлдән төшә дә, Гыйлемдар янына килеп утыра. Аның маңгай сырлары шулкадәр тирән, кайчагында ул, кызык өчен, карандашын колак артына түгел, маңгай сырына кыстырып куя. Тик боларын малай бераз соңрак белде.

Әбкәй яшәгән өй эче ярты гасыр элекке бер бүлмәле коммуналь фатирны хәтерләтә иде. Андыйларны Гыйлемдарның телевизордан гына күргәне бар.

Малай өй эчен күздән кичергәндә Ак әби аның үзенә елмаеп карап торды.

—Бәхет—цивилизациядә түгел, Гыйлемдар,—дип, гади урман анасыннан һич тә көтелмәгән сүз әйтеп ташлады әби.—Түгел! Моны безнең элгәрләребез—болгар бабалар да белгән. Җәй җитү белән алар, шәһәрдәге тынчу өйләрен ташлап, табигать кочагына, җәйләүгә чыкканнар...

Бу әйберләр һәммәсе комиссия кибетеннән, мин аларны киләчәк заман музейханәсе өчен җыям һәм саклыйм.

—Ә телевизорыгыз ... күрсәтәме соң? Ул электрны каян ала?

—Ул энергияне атмосферадан ала,—диде әллә каян фәнни атамаларны үзләштергән әби.—Гади генә итеп әйтсәк, мин шарсыман яшенне магнитлы ятьмә белән тотам да магнитлы чүлмәккә салам. Ул миндә шартламый, энергиясен аз-азлап ай буена чүлмәк электродларына биреп ята. Түшәмдәге люстраны да шарсыман яшен көче кабыза... Ә яшенне мин син килгән

урманнан алып керәм, алар анда яңгырдан соң еш булучан. Түбәнтен генә дулкын өстендә чайкалгандай йөзеп йөриләр... Беләсенме, шартлаган атом станциясе өстендә алар аяз көнне дә күренә.

—Сез кайнар плазманы саклау ысулын уйлап таптыгызмыни? Мин моны аңламыйм..—диде малай, түшәмдәге ефәк абажурга карап.

—Аңларсың. Мин сиңа кирәкле мәгълүматны табып бирермен.

—Китапларданмы?

—Китаплардан да. Аларның копияләрен һәм компьютер дискларын миңа Мәскәүдәге Үзәк фәнни китапханәдән һәм Вашингтондагы Конгресс китапханәсеннән механик күселәр һәм тимер ярканатлар урлап алып кайтып бирә.

Сихер көче белән адәми зат булып күренергә сәләтле бу хамелеон-күселәрне һәм ярканатларны әби «комагыйларым» дип йөртә һәм кирәк чагында йомышка йөгертә икән. Алар Борынгы Казанның «Әрхири тавы»нда мәшһүр Сөембикә көтепханәсенең калдыкларын эзләп тапканнар, анда да «ак вә кара сихер» китаплары байтак икән.

—Ә сезнең компьютерыгыз бармы соң?

Әбинең елмаюы шундый матур һәм килешле иде...

—Син үзең компьютер, балам,—диде ул.—Без синең гадәттән тыш сәләтләреңне ... ачарбыз. Мин дә компьютер кебегрәк, ләкин көчсезрәге... Ярар, хәзергә бу катлаулы нәрсәләрне куеп торыйк, яме? Син бит көне буе зәррә мыскал ризык капмаган...

Малай кыстатып тормады, шундук иягән какты.

Ак әби аш өстәле янына килеп яшел ашъяулыкны күтәреп ачып җибәрде.

Үткәннәрдә калган әкияти авыл табынын тасвир итеп тормыйбыз. Көлдә пешкән кайнар бәрәңгене каймакка мана-мана ашаганда, бер каен җиләген кабып, кулы икенчесенә үрелгәндә малай бөтен дөньясын онытты шикелле. Төче коймак та әле кайнар көенчә, ә ниндидер үлән кушылган чәйнең хуш исе үк туклыклы һәм шифалы иде. Аннары таңгы миләүшә төсендәге чөгендерле катык... Боларны ак әби каян табып бетергәндер.

Тамак ялгагач, Гыйлемдарны йокы баса башлады. Моның шулай буласын Ак әби, әлбәттә, белеп тора иде һәм малайга чардуганлы караватны күрсәтеп ым какты.

Малай ятсынмыйча гына чишенде, шалтыр-шолтыр килә торган калай юынгычта тешләрен ниндидер татлы паста белән чистартты. Кызык, монда анар, целлофанга төреп, өр-яңа теш чистарткыч та әзерләп куйганнар икән.

Төнне сәяхәттә үткәреп алҗыган малай күзен йомуга ук йокыга талды.

Ул, уянып та карамастан, егерме сәгать буена йоклады.

Уянгач малай үзендә яшьлек гайрәте янарганын сизсә дә, аның йөзендә һәм бигрәк тә күзләрендә меңләгән сораулар эленеп тора иде.

Ләкин Гыйлемдар иң мөһимен: үзенең кайда икәнлеген белеп уянды. Үзен әтисе белән әнисенең эзли башлаулары, инде йокычан тимер юлчыны да күреп сорашулары, зонаны әйләндереп алган өч катлы тимерчыбык киртәнең һәр метрын бер төркем милиционерларның овчарка белән тикшереп йөрүләре турында да хәбәрдар иде ул. Тиздән һавага вертолетлар күтәреләчәк һәм алар очсыз-кырыйсыз дип әйтерлек урман-чытырманны һавадан аркылыга-буйга очып күзәтә башлаячаклар.

Малайны эзләүчеләр арасында күрше кызы да бар, чөнки дача коймасында Гыйлемдар чыгып киткән тишекне дә ул эзләп тапкан... Астрономия белән кызыксынганга, Ниса түбәгә менеп, төннәрен кечкенә телескоп янында үткәрә икән. Кызчык төн уртасындарак Гыйлемдарның үләннәрне ера-ера койма тишегенә таба киткәнен күреп калган була.

Боларны малай каян белә иде сон? Үзе килеп чыккан гүзәл аланлыкны беркем дә күрә алмаячак, фотообъективлар да сизмәячәк икәнен, чөнки бу дөньянын башка геометриядә урнашканлыгын ул каян белә иде?

Күрәмсен, боларны ана, анын баш миенә йокыда чакта сендергәннәрдер... Ак әби һәм анын күзгә күренмәс ярдәмчеләре, әлбәттә.

Менә хәзер дә Ак әби, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп, Гыйлемдарга карап тора, анын йокыдан тәмам айнып житкәнен көтә. Барлык сорауларга җавап бирергә әзер иде ул.

Малай сорау бирергә ашкынса да, тирмәнен нәкъ түрендә компьютер өстәле күргәч, түзмәде: «Мондыйны минем реклама китапларында да очратканым юк»,—дип куйды.

—Ин яна марка,—дип компьютерны мактады Ак әби.—Махсус синен өчен Галәм арьягыннан китерттек. Ләкин ул Жир интернетына тоташмаган булыр, анын каравы «Күк интернеты» белән элемтәдә.

—Галәм арьягы? Йолдызара элемтә? Әкият бу! Бөек математик Паскаль: «Йолдызларнын чукрак-телсезлеге куркыта мине»,—дигән...

—Ә бер бөек шагыйрь: «Йолдыз белән йолдыз серләшә»,—ди, балам! Бәлки чыннан да йолдызлар сөйләшәләрдер? Бәлки без генә ишетми торганбыздыр? Бу компьютер параллель Жир дөньясыннан, әгәр инде ышанмыйсын икән,—ерак киләчәк заманныкы диик.

—Ана нинди программалар куелган сон?

—Сина кирәклеләре һәммәсе дә. Менә, ашап алгач, үзен күрерсен.

Яналык бер компьютерда гына түгел икән. Малай йокы сүткән арада, «чуртан кушуы буенча», тирмәгә заманча ванна һәм душ белән жиһазланган гигиена бүлмәсе тоташтырып куйганнар иде. Кемнәр? Аларга мондый сихер көче каян килгән?

Компьютердагы математика программасы ана «хужаларнын» чиксез кодрәтле булуын күрсәтте. Мәсәлән, натураль саннар рәтендәге гади саннарны хисаплый торган төгәл формула Жир планетасы математикларынын исен китәрерлек иде. Ин күренекле акыл ияләре ике мен ел буена эзләп-эзләп тә таба алмаган гүзәл формула иде ул!

Шахмат программасы бу борынгы уенны алгоритмга таркатып, гап-гади уенчыкка әйләндергән. Алгоритм буенча уйнаганда, беренче йөрешне ясаучы якнын жинүе котылгысыз булуын исбат иткәннәр. Тагы шунысы кызык, бу алгоритм кагыйдәсен сабыйлар аеруча тиз үзләштерә һәм, мәшһүр «Рубик кубигы» белән булгандагы кебек, алгоритмлы шахмат ярышында балалар өлкәннәрне артта калдыралар икән...

Гыйлемдар могжизалы компьютерда ун-унбиш программаны ачып карады һәм һәр фән өлкәсендә «Novitas» («Яналык») тамгасы сугылган ачышларны күрде.

Параллель Жир дөньясы, ниһаять, «кош һәм дунгыз грипплары», «вич-инфекция», рак, төрле аллергия кебек авырулардан арынган, радиация авыруы да дәвалауга бирешкән... һәр кешегә, хирург операциясе кирәк булган очракка дип, анын үз организмыннан алынган «кәүсә күзәнәкләре» резервы булдырылган... Тешен төшсә, анын урынына янасын үстерәләр, хәтта сукырайган күзне дә янасы белән алмаштыра башлаганнар... Малай бер очтан рак авыруынын татарда элек ийә һәм сәратан хастасы дип аталганлыгын да белде.

Ләкин, әйткәнебезчә, бу ачышлар Жирдә түгел, бәлки Галәмнен Жир планетасына охшаш меңләгән «сәйяр йолдыз»ларыннан берсендә—Сириуснын иярчене тирәли әйләнеп йөрүче яшел планетада ясалган. Димәк, югары үсешкә ирешкән «Сәйяр»леләр Жир йөзендә яшәүче кечерәк кенә татар халкынын милли телендәге әллә нинди нечкәлекләрне дә беләләр икән. Чөнки аларнын үзләрендә, мәсәлән, Эспаньолия иле

конституциясенең өченче маддәсендә үк: «Эспаньолиядә төрле төсмердәге тел-шивәләр байлыгы мәдәни кыйммәткә ия, ул аерым ихтирамнан файдалана һәм кадерләп саклана»,—дип язылган.

«Параллель жир»дә үз Тукайлары, үз Байроннары, Пушкиннары булган. Ләкин Сәйяр дөньясында Тукай исеме киресенчә—Йакут дип укыла икән. Затлы Йакутның язмышы да жирдәге Тукайныкыннан башкачарак булган: безнең Тукай, Сталин репрессияләреннән үлеп котылган булса, Йакут халык дошманы дип игълан ителгән һәм бездәге Галимжан Ибраһимов язмышын кабатлаган. Соңыннан, әлбәттә, аны аклаганнар һәм әдипләренә Йакут премиясе бирә башлаганнар. Тик премия бирү ялагай һәм шомакай каләм тибрәтүчеләргә медаль өләшүгә әйләнә башлап, бу эшкә криминал килеп кысылгач, ел саен премия бирүне туктатып торырга мәжбүр булганнар.

Кайбер нәрсәләрне белми калу—үзе зур бәхет. Бөтенесен бер Алла гына белсен. Шуңа күрә Гыйлемдарның компьютерында кайбер программаларның беренче пунктында мондый кисәтү тора: «Бу мәгълүматлар хәзергә Сиңа кирәкмәс». Әйе, компьютерның мәгълүмат базасында кеше ашаучы Сталин шәхесенең коточкыч сыйфатлары турында гына түгел, Пушкин турында да, Тукай турында да, Муса Жәлил һәм Галимжан Ибраһимов, хәтта Сәхипжамал Волжская турында да аклы-каралы мәгълүмат тупланган. Ләкин болар белән танышудан баш тартырга малайның акылы житте.

Гыйлемдар компьютер белән мәш килгәндә Ак әби аның яныннан китмәде һәм, малайның хәрәкәтчән йөз сызыкларына карап, аның ничек тәэсирләнүен, балаларча куануын күзәтеп, кичерешләрен чыраеннан «укып» торды. Әлегә Ак әби канәгать иде шикелле.

Төшке ашка гына бүленеп, Гыйлемдар кабат компьютерга багынды.

Бу юлысында мониторда иң элек: «Соңгы атнада син нинди китаплар укыдың?» дигән сорау калкып чыкты. Малай һич тә көтмәгән сорау иде бу.

«Математика тарихы буенча»дип язып куйды ул кыска гына.

Аннары компьютер мондый сораулар әзерләгән иде:

«Мең дә бер кичә»әкиятләрен яратасыңмы?

«Андерсенның «Шыксыз үрдәк бәпкәсе» әкиятен ничә тапкыр укыдың?»

«Бәләкәй принц»ны беләсеңме? Чормада яши торган Карлсонны? Яланаяклы Гекльберри Финны? Әбүгалисинаны? Гарри Поттерны? «Шүрәле» әкиятен?»

Турысын әйткәндә, малай боларның күбесен белеп бетерми, ә кайбер каһарманнарны телевизорда гына күргәне бар, тик алары да аның игътибарын жәлеп итә алмаганнар, хәтерендә бик томанлы сурәт кенә калдырганнар иде. Малайның рухи үсеше берьяклырак, ул гуманитар өлкәләрдә шактый сай йөзә иде шул.

Компьютерның соравыннан соң тынлык озаккарак сузылды.

—Белмим, әбекәй..,—дип пышылдады Гыйлемдар, Ак әбигә таба борылып.

Югыйсә бит конкурсларда сорауны әйтеп бетергәннәрен дә көтмичә чатнатып жавап бирә торган малай иде ул!

Сизгер, хәтта нәзакәтле компьютер экранындагы сораулар сүнеп юкка чыкты һәм ул гадәти режимда эшләүгә күчте.

Гыйлемдар физика, математика кебек, кем әйтмешли, төгәл һәм «әсасый» фәннәр буенча булган китапларны гына укый иде. Әдәби әсәрләргә вакыты житмәгән икән, шигырь-мазарны әйткән дә юк. Гомумән, шигырь язуны ул компьютерга тапшырып була торган вак эш дип карарга күнеккән иде. Әйдә, яна рифмаларны компьютер эзләсен... Ә хис һәм сурәтләргә килгәндә, ул боларын да саннар белән күрсәтеп булырга тиеш дип инанган иде. Хәтта

мәхәббәтне дә компьютерлаштырып буладыр. Анынча, илһам дигән нәрсә дә компьютерда тормышка ашырылачак.

—Туктале, «Нечкәбил»не хәтерлисеңме син?»—дип сорады анардан Ак әби, Абдулла Алиш дигән берәүнең әкиятен искә төшереп. «Юк.» Ә «Шыксыз үрдәк баласы»н? «Юк.» Онытkан. «Бармакбикә» әкиятен? Ә «Ал чәчәк»не? «Көлбикә» турындагысын? Боларын да юкмы? Ә «Гали баба һәм кырык юлбасар»ны?

Малай анысын хәтерли икән хәтерләвен, тик «Мен дә бер кичә» әкиятләрендәге Гали бабаның мәгарә тулы алтын-көмеш күрүе хак түгел, ул—наркоман, киндердән ясаган хәшиш үләне чәйнәп галлюцинация—төш кенә күргән дип ышана. Кайсыдыр бер акыллы баш малайны шулай өйрәткән. Химия укытучысы икән.

—Кем белә, бәлки, син хаклыдыр да, чөнки мәгарә ишегең ача торган сихри «сим-сим» сүзе чыннан да киндер бит...,—диде аңа Ак әби.—Ләкин, наныем, син барыбер әкияткә ышанырга тиеш, әкияткә!—дип өстәде ул.—Әкиятне дә белергә һәм яратырга кирәк... Фәннең әхлагы юк, әкиятнең—бар. Бар! Фән Хиросима һәм Карачирәм фаҗигасен тудырды, адәмнәрне бозарга яңа наркотиклар ясап бирде, ә әкияти «Нечкәбил»ләр сиңа татлы бал белән шифалы кәрәз сөте генә бүләк итәләр...,—дип тәфсилләп аңлатты әби.

Ахырда малай үзе укыган тагын бер әкиятне исенә төшерде: «Менә син, әбкәй, әкияткә ышан да ышан дисең... Син әйткән мәшһүр Андерсенның «Сандугач» әкиятен укыганым бар икән. Анда бер былбылның авыру Кытай императорын сайравы белән үлемнән йолып калуы турында сөйләнә...

Шул чакны Ак әбинең күзләрендә ике бөртек кенә яшь күренде һәм Гыйлемдар үзенең нинди дер ялгыш сүз әйткәнен аңлады. Моның сәбәбен ул бераз соңрак, әбинең биографиясе белән танышканнан соң гына белде.

Шулай да Ак әби тиз тынычланды. Аннары үзенең күбәләк канатыдай җиңел кулы белән малайның инбашына орынды:

—Күңелеңне төшермә, угыл,—диде.—Имтихан тагы кабатланыр әле... Бу китапларны мин сиңа табып куярмын. Син романтик яшьтәшләреңне куып житәрсең. Синнән камил кеше чыгарга тиеш. Шулай кирәк! Әгәр каршы булмасаң, кайбер мәгълүматларны йокыда чагында Бакыркоштан алырсың... Көч тукмичә генә. Ләкин шуны бел: болай тапкан гыйлем үзең казанып тапканнан кайтышрак—ул хиссияткә төренмәгән була, тотрыксызрак та...

Малай яшелләнгән иске трюмо өстәлендәге Бакыркошка таба борылып караган иде, аның да яшькелт күзләрендә ут кабынганын күрде. Ә Шүрәле фигурасы нидер пышылдады бугай. Шунда гына малай куртка кесәсендәге фоторәсемнәрнең көзге пыяласына кыстырып куелган булуын абайлады. Әнисе... әтисе... Ниса-Алтынчәч... Соңгы фотоны малай кызчыкның үзенә сиздермичә генә ерактан төшереп алган иде. Фоторәсемдә Ниса, әлбәттә, яланаяк һәм купшы чалмалы пионнарга су сибеп йөри... Кояш ашамасын өчен борынына кәгазь ябыштырган, бейсболка маңгайчасы астыннан күтәрелеп караганда почык борыны күккә чөелә, әллә масая инде...

Дөресен әйткәндә, Гыйлемдар математик формулаларның төзек гүзәллегендә күрше кызы Нисаның шәүләсен күргән кебек була иде. Җәяләр—аның кашлары кебек, шулар астында зәп-зәңгәр сорау билгеләре төсмерләнә, колагына элгән алкалары менә тамам, менә тамам дип торалар...

Ә Ак әби барын да белә, сизә шикелле... Ул бит кешенең күңелендәгесен укый... Теге бөтендөньяга мәшһүр болгар күрәзәчесе Ванга шикелле... Ниса да шундый бит! Күрше кызы чая Ниса да Гыйлемдарны үтәли күрә иде бугай...

—Ниса исеңә төште шикелле,—диде әби, малайның күзләренә туры карап.

Ак әби Гыйлемдарга күрше кызының исемен атап әйткәч, малайның бит алмалары кызарып чыкты.

Ак әби Нисаны да, Гыйлемдарны белгән шикелле, белә иде, ахрысы. Ул кызчыкның гакыл үсешендә Гыйлемдарны кабатлаячагын күрә... Әгәр берни дә комачауламаса, ике елдан Ниса шахмат буенча шәһәр чемпионы булачак. Биш елдан соң халыкара фәнни журналда Гыйлемдардан калган кулъязма нигезендә матдә төзелеше турында фундаменталь мәкалә бастырып чыгарачак... Ун елдан соң халыкара террористлар кулында Жир планетасын күз ачып йомганчы плазма тамчысына әйләндерерлек бомба булачак...

Ак әби бу хәлгә юл куймаска тиеш иде.

Тирмәдән чыгып киткәндә әби: «Мин ике сәгать ярымлап булмам, мине югалтма, тамагыңа капкала, магнитлы душка кереп чыксан да була, ул кар суы шикелле—кешене янадан ясап чыгаргандай итә»,—диде.

Әбинең ике сәгать ярым дигәне Жир исәбе беләндер, әлбәттә. Бәлки ул шушы вакыт эчендә бүтән йолдыз системасы белән элемтә урнаштыра ала һәм кинәш сорый торгандыр? Бүгенге физикада электромагнит дулкыннарның тизлеге чикле дип каралса да, биокыр дулкыннары өчен ераклык дигән нәрсә комачау булмаска мөмкиндер... Һәрхәлдә Гыйлемдарның бу хакта укыганы бар иде.

Малай фоторәсемнәрне өстәленә тезеп куйды. Компьютер галәменә кереп чумгач, ул тагын дөньясын онытты.

Бу юлы ул «Персоналияләр. Ак Китап» сәхифәсен ачты. Монда Жирнең игезәге булган ерак планетадагы затлы шәхесләр турында мәгълүмат һәм хикәяләр тупланган булып чыкты. Жирнең игезәгендә жәмгыять тарихы мондагы Жир тарихын кабатлый (яки киресенчә—мондагы Жир андагы тарихка ияремә?), шуңа күрә күп нәрсә шәрехләп аңлатып торуны сорамый иде. Анда да Явыз Иваннар, үз Һитлерлары, үз Джугашвилилары булган, ельциномания, аннан соң тагын манияләр... Ниндидер гайре табигый баһадирларга өмет баглау. Шәкүр караклар, аннары Ермак һәм Ермолов кебек нәселләрен саткан чукынмышлар... Дар агачлары, гильотиналар, электр кәнәфиләре, адәм балаларын чалгы кебек ура торган «калашниклар» уйлап табылган. Анда да коммунистик күмәк хужалыклар төзеп азапланганнар, кансыз залимнәргә табынганнар, аларга төрле этбаш-опричниклар, сыераяк-чекистлар, симез жандармнар һәм мускуллы омончылар хезмәт иткән. Анда да Жир планетасындагы кебек үзләренең Хиросима фажигасен һәм Карачирәм һәлакәтен оныта алмыйлар.

Шул ук вакытта Алтынчәч белән Жик Мәргән гыйшкы, Казандагы Сөембикә һәм Себердәге Сүзгебикәләр фажигасе анда да, монда да тәп-төгәл кабатланган... Үз Европалары, Азияләре, Антарктидалары, Шәрык һәм Гаребләре, хәтта хыялый Атлантидалары булган бу дубликат планетада пәйгамбәрләр һәм Хозыр-Ильяслар да гомер кичергән... Дисциплинаны санга сукмый торган ниндидер «роуслар», ярымкырагай «башбүреләр», мең ел буена кол психологиясе сеңгән «татрлар», бакырны алтынга әйләндерергә маһир «жөфетләр» һәм башка ялмавыз андрофаглар...

Гыйлемдар «Тарих» сәхифәсен актарганда «Гөләндәм кыйссасы» дигән хикәяткә игътибар итте.

Гөләндәм—параллель Жир планетасында икенче бөтендөнья сугышы ятимнәре йортында тәрбияләнгән кыз бала икән. Мондый ятимәләр соныннан үзләрен «ятимханә тоткыннары» яки «ятимханә ветераннары» дип атап йөрткәннәр, чөнки бу каты режимлы, әхлаксыз һәм гумансыз йортлар төрмәдән яки концлагерьдан кайтыш булмаган... Кыз балалар анда сафлыкларын жуйган, тормышка өмет-ышанычларын югалткан...

Әле бәдәннәре тулышып, түгәрәкләнеп кенә килгән унбер яшьлек Гөләндәмне Карабаш бистәсендәге ятимханә мөдире, әлеге сугыштан бер

генә яра да алмыйча кайткан Мишәрәкжанов фамилияле, әллә ниткән Карай-Морза исемле астыртын штабист, үзенең кул астында бухгалтер булып эшләүче хатыны район үзәгенә банкка киткән аулак чакны туры китереп, өйләренә тәрәзә юарга чакыра һәм искиткеч матур бер язгы көнне, бакчада чут-чут итеп беренче сандугач сайраган мизгелдә, кыз баланы көчләп ташлый. Тырнашканы, борынын тешләгәне, барлы-юклы чәчен йолыкканы, гәрәбә төймәле жинен умырып төшергәне өчен янаклый да әле... Шушы хәлләрдән соң ятимә кыз сандугач сайравын ишетсә, калтырап төшә торганга әйләнә... Былбыл дигән сүзне ишетсә, идәнгә егылып, тәгәри-тәгәри елый, үз чире тота башлый...

Ятимханәдә яшәгән соңгы елларын ул бик томанлы гына хәтерли. Башка ятимнәр белән бер сафка тезелеп, ул да мәктәпкә йөргән. Тырышкан, өчле билгесе алмаган... Ана монда «йомыкый» дигән кушамат такканнар. Йомыкый булмый нишләсен? Кыз жәйге күкрәвек яңгырларны көтеп ала торган булган. Ләйсән яңгырда күлмәкчән генә торырга яраткан, шулай үзенең бәдәнен пакьлыйм дип өметләнгән, ахрысы...

Кызны ятимханәдән тегүчеләр хәзерли торган һөнәр мәктәбенә жибәрәләр. Ул үзе китапханәчеләр техникумына билгеләүләрен сорый, әмма дирекция, төрле сәбәпләр табып, Гөләндәмне «дәрәжәсезрәк» исемлеккә кертә.

ФЗӨдә аның сәләтле булуын бик тиз күреп алалар һәм Гөләндәмнән югары квалификацияле кием кисүче-модельче хәзерлиләр.

Кызганычка каршы, чибәр һәм сәләтле кызга илнең иң яшерен һәм иң явыз оешмасында да игътибар иткәннәр.

Дәүләт иминлеге сагында торучы органнар үзләренә шымчы булырдай кандидатларны еш кына бәхеттән өлешсез калганнар, нәүмизләр арасыннан эзлиләр һәм табалар да. Алар һөнәр мәктәбендә укучы ятимәне, нинди дер бер сылтау табып, пәрәвез оясына—Мунча күле буенда урнашкан «Бастилия»ләренә чакырып алып, кулга ияләштерергә, анардан көндәм әләкче, яшерен агент, сексот ясарга тырышып карыйлар.

Тик боларның этлеге барып чыкмый, карап торышка бик күндәм һәм беркатлы кебек тоелса да, ятимә кыз инде кемнең кем икәнен аера, юмакайларның әгитенә бирешми, мәкерле тәкъдимне шундук кире кага. Акча белән, дингез буе санаторийлары, киләчәктәге өстәмә пенсияләр белән кызыктырып карыйлар, комсомолка икәнен исенә төшерәләр. «Юк!»—дип үҗәтләнә кыз һәм вәссәлам.

Кара дермантин җәюле өстәл артында утырган яшьрәк әгитче агай, нервысы котырынып, мангаена бөрчек-бөрчек бәреп чыккан тирен сөртергә тотына, янәшәсендә өстәл читенә таянып торган кызыл борынлы бәндәгә сораулы карашын ташлый... Тегесе, югарырак дәрәҗәлесе, ияген кагуга, ашыкмыйча гына торып ишеккә бара да, ачкычын борып бикләп куя. Юри чалтлатып бикли кабахәт.

Биеп кенә атлап, кыз янына килә, алаптай кулы белән Гөләндәмнең ачык түшенә үрелә... Кыз сикереп тора да, тегенең оятсыз күзенә төкерә һәм, гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр авызын пычратып, аты-юлы белән сүгенергә тотына... «Кирәкле» сүзләрне каян табып бетергәндер бу бичара, юаш, басынкы кыз бала? Ул «тәрбияләнгән» ятимнәр йортында, аннары ФЗӨ мәктәбендә шулкадәр шакшы телдә сөйләштеләр микәнни? Димәк, урамда ишеткән һәр яман сүз аның хәтеренә уела барган?.. Мондый усал, чи урысча һәм катлы-катлы, ләкин, кем әйтмешли, «искиткеч талантлы майт»ны ишетеп шаккаткан ГБ айгыры, төссез күзләрен акайтып, чалбар каешын каптыра алмыйча азаплана, чөнки тәмәке төтененнән саргаеп беткән бармаклары калтырый. Уникe томлы «Русский мат» басмасына да керми калган халык теле «җәүһәрләре» батыр чекистларны тәмам коралсызландыра.

Шул рәвешле, бернәрсәдән дә тайчанмый торган «иминлек сакчылары»

бу юлы чигенергә мәҗбүр булалар. «Нәжескә бассаң...»—дип кулын селти чиратта торган чекист, бөрчек-бөрчек галстуклысы.

—Кара аны, кызый,—ди ата опричник,—кара аны, гасабый... Корыч Феликс исеме белән ант итәм, ялынып үзең килерсең әле, тәти кыз...

Нәтиҗәсе көттерми.

Һөнәр мәктәбен тәмамлаганнан соң, Гөләндәм шәһәрдә эш таба алмыйча интегә. Аны хәтта гардеробчы итеп тә алмыйлар, кәгазьләрен актарган сыман итенәләр дә кире боралар. «Күрәсең, чекистларның шушылай үч алуыдыр инде,—дип уйлый кыз.—Ә бәлки өметләрен һаман өзеп бетермәгәннәрдер әле хәшәрәтләр».

Тиздән Гөләндәмне тулай тораклан да сөрәләр. Ул барлы-юклы киемнәрен, иске-москыларын арзан гына бәягә сатып бетерә. Фәкать бер генә нәрсәне—сугыш елларында ачтан үлгән әнисенең йөзеген генә саклый, хәер, ул аны сата да алмаган булыр иде—күгәреп-яшәреп беткән бакыр балдак кемгә хаҗәт?

Аяусыз тормыш, тешләрен ыржайтып, Гөләндәмне урамга, панельгә чакыра.

Юк, кыз төенчеген күтәрә дә, үзенә азмы-күпме таныш булган Карабаш авылына җәяүләп кайтып китә. Юк, ул «кызыл Бастилия» ишек төбенә дә, ятимханә бусагасына да барып егылмый.

Аңа «Карабаш» колхозының ярым җимерек терлек фермасында дуңгыз карауч эше табыла. Мөселман өчен иң абруйсыз, иң пычрак эш. Гөнаһлы эш дисәң дә була. Ферма исә бөтен тәненә сеңә, бу зәһәр исне мунчада җиде тиреңне чыгарып та бетерә алмыйсың, җитмәсә сабынга кытлык, фермага су мичкә белән генә кайтарыла... Гөләндәм мәтрүшкәле себерке белән дуслаша.

Баштарак ул сыңар тәрәзәле түбәсез каравыл өендә яшәп тора, аннары үз аяклары белән балчык изеп, үз куллары белән саман кирпеч сугып, өч тәрәзәле, ләкин килешле генә өй дә салып керә. Аның түбәсен балчыклы салам белән яптыра. Шуңа күрә эссе җәй көннәренең берсендә авылда ут чыгып, байтак йортлар кара күмергә әйләнсә дә, дуңгыз карауч кызның ап-ак итеп агартылган балчык куышы афәттән котылып кала. «Гөнаһсыз булганга, гөнаһсыз булганга...»,—ди авыл халкы яшь аралаш, янганнарны да, янмаганнарны да кызганып.

Дуңгыз фермасы авыл читендә булса да, аннан агып чыккан шакшы сыекча Каран суына ук барып төшә, аннары Каракүлгә эләгә... Гөләндәм боларны күрә, аңлый. Исерекбаш колхоз рәисенә барып сөйләшеп карый, тегесе сүгенә генә... «Күп белсәң, тиз картаерсың»,—ди, җитмәсә әле күз кысып маташа...

Көннәр шулай ферма белән өй арасында йөреп уза тора, кичә тора. Гөләндәм бәләкәй генә бакчасында яшелчә, үзенә генә җитәрлек кадәр җиләк-җимеш һәм чәчәк үстерә. Әлбәттә, малай-шалай җиләкләргә бер дә тынгылык бирми, ә чәчәкләрне ел саен беренче сентябрьгә каршы төнне ботап чыгалар. Гөләндәм боларга үпкә тотмый, чәчәкләр мәктәп өстәлен бизәп торачак бит... Кайберәүләр, дуңгыз карауч Гөләндәмнән күреп, өй буйларын матур гына гөлбостанга әйләндерәләр. Гөләндәм шуңа да бәхетле, бу йортлар янынннан ул елмаеп уза.

Карабаш авылыннан күп булса йөз чакрымда Карачирәм атом станциясе эшләп ятканын җирле халык оныта башлаган инде. Станциягә утыз чакрымнан да якын килү өчен махсус рөхсәт кирәк булганга, атом шәһәрчегенә барып чыккан кеше авылда сирәк була. Дөрес, төрле зарарлы гамма-нурланышларны үлчәп йөрүче белгечләр җәй саен авылда булып китәләр, елга-күлләрдән, чишмәләрдән, коелардан анализ алалар. Күпме сорашсаң да, «Бөтенесе дә тәртип, норма»,—дип җавап бирәләр, тик күзләрен яшерәләр. Халык ышана да, ышанмый да кебек, чөнки гарип һәм авыру балалар елдан-ел күбрәк туа, Карабаш күлендә ике башлы мутант балыклар тоткалыйлар... Җир-сулар, урманнар инде агуланган,

ләкин хакимият, бу мәгълүматны чит илгә чыгарсан, утынлык агач та сата алмабыз дип курка.

Атом станциясе төзүчеләрнең ялгышы, партиянең фәләненче корылтаена төгәллибез дип кабалануы һәм проекттагы хаталар коточкыч һәлакәткә китерә. Көннәрдән бер көнне станциянең дүртенче блогы шартлый...

Әгәр станция жир астында тирәндә, калын бетон һәм катлы-катлы һәм чыдамлы кургаш-графит тышча эчендә урнашкан булса, ихтимал, радиоактив нурлар шул табут эчендә бикләнеп калыр һәм мохиткә ул кадәр зыян китерә алмаган булыр иде.

Берничә көннән Скандинавиядә радиоактив яңгырлар ява, куркыныч болытлар Көнбатыш Европага да барып житә... Шау-шу куба.

Ләкин Европа шартлау булган зонадагы хәлләрдән хәбәрдар булмый. Ә монда йөз километр радиуслы мәйданнан халыкны бер-ике көндә чыгарып бетерәләр, өй жиһазларыннан һәм хәтта кием-салымнан да берни алырга рөхсәт ителми. Тәрәз төпләрендәге курчакларга тикле радиация кочагында нәүмиз кала. Бу зонага угрылар кереп йөрмәсен өчен кайсыдыр акыллы башы иң ансат юлны уйлап таба: тоталар да егермеләп авылны ут төртеп яндыралар... Һавага янә радиоактив төтен күтәрелә.

Карабаш авылы бер көн эчендә совхозы-ние белән юк ителә. Гөләндәмнең инде беркадәр аякка баса башлаган фермасы да төтен булып оча...

Зонага ликвидаторлар килеп тула. Алар атом шартлавының нәтижәләрен киметергә, станция тирәсенә бетон стеналар торгызып, бөтенесен кургашын ядрәләр белән тутырырга тиеш булалар. Шулай итеп, ашыгып төзелгән атом станциясе өстәмә миллиардларга төшә, кечерәк кенә бер ил булырлык жир-сулар хужалык әйләнешеннән чыга, елдан-ел акча йота торган туймас «кара упкын»га әйләнә. Тагын бер Карачирәмне ил экономикасы күтәрә алмаячак диләр белгечләр. Гадәттәгечә, алар ялгышалар—бердәнбер Карачирәм дә илне аяктан ега.

Хөкүмәт алмашына. Бер фиркале тоталитар система жимерелә. Ата улны, ана кызны белми торган болгавыр заман башлана. Радиоактив зонага эләккән кешеләр кайсы кая таралып бетәләр, утыз мең ликвидаторның яртысы биш ел да яшәми, нур авыруыннан үлә.

Гөләндәмнең зонада яшәп калганын бер генә жан иясе дә белми. Радиацияле зонага якын килергә дә курыккан жаваплы агайлар аны хәбәрсез югалучылар исемлегенә терки.

Радиация тәэсирендә үз организмында нинди үзгәрешләр килеп чыкканын Гөләндәм белми, белсә дә аңламас иде.

Авыру тудыручы бактерияләр, мутацияләп, төрле дару препаратларына каршы торырга «өйрәнгән» шикелле аның организмы да радиоактив нурланышларга һәм, гомумән, тышкы мохит тәэсирләренә бирешми торганга әйләнә. Ә баш миендә өстәмә бәйләнешләр хасил булу аның акыл эшчәнлеген уннарча тапкыр көчәйтә. Ул дөньяны һәм анда хөкем сөргән кануннарны үтәли күрә башлый дияргә мөмкин. Шул ук вакытта Гөләндәм уй-фикер көче белән әйберләргә физик тәэсир ясарга—аларны кагылмый-нитми генә күчереп куярга, юктан бар итәргә һәм юкка чыгарырга өйрәнә. Бу сәләтнең сихергә һәм күз буугa бәйләнеше булмаса да, асылда ул аннан кайтыш түгел икән. Ул фикер көче белән башка кыяфәткә керә, төсен алмаштыра, ягъни үз теләге белән ябалак булып та, күбәләк булып та күренә ала...

Менә шушыларны укыгач, Гыйлемдар «параллель жир»дәге Гөләндәмнең үзебезнең жир кызы Ак әбигә (Гөлгенәгә) игезәк тиеш икәнен аңлады.

Бер мәл, атом шартлавыннан соң күп еллар үткәч, Гөләндәм—Ак әби балалар йортын һәм директор Мишәрәков яшәгән өйне барып карый. Заманында таза нараттан ике катлы итеп салынган балконлы, калай

түбәле чибәр өй, тышкы яктан күмерләнгән, ә кайчандыр ятимә бала юып азапланган тәрәзә пыялалары, яшен сугудан ахры, эреп, яшел борчак булып җиргә тамганнар... Бер тәрәзә төбендә педагогнын «трофейный», ягъни кайчандыр нимес офицеры кесәсеннән табылып, әйләнеч юллар белән татар авылына килеп җиткән көмеш портсигары ята. Көмеше күптән каралган, өстәвенә ул инде үтә радиоактив, аңа кагылырга да ярамый торгандыр. Хәер, Гөләндәмгә бернинди дә радиация куркыныч түгел-түгелен...

Карачирәм радиациясен кичергән кешеләр инде күптән вафат—гөнаһсыз сабыйлар да, айнымас колхоз рәисе дә... Ә Мунча күле чекистларыннан Гөләндәмгә таныш булган бәндәләрнең икесе дә наркоманиягә әсир төшеп, озак яшәмәгәннәр. Шуларга әләк ташып яткан фахиш директор Мишәрәк Карай-Морза белән аның хатыны эчүгә сабышып үлгәннәр иде.

Зона җәһәннәм тыюлыгына әйләнгән.

Мондагы әкәмәт хайваннар: әкияттәгедәй икешәр-өчәр башлы еланнар, канат урынына тырнаклы тәпи үскән кошлар, мыраулый торган ерткыч бүреләр, эт баш-сыер аяклар, өч күзле яшел (хлорофиллы) сарыклар, адәм тавышы белән сөйләшә торган мәче башлы ябалаклар, берәр метр озынлыктагы симез суалчаннар, аларны ашый торган үтә зур ерткыч кырмыскалар, эре инәле шәмәхә чыршылар, зәһәр исле сиреньнәр, көтмәгәндә корбанын кочып ала һәм чагып үтерә торган тере кычыткан агачлары... коточкыч зур үрмәкүч...

Үзен радиация белән газаплауга түзә алмыйча, гөнаһсыз табигать саташып тудырган азманнар болар. Биологиядә мутантлар дип атала торган гарип ярымтыклар монда атлаган саен очрый иде. Геннары буталып беткәнгә, гомерләре озын түгел, күрәсең, яшәү шартларына җайлаша алмыйлар. Үләнсез урман куелыклары шул азманнарның зәгыйфь сөякләре белән түшәлгән,—аяк баскан саен чытырдап уалып калалар.

Бу тирә йөз километрлы даирәдә чәнечкеле тимерчыбык белән киртәләп алынган, киртәнең биеклеге өч метрга җитә. Селәүсен, тиен кебек хайваннар чикне бозмасын өчен киртәнең ике ягында да агачлар киселгән. Тыюлык зонаның эчендә ярты чакрым киңлектәге «божра»—сөрелгән җир, аны әледән-әле агулап торалар, анда берни үсми, бер генә җанвар яки бөҗәк тә яши алмый. Бу божрадан тышта чакрым саен, ягъни үзара күз күремендә каравыл каланчалары тезелешеп тора. Анда көне-төне снайперлар һәм ликвидаторлар утыра. Болар теге якка да, бу якка да бер генә җан иясен дә үткәрмиләр. Үтерелгән хайваннар һәм кош-корт кургаш биләүләргә төреп җиргә күмелә. Шунысы мәгълүм, аларның калдыклары әле мең ел буена бөтен тереклеккә үлем куркынычы белән янаячак.

Ак әби белән кичке сөйләшү аеруча җитди булды.

—Миннән дә, ерак галәмдәге Гөләндәмнән дә ялмавыз карчык чыгарга тиеш иде..,—диде Ак әби, көрсенеп.—Үземдә гайре табигый көч барлыгын сизгәч, мин булачак даһиларны гына түгел, сәясәтчеләрне, фиркале түрәләрне ана карынында чакта ук һәлак итәргә кирәк дигән уйга килгән идем... Шөкер, остазларым туры юлга күндерде.

Ак әби адәмнәрне бер күрүдә таный, аларның кем икәнен һәм кем булачагын, нинди гамәлләр кылачагын белә... Күргәнче үк сизә... Киләчәк китабын укый...

—Син, бәләкәч, шарсыман яшеннең серенә төшенеп җиткәнсең диярлек... Син бу яшен чыганагын һәр өйдә булдыру турында хыялланасың. Яшен көче йортларны җылытыр, яктыртыр, әниең ашны да яшен утында пешерер дип уйлыйсың. Һәр кухарканы шул яшенне идарә итәргә өйрәтәчәксең син! Димәк, җинаятьчеләрне дә. Ә алар җирдәге тормышны һәлак итәчәк... барыбызны да... Аңлыйсыңмы?

Малай башын чайкап маташтьі. Ак әби сүзен дәвам итте:

—Күп булса ун елдан соң син нейтриноны тураклап, матдәне тулаем энергиягә әверелдерүнең математик нигезләрен эшләп бирәчәксең, ә бөтен дөньяны кулга төшерү турында хыялланган явызлар, хәзергечә әйтсәк, террорчылар моннан һичшиксез файдаланачак...—диде әби һәм тагын көрсенеп куйды.—Шул рәвешле, син залимнәр кулына абсолют корал тоттырачаксың...

Әби XX гасыр башларында яшәгән инглиз короле Георг Бишенчене искә төшерде: «Бердәнбер акыллы кеше шул булган бит ул заманнарда,—диде.—Резерфорд кебек бөек галимнәргә король матдә атомнарын таркатып уйнау тәҗрибәләрен туктатырга боера, бөтен Җир планетасын элементар кисәкчекләргә бүлеп ташлавыгыз бар сез иблисләрнең,—ди.—Йә, әйт инде, хаклы булганмы шушы надан Георг патша, әллә юкмы? Адәми затка галимлек кирәкме, әллә миһербанлы булу мөһимрәкме?

—Озын сүзнең кыскасы...,—дип йомгаклады ул сүзен,—озын сүзнең кыскасы, бүген адәмнәргә абсолют энергияне кулга иялә́штерергә иртә әле. Менә киләсе гасырда... Әйе, вакыты житкәч, без кешелек дөньясы каршындагы бу тыюны гамәлдән чыгарырбыз...

—Кем ул—без?—дип сорады Гыйлемдар.

—Күпчелек йолдыз дөньяларын, акыллы затларны берләштергән система... Бөек Божра... Галәми акыл вәкилләре...

—Ак әби, мин фән белән шөгыльләнү турында хыялланам. Фәннән башка минем яшәвемнең мәгънәсе юктыр да... Әгәр инде галәми акыл вәкилләренә барысы да билгеле икән, Җирдән читтә миннән ни файда?

—Юк, юк, без сине фәннән аермабыз!—Ак әби чак кына уйлап торды да:—Ә икенчедән, Бөек Божра вәкилләре барын да белеп бетергәннәр икән дип уйлавың—хата, дип өстәде.—Адәм барын да белеп бетерә алмый. Бөтенесен Бөек Зат кына белә. Әгәр син бер фәнни ачыш ясап офыкны киңәйткәнсең икән, яңа офык артында янә мавыктыргыч сораулар, мәсьәләләр пәйда булачак... «Кешегә чикләнмәгән хакыйкатькә, ягъни абсолют хакыйкатькә ирешү сәләте бирелмәгән, шунлыктан ул нисби хакыйкать белән канәгатьләнергә мәҗбүр»,—диләр галимнәр. Өченчедән, син...

Малай ялт итеп Ак әбигә күтәрелеп карады.

—Ә өченчедән, син әти-әниеннән һәм якыннарыннан аерылып ук бетмәссең, һич кайгырма. Тик ике яклы элемтәгез булмас...Сез бер-берегезне төштә күреп торырсыз, ә төшләрегез рас төшләр булыр.

Аннары Ак әби фикерен дәвам итте:

—Җир йөзендә җәннәт бакчасы ясыйм дип өметләнгән кешелек мәдәнияте үзе үстергән карурман эчендә адашты. Экологик һәлакәт чоры бу. Гомумән, мондый һәлакәтне Галәмдәге күпчелек мәдәниятләр кичерә. Галәм тарихына үзен-үзе аңлы рәвештә һәлак иткән цивилизацияләр дә билгеле. Менә шул чагында алдынгы дөньялар адашканнарга ярдәмгә килеп, камил шәхесләр тәрбияләргә булыша... Камил шәхесләр планетаны коткару эшен житәкли... Син менә шул күркәм затларның берсе булып житлегергә тиеш... Син бире дә әле башлангыч белемне генә аласың, сине Югары Академия көтә... Генийлар да мәктәптә укырга тиеш.

Гений дигәннән. Беләсәнме икән, бу гарәпчәдән кергән сүз татарча «җен» мәгънәсендә бит. Әүвәлгеләр һәркемнең үз «җене» була дип уйлаганнар. «Җенем сөйми», «җене карыша», «җенләнгән» дигәндә нәкъ менә шушы эчкәрге җен, асылда Фрейд әйткән күңел күздә тотыла. Балага ачышлар ясарга шушы «җене» ярдәм итә. Үсә төшкән саен «җен»нең йогынтысы кими, кеше тормышында «гакыл» дигән прагматик нәрсә дилбегәне үз кулына ала.

Генийларда кайчак «гакыл» белән «жен» парлап жигелеп эшли, тик мондый хәл сирәк булучан. Кайбер генийлардан коточкыч жинаятьчеләр чыга...

Бакыркош белән Шүрәле—роботлар, параллель планетаның бүгенге хужалары. Алар төрле формага кереп, төрле затларга әверелергә сәләтле. Асылда алар бер үк затның төрлечә гәүдәләнеше генә. Шүрәле, мәсәлән, кирелекне гәүдәләндерә, тискәре дәлилләр китеререгә ярата. Әллә каян гына алып кара күзлеген борынына элеп куйса, көт тә тор: Шүрәле берәр явыз сүз әйтеп ташлаячак...

Иң гаҗәбе шунда: Сәйярдә яшәүче роботлар бер калыптан сугылмаган, алар элек үзләренең хужалары булган төрле ил, төрле милләт үзенчәлекләрен саклап калганнар, төрле телдә сөйләшсәләр дә, «милли роботлар» арасында тел киртәләре юк икән, чөнки аларның уртак «математик» телләре бар...

Ни өчен соң роботлар үзләре өчен бөтенләй ят булган органик тереклек әһелләрен, әйтик кешелек дөньясын, һәлакәттән саклап калуны максат итеп куйганнар, дигән сорау синдә тумадымыни, Гыйлемдар?

—Туды, Ак әби.

—Чөнки космик һәлакәттән соң яңаргач, органик тереклек роботехниканы кабат тудыра ала. Яңа кешеләр хәтерендә бөтен мәгълүмат та сакланачак бит. Мин яңа кешеләр роботларны хөрмәт итәрләр, аларны «арбайтер» дип кимсетмәсләр дип ышанам.

Бу кичне Гыйлемдар бик озак йокыга китә алмыйча борсаланып ятты. Озын-озак төш күрәсе булганга икән. Төшендә ул үзләренең дачаларына бер төркем погонлы кешеләр килгәнен күрде. Тикшерергә килгәннәр. Иң беренче эш итеп, алар Гыйлемдарның бүлмәсен жентекләп тентиләр. Ни гажәп, Алтынчәчне дә чакырып сораштыралар... Вәкилләрнең берсе, ярты метрдан тәмәке исе аңкып торганы, өстәлдәге «Математика яналыклары» журналын алып, дипломатына салмакчы була. Шунда Алтынчәч, йөгереп килеп, китапка ябыша:: «Гыйлемдарның бүлмәсе элек нинди булса, шул килеш калсын. Ул кайтачак!—ди. Гыйлемдарның баһадир гәүдәле әтисе, тавышында металл чыңлатып: «Китапка кагыласы булмагыз!»—дип катгый итеп әйткәч, «Черек күл» вәкиле кул селтәргә мәжбүр була, ләкин китапны исемлегенә аерым терки, үзе Алтынчәчкә бармак яный. «Сез явыз кеше!—ди аңа Алтынчәч һәм көтмәгәндә генә: «Бүген сезнең автомобилегез ватылачак»,—дип әйтеп ташлый...

Төшенең ахырында Гыйлемдар чыннан да юл буенда кюветка ауган кара төстәге җиңел автомобиль күрде. Аның янына ашыгыч ярдәм машинасы килеп туктаган иде. Ак халатлы егетләр, жимерек машинаны каерып ачып, эченнән канга баткан, ләкин, бәхетенә, исән калган берәүне тартып чыгардылар...

Төшендәге шушы куркыныч «кадр»дан соң малай иртәнгә кадәр тыныч кына йоклады.

Ак әби иртән Гыйлемдарны вак пәрәмәч белән сыйлады. Малайның борынгы морзалар нәселеннән булган әнисе дә бәйрәм көннәрне шундый пәрәмәч пешерергә ярата иде, моны, әлбәттә, Ак әби белмичә калмагандыр.

Иртәнге аштан соң малайга тагы житди күрсәтмәләр бирелде.

Ак әбинең кулында «башлангыч белем» бирүнең ансатрак ысулы бар икән.

—Өйдә ялгыз гына чагыңда Бакыркош каршына килеп утыр да күңелеңнән генә соравыңны бир. Кошның күзләре жемелди башлар. Шул мизгелдә үк жавап синең ми күзәнәкләреңә мәңге онытылмаслык булып язылыр. Мин бакыр ярдәмчемне «лектор» дип атыйм. Ул сиңа—фәкать

синең өчен генә—лекцияләр укыр... Телисең икән, гадәти сөйләү юлы белән. Ләкин бусы бик озакка сузыла. Аңлыйсыңмы?

—Аңлыйм,—диде малай,—Ләкин көч куймыйча, бушка гына, артык җиңел бирелгән белем..? Минем баш мием гап-гади бер дискетага гына әйләнгән кебек була ич?

—Борчылма бер дә. Үз ачышларыңны син шул ансат ысул нигезендә, әмма барыбер күп тырышлыклар куеп ясарсың, балам.

Шулай да Ак әби нәрсәнедер әйтмичә калдырды шикелле. Әллә инде монда шүрәленең нинди роль уйнаганын микән?

Гыйлемдар Ак әбинең киңәшен икенче көнне үк тотарга булды—ялгыз калгач, көзге каршысына килеп утырган гына иде, Бакыркош үзе телгә килде:

—Мин синең иң элек ни сораячагыңны беләм,—диде ул гөбедән чыккан калын тавыш белән.—Син әти-әниләрең белән элемтәң нинди булачагы турында белешмәк буласың. Бу—виртуаль элемтә булыр. Сез бер-берегезне фәкать төштә генә күрәчәксез, ләкин төштә абсолют чынлык сакланыр һәм синең дә, якыннарыңның да күңеле тынычланыр дияргә мөмкин.

Гыйлемдар үзенең гуманитар фәннәр өлкәсендә, бигрәк тә нәфис әдәбият даирәсендә артта калганлыгын әйтергәме-юкмы дип торганда, Арысланбаш сүзне үзе шул якка таба борды. «Сүзне» дибез, ләкин фикерләренең күбесен ул малайга турыдан-туры, сүзсез генә тапшырды шикелле.

Бакыркош бөтен дөнья әдәбиятын белә, кирәк икән ул «Одиссея»ны, «Җөмҗемә солтан»ны, «Һамлет»ны, «Евгений Онегин»ны, «Кисекбаш»ларны, «Мастер белән Маргарита»ларны башыннан ахырына кадәр, төрле комментарийлар бирә-бирә, яттан укый ала, чөнки аның хәтере чиксез. Тик шунысы сәер, ул бүгенге Рәсәй әдәбиятын санга сукмый, һәрхәлдә ихтирам итми икән. Ул аны әдәбият дип тә атамый, чөнки бу әдәбиятта бернинди әдәп тә күрми, куллары кычыткан вакчыл һәм түбән хәттатларның «иҗат җимеше» дип кенә атый. Ә менә шуна да карамастан, иллә әдәби тәнкыйть чәчәк ата, чөнки ялганатлы мөтәтәнкыйтьчеләр бихисап. Эш хакы алу өчен аларга әдәбиятыбызны бар дип күрсәтү кирәк ич. Шәрә король турындагы әкиятне хәтерлисеңме? Анда ике алдакчы тегүче кәбестә төсле беркатлы корольгә гаҗәеп күлмәк-ыштан тегәргә алыналар. Тик, имеш, ул кием гөнаһлы кеше күзенә күренмәячәк икән. Шарлатан тегүчеләр әллә нинди затлы ситсыларны үлчәгән, кайчы белән кискән, күзгә күренмәс җеп саплаган инә белән текклән булып кыланалар, корольгә нидер кигезеп карагандай итәләр, сокланган булалар. Әлбәттә инде, болар күз буалар, чынлыкта әрфия киемнәр корольнең үзенә дә, аның министрларына да күренми... Тик барысы да киемне күргән булып кыланырга мәҗбүр, кемнең гөнаһлы йә ялганчы булып каласы килсен? Бүгенге әдәби тәнкыйтьчелер менә шушы тегүчеләр шикелле инде... Бәрәч, король шәрәтән ич! дип кычкырган гөнаһсыз сабый гына күренми гипнозланган укучылар арасында. Хәер, Хәйдәр Әлим дигән бер зыялы вөҗдан иясе бу хакыйкатьне читләтебрәк булса да әйтеп биргән иде. Шөпшә оясына таяк тыгып айкаган шикелле булды ул... Дәрәҗәле тәнкыйтьчеләр, дәррәү күтәрелеп, Хәйдәр Әлим өстенә ябырылдылар, аны яклаучыларны да чагып бетерделәр.

Җәмгыятьтә Хәйдәр Әлимнәр, Зөлфия Бәйрәшевалар саны билгеле бер критик массага житкәч, шөпшәләр һәм соры кортлар җиңелер, алдартаз җөйчеләр һәм тиресбит мөтәгалимнәр сәхнәдән куып төшерелер. Ләкин бу критик масса үзеннән-үзе барлыкка килмәячәк. Хәер, бу хакта соңрак махсус әңгәмәбез булыр...

Бакыркош Гыйлемдарга турыдан-туры мәгълүмат тапшыруын дәвам итте:

—Һәр сәнгать әсәрендә зурмы-кечкенәме ачыш булырга тиеш. Әсәргә бәя биргәндә иң беренче таләп шул.

Шунда кинәт кара күзлек кигән Шүрәле телгә килде:

—Яки теге, яки бу мәсьәләне ябып куеш. Аннары. Рус әдәбияты Көнбатыш әдәбиятының шәүләсе булса, татар әдәбияты рус әдәбиятының сыек күләгәседер. Татар әдәбияты—«өйрәнчек шәкерт» кенә, нәтиҗәдә «куян шулпасының шулпасы» килеп чыга. Остазыннан уздыра алмаган шәкертнең бәясе бер тиен. Кыскасы, хәзерге татар әдәбияты тулы канлы әдәбият түгел... Сәбәбе нидә,—беләсенме?

Шүрәле бу сорауны кемгә биргәндер,—билгесез. Шуна күрә ул үз соравына үзе җавап бирде:

—Сәбәбе бик гади, егетләр. Җаһиллек. Хәтта икеләтә җаһиллек, чөнки автор агай үзен ялангач дип санамый, ә тәнкыйтьчеләр анадан тума әдипнең күзгә күренмәс күлмәк-ыштанын җөйләренә тикле мактап, йә балагындагы үтүк сырында гына кимчелек тапкандай булып кыланалар. Шунысы аяныч: менә шушындый алдартазларга ышанучылар да табыла. Совет чорында татар әдипләре өчен матбугат мәйданы җитәрлек түгел иде, ә бүгенге көндә язучылар өчен мәйдан кирәгеннән артык киң, шунлыктан җитлекмәгән гарип әсәрләр дөнья күрә. Егерменче гасырда бер сатирик: «Әдәби алгарыш нәшер итәлә торган журналлар санына кире пропорциональ»,—дигән иде. Ул хаклы. Кибет киштәләре сатылмыйча яткан татар китапларыннан сыгылып-сыгылып тора. «Кайбер китапларны яхшы эш хакы түләсәләр генә укырга була»,—дигән ди бер корректор. Озын сүзнең кыскасы, әдипләрегез киръксез эш белән шөгыльләнәләр, баксаң, халык җилкәсен кимереп яталар... Аларның каләмен илһамнан бигрәк матди мәнфәгатьләр йөртә.

Тарихи романнарыгыз укырга яраксыз. Әкият ярым әкият алар. Бармактан суырып алынган ялган, хәбәрдарсызлык җимеше...

Әкиятләр... Мин бүгенге әкият авторларының кулларын тәеп, кытыклап үтерер идем, кабат бер авыз сүз язмаслык итәр идем мин аларны. Алишка да канатлы хыял җитмәгән, ул очарга дип талпына гына. Ә аннан соңгы әкиятчеләрнең планкасын яңа тәпи йөри башлаган бала да атлап кына уза бит.

Сәясәткә, ялган милләтчелеккә кереп баткан әдипләрне жәллим. Димәк, дим, ул бичараларның иҗат чишмәсе саеккан, кипкән, ә чамасыз зур «минлек»ләре тынгы бирми, көн саен үзенә сокланып йә көнләшеп караучыны, үзенә табынучыны эзли. Аларның көндәлек ризыгы—кол һәм җаһилләрнең күндәмлеге, көндәшләреннән уздырырга омтылу... Теге ... Иосиф Джугашвили да берәр көндәшен таптап измәгән көнен заяга үткәрдем дип санаган диләр.

Сез, татарлар, практик тормышта ифрат тар карашлы, бүгенге көн белән, күп дигәндә иртәгесе көн белән генә яшисез. Иртәгене «ишәк кайгырткан» дисез бугай әле. Сездә беренче урында тамак кайгысы... мал-мөлкәт, акча кайгысы... Гали материяләр турында уйланырга яратмыйсыз сез... Авыр тарихыгыз сезне шундый кол итеп тәрбияләгән.

Шүрәле сүздән туктап калды. Аннары, кара күзлеген каядыр яшереп, сынар мөгезен бора-бора суырып чыгарды да, аңардан төребкә ясап, куышына әллә нинди хуш исле тәмәке тутыра башлады.

Ә Бакыркош, берни булмагандай, бая өзелгән нотыгын әүвәлгечә тавышсыз гына дәвам итте:

—Сәнгать кешесенең аерылгысыз хасияте—балалык сыйфаты. Еш кына сәнгатькяр адәм баласына тиеш бәхеттән өлешсез кала, шуңа күрә сакаллы сабыйларның маңгаенда—шеш, күз төбендә—фонарь күгәреп торыр, ә җаннарында бетәшмәс яра... «Сабыйлар кебек булыгыз...», «Күңелләре пакь булганнар бәхетле» кебек Инҗил сүзләре бөтен инсаният өчен уртак

хакыйкать бит югыйсә.

Шүрәле-явыз, төребкәсен кабызып, зәңгәрсу төтенен бер тапкыр ләззәтләнеп суыргач, янә кара күзлеген табып киде. Сүз капчыгын бушатып бетермәгән икән әле:

—Бүгенге чынбарлык сабыйларны да балачак бәхетеннән мәхрүм калдыра,—диде.—Хәзерге балалар ана кулы җылысын тоеп житкермичә, катырак куллы ата тәрбиясен дә күрмичә үсәләр һәм ... кеше булып, көрәшче булып житлекмиләр. Адәмнәр арасында ирдарлык бетеп килә. Ир-ат арасында феминизация—«катыншаклану» процессы бара. Хатын-кызлар исә, киресенчә, буыннан-буынга ир-ат сыйфатларын үзләштереп, ирдәүкә азманнар санын арттыралар. Алар чын мәгънәсендә чалбар киделәр: футбол-хоккейда гына түгел, иң аяусыз бокста да «зәгыйфә женес» үзенең мускулларын күрсәтеп өлгерде инде. Сәхнәне пәрдәсез мадонналар, лолиталар, пугачевалар басты...

Кешеләрнең мең еллар буе тупланып килгән әхлак кагыйдәләрен онытуы тоталитар режим шартларында җәмгыятьнең икегә бүленеп яшәвеннән килә. Халыкның бер өлеше еллар буе иректән төрмә рәшәткәләре белән аерылган зоналарда яшәп, гуманлык дигән нәрсәне, кеше тормышының илаһи бүләк икәнен оныта. Иреккә чыккач, бу кешелексезлек йогышлы чир, кизү кебек геометрик прогрессия буенча тарала... Житмеш еллык коммунистик ялган китергән зыянны оныту өчен янә өч буынның кичүе зарур. Кайсыдыр бер ялагае Ленинны «иң кешелекле кеше» дигән, ә бит төптә Ленин—иң кешелексез кеше, СССРда пролетариат исеменнән канлы репрессияләрне башлап җибәрүче.

Әйткәнемчә, кешелек кауме генетик тирәнлектә нигездә ике сыйныфка—инде берничек тә төзәлмәслек җинаятьчеләргә һәм сабыйларча беркатлы эшчәннәргә—эргоголикларга бүленде. Беренчеләре—сорыкорт тормышы алып баралар, эшчәннәр хисабына яшиләр. Бу факт философ Герберт Уэллсның «Вакыт машинасы» дигән әсәрендә аеруча кискен итеп тасвирлана. Ахырда җинаятьче морлоклар ялмавыз андрофагларга, ягъни кеше ашаучыларга әйләнеп, баласымак дәрәҗәгә төшкән беркатлы элойлар белән ризыклануга күчәләр, аларны махсус фермаларда асрыйлар, тәрбия итәләр, әйбәтләп ашаталар, курчак кебек киендерәләр...

Бүгенгесе көнне морлок сыйныфы финансистлар кауме белән тәнгәл.

Сездә бүген ике төрле цивилизация яши: бар көндезге цивилизация, бар—төнгесе. Төнге, яшерен цивилизация—ул криминал, бандитизм, угрылык, паразитизм. Уэллс әйткән элойлар—көндез яши, ә морлоклар—төнге (яшерен) ерткычлар. Адәм сурәтендә булсалар да, алар инде кешелек сыйфатын җуйганнар. Аларны тәрбияләү, мәдәниләштерү яки кулга ияләштереп маташу мөмкин нәрсә түгел.

Планетага кем хуҗа? Сезме, әллә төнге морлокалармы? Кем—кемне? Кешелек дөньясы каршында менә шушы сорау тора. Морлоклар хакимлеге белән көрәшү өчен иң элек менә шушыларны аңлау зарур. Ә бит тәкъва битлек кигән морлоклар Думада да утыра, Ак йортта, Кремльнең үзендә дә ... Кем—кемне? Баһадирлар кайда? Кайда үзләрен корбан итәргә әзер Данколар? Бу хакта пәйгамбәр галим Иван Ефремов та уйланган. Укыгыз, кайта-кайта укыгыз аның «Үгез мизгеле»н! Укыгыз брадәр Стругацкийларның «Алла булу җинелмени» романын! Азимовны укыгыз, Карел Чапекны өйрәнегез. Әйе, Антон Чехов, Галимҗан Ибраһимов, Әмирхан Еники кебек язучыларны һичшиксез белергә кирәк. Ләкин алар пәйгамбәр үк түгел, классик әүлия гына.

Тик сезнең буын хәтта аларын да укымый инде, сез башкатыргыч детективларга, «матур әдәбият» дип атала торган буш әкиятләргә, гыйшык

романнарына багынасыз. Сез йомшак һәм зәгыйфь элойлар... Чыннан да, бәлки сез яшәргә дә хаклы түгелдер инде? Бәлки, жырыгыз жырлангандыр инде? Тарих сәхнәсенә морлоклар менәчәктер, ә хезмәт ияләре аларның колларына әйләнергә тиештер?

Мең ел буе качып-посып катакомбада (бистәләрдә) яшәгән морлок каүме хәзер бөтендөнья финанс империясе төзеде. Сез—бичара элойлар, икенче сорт адәмнәр. Тегеләр—баш булырга яралган, алар «сайланмыш» халык.

Фажига тагы да тирәнрәк, ахрысы.

Заманында Америка президенты Рональд Рейган СССРны «Яманлык империясе» дип атаган иде. Ул чак кына ялгыша: СССР абсолют яманлык империясе иде. Бүген исә сәйярләләр бөтен Жир планетасын «Яманлык планетасы» дип атый алалар, чөнки яманлык чире Россиядән бөтен Жир йөзенә таралды.

Малкуарлык һәм жинаятьчелек чире бик тиз йогучан.

Бинибая явызлык һәм гаделсезлек зинданнардан ирекка чыкты һәм бичара элойларның жилкәсенә менеп атланды.

Ирекле һәм ирексез дигән зоналар арасындагы чик жуела бара. Алар, бер-берсеннән чәнечкеле тимерчыбык белән аерылса да, бу чик шартлы бер нәрсә генә булып калды. Төрмә кануннары һәм тәртипләре белән бергә, тормышыбызга һәм гомумәдәби телгә кешелексез төрмә теле үтеп керә. Шуңа килеп життек ки, әгәр дә яманлыкны бизмәнгә салып үлчәп була торган булса, ирекле зона тәлинкәсе басар да иде әле.

Галим-голәмә халкы адәми затны homo sapiens дип йөртмәктә. Янәсе «гакыллы кеше» була инде. Юк, әлегә адәмнәр бу исемгә лаек түгел. Менә әгәр атом афәтеннән котылу, исән калу һәм планетаны коткару юлын тапса, адәми зат «һomo sapiens» дигән дәрәжәне күтәрә алачак. Ак әби менә шушы изге максатка хезмәт итә. Әйе, ул Жир планетасында фән үсешен беркадәр,—кирәк кадәр генә,—тоткарлый, юкса дәһшәтле субатом коралының эреле-ваклы Һитлерларга—Сәддам Хөсәеннәргә, Кем-Синнәргә, Суганныкыларга һәм башка шашкыннарга эләгүе бар... Яңа корал яшел Жирегезне жансыз таш өеменә, йә булмаса комета-мазарга әйләндереп, бөтен Кояш системасын бүсеп ташларга бик мөмкин... Чөнки әгәр Жир тузан болытына әйләнә калса, Кояш системасы гаиләсендә миллион еллар буена тотрыклы килеш калган гравитация көчләре һәлакәткә китерергә мөмкин.

Жир—сезнең космик йортыгыз. Асылда сез табигый космик станциядә яшисез. Атмосфераның, елга-күлләрнең, гомумән, әйләнә-тирә мохитнең чисталыгы һәм язмышы сезнең ничек хужалык итүегезгә бәйле. Арал диңгезен кешеләр харап итте. Израилнең мактанычы булган Үле диңгез дә ел саен бер метрга саегып бара һәм тиздән тозлакка әйләнәчәк. СССРдагы күмәк хужалыклар, ягъни колхозлар, зур-зур терлек асрау фермалары, миллионлаган тавык житештерә торган фабрикалар экологиягә гаять зур зыян китерделәр. Мондый эре хужалыклар—гайре экологик, димәк ки, гайре экономик та...

Тыелгысыз үсә барган цивилизация планетадагы биологик балансны бозып, ике гасыр эчендә Жирне чүплек башына әйләндерде. Шәһәр тирәләрен карагыз. Шәһәр чүплекләрен. Анда үрчегән күселәрне. Балыксыз елга-күлләрне ташлап, шәһәр чүплекләрендә туклануга күчкән бихисап акчарлакларны, исәпсез-сансыз карга-козгыннарны, янадан кыргыйлашкан эт өерләрен...

Беләм, илдә үтә сабыр мөселманнар изге Мәһдинең кайтып гаделлек урнаштырганын көтеп яшиләр. Ә хыялый һәм ялкау Рәсәй, тулаем алганда, Иблис-Воландның әйләнеп кайтканын зарыгып көтә... Мастерның кайтканын... Маргаританы...

Шүрәле, тыны беткәндәй, сүздән туктап калды. Анын да күкрәгендә чын адәми хисләр тулып ашкан иде, күрәсен..

Монарчы тыныч кына Гыйлемдарга джемпер бәйләп утырган Ак әби, ниһаять,сүзгә кушылды:

—Чыннан да безнең иң якын максат—экологияне яхшырту,—диде ул, сүзне башкага борып.—Ерак перспективага килсәк, тормышынын икенче яртысын ваклый башлаган Кояшта кире кайтаргысыз картаю билгеләре пәйда булганчы чарасын күреп өлгерергә кирәк безгә. Кояшыбыз суына бара, чөнки анын үзәгендәге ягулык—гидроген кимегәннән-кими. Берничә миллиард елдан соң Кояш Кызыл гигант булып кабарачак, хәтта Жирне дә йотачак... Аннары Кояш, газ тышчасын читкә ыргытып, бәләкәй генә Ак кәрлә йолдызга әверелер... Хәер, Жиргә һәлакәт белән яный торган башка куркынычлар да житәрлек...

—Сез нинди куркынычларны күздә тотасыз, Ак әби?—дип сорады Гыйлемдар бик житди кыяфәттә.

—Менә боларын инде без янә Шүрәле агайдан сорыйк,—диде әби.—Бу мәсьәлә белән ул махсус шөгыльләнгән иде...

Шүрәле, шуны гына көтеп торгандай, үзенен хәтәр фаразларын тезеп китте:

—Безне тагы да дәһшәтлерәк космик һәлакәтләр көтә,—дип башлады ул.—Күктә Киек Каз юлына ин якын торган икенче бер галактика—Андромеда томанлыгы бар. Ул безгә сәгатенә 400 000 км тизлек белән якынлашып килә. 3 миллиард елдан сон ике галактика бәрелешәчәк. Бу—котылгысыз.

—Бу бәрелешү ничегрәк булыр сон? Кояш системасы нишләр?

—Хөрмәтле шәкертебез Гыйлемдар, монда төп ике сценарий уйналырга мөмкин. Беренчесе: гравитация көчләре тәэсирендә Кояш, үзенен гаиләсе белән бергә, галактикадан читкә атылып чыгып киткән очрак. Ул чагында безнен планета исән калырга да мөмкин. Алдан ук чарасын күргәндә Жирдәге тереклекне дә саклап калып булыр иде.

Икенчесе—Кояш ике галактика кушылунын эпицентрына эләккән очрак. Бу вакытта галактикалар үзәгендәге ике кара упкын бергә укмашачак. Жирнен атмосферасы бушлыкка таралып бетәчәк, океан-диңгезләр кайнап, аларнын суы пар булып космоска очачак, ә Жир шары, хәзерге Меркурий планетасы шикелле, тереклек итү өчен яраксыз эссе чүлгә әйләнеп калачак.

Оптимист Бакыркош телгә килде:

—Кешелек дөньясы «космик кышны» исән-имин уздырыр дип өметләнергә һәм шуна омтылырга кирәк. Монын өчен кешеләргә Һәм, гомумән, жир тереклегенә вакытлыча наноформага күчеп, үлчәнешсез нуль-ноктага әйләнеп торырга мөмкин булыр иде. Мондый үзенә бер төрле үле тереклеккә яки терек үлемгә һичнинди космик һәлакәтләр дә куркыныч түгел. Тереклек дигәндә мин органик тереклекне генә күздә тотам, чөнки роботлар, илаһи сәбәпләр аркасында, моннан мәхрүм. Күрәсез, кешегә робот кирәк булган шикелле, ясалма роботларнын мәнге яшәеше өчен дә табигать үзе тудырган кеше заты кирәк.

Инкыйраздан котылу чарасын, илаһи гакыл ярдәмендә, сез—адәми гыйлемдарлар табарга тиеш.

Малай озак уйлап тормады, бик тиз фикерен әйтеп ташлады:

—Әгәр Галәм бер киңәеп, бер кысылып, бөтенесе юкка чыгып һәм кабат туып, цикллар кабатланып тора икән, анда гакыл ияләре дә кат-кат туып торган булырга тиеш. Чиксез озын эволюция дәвамында Галәмдә сез әйткән мәсьәләне инде хәл иткән мәңгелек цивилизацияләр дә булырга тиеш түгелмени? Минемчә, ихтималлык теориясе мона юл куя.

—Син безгә шул затларны эзләргә киңәш итәсеңме?

—Әлбәттә, Ак әби. Мәсьәләнең иң ансат чишелеше шушы булырга тиеш!

—Ләкин ул да бик үк ансат түгел, Гыйлемдар. Аны хәл итүгә, ихтимал, миллион еллар китәр.

—Ул вакытта әле Кояш критик яшькә җитмәгән булыр... Без—Җир хуҗалары—өлгерәчәкбез.

—Ә өлгермәсәк? Галәмдә гадәттән тыш куәтле акыл ияләре булырга тиеш дигән фикер фараз гына бит? ...

—Димәк, безгә бер үк вакытта космик һәлакәтләрдән мөстәкыйль рәвештә котылу чараларында эзләргә кирәк.

Бакыркошның яшел күзләрендә ут кабынды:

—Сез нәкъ материалистларча фикер йөртәсез..,—диде ул.—Сез Галәмдә Алла яки Бөтендөнья гакылы дигән иң көчле фактор булырга тиешлеген исәпкә алмыйсыз...

«Алла» сүзен ишеткәч Гыйлемдарның уйга калганын күреп, Ак әби сизелер-сизелмәс кенә көлемсерәгән шикелле тоелды. Күрәсең, әби дөрес җавапны белә, ләкин малайдан мөстәкыйль фикер көтә иде.

Пауза шактый озакка сузылды.

—Әй-йе,—диде ниһаять Гыйлемдар, тәмам өлкәннәрчә кабаланмыйча гына.—Бу фактор мәсьәләне тамырдан үзгәртә бугай... Тик боларны мин аңлап бетермим...

—Моның өчен Алла төшенчәсен даһи Ньютон, Гегель яки суфилар салган мәгънәдә анларга кирәк,—диде Ак әби.—Боларын син киләчәктә үзләштерерсең... Син әле монда—минем куышта башлангыч белемне генә алдың... Калганы—Академиядә булыр.

—Академия? Ә ул кайда?

—Еракта, бик еракта икәнен генә әйтә алам. Аны «Инкыйразга каршы Академия» дип атыйлар... Мин үзем дә белемемне шунда камилләштердем, балакаем. Сине без шунда озатырбыз.

—Кайчан...?

—Тиздән, Гыйлемдар. Син инде күп нәрсәне белдең... Син көрәшче булырга әзер.

Асылда Ак әби көрәшче һәм пәйгамбәрлеккә кандидатлар гына тәрбияли һәм аларны «Космик үзәк»кә озата икән. «Үзәк» дигәне—әлеге Галәмара инкыйразга каршы академия. Аны уңышлы тәмамлап чыгучылар үзләрен теләсә кайсы затка «әверелдерергә» сәләтле, алар чын могҗиза эшли алалар. Бу Үзәк барлык Галәмнәр өчен, гадәттә һәр дөньяга аерым җитәкчеләр әзерләү белән шөгыльләнә. Ә менә Җир кешесеннән тәрбияләнгән пәйгамбәр, табигатьнең гап-гади капризы аркасында булса кирәк, башка барлык дөньяларда да хезмәт итә ала, ягъни ул универсаль.

Җирдә яшәүче кешеләр җәмгыяте, роботларның туган планетасы тарихын кабатлый башлап, монда да финансистлар кауме көч алгач, роботлар цивилизациясе җирдәге бу тарихи хатаны булдырмаска ниятли. Роботлар иң сәләтле, иң өметле адәм балаларын үзләре янына алып, көрәшчеләр тәрбияләргә керешәләр... Кешеләргә алмашка киләчәк яңа буын физик чыдамлык ягыннан роботларга тиң булырга тиеш, ләкин алар биологик сәләтләрен саклап калачак, алмаш буында җенесләр һәм бөтен прогрессны алга әйдәкли торган мәхәббәт хисе дә, гуманлылык сыйфаты да сакланыр. Яңа финансистларга каршы котылгысыз сугыш та гуманлы булырга тиеш. Менә шушы мәсьәләне хәл итә алырлык адәми затлар роботлар планетасында тәрбияләнә...

Кешелек дөньясы белән робототехника берләшкән цивилизация мәңгелек

тереклекне тормышка ашыра ала. Мондый цивилизацияне наноцивилизация дип атарга мөмкин. Ихтимал, кирәкле мизгелдә ул үлчәнешсез һәм үзгәрешсез бер ноктага әйләнеп тә тора алыр иде...

Жир планетасына бүген тимер мускуллы спорт мастерларыннан, «аяк уены» уйнарга маһир ярымшәрә биючеләрдән яки чытлык сәхнә жырчыларыннан—кыскасы, бәдәни рәхәтләрне генә сөючеләрдән бигрәк, ижтимагый көрәш осталары, гаделләр гаскәре кирәк. Аларны каян алырга? Ничек житештерергә? Кайда тәрбияләргә? Моны Жирнең үзендә эшләү мөмкин түгел, мона бөтен дөньяны чорнап алган финанс пәрәвезе һәм күп санлы криминал режимнар мөмкинлек бирмәячәк. Димәк, көрәшчеләрне Жирдән читтә тәрбияләү зарурлыгы килеп туа. Галәми гакыл нәкъ менә шунын белән шөгыльләнә дә. Син—Гыйлемдар—фидакарь көрәшче булып житешергә тиеш, монын өчен менә дигән кандидат син... Галәми гакыл шундый кандидатларны берәмтекләп эзләп таба. Ә алар бик күп кирәк... Һәрхәлдә мен генә житми, әйтик, жир йөзендәге оешкан криминалга каршы тора алырлык көчле рухлылар—пассионарийлар кимендә халык санынын 15 проценты кадәр, ягъни миллионнарча булырга тиеш. Фәкать шул вакытта гына уңышка ирешеп булачак.

—Ә ни өчен мине сайладыгыз? Вундеркиндлар беткәнмени?

—Безгә, гакыл һәм әхлак күрсәткечләренен югары булуыннан тыш, кандидатның генетик сафлыгы да мөһим. Гади генә итеп әйткәндә, синең геннарың нормаль, хромосомаларында һәр аминоацид үз урынында... Син абсолют сәламәт, Гыйлемдар. Сиңа кызыл авызлы коммунистлык чире дә, карамилләтчелек хастасы да йокмаган.

«Инкыйразга каршы Академия»дә чагында да син ватаныңдагы жәмгыять тормышыннан хәбәрдар булырсың, ләкин үзең Жиргә берни дә хәбәр итә алмассың, элемтә бер яклы гына булыр. Шулай да син саф мәгънәгә—психотрон болытына әйләнеп, әти-әниләреннең төшенә гел матур булып керерсен, аларны мин дә юату юлын табармын... Алар сине исән дип уйлыйлар һәм, дөресен әйткәндә, хаклы да булачаклар. Киләчәктә сез кавышачаксыз...

Ак әби Гыйлемдарга йоклар алдыннан үтә күренмәле башлык киеп ятарга кушты. Башлык кабель белән тирмә түбәсендәге антенна көзгесенә тоташкан иде. Шуның аркылы Гыйлемдар галәми информация кыры белән бәйләнып, йокыда килеш программ лекция тыңларга тиеш икән.

Бу нәсихәт-программа Гыйлемдарның ике атна буена Ак әби тирмәсендә алган белеменә йомгак ясарга тиеш иде.

Ләкин иртә белән уянгач, Гыйлемдар бу нәсихәтләрнең бер генә сүзен дә исенә төшерә алмады. Шул ук вакытта малай үзенең ниндидер олуг хакыйкатьләрне үзләштергән һәм аңлаган булуын тоя, моңа ышана һәм белеме белән горурлана иде. Күрәсең, программада шулай каралгандыр—бу белемнәр Гыйлемдар хәтерендә нәкъ кирәкле мизгелләрдә калкып чыгарга һәм жимеш бирергә тиештер.

Аның каравы уяну белән Гыйлемдар өстәлдәге Шүрәле статуэткасы торган урында ауган агачка утырып ял итүче берәүнең төсле фоторәсемен күрде. Ачык төстәге цивиль костюм кигән бер ир-егет. Түшендәге алтын нишанга гомумжир хәрефләре белән «President» дип язылган. Кем бу? Аның йөз чалымнарында Гыйлемдар әтисенә дә, әнисенә дә охшашлык барын абайлап алды. «Бу бит мин,—дип уйлады ул, аптырабрак.—Утыз-кырык елдан соң мин нәкъ шушы сурәттәге кебек булачак микәнни?»

Фоторәсемдәге ир көлемсери кебек тоелды.

Гыйлемдар өстәлдәге Бакыркошның юкка чыкканын да абайлады. Димәк, әбинең ярдәмче роботлары эшлисе эшләрен башкарганнар инде...

Чаршау белән бүленгән аш-су пешерү почмагында Ак әбинең әвәрә булып йөргәне ишетелә, ул тагы тәмле таба исләре чыгарган иде. Бүген

нинди бәйрәм микән?—дип уйлап куйды малай.

Менә бер вакыт әби: «Тор, матурым, пәрәмәч әзер, кайнар чакта ашыйк әле бергәләп»,—диде.

Бу бәйрәм Гыйлемдарның «башлангыч мәктәп»не—Ак әби мәктәбен тәмамлавына багышланган иде, әлбәттә.

Пәрәмәчтән соң Гыйлемдарның кәефе тагы да хушланды. Ул яшь бәдәненең һәр күзәнәге куаныч һәм гайрәт белән тулганын тоя һәм таулар актарырга атлыгып тора иде.

Менә Гөлгенә әби малайны әүвәлгечә шау чәчәккә күмелгән аланга алып чыкты да аның кулына йомшак төенчек тоттырды.

—Истәлеккә булыр,—диде ул, ләкин төенчектә ни барын әйтәсе итмәде. Ихтимал, «Сәйяр» планетасында климат салкынчадыр, Ак әби шуңа күрә Гыйлемдарга джемпер бәйләгәндер...

Шул мизгелдә иртәнге күктән түбәнтен генә яшен ташы очып узды, аның якты эзеннән түгәрәк аланны кап урталай ярган куш салават күпере пәйда булды.

Төсләре чиратлашып ике тапкыр кабатланган көянтәнең нәкъ уртасында ун-унбер яшьләрдәге бер кыз бала басып тора иде. Ул чиксез гаҗәпләнгән зуп-зур күзләрен чәчәкле алан өстеннән йөртеп чыкты. Сак кына атлап җиргә төште... Аяк астына караган иде, ак чүпрәккә төрелгән уймак кадәрле генә төенчек күрде. Үзе дә аңышмастан, аны иелеп алды, төенен чишеп җибәрде. Ни гаҗәп: чүпрәккә яшәреп беткән бакыр балдак төрелгән иде. «Моны кем югалтты микән?—дип пышылдады Ниса.—Бу балдак аңа җәүһәр кашлы йөзектән дә кадерлерәктер... Әллә соң әкияти сихерле балдак микән?»

Кызыйның түшенә, аның ефәк тасма белән үргән толымына ак күбәләк килеп кунды... Әйтергә онытканбыз: Нисага бер маэмай ияргән иде. Маэмай, башын кыегайта төшеп, акыллы күзләре белән күбәләккә карап алды, аннары үзләренә таба йөгереп килүче малайны күреп, чын адәми канәгатьлек белән елмайган төсле булды.

—Ниса! Алтынчәч!—дип кычкырды Гыйлемдар ерактан ук, куанычы эченә сыймыйча.

—Мин монда, мин монда, Вундеркинд!—дип көттермәстән җавап бирде Ниса.

Менә алар—Җир балалары—җитәкләшеп, Акбайны да ияртеп, салават күперенә аяк бастылар һәм бәллүрдәй җемелдек төсләрдә эреп, психотрон болытына әверелделәр... Шул болыт эченнән Гыйлемдарның:

—Хуш, сау бул, әбкәй!—дигән тавышы ишетелгәндәй булды.

Чәчәккә кунып калган күбәләк исә, фәрештә канатларын җилпеде дә, янадан Ак әби кыяфәтенә керде. Хәер, ул һич тә әби түгел, бәлки яп-яшь татар кызы Гөлгенә-пакизә иде хәзер. Салават күпере эреп югалгач, ул яулык почмагы белән күз яшьләрен сөртте. Үзе елмая иде. «Карурман аша ... яхшы атлар кирәк лә үтәргә»,—дип, «Галәм инкыйразга каршы» җырын борынгычалап, яшь, янгыравык тавыш белән көйләп кабатлады Гөлгенә:

—Юлыгыз уң булсын! Әнкәемнең балдагы сезгә бәхет-сәгадәтләр китерсен!

Ап-ак каен урманы эчендә, берсеннән-берсе уздырып, кошлар сайраша, кайдадыр бер яшь тавышлы кәккүк тырышып-тырышып адәмнәр гомерен саный, ләкин һич кенә дә мәңгелекнең очына чыга алмый иде...



Айрат
Суфиянов

# ТОРМЫШ ЙӨРӘГЕНӘ—ЧӘЧӘК...

## Серле абага

**Үзем салган төнге сукмагымнан
Атлап барам, күктән ай бага.
Бер могҗиза көтеп урман тынган.
Чәчәк аткан серле абага.**

**Үкенмим дә гомер үтә диеп,
Сүтә-сүтә еллар төргәген:
Сайрый һаман—тереклекне сөеп,
Кош илһамы йөрткән йөрәгем.**

**Тантанада бөтен тирә-ягым.
Йолдызлардан энҗе чәчелә.
Дөрли-дөрли яна уй учагым.
(Хәерле төн сиңа, уяу чагым!)
Ялкын теле үрли чәчемә.**

**Сулыш алып, туфрак таңны көтә,
Орлык көтә һәрбер карышы.
«Яшим!»—дигән тойгым—иркенлектә,
Юкка чыкмас өчен карышып,
Үләннәрнең тамырына төшә,
Наратларны коча җил булып.
Абагалар белән исәнләшә,
Дәшә төнгә туган ил булып.**

**Чорлар аша киләчәккә күчә,
Үткәннәргә карый борылып...
Шул тойгыда күкрәп, яшьнәп яшә,
Мине кеше иткән горурлык!**

Айрат СУФИЯНОВ (1958)—*шагыйрь; «Кылычлы җил»исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши.*

Мин ышанмыйм—кире кайтмас өчен
Китәремә бу җир йөзеннән:
Чәчәк аткан абагамның көче
Таңга тамар тойгым күзеннән...

***

Балачактан кайткан ак болытлар,
Исәнмесез! Мин таныдым сезне—
Тургай булып сайрап тавыш биргән
Могҗизалы, серле күк-диңгезне
Мин таныдым ... Ак болытлар узды ,
Ак болытлар мине танымады.
Әллә инде садә чәчәгемне
Сулдырдыммы—ерак таңымдагы?

Үкенечем ярсып, авыр сулап,
Башын ташка ора—шуны уйлап...

***

Могҗизасын күргән чагыммы?—
Туктап калды вакыт агымы.
Яфрак төшеп тынды учымда.
Басып тордым балкыш очында,
Җаным белән күккә ашыпмы?
Саташыпмы, Җирдән качыпмы?
Ләйлә, күреп, зәңгәр киңлеккә
Чиксезлектән дәшкән иреккә
Мәҗнүннәрчә мин дә гашыйкмы?
Үзем белмәгән дә үлчәмгә
Бербөтенлек биргән гамь-ямьгә
Тоташыпмы? Серен ачыпмы?
Бәхилләшкән кошлар моңыннан
Тыным куырылды—шашыпмы?
Күкнең капусы да ачыкмы?

...Төшенермен кебек соңыннан...
Тик әлегә берни аңламыйм.
Күк белемен бирче, Аллам!—дим.

## Алтын балык

Тыелгысыз ургый-ургый елга ага,
Җил чыкканда дулкыннарын кага-кага.
Ә ярында көчкә-көчкә сулыш алып,
Чәбәләнә әкияттәге алтын балык.

Бер мизгелдә үткән иде бу араны—
Буш кармакмы эләктергән бичараны?
Кояш күреп, сикергәнме әллә күккә—
Балык өчен хыял булган биеклеккә?!

Ни булганын аңлый алмый алтын балык,
Дөньяда көч юк микәнни коткарырлык?
Саңагына һава җитми, су һавасы,
Ник, ичмасам, тартып алмый су анасы?

Яр читенә йөзеп килә зур бер җәен.
Ләззәт имеп үткәрә ул тормыш җәен.
Һәр үләксә җаны сөйгән сые аның—
Каршылыксыз көтеп тора туенганын.

...Тыелгысыз ургый-ургый елга ага,
Җил чыкканда дулкыннарын кага-кага.
Ә ярында бәргәләнә мескен язмыш,
Бер язмышта—бер диңгезгә сыймас сагыш.
Күзен ача ялгыш кына тамчы тисә,
Караңгылык тарафыннан җилләр иссә...

...Кайнар комда көч-хәл белән сулыш алып,
Ята әллә алтын балык, әллә халык...

***

Елау—бәхет... Тирән яшеренгән
Хәсрәтләрең чыга яшең белән.
Елау—бәхет... Ә мин хәтерләмим
Соңгы яшем кайчан тамганын да.
Төер булып болгавыр чор тора
Әллә йөрәк... әллә тамагымда...

***

Тук елмаеп, кошка атты
Тидерер ният белән
Һәм кавышты кичермәслек
Гөнаһ-җинаять белән.
Ләззәтле какты йөрәге:
Сусагандыр шул канга...
Уйламады—аттым диеп
Үзем—үземнең җанга.
Ятмы шәфкать төшенчәсе
Кыйбласыз—адашканга?

Ач күзләнеп корбан эзләп,
Ерткычлыктан шашканга?
Ишетмәде, кызган диген
Мескен кош гозерен дә.
Янмады соңлап булса да
Үкенеч күмерендә...
Ә кош булып яратылса
Киләсе гомерендә?!
Галәм—бөҗра... һәрбер язмыш
Ходайның хөкемендә.

* * *

Басмаган әле тәнемне
Кабернең салкын ташы.
Үземне эзләп талпынам
Көчле давылга каршы.

Давыл артында мине дә
Көтәдер бәллүр бәхет—
Күбәләк килеп кунса да
Уала торган тәхет.

Татыдым тормыш ачысын,
Татыдым төчесен дә...

Йөрәккәем һаман әле
Мәхәббәт бөресендә.

Ташкын булып җырым туа
Газаплы төшләр күреп:
Бу тормышның йөрәгенә
Чәчәк кадәрмын кебек...

Күк астында бер нәрсә дә
Мәңгелек түгел, беләм.
...Ярала бөтен яхшылык
Тиңдәшсез газап белән.



## Иделбикә

### Гомер симфониясе

ПОЭМАДАН ӨЗЕК

**Җыр-дәрьямның башы? Чишмә ташы—**
**Горур Урал итәгенең чаты—**
**Кемнәр сыенмаган ул җиргә?!**
**Чукынудан качкан күп мөселман,**
**Минем токымым да әнә шуннан,—**
**Баш имәгән төшкән җәбергә.**

**Нәсел җебен эткәй барлый килгән,**
**Хәтер дәфтәрендә болай дигән:**
**«...Токым башы Чистай җиреннән:**
**Алты гасыр чамасыдай элек**
**Без—Чистополь өязеннән китеп,**
**Өем-өем качкан тәредән...»**

*** * ***

**Җирле башкорт халкы тора-бара**
**Күпсенгәндер—кискенләшкән ара,**
**«Килмешәк»кә булмый якты йөз.**
**Горур татар кимсенүгә түзми,**
**Изелүдән чыгу җаен эзли—**
**Ерак офыкларны күзли күз.**

**Байкыбаш, Яугилде, Көндәшледән,**
**Уразайдан—Бөре өязеннән**
**Унҗиде гаилә җыелып,**
**Унсигезенче гасыр башларында**
**Эз төшмәгән урман якларына**
**Кучәргә уйлашкан бер булып.**

**Күз алдына баса үткән заман:**
**Ерткыч оя корган кара урман**

Урын булган яңа өйләргә.
Исем кушылмаган якты елга—
Бал, балыклы җиргә юлыгырга,
Исем алып, килгән ярдәмгә:

Карурманны кисеп, авыл коргач,
Төпләрен яндырып, җир сугаргач,
Исем кушкан Яңа Мөслим, дип.
Халык Чистай токымыннан булгач,
Анда якты Ык елгасы аккач,
Елгасын атаган Эк диеп.

***

Әткәй мәрхүм хәтер дәфтәрендә
Унҗиде гаиләнең һәрберен дә
Тәгаенли нәсел атасын.
Кемнәр таралышкан һәр нәселдән,
Кемнәр авылыбызда бүгенгедә...
Тик киткәннең белми кайдасын.

Гомре буе авыл шәҗәрәсен,
Һәрберенең тәүге фамилиясен
Әткәй дәфтәрендә саклады.
Истә: җыелышып тик ир-атлар,
Өстәл тирәсендә аксакаллар
Шаулап-гөрләп буын барлавы.

Дулкынланган алсу йөзле картлар
Бусаганы ләззәт чигеп атлар,
Гүя үтеп Ходай кушканын:
Татар нәселләре буталмаган,
Никах шәригатьчә юлдан барган—
Саф саклаган халык үз канын...

## Ак кәгазь

Нинди аңга юлыгырсың, ак кәгазь?
Пакь җанлымы бирер синдә пакь вәгазь?
Бушка юрап, тезмәсләрме шагыйрьләр,
Ах, вәземле, әмма тозсыз шигырьләр?

Йә ябышыр өсләренә якты хат,
Эчке зәрен уртаклашса адәм-зат...
Тагар бәгъзе асыл затка яманат,
Көнчеллеген җиңә алмый ничә кат.

Вәйранлыкка өндәмәстер—зиһене бар:
Ун дистә ел гомернең дә чиге тар.
Чарлар өчен тәңре биргән үткен чар,
Корыч каләм... Эзен котә кайчак дар...

Аңлы җаннан уңыш килер, ак кәгазь,
Син тик төргәк, таратмасаң пакь вәгазь.
Сип көчләрең—өзсен ябык калыпны,
Күтәр кулын сонып чүккән халыкның!

## «Ак калфак» гимны

*(«Ак каен» көенә)*

**Озын еллар югалышып калган,**
**Куе томаннарда ил гизеп.**
**Әнкәйләрнең ак калфагы кайтты,**
**Энҗе-сәйләннәрдән нур сибеп.**

**Әнкәйләрнең күкрәк сөте сыман**
**Ап-ак калфак—сафлык билгесе.**
**Милләтебез гамен иңдергән ул,**
**Изге тарихыбыз өлгесе.**

**Югалтмыйча саклыйк ак калфакны,**
**Көнгә сафлык яккан ак төсен.**
**Ак калфаклар сәхнәләрдән төшеп,**
**Дөнья зиннәтенә әверелсен!**

**Ак калфаклар бизи башкайларны,**
**Гүзәлләрнең ямен арттыра.**
**Ак бәрхеткә кунган ак йолдызлар**
**Берләшергә безне чакыра.**

***Редакциядән:***

*Август аенда Ульяновск (Сембер) шәһәрендә яшәүче шагыйрә, журналыбызнын күптәнге авторы Иделбикәгә (Лена Беньямин кызы Садыйкова-Сабитова) 80 яшь тула. Иделбикә—Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Дөнья авазлары», «Күнел күккә омтыла» һ. б. китаплар авторы. Русчага тәрҗемә ителгән шигырьләре дә байтак.*

*Шагыйрәне олуг гомер бәйрәме белән котлап, аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.*

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстынын беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянен электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша анын оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.



Туфан
Миңнуллин

# МУЛЛА

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМА

**Катнашалар:**

Әсфәндияр—мәдрәсә тәмамлаган яшь мулла
Самат—эшмәкәр
Мөслимә—авыл карчыгы
Вәлиәхмәт Габделхәтович } Чуртыш авылы кешеләре
Бәдретдин (Бәрттин) } Чуртыш авылы кешеләре
Налимә } Чуртыш авылы кызлары
Гөлназ } Чуртыш авылы кызлары
Сәлахетдин—Чуртыш авылы мулласы

Лемур—жирле үзидарә рәисе
Әмир—участок милиционеры
Илдар } Мөслимәнең авылдагы шәһәрдән кайткан оныклары
Вилдан } Мөслимәнең авылдагы шәһәрдән кайткан оныклары
Илдария } Мөслимәнең авылдагы шәһәрдән кайткан оныклары
Эльбрус—Чуртыш авылы егете

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

*Самат әтиләренен авылдагы өе. Самат белән Әсфәндияр керәләр.*

Самат. Менә, хәзрәт, сиңа өй. Бөтен нәрсәсе бар. Газ, су кергән. Мебель дә житәрлек. Бу безнең әтиләрнең өе. Әнкәй үлгәч, әтине үзебезгә алып килдек. Бу—сина. Дөресрәге—мәчеткә. Әгәр безнең авылда төпләнергә жыенасың икән, үзеңнеке булыр. Акча сорамыйм. Китәсең икән, ничек алган өйне шулай калдырып китәсең. Тик киткәненне мина белдер.

Әсфәндияр. Зур авыл.

Самат. Элек тагын да зур иде. Та-

рала. Авыл зур, ләкин тәртип юк. Сине эзләп табуым да, беләсең, шуның өчен. Монда, әйткәнемчә, мулла бар. Ләкин тәртип юк. Мәчет салдыр диделәр. Салдырдым. Йөрүче юк. Мулла үзе дә мәчетне гает көннәрендә генә ача диләр. Формаль якларын мин мөфти белән, тиешле кешеләр белән сөйләшермен, кыскасы, бу авылның хуҗасы—син.

Әсфәндияр. Авыл советлары, колхоз бардыр бит.

Самат. Идарә итә алмый торган үзидарә бар, колхоз юк. Аның урынына нәрсәдер оештырдылар бугай. Кыскасы, син—хуҗа.

Әсфәндияр. Алай булмыйдыр ул.

Самат. Булдырсаң, була. Булдыра алмасаң, кит, гаепләмәм.

Әсфәндияр. Сез шундый итеп тасвирладыгыз авылны, монда кешеләр түгел, ниндидер иблисләр яшидер сыман.

Самат. Иблисен белмим, шайтаннар җитәрлек. Хуҗа бул. Үзидарә дә, колхоз урынына калган нәрсәнең дә председательләре синнән куркып торсыннар.

Әсфәндияр. Куркытып кешене иманга китереп булмый.

Самат. Ничек икәнен үзең карарсың, өйрәтеп тормыйм. Өйләнгәнчениткәнче сиңа бит ашарга пешереп, өй җыештырып торырга да кеше кирәк. *(Тәрәзәдән карый да, тәрәзәне ачып)* Мөслимә апа! Кер әле, Мөслимә апа... *(Әсфәндияргә)* Бик чиста апа. Авылга килгән нәчәлстволы ул ашата. Борчылма, хезмәт хакың җитәрлек булыр, сәдака хисабына гына яшәтмәбез, ә сәдаканы мәчет файдасына ал. Бирсәләр, әлбәттә. Өйрәнсеннәр сәдака бирергә. Өйрәт. *(Кергән Мөслимәгә)* Мөслимә апа, менә мәчеткә мулла алып кайттым.

Мөслимә. Әстәгъфирулла *(Әсфәндиярне, карый-тикшерә).*

Самат. Мондый чакта әстәгъфирулла димиләр, Мөслимә апа, сөбханалла диләр.

Мөслимә. Бигрәк яшь күренә түгелме соң?

Самат. Сина гына яшь күренә ул. Мәдрәсә тәмамлаган белемле хәзрәт ул. Исеме—Әсфәндияр.

Мөслимә. Сәлахетдинне кая куясыз соң?

Самат. Теләсә, Әсфәндияр янында йөрер. Сина шуны әйтергә чакырдым, Мөслимә апа. Хәзрәтебез әле өйләнмәгән, егет кеше. Ул монда яшәячәк. Аны ашатып, өен җыештырып, керләрен юып торырга хатын-кыз кирәк. Син күршедә генә. Бер көтү малай үстердең. Нәрсәнең ничек икәнен беләсең. Әсфәндиярне сина тапшырам. Акчаң җитәрлек булыр.

Мөслимә. Туктале, акча дип... Казан кешесеме соң син, улым?

Әсфәндияр. Әйе, мин Казанда үстем.

Мөслимә. Шәһәр кешесенә ошап булыр микән соң?

Самат. Ошарсың. Бал-май эчендә үскән малай түгел. Ятим. Әби-бабайларының пенсиясенә үскән.

Мөслимә. Белмим инде тагын. Син әйткәч каршы килеп булмас инде. Рәхмәт инде сина, авылны онытмыйсың. Күперебез юк иде, күперле иттең. Ярар, Винирага да әйтермен. Ач тормас, Алла боерса. Берәр кыз да табып бирербез. Тик менә рәтле, юньле кыз гына калмады авылда. Хисмәтуллада бар иде, ул да аракы эчә башлаган, хәерсез. Унҗидесе дә тулмаган килеш.

Әсфәндияр. Авыл кызы эчәме?

Мөслимә. Авылныкы шул. Ярый, борчылма, Самат. Синең сүзенне аяк асты салмабыз. Чыгыйм әле мин, казлар карарга чыкканыем. Кичен безгә генә кереп ашар инде, алайса. *(Китә)*

Самат. Ишеттеңме, хәзрәт?

Әсфәндияр. Авылны мин башкачарак күз алдына китерә идем.

Вәлиәхмәт. *(Ишекне кин итеп ачып керә. Аңа Бәдретдин ияргән)* Мине эзләмиләр икән, димәк, мин кирәкмим. Казан байларына сәлам бирдек. Бәрттин, исәнләш.

Бәдретдин. Әссәләмәгаләйкүм.

Вәлиәхмәт. Менә шулай. Син, Бәрттин, беркайчан да исәнләшергә онытма. Исәнмесез, Самат Закирович.

Самат. Исәнмесез.

Вәлиәхмәт. Бу егетне кем дип белик?

Самат. Ул безнең авылның мулласы.

Вәлиәхмәт. Мулла?! Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала.

*(Саматка)* Син алып кайттыңмы?

Самат. Әйе, мин.

Вәлиәхмәт. Әллә мөфти дә булып алдыңмы?

Самат. Синең белән акыл сатырга минем вакытым юк, Вәлиәхмәт.

Бәдретдин. Вәлиәхмәт түгел, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Самат. *(Бәдретдингә)* Ә син нәрсә көпә-көндез эчеп йөрисең?

Вәлиәхмәт. Төнлә эчсә, аның эчкәнен кем күрә, әйеме, Бәрттин?

Бәдретдин. Шулай, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Вәлиәхмәт. *(Әсфәндиярга карап торып).* Мулла... Әйе, муллалар күбәйгән саен гонаһлылар арта. Исемегез ничек?

Әсфәндияр. Әсфәндияр.

Вәлиәхмәт. Мин—Вәлиәхмәт. Вәлиәхмәт Габделәхәтович Әхмәтгалиев. Кайчандыр шушы авылдан сөрелгән Мөхәммәтгали мулланың оныгы. *(Бәдретдингә күрсәтеп.)* Менә бу мәхлүк минем бабамны сөргән һәм мәчет манарасын кискән бәндәнең оныгы. Әйе, диген Бәрттин.

Бәдретдин. Әйе, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Вәлиәхмәт. *(Саматка күрсәтеп.)* Менә бусы да минем бабамны, ягъни шушы авыл мулласын сөргән һәм мәчет манарасын кискән адәми затның оныгы.

Самат. Житте инде, Вәлиәхмәт.

Вәлиәхмәт. Син мине туктатма, Самат. Мин синең офисыңда утыра торган хезмәткәр түгел. *(Әсфәндиярга.)* Самат әфәнде бабасының гонаһларын юар өчен авылда мәчет салдырды. Бәрттин, кил әле монда. *(Бәдретдин килгәч)* Бу мәхлүк бабасының гонаһларын юып йөри. Минем акчага. Үз акчасы юк. Нәселләре белән хәерчеләр һәм теләнчеләр. Дөрес әйттемме, Бәрттин?

Бәдретдин. Дөрес, бик дөрес, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Вәлиәхмәт. Үзе адашасы килгән кешегә юл күрсәтергә кирәкми. Киттек, Бәрттин. Сине күрергә килгән кеше үзен күрсәтергә дә килә. *(Кырт борылып ишеккә таба атлый.)*

Самат. Вәлиәхмәт, туктагыз әле.

Вәлиәхмәт. Туктадык.

Самат. Миннән курыкмасагыз да сез канатыгызны бик үк җәймәгез, ярыймы.

Вәлиәхмәт. Бөркет канатын җәймәсә, җиргә мәтәлеп төшә *(Чыгып китә. Ана Бәдретдин ияргә.)*

Самат. Бу кеше белән сак бул. Бабасы Магнитогорскийга сөрелгәч, шунда туып үскән кеше ул. Биш ел элек авылга кайтты. Берүзе яши. Өе тулы китап. Коръәнне яттан белә диләр. Эчми, тартмый, бүтәннәрне эчертә. Авылда кибет ачкан. Кибетендә аракыдан башка нәрсә юк диләр. Тәүлек буе сату итә. Каратэ буенча разряды бар бугай. Үзе әйтте. Дөресмедер, анысын белмим. Ярый, мин китәм. Телефон номерын беләсең. Сиңа бер үтенечем—зарланма. Зарланганнарны, җылак-мескеннәрне яратмыйм.

## II күренеш

*Вакыт кич. Әсфәндияр намазлык өстендә ястү намазын укый. Сәлахетдин керә. Ишек төбендә Әсфәндиярның намаз укып бетергәнен көтә.*

Сәлахетдин. *(Әсфәндиярның намазлыкны җыйганын күреп)* Әссәләмәгаләйкем...

Әсфәндияр. Әссәләмәгаләйкүм. Түрдән узыгыз, бабай.

Сәлахетдин. *(Түргә узып утыра. Дога кыла.)* Ишеттем дә менә килдем әле. Мин бу авылда мулла булып торам. Самат яшь мулла алып кайткан диделәр. Шулай тиештер. Үзе салдырган мәчет. Сәлахетдин атлы мин. Мәдрәсә-фәлән бетергәнсеңдер инде.

Әсфәндияр. Әйе.

Сәлахетдин. Хәзерге мәдрәсә бетергәннәр «вахабислар» була инде ул. Без дә болай, Аллага шөкер, «Әлхәм» белән «Колһуалла»ны беләбез. Кирәк чакта «Ясин»ны да чыгабыз. Үлем-җитем булганда үзебезчә җирлибез дә. Болай зарланмыйлар иде. Сәдака дигән нәрсә юк инде.

Әсфәндияр. Сезне аракы эчә дип сөйлиләр.

Сәлахетдин. Самат әйткәндер инде. Кем эчми инде хәзер. Без бит фронтта эчәргә өйрәнгән халык. Унҗи-

де дә тулмаган иде сугышка киткәндә. Сәгать саен үлем. Ул яшьтә үлем күреп торып әллә ниләр эчәрсен. Эчелә инде. Бүтән кешесе табылмагач алындым инде. Аллага шөкер, мәетне дога укып озатабыз. Син инде монда кирәкмәгәнне тынлап йөрмә. Үз эшенне бел. Авылга үзең сыман вахабисларны җыя күрмә.

Әсфәндияр. Кем соң ваhhабист?

Сәлахетдин. Кем булсын, шул тиррур ясаучы инде. Өйләр шартлатып йөрүче. Хәер, авылда шартлатырлык өе дә калмады инде. Бетә инде авыл.

Әсфәндияр. Нигә бетә соң ул?

Сәлахетдин. Кирәкмидер инде өстәгеләргә. Шәhәр кирәк булгач тәзиләр бит. Авыл белән нишлисен. Җир сукалап интеккәнче сатасың да аласың ризыкны Америкадан. Монда бер тавык боты ашар өчен ел буе интегәсең. Шәhәрдә саттың да алдың Америка ботын. Рәхәтләнеп кимер... Болай, мәет юарга җирәнмисеңме?

Әсфәндияр. Юып караганым юк.

Сәлахетдин. Авылда мулла мәет юганда гына кирәк инде ул. Җирәнсәң, ул эшне мина калдыр. Мин өйрәнгән. Әз-мәз акчасы да шул үлем-житем булганда гына килә. Казанда ясин чыкканга ике йөз сум бирәләр ди. Без монда егерме тәңкәгә эшереләбез.

Вәлиәхмәт. *(Керә).* Әссәләмәгаләйкүм. Нәрсә, сәдака бүлешәсезме?

Әсфәндияр. Кеше өенә рөхсәт сорап керергә кирәктер.

Вәлиәхмәт. Рөхсәт сорап нәчәлство янына гына керәләр. Түрә булырга җыенмыйсындыр ич?

Әсфәндияр. Әдәп дигән нәрсә бар. Сез бит мулла оныгы. Ул әдәпсез булмагандыр.

Вәлиәхмәт. Оho! Бабайлар ялгышын оныклар төзәтә.

Әсфәндияр. Бабагыз ялгышканмыни?

Вәлиәхмәт. Ялгышкан. Кара мужикның аңгыра башына аң кертергә тырышкан. Шуның өчен мужиклар аны авылдан сөргәннәр. Алачыкта туган алга чыкмый. *(Сәлахетдингә.)* Ә син монда нишләп утырасың?

Сәлахетдин. Килдем әле менә.

Вәлиәхмәт. Йөрмә монда. Яшисең килсә, үләргә өйрән.

Сәлахетдин. Син дә мәңгелеккә килмәгән, Вәлиәхмәт. Кайттың да монда...

Вәлиәхмәт. Кайтып нишләдем? Әйтеп бетер, кайтып нишләдем?

Сәлахетдин. Авылга хуҗа булдың.

Вәлиәхмәт. Булдым. Сарык көтүе көтүчесез булмый.

Сәлахетдин. Мыскыл итмә инде ул кадәрле.

Вәлиәхмәт. Итәм. Сез мыскыл ителергә яратылган. Сез бетәргә тиеш. Бер югалган оят табылмый. Мин сезнең авылыгызга ясин чыгарга кайттым.

Сәлахетдин. Ярый, китим инде мин, кем...

Әсфәндияр. Әсфәндияр...

Сәлахетдин. Әйе, Әсфәндияр. Ә син, Вәлиәхмәт, бик азынма. Кешегә ясин чыгу җинел нәрсә түгел ул. *(Китә.)*

Әсфәндияр. Нигә сез шундый усал?

Вәлиәхмәт. Усал гына түгел— явыз.

Әсфәндияр. Минем янга шуны исбатларга килдегезме? *(Паузадан сон.)* Нигә шулай текәлеп карап торасыз?

Вәлиәхмәт. Өйрәнәм. Мин бит психолог. Синең кем икәнлегеңне күзенә карап беләсем килә.

Әсфәндияр. Белдегезме соң?

Вәлиәхмәт. Чамаладым. Куркак малай түгел син. Тәвәккәл күренәсен. Казандагылар белән ызгышырлыгың бар. Югыйсә, анда власть белән бәлеш төбен бүлә алмый интегәләр.

Әсфәндияр. Бүлешер власть монда да бар шикелле.

Вәлиәхмәт. Мондамы власть? Бер яртыга социализмны саттылар, ике яртыны куйсаң, капитализмны сатачаклар. Үз җирен сатып эчкән мужикта нинди власть...

Әсфәндияр. Ә сез?

Вәлиәхмәт. Мин власть түгел.

Әсфәндияр. Әлегә мин сездән башка властьны күргәнем юк. Мин дә бит психолог. Имам-хәзрәтләр психология фәнен белергә тиешләр. Уйлавымча, бу авылга бүген сез хуҗа.

Вәлиәхмәт. Шуннан?..

Әсфәндияр. Шуннан шул. Сез-

дәге властьны мин алырга телим. Сез авылны бетерергә, ясин чыгарга кайткан, мин аны яшәтергә килдем.

Вәлиәхмәт. Әй, сабый, сабый... Мәеткә аспиринның файдасы юк, энекәш. Әгәр проблема ясиндә генә булса. Авылның хуҗасы мин түгел. Авылның хуҗасы—азгынлык, бозыклык, имансызлык. Мин шуларны күреп куанучы гына. *(Ишек шакыйлар.)*

Әсфәндияр. Керегез *(Налимә керә. Кулында бидон).*

Вәлиәхмәт. Әнә, хуҗаларның берсе.

Налимә. Нәрсә булган? Нигә ыржаясың?

Вәлиәхмәт. Прости, тётка, ыржаймыйм, яратып әйтәм.

Налимә. *(Бидонын идәнгә куеп.)* Кем диден? Нинди праститутка мин сина, ә? Күрсәтермен мин сина праститутка. Авызына берне тондырырмын. Тешләренне җыеп ала алмассын.

Вәлиәхмәт. Йәле, тондырып кара. *(Налимә кизәнеп торып Вәлиәхмәтнен йөзенә суга. Вәлиәхмәт аптырап калган.)* Нишлисен син? Нишлисен син, ә? *(Налимәнен җилкә тамырыннан эләктереп ала).*

Налимә. Җибәр!.. Җибәр!..

Әсфәндияр. *(Налимәне Вәлиәхмәт кулыннан аерып ала. Вәлиәхмәткә).* Чыгып китегез.

Вәлиәхмәт. Вот кабәхәт, әтисе кебек кешегә суга.

Әсфәндияр. Чыгып китегез, Вәлиәхмәт Габделәхәтович. Үтенеп сорыйм.

Вәлиәхмәт. Вот кабәхәт... *(дип сөйләнеп чыгып китә).*

Налимә. Күрсәтермен мин сина праститутка. *(Муенын тотып.)* Буып үтерә язды, заразы.

Әсфәндияр. Башлап үзегез суктыгыз бит.

Налимә. Әйтмәсен теләсә нәрсә. Рәтле сүзе юк. Өе тулы китап. Үзе тагын мулла оныгы диләр. Вәт хәшәрәт, нәрсә ди, ә. Кеше әллә нәрсә уйлар. *(Стенадагы көзге янына килеп чәчен төзәтә.)* Кара син аны... *(Бидонны кулына алып.)* Менә Мөслимә апа аш җибәрде. *(Кесәсеннән төенчек алып.)* Ипие монда. Кайда икән боларның савыт-сабалары. *(Шкафтан тәлинкәләр, кашыклар табып ала.)* Бөтенесе бар, берсен дә алмаганнар. Самат абыйдан куркалар, бүтән булса әллә кайчан чистартып чыгарлар иде.

Әсфәндияр. Урлашаларммыни авылда?

Налимә. Кайда урлашмыйлар соң. Урлыйлар да сатып эчәләр. *(Тәлинкәгә аш сала-сала.)* Бар, кулынны ю. Кранда су бар. Сөлге шунда. *(Кулларын юып килгән Әсфәндияргә.)* Утыр, бисмилланны әйт тә аша. Бидонны алып чык диде Мөслимә апа *(Урындык алып ишек янына барып утыра).* Аша, оялма.

Әсфәндияр. *(Өстәл янына утырып.)* Сез кем?

Налимә. Ничек кем? Налимә.

Әсфәндияр. Мөслимә апаның кеме?

Налимә. Кеме булсын, күршесе. Аша әйдә аша, оялма. *(Әсфәндиярнен ашау рәвешен күзәтеп торып.)* Син чынлап та мулламы?

Әсфәндияр. Ә нигә?

Налимә. Сакалың да юк. Сакалсыз мулла булмый инде.

Әсфәндияр. Аның каравы, түбәтәем бар.

Налимә. Түбәтәйне хәзер бөтен кеше кия инде.

Әсфәндияр. Каты суктыгыз теге кешегә. Үтерүегез мөмкин.

Налимә. Үтерерсен аны.

Әсфәндияр. Өлкән кешенен йөзенә сугу кыз кешегә килешми.

Налимә. Нинди өлкән кеше. Очраганда беренче сүзе—«кайчан үләсең инде». Бөтенесе курка аңардан, мин генә курыкмыйм.

Әсфәндияр. Кыз кешегә барыбер сугышу килешми.

Налимә. Кызлар диеп торсаң монда.

Әсфәндияр. Кулыгыз да саллы ахырысы.

Налимә. Сабан туенда гер күтәрәм, кул көрәштерәм.

Әсфәндияр. Ничә яшь соң үзегезгә?

Налимә. Нигә кирәк ул сиңа?

Әсфәндияр. Болай гына. Бик яшь күренәсез.

Налимә. Кара моны. Олылар кебек сөйләшеп утырган була. Үзең әле миннән дә яшьтер. Озак ашыйсын икән син.

Әсфәндияр. Ризыкны хөрмәт итәргә кирәк.

Налимә. Озак ашапмы?

Әсфәндияр. Тиз ашасаң тәмен белеп өлгереп булмый.

Налимә. Барыбер бер корсакка керә инде ул. Сине монда Самат абый алып кайттымы?

Әсфәндияр. Юк, Путин җибәрде.

Налимә. Нәрсә-ә-ә-ә?

Әсфәндияр. Ә нигә?

Налимә. Урыс ич ул мулла җибәрергә... И-и, котыртып утырган була...

Әсфәндияр. Чынлап. Чуртыш авылы кешеләре мәчеткә йөрми икән, барып кайт әле ди.

Налимә. *(Көлеп).* Дурак. Миннән көлгән була.

Әсфәндияр. Чынлап менә.

Налимә. Син мәчеткә йөрттерәсенме?

Әсфәндияр. Йөрмәсәләр, хәбәр ит, милиция җибәрттерәм, диде.

Налимә. Бик исләре китә безнең авылда милициягә. Учаскавай үзе безнең авыл малайлары белән эчеп йөри.

Әсфәндияр. Бер дә аек кеше юк мәллә районыгызда?

Налимә. Бар да инде ул. Күбесе эчә шул.

Әсфәндияр. Сез дә эчәсезме?

Налимә. Минме? Дурак. Нишләп мин эчим. Сүзеңне үлчәп сөйлә.

Әсфәндияр. «Дурак» сезнең яраткан сүзегезме әллә?

Налимә. Әйтелә инде шунда. Ачуланма тагын.

Әсфәндияр. Исемегез ничек әле?

Налимә. Ничек булсын—Налимә.

Әсфәндияр. Матур исем.

Налимә. Әти кушкан инде—Галимә, Сәлимә, Налимә... Аша инде тизрәк.

Әсфәндияр. Булды бугай бу. Рәхмәт сиңа, Налимә.

Налимә. Аминыңны тот *(Әсфәндиярнын эченнән генә дога укыганын дикъкать белән күзәтеп).* Ә син нәрсә укыдың?

Әсфәндияр. Әлхәмделиллаһи әлләзи вә тәгамәнә, вәсаканә, вәҗәгаләнә минәлмөслимин. Биррәхмәтикә ярабби. Аллаһы әкбәр.

Налимә. Матур икән. Мина да язып бирерсең. Ату мин битне генә сыпырып куям *(Өстәлдәге табак-савытны җыештырганда Әсфәндиярның күзләрен күреп туктап кала).* Нишлисең, ә? Нигә шулай карап торасың?

Әсфәндияр. Чибәр сез, Налимә.

Налимә. Алай итеп карама бүтән. Ату ашарга кертмим. *(Табак-савытларны кухня ягына алып чыгып китә. Бәдретдин керә).*

Бәдретдин. Әссәләмәгаләйкем.

Әсфәндияр. Вәгаләйкем әссәләм. Әйдә, түрдән узыгыз Бәдретдин абзый. *(Бәдретдиннен кеткелдәп көлгәненә гаҗәпләнеп.)* Нигә көләсез?

Бәдретдин. Түрдән уз дисең бит... *(Паузадан соң.)* Баш авырта, берәр нәрсәң юкмы?

Әсфәндияр. Нинди нәрсә?

Бәдретдин. Ни нәрсә дип... Зарифулла абыйның әче балы була иде. Калмады микән? Баш авырта.

Әсфәндияр. Вәлиәхмәт Габделәхәтовичта юкмыни?

Бәдретдин. Ул минем ишеләргә бирми.

Әсфәндияр. Сез кем соң?

Бәдретдин. Кем дип. Алкашлар инде без...

Налимә. *(Кухня ягыннан чыга. Бәдретдинне күреп).* Син монда нишләп йөрисең, алкаш? Бар. Бар-бар, йөрмә монда. *(Бәдретдинне төрткәләп чыгарып җибәрә).*

Әсфәндияр. Нигә аны куасыз?

Налимә. Йөрмәсен. Иярләштермә. Куып чыгара алмассың.

Әсфәндияр. Бу бит сезнең өегез түгел.

Налимә. Булмаса тагын. Син әле аларны белеп бетермисең. Юаш булсаң, өстеңә менеп атланалар. Тьфү, заразы. Сасытып чыгып китте.

Әсфәндияр. Ул бит сездән өлкән кеше.

Налимә. Нәрсә һаман өлкән дә өлкән. Өлкән дип әллә алдына тезләнимме. Сау бул, иртәгә керермен. Нәрсә кертим?

Әсфәндияр. Ни булса да ярый.

Налимә. Мөслимә апа әйтә, муллалар бәлеш ярата ди... Ашагач укый торган доганы язып бирергә онытма *(Чыгып китә).*

## III күренеш

*Шул ук өйдә Мөслимә, Налимә, Гөлназ. Мөслимә утырып тора, кызлар өй җыештыралар.*

Мөслимә. Мин чыгыйм, кызлар. Бөтен җирне әйбәтләп сөртеп чыгыгыз. Тормаган өйгә тычкан да ияләшкәндер. Исе сизелә.

Налимә. Карале, Мөслимә апа, моның өчен безгә түлиләрме соң?

Мөслимә. Кем түләсен, савабы булыр.

Налимә. Савабы дип ничә ел бушка эшләтәләр.

Мөслимә. Бушка эшләүнең нәрсә икәнен белмисез әле сез. Менә без эшләдек ул бушка. Элек тә акча түләмәделәр. Хәзер дә хезмәт хакыгыз әз булган дип пинсәне тиенләп кенә бирәләр. Өйрәнә тор, ияләшә тор бу өйгә. Бәлкем әле шуна кияүгә дә чыгып куярсың. Өйләнмәгән ди. Төс-кыяфәте дә, Алланың биргәненә шөкер. Абыстай булып йөрерсең.

Налимә. Кит әле. Абыстай дип ул хәтле... Син кушканга гына эшлибез.

Мөслимә. Кайтып житмәсә, ачкычын ишек өстенә куярсыз *(чыгып китә).*

Гөлназ. Карале, малай, урынын кызлар кебек җыештырган. Прастыйналары чиста. Казаннан алып килгәндер инде.

Налимә. Кәнишне. Монда кем әзерләп торсын ана.

Гөлназ. Бигрәк яшь күренә, әйеме?

Налимә. Күз читләрендә җыерчыклар күренә инде, бигүк яшь түгелдер.

Гөлназ. Көләч кешеләрнең күз кырыенда җыерчыклар була, ди.

Налимә. Миннән көлгән була. Путин җибәрде ди. Шәймиев дисә, бер хәер.

Гөлназ. Шәймиев тә мулла җибәреп ятмый инде. Ул главаларны гына җибәрә. Боларның башлыгы мөфти дигән кеше.

Налимә. *(Караватка авып).* Шушында мулла хатыны булып ятсаң, ә.

Гөлназ. Тор, бәгәрлисең. Кайтып керсә...

Налимә. Кайтып керсә, яныма ятыр. Ят әле син дә, ике кеше сыя микән. *(Гөлназны кулыннан тартып яткыра, кочаклый).* Кайттыңмы, җаным бәгърем. Муллакаем.

Гөлназ. Алай көлмә мулладан, гөнаһы булыр.

Налимә. Мулладан көлгәннен гөнаһысы юк, Аллалан көләргә генә ярамый.

Гөлназ. Тор әйдә, сөртеп чыгыйк. *(Шулчак азан тавышы янгырый. Кызлар сикереп торып, тәрәзәне ачып тыңлыйлар).*

Налимә. Карале, жырлаган кебек...

Гөлназ. Үзе микән ул?

Налимә. Кем булсын инде тагын. *(Тыңлыйлар).* Кара, бер җырга охшаган бит. *(Азаннан соң укылган дога аһәненә кушылып көйли).*

Гөлназ. Безнең татар теле укытучысы Зәки абый Мөхәммәт Пәйгамбәр татар булган дип әйтә иде бит, дөрестер ахры, иеме?

Налимә. Ана бөтенесе дә татар инде. Иван Грузный гына урыс. Әйдә, киттек. Догасын укып бетергәч кайтыр.

Гөлназ. Кайтса соң...

Налимә. Әй, көтеп торган кебек. Болай да инде... Кичә ашарына кергән идем. Күзенә ялгыш караган идем, сихерле. Кочагына кергәненне сизми дә калырсың. Илбрүснең күзе оятсыз. Ыржаеп көлә, барыбер кызлыгынны мин алам ди. Бирделәр ди, көтеп тор. Кагылып кына карасын, Казандагы дәү абыйның мылтыгы белән маңгаена тәрәп атырмын. Син беләсеңме, яратам дип миннән әйттермәкче була, үзе әйтми. Ничә кызның башына житте инде, хайван.

Гөлназ. Житкергәч житәләр инде. Синең белән мина житмиләр бит.

Налимә. Житмиләр дә... Кыз килеш картаеп та инде... Синеке килеп йөриме әле?

Гөлназ. Килә дә. Куркытканнар әле теге бандитлар. Безнең авыл кызы янына килеп йөрмә, үтерәбез дигәннәр.

Налимә. Вәт заразы паразитлар. Үзләре дә алмый, бүтән авылга да бирмиләр.

Гөлназ. Шундый нәрсә уйлап чыгарганнар ди. Чит авылга кияүгә чыгарга

жыенсаң, башта үзебезнең авыл егете белән йоклыйсың дип әйтәләр ди.

Налимә. Сиңа әйттеләрме?

Гөлназ. Әйткәннәре юк та. Әгәр бездән качып чыксаң, иреңне имгәткәнче кыйныйбыз, инвалид ир белән яшәрсең дип әйтәләр ди... Әйдә, карават астын гына сөртәбез дә... *(Карават астына иелә. Аннан гантельләр тартып чыгара).* Налимә, нәрсәләр бу?

Налимә. Куй урынына, кирәк әйбердер.

Гөлназ. Гер да бар монда Налимә.

Налимә. Йәле, Йәле... чынлап гер бит бу, ике потлы. *(Күтәреп карый.)* Әллә спортсмин микән? Юри генә мулла булып йөридер әле. *(Әсфәндияр кайтып керә. Налимә гер күтәргән килеш торараш булып катып, Әсфәндиярга карап тора. Аннан герне атып бәреп чыгып йөгерә. Аңа Гөлназ да иярә. Әсфәндияр гер, гантельләре карават астына урнаштыра. Сәлахетдин керә).*

Сәлахетдин. Керергә ярыйдыр бит.

Әсфәндияр. Әлбәттә ярый, исәнмесез.

Сәлахетдин. Әссәләмәгаләйкем. *(Утырып дога кылгач).* Түбән очның Әйзенхауыры үлгән.

Әсфәндияр. Кем?

Сәлахетдин. Шундый исемле кеше инде. Кушаматы бугай инде. Исеме белән әйтүче юк. Нииндидер ярамаган нәрсә эчеп үлгән. Уксус диме шунда. Миңа килгәннәр. Мин инде синнән узып... Ю дисәң, юармын анысы.

Әсфәндияр. Эчеп үлгән дисезме?

Сәлахетдин. Шуның белән кырыла инде халык... Нәрсә әйтәсең?..

Әсфәндияр. Нәрсә әйтәмме? Мин, Сәлахетдин абзый, эчеп үлгән кешегә ясин чыкмыйм.

Сәлахетдин. Догасыз китсен дисеңме?

Әсфәндияр. Догасыз яшәгән бит.

Сәлахетдин. Догасыз дип... ул гына да гаепле түгел инде аңа. Заманасы догасыз булгач. Яши белеп яшәмәгән икән, җәзасын тегендә алыр. Ходай үзе белер.

Әсфәндияр. Бөтен эшне Ходайга тапшырсак, без нәрсәгә кирәк соң? Без Ходай язганны халыкка житкерүчеләр. Безнең сүзгә колак салмыйлар икән, димәк, Ходай язганга каршы бармакчылар. Мин исерткеч эчеп үлгәннәргә һәм үз-үзләренә кул салган мордарларга ясин чыкмыйм.

Сәлахетдин. Алай миһырбансыз булырга ярамый.

Әсфәндияр. Ә сез миһырбанлы яшисезме соң? Килгәнемә ике көн әллә ниләр ишетеп бетердем инде. Иң миһырбанлы затыбыз Аллаһы Тәгалә, әмма ул да тәмуглар яраткан. Кешеләр моны белергә тиеш.

Сәлахетдин. Вахабис дигәч тә алай ук булырга ярамый. Син килгән кеше. Без монда бергә яшәгән. Яманы да яхшысы да үзебезнеке. Тормыш син дигәнчә генә бармый инде ул.

Әсфәндияр. Мин дигәнчә түгел, Ходай кушканча барырга тиеш.

Сәлахетдин. Ходае да инде анын иялләшкәндер. Карап тора бит... Алайса үзем юып, үзем озатам инде.

Әсфәндияр. Карагыз үзегезгә. Әмма минем фатихам юк. Исәннәр гыйбрәт алып, нәтижә ясасыннар.

Сәлахетдин. Ясамый, улым, ясамый. Берәүсе эчеп үлә, икенчесе шуның мәете өстенә эчеп килә.

Әсфәндияр. Сез үзегез дәме?

Сәлахетдин. Син, малай, алай итеп сөйләшмә. Уйлаганыңның һәрберсен кычкырып әйтү егетлек түгел. Мин эчәм икән, бисмилла әйтми генә эчәм. Шуны да бел: беркайчан да исергәнче эчкәнем юк. Рәнжеттең, энем.

Әсфәндияр. Гафу итегез. Мин сезне рәнжетергә теләмәдем.

Сәлахетдин. Теләмибез дә бит... *(Лемур белән Әмир керәләр.)*

Лемур. Керергә ярыйдыр бит.

Әсфәндияр. Рәхим итегез.

Сәлахетдин. *(Әсфәндиярга.)* Алайса, синең рөхсәтең белән озатам...

Лемур. Кемне озатасың, Сәлахетдин абый?

Сәлахетдин. Ишеткәнсеңдер, Әйзенхауыр үлгән.

Лемур. Нигә син йөрисең анда? Син хәзер мулла түгел инде.

Әсфәндияр. Барыгыз, Сәлахетдин абзый. *(Сәлахетдин чыгып киткәч.)* Рәхим итегез, узыгыз. Тик татар өенә аяк киемнәрен салып керәләр. *(Лемур ишек янына барып аяк киемен сала).*

Әмир. Панимаешь, мина аякны, фуражканы салу не положено. И минем ботинкалар чиста да. Младший лейтинант Хабриев. Участковый.

Әсфәндияр. Бик яхшы, утырыгыз. Әсфәндияр Әхмәтжанов.

Лемур. Үзидарә Председателе Лемур Сафиуллин. Үзегез килмәгәч менә үзем килдем.

Әсфәндияр. Лемур дидегезме?

Лемур. Лемур. Ә нигә?

Әсфәндияр. Маймыл исеме түгелме сон ул?

Әмир. *(Шаркылдап көлеп.)* Точно! Так... *(Өй эченә күз йөртеп чыгып.)* Документлар бардыр инде сезнен?

Лемур. Әйттем бит инде, Самат Закирович алып кайтты.

Әмир. Самат Закирович понятно. Но документлар булырга тиеш. Положено. О назначении муллой например.

Лемур. Туктале, Әмир. Әйтеп торалар бит сина.

Әмир. Падажди, падажди, Лемур.

Әсфәндияр. Ызгышып китмәгез тагын. Икегез дә салып алган.

Әмир. *(Паузадан сон.)* М-да... Значит так... Значит документлар в порядке. Яхшы. А то монда кайталар разный шантрапа. Кайсы законный переселенес, кайсы незаконный переселенес. Разбирайся тут... Кайсы үлгән черт знает што эчеп. За всех отвечай... *(Лемурга.)* Мин сина точно әйтәм, хатыны гаепле монда. Ул белгән что муж будет искать. Специально уксусны аракы бутылкасына салып куйган. Айзынхауыру что? Тапкан и эчкән и вообще. Из-за бабы пьют мужики.

Әсфәндияр. Ә сез ни өчен эчәсез? Вәлиәхмәт Габделәхәтович сыйлагангамы?

Әмир. Какой Валиахмат?

Әсфәндияр. Сезнен кебекләр өчен кибет тота бит. Көне-төне аракы сата.

Лемур. Анын рөхсәте бар кибет тотарга.

Әсфәндияр. Сезгә барысы да законно. Закон нигезендә эчәсез.

Лемур. Ты не очень то выступай, братан.

Әсфәндияр. Я вам не братан. Зарубите на носу.

Лемур. *(Урыныннан торып.)* Киттек, Әмир.

Әмир. Че ты?

Лемур. Киттек дим.

Әмир. Че ты? Куда ашыгасын. Ну подох и подох ваш Айзанхауыр. Туда и ему дорога. *(Әсфәндиярга.)* Значит, не братан. Давай, давай наводи монда порядок. Лемур—маймыл значит? Обизияна. *(Шаркылдап көлә.)* Че ты тут, Лемур, будь хозяином. Досиделся, понимаешь.

Лемур. Әмир, кит-те-ек...

Әмир. Ярый, ярый... значит документлар порядкада? Пашли, значит. *(Чыгып китә)*

Лемур *(чыга-чыга.)* Ачуланмагыз. Гафу итегез. *(Чыгып китә).*

## IV күренеш

*Жәйге төн. Әсфәндияр капка төбендәге утыргычта дөнья тынлап утыра. Кайдадыр адашып калган сарык бәрәне кычкыра, кайдадыр эт өреп куя. Кайдадыр транзистор акырталар. Мәче башлы ябалакнын чыелдап алганы да ишетелә. Ут яктысы урамга төшкән. Урамнан узучыларга Әсфәндияр күренми дә диярлек. Урамнан өч-дүрт малайны Мөслимә куып алып кайтып бара.*

Мөслимә. Шушы вакытка хәтле йөрмәсәгез, дунгызлар. Иртән уятып булмый. *(Малайлар көлешкәч.)* Ермагыз авызыгызны. Кайттылар да монда Казаннарыннан. Дуңгыз көтүчесе ясап бетерделәр әниләреннән. Вилдан! Куда пайдуш! Өйгә кайт.

Вилдан. Ну, бабушка...

Мөслимә. Бирермен мин сина бабушка. Ристан.

Вилдан. Дау ани, рано еще...

Мөслимә. Бирермен мин сина ранынны. *(Илдарга)* Син зур бит инде, нигә иярлеп чыгып китәсең. Син хужа бит, алар—кунак.

Вилдан. Мы тоже хужа. Синен внуки.

Мөслимә. Күрсәтермен внукиенны. Мулла абыегызга әйтермен дә...

Вилдан. Ул нишләтә, дау ани?

Мөслимә. Нишләтергә белер. Чокиләрегезне кисәр.

Вилдан. Нәрсә ул чоки?

Мөслимә. Атла аягынны. Кяфыр

булып беттеләр. Илтәм дә бирәм әниегезгә.

Илдария. Илтмә, бабушка. Илтмә, дау ани. *(Мөслимәнең кайсы кулына, кайсы итәгенә асылынып чыгып китәләр. Вәлиәхмәт белән Бәдретдин узып бара).*

Бәдретдин. Вәлиәхмәт, салып бир инде бераз гына.

Вәлиәхмәт. Вәлиәхмәт түгел. Иләктән чиләкне, бизәктән тизәкне аерырга өйрән.

Бәдретдин. Вәлиәхмәт Габделәхәтович, салып бир бераз гына.

Вәлиәхмәт. Әле яңа гына эчтең.

Бәдретдин. Әз саласың бит, тел очына да йокмый.

Вәлиәхмәт. Тезләнеп сора. Тормыш ул Сабан туе, Бәрттин. Кемдер көрәшә, кемдер чүлмәк вата, кемдер шуларны күреп кызык таба.

Бәдретдин *(Вәлиәхмәт алдына тезләнеп).* Әз генә салып бир. Үләм бит. *(Вәлиәхмәт кесәсеннән шешә белән стакан алып, стакан төбенә аракы сала).*

Вәлиәхмәт. Мә, лыкын. Үләр өчен егетлек кирәкми, үлә белеп үләргә егетлек кирәк.

Бәдретдин. Әз бит бу. Өстә инде бераз.

Вәлиәхмәт. Нәфес нәфислекнең дошманы, Бәрттин *(Берничә тамчы аракы өсти. Бәрттин тәмләп эчә. Вәлиәхмәт шешә белән стаканны кесәләренә тыгып куя).*

Бәдретдин. Рәхмәт, Вәлиәхмәт. Әзрәк булды инде...

Вәлиәхмәт. Исерәсең килсә, аракы эчмә, гашыйк бул. Иртүк өйгә килеп керәсе булма, ботыңны сугып сындырырмын. Теге ташны күрәсеңме? Тәгәрәтеп китер шуны. *(Бәрттин тәгәрәтеп китергән ташка утырып.)* Жырла. «Герман көе»н.

Бәдретдин. Әз генә салып бир.

Вәлиәхмәт. Жырла. Күп итеп салырман.

Бәдретдин *(Шактый ук моңлы тавыш белән жырлый).*

Атландым атның биленә,
Китттем Герман иленә:
Герман жире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.

Без урамнан үткән чакта
Күтәрелде тузаннар;
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар.

Вәлиәхмәт. Жырла, ник туктадың?

Бәдретдин.

Атландым атның биленә,
Китттем Герман иленә:
Герман жире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.

Вәлиәхмәт. Син, бөжәк, бу тавыш белән театрда жырларга тиеш идең. Син шуны әрәм итеп... Мә эч, тыгын. *(Аракы салып бирә.)* Бабаң—кабәхәт, атаң—хәшәрәт, үзең—тизәк. *(Бәдретдинне тибеп ега. Әсфәндияр түзми, торып болар янына килә).*

Әсфәндияр. Нишлисез сез?

Вәлиәхмәт: Ә-ә-ә, сез монда мыни? Өр шуңа эт булып, Бәрттин.

Әсфәндияр *(Үзенә өргән Бәдретдинне торгызып, өстен каккалый).* Бар, абзый, кайтып йокла.

Вәлиәхмәт. Өстең кагасыз, ә? Жирәнмисез.

Әсфәндияр. Ул жирәнгеч, ә сез анардан да жирәнгечрәк.

Вәлиәхмәт. Сүзеңне үлчәп сөйлә. Телеңне тешләвең бар. Син акыллы булсаң, тизәктән бизәк ясарга алынма.

Әсфәндияр. Кеше тизәк түгел.

Вәлиәхмәт. Бу авылда кешеләр яшәми.

Әсфәндияр. Бәлки сезнең бабагыз да сезнең кебегрәк булгандыр. Шуңа куганнардыр.

Вәлиәхмәт. Әй, син!.. *(Сугарга кизәнә. Әсфәндияр аның кулын тотып ала. Вәлиәхмәт Әсфәндияр кулының көчле икәнен сизеп, каратэ алымын кулланa, ләкин үзе сырты белән килеп төшә. Сүзсез генә күтәрелә. Әсфәндиярга карап тора да китеп бара. Әсфәндияр ташны күтәреп алып юл өстеннән читкә алып куя да урынына барып утыра. Налимә белән Гөлназ үтеп бара.)*

Налимә. Вәт заразы, тәки бәйләнә бит. Син мулла өенә кереп йөрисең икән ди. Керсә, аның ни эше бар, хайван. Бик исе китте ди ул мулланың безнең ишеләргә. Кичә миңа әйтә, үзең шундый чибәр, шундый сылу, ямьсез сүзләр кушып сөйләшмә ди. Дурак дигәнне дә ошатмаган, заразы дигәне дә ярамый. Ул Илбрүскә заразы дими ни дисең инде.

Гөлназ. Өендә берүзе ничек утыра икән. Клубка барырга ярамыйдыр инде аларга, иеме? Тәрәзәсеннән карыйк, нишли икән.

Налимә. Китәле, егетләр тәрәзәсеннән карап йөрергә теге...

Гөлназ. Нинди егет булсын, мулла ич ул.

Налимә. И, дурак. Муллаларның да егетләре була инде.

Гөлназ. Тот та алайса кияүгә чык шуна.

Налимә. Кит әле, нишләсен ул минем белән. Укып та булмады, Казанга китеп тә булмады. Шул Илбрусләр кала инде. Ярый ла синең егетең бер.

Гөлназ. Килмәде бит әле бүген.

Налимә. Әйдә, чыннан да карыйк әле, нишләп утыра икән. *(Әсфәндияр яшәгән өйнең капкасына таба атлыйлар. Налимә Әсфәндиярны күреп алып.)* Бәтәч! *(Баскан жиреннән катып кала).*

Әсфәндияр. Хәерле кич, кызлар. *(Китәргә борылган кызларга.)* Качмагыз инде. *(Туктап калган кызлар янына килеп.)* Менә сезнең тавышны ишеттем дә чыктым әле.

Налимә. Нәрсә сөйләшкәнне дә ишеттеңме?

Әсфәндияр. Нәрсә турында сөйләштегез соң? Кызларның сүзе серле була бит ул... Төнлә авылыгыз бигрәк матур.

Налимә. Авылыгыз ди. Авылыбыз диген. Хәзер синең дә авыл инде ул.

Әсфәндияр. Әйе шул. Бигрәк матур.

Налимә. Нәрсәсе матур инде.

Әсфәндияр. Мин кичә сандугач сайраганны тыңладым.

Налимә. Таңнан уяныпмы?

Әсфәндияр. Гөлназ нигә сөйләшми?

Налимә. Аның йөргән егете бар, ярамый.

Әсфәндияр. Сезнең юкмы?

Налимә. Юк шул әле әлегә. Киттек, Гөлназ.

Әсфәндияр. Ашыкмагыз инде. Минем үземә генә күңелсез.

Налимә. Күңелсез дип. Клубка барырга кирәк.

Әсфәндияр. Анда күңеллеме?

Налимә. Күңелле дип... Селкенәбез дә таралабыз инде. Җыен бала-чага белән.

Әсфәндияр. Егетләр юкмыни?

Налимә. Аларның егетлекләре. Киттек, Гөлназ.

Әсфәндияр. Гөлназның китәсе килми. Сез тарткалыйсыз.

Налимә. Кем тарткалый, калсын.

Гөлназ. Үзең кал, ярыймы. *(Китеп бара).*

Әсфәндияр. Сез кайтмагыз инде. Бераз утырыйк.

Налимә. Нишләп?

Әсфәндияр. Тыңлап.

Налимә. Нәрсәне?

Әсфәндияр. Дөньяны.

Налимә. Һе... Кызык икәнсең син... Мин өйрәндем теге доганы.

Әсфәндияр. Сез җырлый беләсезме?

Налимә. Юк. Мин тыңларга гына яратам. Минем дәү әтием матур җырлый, әнием дә. Минем колакка аю баскан. Мин синең җырлаганыңны гел тыңлыйм.

Әсфәндияр. Кайчан?

Налимә. Мәчеттәге радиодан.

Әсфәндияр. Җыр түгел бит ул. Азан.

Налимә. Җыр кебек инде. Мөслимә апа әйтә, сиңа егерме ике яшь ди.

Әсфәндияр. Дөрес әйтә. Сезгә ничә?

Налимә. Егерме тула көзгә. *(Урамнан үтеп барган Эльбрус Налимәнең кулыннан эләктереп ала да сөйрәп алып чыгып китә. Анда кычкырышкан тавышлар, Налимәнең чырылдап кычкырганы ишетелә. Әсфәндияр йөгереп чыгып китә. Налимәне күтәреп алып керә.)*

Әсфәндияр. Налимә, Налимә!.. *(Налимә дәшә алмый. Сыны каткан.)* Налимә... *(Налимәне кочагына алып.)* Йә, йә... Тынычлан...

Налимә *(телгә килеп).* Эчемә сукты, зарազы.

Әсфәндияр. Әйтмәгез, әйтмә андый сүзне.

Налимә. Авырта.

Әсфәндияр. Районга шалтыратыйк.

Налимә. Кирәкми. *(Сулкылдап.)* Син мине кыйнаттырма, ярыймы. *(Әсфәндиярның кочагына сыенып.)* Кыйнаттырма. Син көчле бит. Син спортсмен бит.

Әсфәндияр. Йә, йә, тынычлан, тынычлан...

Налимә. Син минем абыем бул, абыйлыларга тимиләр.

Әсфәндияр. Ярый, ярый, тынычлан.

Мөслимә. *(Кереп)* Ни булды монда?

Налимә. Мөслимә апа, минем әчемә суктылар.

Мөслимә. И Ходаем! Кайсысы инде тагын?

Налимә. Илбрус.

Мөслимә. Хәерсез. Бер ел да юк бит төрмәдән чыкканына. Әйдә, кайтабыз.

Налимә. Йөри алмыйм, Мөслимә апа, авырта.

Мөслимә. Милитсия чакырырга кирәк мөртәткә.

Налимә. Кирәкми, кирәкми.

Мөслимә. Кирәкми димә. Үтереп ташлар.

Налимә. Кирәкми, кирәкми. Хәзер, бетә авыртуы, туктый.

## V күренеш

*Әсфәндияр яшәгән йортның өй эче. Караватында чишенмәгән килеш Әсфәндияр ята. Самат кергәнне күреп торып утыра.*

Самат. Нәрсә, эш беттемени, хәзрәт?

Әсфәндияр. Әссәламәгаләйкүм, Самат абый.

Самат. Сәлам, сәлам. *(Кул бирешеп күрешкәч.)* Нәрсә, кәеф юграк мәллә?

Әсфәндияр. Болай гына...

Самат. Болай гына булса ярый. Иялләшеп беттенме инде?

Әсфәндияр. Мондыйга иялләшеп булмый. Иялләшергә Ходай язмасын.

Самат. Шулайдыр. Сәлахетдин абыйны утыртып кайттым. Мактый үзеңне. Халыкны клубка жыеп вәгазь укыгансың. Мәчеткә жыярга иде.

Әсфәндияр. Мәчет клуб түгел бит.

Самат. Вакыты-вакыты белән клуб булса да ярый. Иялләшсеннәр, үз итсеннәр.

Әсфәндияр. Юк, йөрмиләр. Берничә малай-шалай кызык итеп килгәли.

Самат. Бик әйбәт. Башта кызык итеп килсеннәр. Аннан инде... Тормыш яклары ничек, жайлымы?

Әсфәндияр. Мөслимә апа үз баласы кебек карый.

Самат. Өйләнеп жибәр. Күзең төшкән кыз юкмы соң әле?

Әсфәндияр. Бөтен авылларда да шулай микән, Самат абый? Монда бит... Болай булмый бит. Яшәү түгел бит бу.

Самат. Без мактап язган авыл юк ул бүген.

Әсфәндияр. Мин авылның элеккесен дә, хәзергесен дә белмим. Элеккесен мактыйлар, ләкин ун-унбиш ел эчендә генә кешеләр болай үзгәрә алмый.

Самат. Азынып өчен кешегә күп вакыт кирәкми.

Әсфәндияр. Хайван хәленә төшкән Бәдретдин, ерткыч жанварга әверелгән Вәлиәхмәт абыйлар...

Самат. Мин сина тагын өсти алам... Моннан егерме чакырымдагы татар авылында фәхишә. Акчага... Бөтен авыл белә. Йөриләр.

Әсфәндияр. Алып китегез мине моннан...

Самат. Йә, йә. Теге әчеп үлгәннен женазасына бармый дөрес эшләгәнсең. Киләчәктә дә йөрмә. Тик кисәтеп куй, ни өчен бармаганыңны ачык белсеннәр. Кунакка чакырсалар, бар... Аракылысына барма. Әйдә, мәчетне карап кайтыйк. Намаз вакыты да житә.

*Чыгып китәләр. Тастымалга төрелгән ризыклар күтәреп Мөслимә белән Налимә керәләр.*

Мөслимә. Гел ташып ашатып булмас. Газлары, сулары бар. Шушында гына әзерлик. Минем балалар белән вакытым юк, сиңа кала инде.

Налимә. Мин оялам, Мөслимә апа.

Мөслимә. Нидән? Кемнән?

Налимә. Әлләни уйлавы бар. Нигә бу гел монда чуалана дип...

Мөслимә. Уйласа тагын. Иплләбрәк карасын. Карамаслык түгел. Менә күлмәк киеп, яулык бәйләгәч тагын да чибәрләнеп киттең. Яшең унбиштә түгел, вакытында оя кормасаң, йөрерсең карт кыз булып. Үзе өчен саклап

калган ул сине. Кара син явызны. Теге Илбрүсне әйтәм. Хатын-кызның эченә сугарга ярыймы соң. Бала ярала торган урын бит ул. Аныкы шикелле аракы тутыра торган корсак түгел. Оялма, син үз эшенне эшлә. Караса карый, карамаса, аның эше. Ошатасыңдыр бит үзең.

Н а л и м ә. Ошый инде, ничек ошамасын.

М ө с л и м ә. Бик әйбәт. Мәхәббәт ул ошаудан башлана. Син егерме яшенә житеп мәхәббәтнең ни икәнен дә белмисең. Мин аны унҗиде яшемдә татыдым... Киттем. Оялма. *(Чыгып китә. Налимә урын-жирләрне рәтли. Әсфәндиярнын мендәрен иснәп-иснәп карый. Азан тавышын ишетеп, Әсфәндиярнын намазлыгын ала, идәнгә жәеп шунда чүгәли дә Әсфәндияр язып биргән доганы укый).*

Н а л и м ә. Әлхәмдлиллаһи әлләзи вә тәганәмә, вәсаканә, вәжәгаләнә минәл мөслимин. Бирәхмәтикә ярабби. Аллаһы әкбәр. *(Намазлык өстендә бер иелеп бер торып һаман шул доганы укый. Азан тавышы туктагач, намазлыкны жыеп куя да, көйли-көйли табын әзерли.)*

Китәм дисен, китәм дисен,
Китәм дисен—кайларга шул?
Ниләргә сабыр итмисен
Тагын бер-ике айларга?
Китәм дисен, китәм дисен
Китәм дисен күпкәме?
Әллә айга, әллә елга,
Әллә мәнгелеккәме?
Китәм дисен, китәм дисен...

*Лемур белән Әмир керәләр.*

Л е м у р. *(Налимәгә)* Син нишлисен монда?

Н а л и м ә. Исәнмесез. Мөслимә апа ашатырга кушты.

Л е м у р. Самат абый кайда?

Н а л и м ә. Әсфәндияр белән мәчеткә кереп баралар иде. Ишетмәдегезмени дога укыганнарын.

Л е м у р. Нишлибез, Әмир? Шунда керәбезме?

Ә м и р. Чыгарлар әле.

Л е м у р. Чыгарлар әле димә, Самат абый бит ул.

Ә м и р. Беләм инде, беләм. Крутойларны синнән күбрәк күргән.

Л е м у р. Самат абый крутой түгел. Ул—бизнесмен.

Ә м и р. Бизнесменнарын да күргән.

Л е м у р. Син күргәннәр бит ул вактәяк. Моны Казанда да беләләр. Телевизорда күрсәттеләр.

Ә м и р. Ну и што.

Л е м у р. Әй-й-й. Ну и што дип торма инде. Шулар тирәсендә ялманып йөрисен.

Ә м и р. Но-но-но. Син ялмаймыйсың чтоли?

Л е м у р. Шулай инде, акчаң булмаса ялманасын инде.

Ә м и р. Син анардан иномарка машина сора. Үзидарәнен авторитетын күтәрергә диген. Сорап барасын, панимаешь, районга берәр нәрсә иномаркага утырып... Главанын күзе акая.

Л е м у р. Әйдә, керик мәчеткә.

Ә м и р. Анда керсәк опять ботинка салдыралар. Ә минем носкинын үкчәсе тишек.

Л е м у р *(көлеп).* Син Самат абыйдан носки сора.

Ә м и р. Син над милицией көлмә. Без булмасак, сине өч көн дә тотмыйлар. Понял? Яшисен монда, панимаешь, суслик кебек. Кругом безобразие.

Л е м у р. Безобразиене син карыйсың инде.

Ә м и р. Карыйм мин Малаевка Маринасы белән кайсы посадкага кереп киткәненне.

Л е м у р. Тавышланма инде.

Ә м и р. Вот и тавышланма. *(Самат белән Әсфәндияр кайталар).*

Л е м у р. Исәнмесез, Самат Закирович. Машинагызны күрдек тә. *(Әмиргә күрсәтеп).* Бу...

С а м а т. Беләм. Хәлләр ничек соң, иптәш лейтенант? Тәртипме?

Ә м и р. Так точно, товарищ...

С а м а т. Ефрейтор. Армиядә мин ефрейтор идем. Нигә ишек төбендә торасыз, түргә узыгыз. *(Лемур белән Әмир аяк киемнәрен тиз-тиз генә салып түргә узалар).*

С а м а т *(урындыклар биреп).* Утырыгыз. *(Налимә кухнядан поднос белән чәй күтәреп чыгып өстәлгә куя да яналан кереп китә. Самат аны күзе белән озатып калып, Әсфәндиярга карый).*

Ә с ф ә н д и я р. Күрше кызы ул.

С а м а т. Их күрше кызлары—йөрәгемнең сызлавы. *(Әмир белән Лемурга.)* Ничек соң, егетләр?

Л е м у р. Яхшы, Самат Закирович. Менә күперебез жимерелде әле.

Самат. Акча кирәкме?

Лемур. Кирәк инде.

Самат. Мәчеткә йөрисезме?

Лемур. Мәчеткә? Мәчет дәүләттән аерым бит, Самат Закирович.

Самат. Син нәрсә, дәүләт булдыңмыни?

Лемур. Эш шундый бит инде безнең.

Самат. Нинди эш?

Лемур. Нинди эш дип. Вакыт та җитми.

Самат. Кая куясыз соң ул вакытны?

Лемур. Табыла инде эш.

Самат. Шулайдыр. Мәчеткә эшлексезләр генә йөридер. Менә син дәүләт инде, Лемур энекәш. Әйт әле син, дәүләттән ни өчен акча аласың? Ә сиңа ни өчен түлиләр, иптәш лейтенант?

Әмир. Мы выполняем то, что предписано.

Самат. Татарча белмисеңмени?

Әмир. Беләм.

Самат. Белгәч, нигә азапланасың? *(Лемурга).* Авылдагы тәртиптән син канәгатьме?

Лемур. Ә нәрсә, Самат Закирович?

Самат. Канәгатьме дип кенә сорыйм.

Лемур. Яшибез.

Самат. *(Әмиргә)* Ә син?

Әмир. Нормально.

Мөслимә *(ашыгып кереп).* Әсфәндияр, кил әле. *(Әсфәндиярнын колагына пышылдый).*

Самат. Исәнме, Мөслимә апа. Нәрсә анда серләшәсез?

Әсфәндияр. Бәдретдин абый үлгән. Асылынып.

*Пәрдә*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### VI—күренеш

*Мәчет эче. Ахшам вакыты. Әсфәндияр белән Сәлахетдин намаз укыйлар. Илдар, Вилдан, Илдария йөгереп кереп, алар янына чүгәлиләр. Өлкәннәр эшләгәнне кабатлыйлар. Үзара төртешеп алырга да өлгерәләр.*

Сәлахетдин *(намаз тәгәлләнгәч).* Ярый, мин ашыгыйм әле, малайлар кайтабыз дигәннәрие. Сау булып тор. *(Чыгып китә).*

Әсфәндияр *(балаларга).* Ә сез нихәл? Нигә соңга калдыгыз?

Илдария. Илдар аягын юмады.

Илдар. Юмадымы, юмадымы? Менә кара.

Илдария. Дәү әни ачулангач юдың. Грязными ногами мәчет нельзя. Әйе бит, Әсфәндияр абый?

Әсфәндияр. Әйе, мәчеткә чиста тән, чиста күңел белән керергә кирәк. Кичә өйрәткәннәрне онытмадыгызмы?

Вилдан. Мин беләм. Лә илахы иллә аллахы.

Әсфәндияр. Әйе, Лә Илаh, иллә Аллаh. Мөхәммәт рәсүлуллаh. Алладан башка Алла юк. Ә Мөхәммәт галәиссәләм вә Сәләллаhу аның илчесе. Онытмагыз, кем дә кем мин Алла дип мактана икән, ул ялганчы. Алладан башка Аллаh юк. Аннан инде сезнең әниләрегез, әтиләрегез, әби-бабаларыгыз...

Илдария. Вилдан намаз укыганда бисмилла, бисмилла дип кенә торды. Мин Аллакбәр, Аллакбәр дип укыдым. Илдар дөрес укымый бит, әйеме?

Вилдан. Тик тор диләр сиңа, дура.

Әсфәндияр. Нигә алай дип әйтәсең сеңлеңә.

Вилдан. Че она хатын кыз башы белән. *(Илдариягә.)* Тебе вообще мәчеткә керергә ярамый, белдеңме? Бабам мәчеткә керергә ярамый, әйе бит, Әсфәндияр абый?

Әсфәндияр. Нигә ярамасын.

Илдар. Минем әти әнигә әйтә. Син минем кабыргадан яралган ди. Ачуымны китерсәң, кире тыктым куйдым булыр урынына ди. Ходай сезне мәчеткә керергә дә кушмаган ди.

Әсфәндияр. Әтиләр дә кайвакыт ялгыша. Барыгыз, икенче килгәндә бүтән малайларны алып килегез. Футбол уйнарбыз.

Вилдан. Мәчеттә что ли?

Әсфәндияр. Мәчет янында нинди матур урын бар. Ярый барыгыз.

Илдар. Сау булыгыз, Әсфәндияр абый.

Илдария. Сау булыгыз, Әсфәндияр абый.

Вилдан. Сау булыгыз, Әсфәндияр абый.

Әсфәндияр *(Лемур кергәнне күреп, елмаеп)*. Намазга сонга калдыгыз.

Лемур. Син инде мине ачуланма. Булмый миннән. Ну картларны китерәм. Кәлимулла абыйга да әйттем. Хәлиулла абыйга да әйттем. Әгәр мәчеткә йөрмәсәгез, мина йомыш белән килмәгез дидем. Телгә остарып беттеләр. Синен нигә кирәген бар. Зирна бирмисен, салам бирмисен диләр. Ә Самат абый мине тәнкыйтьли. Нишләтә алам мин аларны.

Әсфәндияр. Мәчеткә куып китермиләр.

Лемур. Килмәгәч куасын инде. Самат абый әйтте бит.

Әсфәндияр. Самат Закирович куып китерергә кушмады.

Лемур. Нишләтим мин аларны тагын. Тагын бер-ике картка әйтеп карармын.

Әсфәндияр. Кирәкми, йөрмәгез. Йа, ходa, кешеләр...

Лемур. Кешеләр шул. Йөзәр грамм салып бирәләр дисән, киләләр. Белмим, Кая барадыр дөньясы. Син миннән көләсен, исемемне маймыл исеме дисен. Бәлкем шулайдыр. Анысында минем гаебем юк. Бүгенге эшемнен рәте-чираты булмаганга да гаебем зур түгел. Житешмәгән якларым бардыр, гаебем юк. Кем мин авылда? Нишли алам мин хәерче авылда? Бетәргә хөкем ителгән авылда нишли алам? Власть диләр. Кайда ул власть? Ярдәме тимәгән властьне кем санга суксын. Син мине бик ачуланма инде, хәзрәт. Син килгәч ничектер ни булды әле. Үземнен кирәгемне сизә башладым кебек. Кыен, бик кыен.

Әсфәндияр. Бергәләп тырышыйк.

Лемур. Әйе, әлбәттә. Рәхмәт сина. Вәлиәхмәт абыйга да әйттем, төнлә аракы саттырма кибетендә, дидем. Вон отсюда, ди. Мин нинди власть шуна көчем житмәгәч...

Вәлиәхмәт. *(Керә)* Керергә ярыйдыр бит.

Әсфәндияр. Әлбәттә.

Вәлиәхмәт. Ә син монда нишләп йөрисен, муниципаль берәмлек?

Лемур. Исәнмесез, Вәлиәхмәт Габделәхатович.

Вәлиәхмәт. Исән. Бар, йөрмә буталып эшләгән кешеләр арасында *(Лемур чыгып киткәч бусагага утыра да Әсфәндиярга карап тора. Шактый озак паузадан сон.)* Нихәл.

Әсфәндияр. Сезнекеннән яхшырак.

Вәлиәхмәт. Нәрсә, минем хәлем начармыни?

Әсфәндияр. Бәдретдин абый юк бит.

Вәлиәхмәт *(сикереп тора да яңадан утыра)*. Ызгышырга килмәдем.

Әсфәндияр. Безнен ызгышканыбыз юк шикелле.

Вәлиәхмәт. Шулайдыр. *(Паузадан сон.)* Дөрес эшләде Бәрттин. Анарга бүтән төрле үлем килешми дә иде. Табигать законы—көз артыннан кыш килә. Хайваннын кешегә әйләнгәнен күргәнем юк, кешенен хайванга әверелгәнен күреп торабыз.

Әсфәндияр. Кем турында әйтәсез?

Вәлиәхмәт. Мин хайван түгел, мин—жанвар. Ерткыч жанвар. Хайваннарны ашаучы жанвар...

Әсфәндияр *(паузадан сон)*. Түргә узыгыз. Олы кешегә бусагада утыру килешми.

Вәлиәхмәт. Мәчеттә минем урыным бусагада. Мәчет минем өчен изге йорт. Сезгә генә ул—балаган.

Әсфәндияр. Абзый кеше, ызгышырга килмәдем дидегез. Әйдә, берберебезне мыскыл итми генә сөйләшик. Күреп торам бит: күнелегезне бушатырга килгәнсез.

Вәлиәхмәт. Шулай ук күренеп торамыни?

Әсфәндияр. Тора. Жаныгыз бәргәләнә.

Вәлиәхмәт *(кычкырып)*. Юк! Юк ул миндә жан. Жансыз бәндә мин. Жансыз жан иясе. Жан дигән нәрсә күптән инде адәм балаларын ташлап качты. Кешеләр Газраилнен килгәнен көтмичә үк жан бирәләр. Жаннарын саталар. Бәрттин дөрес эшләде. Нигә ул ит гәүдәне

күтәреп йөрергә. Ә мин куркак. Бәрттин эшләгән егетлекне эшли алмыйм.

Әсфәндияр. Үз гомереңне үзең кисү-егетлек түгел. Ходай биргән гомерне Ходай үзе генә ала.

Вәлиәхмәт. Син миңа икенең ике икәнен исбатлама.

Әсфәндияр. Үзегез белмәгәч исбатларга туры килә.

Вәлиәхмәт. Беләм мин. Аңлый гына алмыйм. Күнелсез миңа, шуны беләсеңме? Шушы авылның кешеләренә ясин чыгарга кайттым. Ә үземнең яшисем килми башлады. Йә, әйт, нишләргә миңа?

Әсфәндияр. Иманга кайтыгыз.

Вәлиәхмәт. Иман? Нинди иман?

Әсәфндияр. Ә сез аның нинди икәнен беләсез.

Вәлиәхмәт *(паузадан соң)*. Йә, килдем ди иманга. Шуннан ни?

Әсфәндияр. Шуннан шул.

Вәлиәхмәт. Карале, егетем, кит син бу авылдан.

Әсфәндияр. Нигә?

Вәлиәхмәт. Кит. Кит яхшы чакта.

Әсфәндияр. Китмәсәм?

Вәлиәхмәт. Куркытырга жыенмыйм. Ялынып сорыйм. Минем үз гомеремдә берәүгә дә ялынганым булмады. Сиңа ялынам. Кит син. Беләсеңме, мин көзге яратмыйм. Көзгегә карасам, андагы кыяфәтемә төкерәсем килә. Син минем көзгем ахрысы. Ул көзгене ватасым килми. Чөнки аның гаебе юк. Югалтасым гына килә. Кит син бу каһәр төшкән авылдан. Комачаулама миңа ясин чыгарга... *(Туктап кала.)*

Әсфәндияр. Нигә туктадыгыз? Әйтеп бетерегез.

Вәлиәхмәт. Мин әйтәсен әйттем.

Әсфәндияр. Юк, әйтеп бетермәдегез. Сез монда аны әйтергә килмәдегез. Сез бушанырга килдегез.

Вәлиәхмәт. Нинди бушану?

Әсфәндияр. Күңелегездәге авыр йөкне бушатырга килдегез.

Вәлиәхмәт *(кычкырып көлә)*. Бала-чага... Нинди бушану... Андагы пычракны бушатып бетереп булмый.

Әсфәндияр. Ә сез тырышыгыз. Мин мәчетне чистарынган Вәлиәхмәт хәзрәткә калдырып китим. Авыл шаккатсын.

Вәлиәхмәт. Мондагы бәндәләргә ыштаның салып артыңны күрсәтсәң дә шаккатмыйлар. Ияләшкәннәр. Үзләрендә бар нәрсәне телевизордан күреп рәхәтләнеп утыралар.

Әсфәндияр. Вәлиәхмәт Габделәхәтович, муллалар вәгазь укырга яраталар. Алып ташлагыз күңелегездән үчне. Үч саклау кешене харап итә. Бабагызны куууда, мәчет манарасын кисүдә бүгенге авыл халкының гаебе юк. Кешеләр язмышы белән хакимнәр уйный.

Вәлиәхмәт. Тәкъдирне ягъни язмышны Ходай яза.

Әсфәндияр. Язганны укый да белергә кирәк. Күзе сукырайган кешеләрдән нигә үч алырга.

Вәлиәхмәт *(кинәт урыныннан торып чыгып китә)*. Сау бул.

Әсфәндияр. Вәлиәхмәт абый, минем сезгә үтенечем бар.

Вәлиәхмәт. Үтенеч.

Әсфәндияр. Ябыгыз аракы сата торган кибетегезне. Һич югында төнлә сатмасыннар.

Вәлиәхмәт. Эчсеннәр. Бетсеннәр.

Әсфәндияр. Үтенеп сорыйм.

Вәлиәхмәт. Тапмаслар дисеңме?

Әсфәндияр. Сез сатмагыз. Сез бит мулла онygы.

Вәлиәхмәт *(зәһәрләнеп)*. Это не твое собачье дело (чыгып китә).

Әсфәндияр *(тәрәзә янына килеп Вәлиәхмәт артыннан карап кала)*. Аллам. Адәм балаларын рәхмәтеңнән ташлама. Күгәргән күңелләрен чистарт. Адашкан жаннарга туры юл күрсәт. Иманын югалтканнарга иманын табарга ярдәм ит. Күңелләренә миһырбан, мәрхәмәт иңдер. Кылган гөнаһларын ярлыка, уйфикерләрен, кыласы ниятләрен изге ит. Йа Аллам, йа Хода, йа Тәңрем... *(Әкрен генә кыймыйча гына Налимә керә. Тамак кыра.)*

Әсфәндияр. Килгәнеңне күрмәдем.

Налимә. Мин икенче яктан килдем. Кайтмыйсың.

Әсфәндияр. Жыена идем.

Налимә. Сагындым.

Әсфәндияр. Нәрсә-ә-ә?

Налимә. Бүтән әйтмим, ишетмәдең.

Әсфәндияр. Ишеттем. Ләкин...

Налимә. Әллә мәчеттә ул сүзне әйтергә ярамыймы?

Әсфәндияр. Менә анысын белмим.

Налимә. Синең дә белмәгәнең бармыни? Яратам дип әйтергә ярый микән?

Әсфәндияр. Нигә ярамасын икән.

Налимә. Алайса, нигә әйтмисең? Яратасың бит син дә. Ату йөрим дә йөрим. Сөйлиләр. Әни дә әйтә: ашарга пешерергә генә йөрмисендер ди. Кешеләр дә сөйли, үзе мулла, үзе гуләйт итә диләр. Мин бит миңа кызыгып караганыңны сизәм. Кызыгып карыйсың, якын килмисең. Сөйгән кызың калгандыр әле Казанда.

Әсфәндияр. Беркемем дә юк минем.

Налимә. Налимә диген.

Әсфәндияр. Налимә.

Налимә. Алай гына әйтмә. Беркемем дә юк минем, Налимә, диген... Ярый инде, әйтәсең килмәсә. Хатын-кыз сүзен кабатлаган ир кеше ир кеше түгел инде ул.

Әсфәндияр. Әйдә, кайтабыз, Налимә.

Налимә. Юк. Кайтасым килми әле. Монда рәхәт икән. Мин синең намаз укыганыңны карап торырга яратам. Шундый тыныч. Дөньяда бер кайгы да юк кебек. Син укы—мин карап торыйм.

Әсфәндияр. Мин сине гел күрәм, Налимә. Әниеңне бер тапкыр да күргәнем юк.

Налимә. Өйдән чыкмый ул. Мине тапкач өзлегеп калган.

Әсфәндияр. Әтиең?

Налимә. Аны сорама. Әтисез тумаган инде билгеле. Әни авыргач киткән. Мөслимә апа да минем әнием кебек. Ул мине карап үстергән. Монда коверлар күп икән. Талап чыкмасыннар тагын.

Әсфәндияр. Мәчет әйберенә кемнең кулы күтәрелсен.

Налимә. Гөлназ кияүгә чыгарга җыена. Никах укытабыз ди. Әсфәндияр укымас микән ди. Әйткәннәр тегеләр килеп. Калымыңны түлә дигәннәр. Гөлназ белән үзидарәгә барып әйттек. Әкият сөйләп йөрмәгез ди Лемур абый. Әкият ди. Белми. Былтыр Гөлфиягә дә калым түләттергәннәр. Караташ авылыннан иде егете. Миңа мондый кирәкми дип өйләнмәгән. Гөлфия хурлыгыннан аллә кая китте. Беркемгә дә бер нәрсә дә булмады. *(Атылып Гөлназ керә. Аның артыннан Эльбрус һәм тагын бер-ике калым түләттерүчеләр керә. Эльбрус Гөлназга таба атлый).*

Әсфәндияр. *(Аның юлына каршы төшеп)* Туктале син, егет.

Эльбрус *(ишек төбендә калганнарга).* Тотыгыз аны.

Әсфәндияр. *(Янына килеп басканнарга)* Мәчет бит бу егетләр. Чыгып сөйләшик.

Эльбрус. Төкердем мин синең мәчетеңә.

Вәлиәхмәт. *(Ашыгып килеп керә. Эльбрус янына килеп баса).* Нишләп йөрисез монда?

Эльбрус. Менә, Вәлиәхмәт Габделәхәтович, бу мулла кисәге кызларны бикләп тота.

Вәлиәхмәт. Бар әле, ычкын моннан.

Эльбрус. Вәлиәхмәт Габделәхәтович...

Вәлиәхмәт. Ычкын диләр. Мине беләсең. *(Эльбрус әкрен генә борылып ишеккә китә. Ана иярченнәре тагыла)*

Эльбрус *(ишек янында туктап).* Зря син, Вәлиәхмәт Габделәхәтович. *(Чыгып китәләр).*

Вәлиәхмәт. Нәрсә алар? *(Гөлназга күрсәтеп.)* Моның өченме? Бар, чык киявеңә. *(Налимәгә.)* Син дә бар. Мәчеткә егет эзләп килмиләр... Барыгыз, бар, бар... *(Кызлар чыгып киткәч.)* Нәрсә мәчеткә кызлар җыясың. Урын беткәнме?

Әсфәндияр. Үзләре керделәр.

Вәлиәхмәт. Кертсәң, кочагыңа да күчәләр алар. Нәрсә, яныймы теге маңка? Шакшы малай, мәчет манарасын кисүчеләр нәселеннән. Нәрсә син маңка малайлар алдында җебеп төштең?

## VII күренеш

*Шул ук күренеш. Мәчет иләнenә җәелгән келәмнәр юк. Мәчеттә Әсфәндияр, Лемур, Әмир.*

Әсфәндияр. Тикшерүчеләрне чакыртыйк.

Лемур. Туктале, зурга җибәрмик. Кемнәр булыр икән, Әмир?

Әмир. Черт знает. Откажусь сезнең авылыгыздан. То сарык юк, то бозау, инде бу. Вор на воре сидит.

Лемур. Алай ук димә. Бүтән авылларда да шулай хәзер. Берсен дә тотканыгыз юк.

Әмир. Как это тотканыбыз юк. Тотып торабыз, тагын чыгалар. Без тотып ябып торабыз, там выпускают. Мы штоли виноваты. Уф-фу-фу. *(Лемурга)*. Басма анда, не видишь—следы. Даже обувь не снимали, сволочи. Может эти?

Лемур. Кем белә инде.

Әмир. Кем белә, кем белә. Банда асырыйсың.

Лемур. Нинди банда? Син нәрсә инде. Авыл малайлары.

Әмир. Малайлар. А этот Эльбрус малай штоли?

Лемур. Ә син нәрсә карыйсың соң?

Мөслимә *(керә)*. И Ходаем, әллә дөресме?

Әмир. Бар әле, апа, йөрмә монда.

Мөслимә. Йөрмә монда дип. Инде мәчеткә житештеләр.

Лемур. Синең бер дә күрмәгәнең юк, мәчет тирәсендә кеше күрмәдеңме?

Мөслимә. Күрмәдем.

Лемур. Кирәгән күрмисең син дә.

Әмир. Может этот. Как его... Вәлиәхмәт? Подозрительный тип. Ничә ел яши авылда, ничек яши, никто не знает.

Әсфәндияр. Ул түгел.

Әмир. Как ул түгел? Карап тордың штоли?

Әсфәндияр. Ул түгел. Тикшерүче чакыртыгыз. Әнә бит аяк эзләре күренеп тора.

Әмир *(үтеп баручы Эльбрусны тәрәзәдән күреп)*. Әй! Брусок! Кер әле монда.

Лемур. Ул төнлә авылда түгел иде.

Әмир. Посмотрим. *(Кергән Эльбруска)*. Сәлам, Брусок.

Эльбрус. Минем исемем бар.

Әмир. Да, ладно. Күрәсенме монда?

Эльбрус. Сукыр түгел.

Әмир. Кемнәр?

Эльбрус. Ә мин каян белим?

Әмир. Может ты?

Эльбрус. Син нәрсә?

Әмир. Может дружки?

Эльбрус. Может.

Әмир. Кстати, син беркайда да эшләмисен, на што живешь?

Эльбрус. Синең ни эшең бар анда?

Әмир. Эшем бар. Сам знаешь.

Эльбрус. Минем бабай белән әби пенсия алалар.

Әмир. Значит, ночью син авылда түгел идең?

Лемур. Түгел иде, без бергә идек.

Әмир. Чем занимались?

Эльбрус. Это не твое дело. Безне тикшермә, каракларны эзлә.

Әмир. Ну, ладно. Если син замешан в этом деле, посмотри.

Эльбрус. Нәрсә син жикеренәсең?

Әмир *(пистолетын чыгарып)*. Күрәсенме моны.

Эльбрус. Ну, күрәм.

Әмир. Он стреляет.

Эльбрус. Беләм.

Әмир. И уничтожает.

Эльбрус. Син нәрсә мине куркытасың?

Лемур. Егетләр, туктагыз әле. Яхшылап кына сөйләшик.

Әмир. Надоел он мне.

Эльбрус. Нәрсә надоел? Үзең чакырып алдың, мин килмәдем.

Әсфәндияр. Мәчеттән чыгыпызгышыгыз. Мин тикшерүче чакыртам.

Әмир. Да, подожди, ты. Табабыз аны. *(Эльбруска)*. Малайларың да үзең белән идеме?

Эльбрус. Нинди малайлар. Малайларым юк минем, өйләнмәгән.

Әмир. Чё лыбаешься?

Эльбрус. Дурак син.

Әмир. Кто дурак?

Эльбрус. Мин түгел инде.

Әмир. Значит, мин дурак? Я тебя, сука, пристрелю как собаку.

Эльбрус. *(Әмирнең изүеннән эләктереп)* Ты че сказал, падла? Че ты сказал.

Лемур. Егетләр, егетләр... *(Эльбрус Әмирнең изүеннән тоткан килеш ишеккә илтеп бара. Чыгып китәләр. «Егетләр, егетләр», дип Лемур аларга иярә)*.

Мөслимә. И Ходам! Ахырзамандыр бу, ахырзамандыр. *(Тышта пистолеттан аткан тавышлар ишетелә. Әсфәндияр ишеккә бара. Мөслимә анын юлына аркылы төшә)*. Чыкма, улым. *(Әсфәндияр барыбер чыгып китә)*.

## VIII күренеш

*Әсфәндияр яшәгән өйнен эче. Әсфәндияр чәй эчә. Читтәрәк урындыкка утырып Налимә ана сокланып карап тора.*

Әсфәндияр. Нигә син үзен дә минем янга утырып чәй эчмисен?

Налимә. Ярамый.

Әсфәндияр. Ни өчен?

Налимә. Мин бит синен хатынын түгел.

Әсфәндияр. Булмасан ни.

Налимә. Үзен мулла, үзен ярамаган сүз сөйлисен. Ничек инде хатынын булмаган килеш янына утырып чәй эчим?

Әсфәндияр. *(Налимәгә таба борылып утырып).* Әллә ниләр әйтеп куясын син.

Налимә. Әллә ниләр түгел. Мөслимә апа да шулай ди. Хатыны булмаган килеш ир-ат белән икәү генә янәшә утырып чәй эчү анын янәшәсенә яту белән бер ди.

Әсфәндияр. Мөслимә апа шулай ди, ә үзен ничек уйлыйсын?

Налимә. Үзем дә шулай уйлыйм. Янында утырырмын да торып китә алмам. Мөслимә апа әйтә: яратканынны сиздермә, кыз балага килешми, ди. Мин яратканымны яшерә белмим шул. Мин бу өйдән чыгасым килми генә чыгып китәм.

Әсфәндияр. Мина нишләргә кушасын?

Налимә. Кызык син, әйеме. Бүтәнләр нишләргә дип сорап тормыйлар. Гөлназны Дамир яратам диде дә алып китте. Син дә инде йә ярат, йә яратма. Кумыйсын да, якын да җибәрмисен. Ә минем бик тә яратасым килә. Хатынын булып яратасым килә. Бәлки син мине тин күрмисендер. Син бит укыган кеше. Чынлап та килмәгәнсендер әле безгә, китәргә генә килгәнсен. Мине калдырып китәрсен дә, мин нишләрмен. Тагын шул Илбрусләр кулына калырмын.

Әсфәндияр. Юк инде, анын кулына калмаячаксын.

Налимә. Син булмагач мина берсе дә кирәкми. Килмәгән булсан... Өйләнмәсән дә киткәндә алып кит мине моннан. Самат абый белән сөйләш. Берәр җиргә эшкә урнаштырырсын.

Әсфәндияр. Әйдә.

Налимә. Кая?

Әсфәндияр. Сезгә. Әниеннән рөхсәт сорыйбыз.

Налимә. Чынлапмы?

Әсфәндияр. Бу эш белән шаярмыйлар.

Налимә. Алайса, хәзер мин өйгә чыгам. Син килеп керерсен, ярыймы. Мин белмәгән булырмын. Син әнигә әйтерсен, мин Налимәне яратам, анардан башка яшь алмыйм диярсен. Кер, ярыймы, керми калма тагын. *(Китәргә дип ишеккә бара, анда Эльбрус белән очраша. Туктап кала).*

Әсфәндияр. Бар, Налимә.

Налимә. Юк, китмим. Ул нигә килгән? *(Эльбруска).* Нигә килден?

Әсфәндияр. Борчылма, бар.

Налимә. Ул яхшылыкка йөрми.

Эльбрус. Кит диләр бит сина.

Налимә. Юк...

Әсфәндияр. Налимә... *(Налимә чыгып китә).*

Эльбрус. Хуҗа булып алганмы?

Әсфәндияр. Узыгыз, әйдә, утырыгыз.

Эльбрус. Урын бирәсен?

Әсфәндияр. Сез—кунак.

Эльбрус. Кунак?

Әсфәндияр. Ә нигә? Минем бусагамны атлап кергән һәр кеше—кунак.

Эльбрус. Ярый, кунак булып алыйк алайса. Кунакка бездә бер ярты куялар.

Әсфәндияр. Сездә шулайдыр, бездә алай түгел. Налимә әйтә—яхшылыкка йөрми ди.

Эльбрус. Дөрес әйтә.

Әсфәндияр. Башта ук кисәтеп куйыйм—мин сездән курыкмыйм.

Эльбрус. Беләм. Вәлиәхмәт абый әйтте, үзем дә татыдым. Куркытырга килмәдем. Коверны тапмыйлармы?

Әсфәндияр. Әйткәннәре юк.

Эльбрус. Эзләмиләр дә аны. Теге ментны куганнар бит. Пистолет белән шаярганы өчен. Алар өчен пистолет уенчык кына бит. Нигә килгәнемне беләсенме?

Әсфәндияр. Кинәш сораргадыр.

Эльбрус. Нинди кинәш?

Әсфәндияр. Беткәнмени?

Эльбрус. Мина синең кинәшен кирәкми.

Әсфәндияр. Юкка... Минем кинәшемнең файдасы тияр иде сина.

Эльбрус. Әйтеп кара.

Әсфәндияр. Китегез сез бу авылдан. Бу авыл кысан сезнең өчен. Монда сез сыймыйсыз. Монда сезне барысы да яхшы беләләр. Сездән куркалар билгеле.

Эльбрус. Мина шул җиткән.

Әсфәндияр. Ләкин бу зона түгел. Монда пахан булып булмый. Шунысы да бар; зонада петух булганнар чыккач пахан булып кыланалар. Бигрәк тә авыл җирендә. Сезнең турыда әйтмим, кисәгезгә тыгылмагыз. Биографиямнән бер деталь: зонаның ни икәнен беләм. Күреп беләм. Һәм мин бу турыда сезгә генә әйтәм. Китегез сез моннан яхшы чакта.

Эльбрус. Кая?

Әсфәндияр. Барыр урыныгыз булмагач нигә пахан булып уйныйсыз? Яшәгез матур гына. Яши башларга әле соң түгел. Әби белән бабай пенсиясенә яшәү егетлек түгел бит.

Эльбрус. Ә мин ана яшәмим.

Әсфәндияр. Беләм. Мәчетне талаучы син түгел, юл күрсәтүче генә. Юк әйбер белән маташасыз. Сарык, бозау урлау, мәчет келәмен урлау көненә калгач юк инде ул.

Эльбрус. Әллә син!..

Әсфәндияр. Утыр матур гына. Килеп алганнарын кетеп. Мин синең кебекләрне зонада унике яшемдә күргән. Ә Налимәне мин сина бирмим. Син бит минем янга Налимәне бир дип әйтергә килдең. Әгәр дә мин Налимәне синнән тартып алган булсам, гафу үтенер идем. Ләкин Налимә үзе. Күрдең бит.

Эльбрус. Мин аны яратам. Яратмасам, әллә кайчан инде...

Әсфәндияр. Яраткан ир кеше беркайчан да яраткан кызының эченә сукмый. Яратмыйсың син аны. Үзеңә буйсынмаган өчен генә үзеңнеке итәсең килә.

Эльбрус. Нәрсә мулла булып йөрисең, син мулла түгел бит.

Әсфәндияр. Мулла, иптәш Брусок, мулла. Синең кебекләр белән синең телдә сөйләшә белүче мулла. Әгәр дисбе тотып яныма килгән булсаң, бүтәнчә сөйләшер идек. Әйт, келәмнәрне китереп куйсыннар. Минем янга килгәнең өчен бер юлга сине кичерәм.

Эльбрус. Мин!

Әсфәндияр. Әйе, син—син, мин—мин. Хуш иттек, Эльбрус. *(Эльбрус чыгып китә. Кулына балта тоткан Налимә керә).*

Налимә. Бер генә бәрә идем башына.

Әсфәндияр. Бир әле балтаны. Мин барында беркайчан да кулыңа балта һәм гер алмыйсың, Налимә. Кул ярыштырып йөрмисең. Алар хатын-кыз эше түгел. Аңлыйсыңмы, мине?

Налимә. Аңладым. Яратам диме Илбрүс?

Әсфәндияр. Аның шулай дип әйтергә хакы бар.

Налимә. Яратам дияргәме?

Әсфәндияр. Ә нигә? Син дә бит миңа яратам дидең.

Налимә. Мин бит...

Әсфәндияр. Ул да үзенчә ярата-дыр. Мин дә бит сине үземчә яратам.

Налимә. Әйткәнең юк.

Әсфәндияр. Әйтү ул әле ярату түгел.

Налимә. Син бөтен әйберне беләсең, үзең карт та түгел.

Әсфәндияр. Син өебезгә кайтам дигән идең.

Налимә. Син чынлап киләсеңме?

Әсфәндияр. Яраткан кешеңә ышаналар, Налимә.

Илдар *(керә).* Мулла абый, мәчетнең ачкычын бир.

Әсфәндияр. Нигә ул?

Илдар. Малайлар белән намаз укырга керәбез.

Әсфәндияр. Әле намаз вакыты түгел.

Илдар. Ә без өйрәнә торабыз.

Әсфәндияр. Әнә эленеп тора, ал.

Налимә. Аякларыгызны юып керегез. Комган ишек төбендә.

Илдар. Беләбез инде. Дәү әни куйган комган.

Налимә. Мөслимә апа өйрәтеп җибәрә инде боларны. Мин киттем. *(Китә. Әмир керә. Ишек янында аяк киемен сала).*

Әмир. Исәнмесез.

Әсфәндияр. Исәнмесез, иптәш лейтенант?

Әмир. Формадан түгел. Салдырдылар.

Әсфәндияр. Ишеттем. Барган идем, тыңламадылар.

Әмир. Шулай ул. Үзләре преступностька каршы көрәшергә диләр. Көрәшә башласаң... Мин бит ана атмадым, жиргә аттым. Нәрсә, утергәнне күтәп ятаргамыни?

Әсфәндияр. Сүзне дә үлчәп сөйләргә кирәк шул. Андый сүзне төрмә күргән кешегә әйтмиләр.

Әмир. Ә нәрсә. Мин әйтәм—урлатучы шул. Мин барыбер аның эзенә төшәчәкмен. Кусыннар, барыбер үземнекен докажу. Дәшми килгәч тә, муенга менеп атланды. Төрмәдә булган имеш. Видали мы таких. Әнә Лемур курыксын. Йөрәге алынып тора. Шуның белән аракы эчә.

Әсфәндияр. Сез дә инде...

Әмир. Мин үзем алып эчәм. Беләсеңме, нишли? Берәр әйбер югаласы булса, юри Лемур тирәсендә бутала. Как будто ул түгел. Белә кемнәр урлыйсын. Менә күрерсең, докапаюсь. Аның тирәсендә йөрүче бер дуракны тотып телен чиштердем. Син анда теге кемгә, Самат абыйга әйт әле, сөйләшсен безнекеләр белән. Бизнесменнардан шурлиләр алар.

Әсфәндияр. Шулай да саклансыбрак йөрегез инде.

Әмир. Ничего. Алар сөйлиләр—милиционер тупой. Вот мин формадан түгел, значит не тупой. Посмотрим кто кого. Әгәр син Брусок икән, мин—кувалда. Да, я как кувалда тупой. Син молодец—сугыша беләсең. Каерып кына алдын кулын суканын. Сине үзидарәгә куярга кирәк. Ато утыра анда Лемур. Маймыл есть маймыл.

Әсфәндияр. Нишләсен инде ул.

Әмир. Да. Нишләсен. Үзидарә, үзидарә. Название одно. Хозяева другие.

## IX күренеш

*Шул ук урын. Төн. Налимә урын жәя. Әсфәндияр китап укый.*

Налимә *(урынны жәеп бетереп Әсфәндияр янына килә. Әсфәндиярны кочаклаган килеш китапка карап тора).* Аңлыйсың инде боларны, әйеме?

Әсфәндияр. Юк, карап кына торам.

Налимә. Көләсең инде. Теләсәм, моны укырга мин бер айда өйрәнәм.

Әсфәндияр. Ә син телә.

Налимә. Мин яхшы укыдым мәктәптә. Институтка да керә ала идем дә, әнине ташлап китеп булмый иде.

Әсфәндияр. Монда бик иркен бит—кучерик әниеңне.

Налимә. Әлегә кирәкми. Кышка карарбыз әле. Алдына утырыйм әле, Әсфәндияр.

Әсфәндияр. Син мине туйдыра башладың, аермый булмас.

Налимә. Алай димә, юри дә әйтмә.

Әсфәндияр. Комачаулыйсың бит.

Налимә. Укы, укы, укы... Мина да бер китап бир. *(Караватка барып утыра).*

Әсфәндияр. Әнә Тукай китаплары, ал да укы.

Налимә. Әй, аны беләм инде мин.

Әсфәндияр. Кайсы шигырен беләсең?

Налимә. «Пар ат», «Туган тел»...

Әсфәндияр. Ә син башкаларын укы.

Налимә *(шүрлектән китап алып укырга утыра да, китапны кире илтеп куя).* Укыйсы килми. Мин лутчы жыр чыгарам. *(Кәгазь белән ручка алып Әсфәндияр каршына утыра).* Тәк, тәк... *(Көйли-көйли яза).*

Жыр чыгарам, жыр чыгарам...
Жырлыйсым килгән өчен...
Минем бәхетемә Ходай
Әсфәндиярны биргән өчен.

Йә ничек?

Әсфәндияр. Нәрсә ничек?

Налимә. Мин жыр чыгарам, ул ишетми дә.

Әсфәндияр. Комачаулама инде.

Налимә. Ярар, ярар.

Жыр чыгарам, жыр чыгарам.
Әсфәндияр янымда булган өчен.

Чыкмый да. Карале, Әсфәндияр, мулла хатынына телевизор карарга ярыймы?

Әсфәндияр. Нишләп ярамасын...

Налимә. Нигә алмыйбыз соң алайса?

Әсфәндияр. Алырбыз.

Налимә. Куеп тор инде китапларынны. Гел укыйсың да укыйсың.

Әсфәндияр. Укымыйча булмый. Мин гарәп телен камил белмим.

Налимә. Мина күңелсез бит. Әйдә болай эшлибез. Бер атнаны икегә бүләбез. Биш көне синең өчен, ике көне минем өчен.

Әсфәндияр. Ярый, шулай эшләрбез.

Налимә. Бүгеннән башлап... бүген минем җүләрләнәсем килә.

Әсфәндияр. Ничек итеп?

Налимә. Белмим әле.

Әсфәндияр. Башта бел, аннан әйтерсең.

Налимә. Син картлар кебек сөйләшәсең.

Әсфәндияр. *(Китапларын куеп)* Йә, җүләрлән. *(Налимә Әсфәндиярның алдына утырып Әсфәндиярны коча, үбә.)*

Налимә. Бир әле колагыңны. *(Әсфәндияр колагына пышылдый).*

Әсфәндияр. Аны кычкырып әйтсәң нәрсә була?

Налимә. Ярамый, ишетмәсеннәр.

Әсфәндияр. Кемнәр?

Налимә. Шайтаннар. Син дә минем колагыма пышылдап әйт.

Әсфәндияр. *(Налимә колагына).* Мин дә яратам.

Налимә. Тагын, тагын, тагын... *(Тагын Әсфәндиярны коча, үбә. Әсфәндияр алдыннан төшә).* Менә хәзер укы.

Әсфәндияр. Моннан соң укып буламы...

Налимә. Була. Бер хәреф биш булып күренәчәк. Укы, укы. Мин мишәйт итмичә генә сиңа карап торам. *(Әсфәндияр алдына китапларын куеп).* Укы. *(Үзе өстәлгә таянып Әсфәндиярга карап тора).* Укы инде. Нигә алай карап торасың?

Әсфәндияр. Сокланып... Күпме синең кебек асыл кызларыбыз харап була.

Налимә. Харап була дип. Итәкләрен җыеп йөрсеннәр... Кара, Илбрүс тәки югалган, әйеме. Синнән куркып инде.

Әсфәндияр. Каян беләсең?

Налимә. Теге вакытта әйттең ич. Мин ишек артында тыңлап тордым. Туебызны ямьсезләмәсә ярар иде дип курыккан идем, Аллага шөкер. Рәхмәт инде Самат абыйга, бөтен авылны җыеп туй ясады. Илгиз абый гына әйткән ди. Аракылары да булмады, кайтып киттем дигән. Аракысыз да биеделәр әле. Син биемәдең. Мулла кешегә биергә килешмидәдер.

Әсфәндияр. Бии белмим мин, биегән булыр идем.

Налимә. Сәлахетдин бабай никахны дөрес укыдымы?

Әсфәндияр. Дөрес.

Налимә. Бер сүз сорасам, ачуланмассыңмы, Әсфәндияр.

Әсфәндияр. Сора.

Налимә. Юк, сорамыйм.

Әсфәндияр. Мин синең ни сораячагыңны беләм.

Налимә. Каян беләсең?

Әсфәндияр. Беләм инде.

Налимә. Әйт, алайса.

Әсфәндияр. Әтиең белән әниең дә, туганнарың да туйда булмады, кайда алар дисеңме? Җавап бирәм: берсе дә юк. Әби белән бабай үлделәр. Туганнарым юк. Әти белән әни исәннәрдер. Кайда икәнлекләрен белмим. Артыгын сорама. Киләчәктә сөйләшергә дә сүз калсын. Син минем бердәнберем. *(Налимәне кочагына ала).* Син моны беркайчан да онытма—бердәнберем. Һәм син бердәнбер булырга лаек. Син миннән әллә нинди иркәле сүзләр ишетергә телисең. Син аларны еш ишетмәссең. Син—бердәнберем—онытма. Мин сине эзләмәдем, үзең табылдың. Ходай җибәргән. Син Ходайның иң затлы бүләге. Ят, йокла. Мин һәрвакыт синең янында гына ятырмын. Булдымы? *(Налимәне күтәреп алып урынга яткыра).* Йокла. *(Үзе өстәл янына килеп утыра)*

Налимә. *(Паузадан соң. Урында яткан килеш.)* Әсфәндияр. Бер генә сорау сорыйм инде.

Әсфәндияр. Сора.

Налимә. Мин дә хәзер мөселман булдым бит инде, әйеме.

Әсфәндияр. Ни сөйлисең син. Әллә кайчан мөселман инде син.

Налимә. Юк инде, барыбер. Догалар да белмәгәч. Телевизордан

күрсәтәләр. Казандагы мөселман хатыннары озын-озын күлмәкләр кияләр. Яулыкларын да әллә ничек бәйлиләр. Мин дә шулай йөримме инде?

Әсфәндияр. Үз күлмәкләрең сиңа бик тә килешә, Налимә.

Налимә. Ярый, алайса. Тыныч йокы, тәмле төшләр диген, Әсфәндияр. Син шулай дигәч, рәхәт.

Әсфәндияр. Тыныч йокы, тәмле төшләр.

Налимә. *(Паузадан соң).* Әсфәндияр, тагын бер генә сорау сорыйм инде.

Әсфәндияр. Сора.

Налимә. Син Аллага чынлап ышанасыңмы?

Әсфәндияр. Ни диден?

Налимә. Ачуланма инде.

Әсфәндияр *(паузадан соң).* Юк... Нигә... *(Налимә янына килеп карават читенә утыра)* Бу сорауны миңа берәүнең дә биргәне юк иде әле. Мулла бит мин, Налимә.

Налимә. Анысын беләм инде.

Әсфәндияр. Шулай да бик урынлы һәм вакытында бирелгән сорау. Беләсеңме, бердәнберем, мин беркемгә дә, бернәрсәгә дә ышанмый идем. Ләкин минем ышанасым килә иде. Безгә бер бабай килеп йөри башлады. Сөйли бу татар балаларын җыеп. Тыңлыйбыз инде. Тыңларга кушалар чөнки.

Налимә. Мәктәптәме?

Әсфәндияр. Әйе, «мәктәптә»... Тимерчыбыклы мәктәптә. Тагын килә бу. Кешене өмет яшәтә ди, ышану яшәтә ди. Нинди өмет, кемгә ышану? Шунда инде бу әйтә—шундый бөек көч бар ди. Мөселманнар аны Аллаһы Тәгалә, Ходай дип атыйлар ди. Әллә кайчангы бабаларыбыз Тәңре дип әйткәннәр, руслар Бог дип әйтәләр ди. Җирдә бүтән ышанычың калмаса, шуңа ышанырга кирәк ди. Ул сине саклый ди. Һәм чыннан да ул мине саклап калды. Югыйсә, мин синең янында утырып тора алмаган булыр идем. Мин дә теге бабай кебек кемнәрнедер саклап каласым килә. Ышанмыйча моны эшләп булмый. Аңладыңмы, бердәнберем?

Налимә. Әйе...

Әсфәндияр. Йокла. *(Баланы сөйгән кебек Налимәне сөя дә өстәл янына барып утыра. Шул вакыт тәрәзә чатырдап чатнаган тавыш ишетелә. Әсфәндияр урындыгыннан авып төшә).*

## Х күренеш

*Шул ук урын. Әсфәндияр урындыкта утырып тора. Налимә әйберләр җыештырып сумкаларга тутыра.*

Әсфәндияр. Налимә, әйткәнне тыңла инде.

Налимә. Әйтмә дә, сөйләмә дә. Китәбез. Сине харап иттереп ятим бала үстерер хәлем юк.

Әсфәндияр. Нәрсә инде син: исән ич мин.

Налимә. Бүген исән, иртәгә ни булыр.

Әсфәндияр. Самат абый кайтсын инде ичмасам.

Налимә. Самат абый да кирәкми, беркем дә кирәкми. Кирәк икән, үзе кайтып мулла булсын. Минем синең белән бәхетле буласым килә. Ходай җибәргән бәхетем, беркемгә дә бирмим.

Әсфәндияр. Авыру әниең бар.

Налимә. Булсын. Миңа гына карарга димәгән. Мөслимә апа да әйтте, карарбыз диде.

Әсфәндияр. Уйлап бетерми эшлисең, Налимә.

Налимә. Уйлап бетермәсәм, сиңа кияүгә чыкмаган булыр идем.

Әсфәндияр. Кил әле яныма.

Налимә. *(Кинәт үзгәреп Әсфәндияр янына ашыгып килә).* Нәрсә, бәгырь кисәгем, сызлыймы?

Әсфәндияр. Юк ла инде. Кил, утыр янымa. *(Налимә урындык алып янына утыргач.)* Ашыкма, кабаланма, сабыр булырга өйрән. Беләм, яратасың, югалтасың килми. Ләкин шашып ярату хәерлегә илтми. Акыл белән яратырга кирәк.

Налимә. Син ярат акыл белән. Мин бүтәнчә ярата белмим. Син минем бу дөньяда бердәнберем. Сиңа аттылар, синең исең дә китми. Синең иңбашың яраланды, ә минем йөрәгемә тиде.

Әсфәндияр. Шундый матур итеп сөйлисең.

Налимә. Үзең өйрәттең. Китик, Әсфәндияр.

Әсфәндияр. Кая?

Налимә. Сургутта туганнарыбыз бар. Булышырлар.. Мин эштән курыкмыйм. Сиңа да эш табылыр. Мәчет кенә димәгән. Безгә монда калырга ярамый.

Әсфәндияр. Ярый, уйлашырбыз. Тик кабаланма гына.

Налимә. Юк, уйлашмыйбыз. Миңа күп уйлау килешми. *(Әйберләр җыештыруын дәвам итә.)*

Әсфәндияр *(тавышын күтәреп)*. Тукта!..

Налимә. *(Каушап калган.)* Нишлисең син. Нигә кычкырасың?

Әсфәндияр. Сиңа уйларга килешмәсә, миңа килешә. Ир кеше уйлый икән, аны тыңларга өйрән. Без бит бала-чагалар түгел, ир белән хатын. Нәрсә, мин хатын-кызга ияреп йөрергә тиешмени?

Налимә. Әсфәндияр...

Әсфәндияр. Әйе, Әсфәндияр.

Налимә. Син мине ачуланасыңмыни?

Әсфәндияр. Ачуланам.

Налимә. Яратмыйсыңмыни?

Әсфәндияр. Ярatканга ачуланам.

Налимә. Китмибезмени?

Әсфәндияр. Уйлашыйк дидем.

Налимә. Соң, шулай диген. Уйлашыйк диген.

Әсфәндияр. Әйттем бит инде.

Налимә. Әйе шул. Әйттең шул. *(Әсфәндияр янына утырып.)* Уйлашыйк соң алайса. Син үзең генә уйла инде, Әсфәндияр. Мин уйлый белмим. Атучы шул Илбрүстер инде. Авылда юк диләр. Әллә теге Вәлиәхмәт микән? Авылга ясин чыгарга кайттым дип сөйләнә. Алайса, нигә сиңа аткан? Син бит бу авыл кешесе түгел. Миңа атсын инде, әйеме? Илбрүс булса да миңа атсын иде. Синең бит гаебең юк, сиңа мин үзем яратып чыктым. Күп сөйлим мин, әйеме, Әсфәндияр?

Әсфәндияр. Әйе.

Налимә. Үзең әйттең уйла дип. Хатын-кызның уе телендә инде. Китик, Әсфәндияр, ә? Бу авылда минем яшисем дә килми.

Әсфәндияр. Туган авылың бит.

Налимә. Туган дип. Кеше барыбер бер җирдә туа инде. Гел шунда яшәмиләр. Синең дә бит туган җирең бу түгел. Китик синең туган җиреңә.

Вәлиәхмәт *(ишекне ачып)*. Ярыйдыр бит.

Налимә. Ярамый.

Вәлиәхмәт. Нәрсә, бу өйгә хатын-кыз хуҗамыни?

Әсфәндияр. Түргә узыгыз, Вәлиәхмәт абзый. Налимә, чәй куясыңмы? *(Налимә әйтер сүзен әйтмичә, түзеп, чәй кайнатырга китә.)*

Вәлиәхмәт. Урынны кайдан бирәсең?

Әсфәндияр. Кунакның урыны—түрдә.

Вәлиәхмәт. Ярасы куркыныч түгел диделәр. Инбашың гына тырнап узган, диләр. Тидерә алмагач нигә атарга диген. Шакшы кешеләр шундый инде—үзләре аталар, үзләре тидерә алмыйлар.

Әсфәндияр. Тидергәннәр шакшы түгелме?

Вәлиәхмәт. Түгел. Явыз, ләкин шакшы түгел. Ярый, мәтәлеп китсеннәр. Иң яхшысы—исән калгансың.

Әсфәндияр. Әллә сөенәсез?

Вәлиәхмәт. Син нәрсә, әллә мине хайван дип белдеңме? *(Ишектән башын тыгып тыңлап торган Налимәгә.)* Куй чәеңне, тимим иреңә.

Налимә. Тиеп кенә кара. *(Ишеген ябып куя.)*

Вәлиәхмәт. Нәрсә, китәм дисеңмени?

Әсфәндияр. Кит дигегез бит.

Вәлиәхмәт. Һәр әйтелгән сүз соңгысы түгел. Соңгы сүзне әйтерлек рәтең калса, җан биргәндә генә әйтәсең. Әле анысы да түгел. Соңгы сүзне синең өчен бүтәннәр әйтә. Ленин белән Сталин да соңгы сүзне әйтмәкчеләр иде. Әнә алар әйтәсене бүген бүтәннәр әйтә.

Әсфәндияр. Философ сез.

Вәлиәхмәт. Һәрбер эшлексез кеше философ була. Эшләргә ирэнгәч акыл сата башлый. Мин килгәнгә ачуланмыйсыңмы?

Әсфәндияр. Нигә?

Вәлиәхмәт. Сиңа килмәгәч үзең киләсең инде.

Әсфәндияр. Килгәннәрне кертмисез дип ишеттем. Хәтта Бәдретдин

абзыйны да бусагадан уздырмагансыз.

Вәлиәхмәт. Бәрттиннәрнең урыны түрдә түгел. Син килсәң әгәр, уйлап карар идек... Китәм дисең инде? Бәлки дөрес эшлисеңдер. Муллалар заманы узгандыр. Безнең бабайлар гына ул кешенең хак юлга басачагына ышанып яшәгән. Үзләрен атканда да бисмилла әйткәннәр. Мәнә сиңа аттылар. Муллага мылтыктан аттылар. Авыл халкы ах итте дип уйлыйсыңмы? Авыл халкы синә атучыны эзли дип беләсеңме? Тот капчыгыңны. Көтү куганда хатыннар бер дә юкка атмаганнардыр әле дип сөйләнәләр. Бер Мөслимә апа гына ахвах итеп йөри. Миңа иманга кайтырга кушасың. Мин кайтырмын ул, мәнә бу сарыкларны ничек кайтарырсың... Китеп дөрес эшлисеңдер.

Әсфәндияр. Бәлки минем урынга сез калырсыз.

Вәлиәхмәт. Һе... Синең авызга бармак тыгарга ярамый.

Әсфәндияр. Нигә? Коръәнне яттан белә диделәр.

Вәлиәхмәт. Ялган. Мин аны урыс телендә укып кына өйрәндем. Тәрҗемәләр алар барысы да. «Ясин»ны гына Коръән телендә беләм. Аннары, мулла булу өчен дога укый белү генә җитми. «Интернационал»ны яттан белгән коммунистлар үз партияләренең башына җиттеләр.

Әсфәндияр. Авырдыр сезгә яшәве, әйеме, Вәлиәхмәт абый?

Вәлиәхмәт *(озак паузадан соң).* Китмә син. *(Торып ишеккә юнәлә.)*

Әсфәндияр. Кая сез? Чәй өлгергәндер.

Вәлиәхмәт. Яратып эчермәгән чәйнең тәме юк аның... *(Лемур белән Әмир керәләр).*

Лемур. Керергә рөхсәтме, хәзрәт, исәнмесез, әссәламәгаләйкем. Хәзрәт, минә Әмирнең әйтәсе сүзе бар.

Әмир. Исәнмесез. Менә болай. Әйе, мине эштән кудылар. Кусыннар. Кусалар да мин үз дигәнемне эшләдем. Сина аткан кеше, мулла, милициядә утыра. Вот так. Мин эләктердем аны. Куып тоттым мин аны. Вот так.

*(Машина килеп туктаган тавыш. Самат керә.)*

Самат *(Лемурга).* Ни булды монда?

Әсфәндияр. Гафу итегез, Самат абый. Намаз вакыты җитте, азан әйтергә кирәк. *(Шул вакыт азан әйткән тавыш ишетелә)*

Мөслимә. *(кереп)* Әсфәндияр энем, ачулана күрмә. Илдарыбыз бу. Таһарәтен алды. *(Азан яңгырый).*

*Пәрдә*

---

***Редакциядән:***
*Август аенда күренекле драматург, әдип, публицист, Татарстанның халык язучысы, Республиканың Дәүләт Советы депутаты, җәмәгать эшлеклесе, журналыбызның күп еллардан бирле редколлегия әгъзасы һәм даими авторы Туфан Миңнуллинга 75 яшь тула.*

*Аксакал язучыны олуг юбилее белән котлап, яна иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез.*



*Миңнуллиннар гаиләсе. Сулдан: Габдулла Миңнуллин (Туфанның әтисе), сеңлесе Өммия, абыйсы Кәбир, энесе Реваль, әнисе Халисә һәм Туфан. 1947 ел.*



*Миңнуллиннарның Олы Мәрәтхуҗа авылындагы йорт күренеше. Үткән гасырның 50нче еллары. Соңыннан бу бина авыл мәктәбенә бүләк ителде.*



*Мәскәүнең Щепкин исемендәге театр училищесы студентлары (татар студиясе). Сулдан уңга. Беренче рәттә: Николай Дунаев, Гөлсем Исәнгулова, Дамир Бәдретдинов, Мәсгудә Фәйзуллина, Нәҗибә Ихсанова, Дамир Хәйруллин. Икенче рәттә: Рәшит Галиәкбәров, Флера Хәмитова, Ринат Таҗетдинов, Әхтәм Зарипов, курс җитәкчесе Михаил Николаевич Гладков, СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов, Фирая Вәлиуллина, Миргалим Харисов, Иркә Сакаева. Өченче рәттә: Хәмзә Арсланов, Әзһәр Шакиров, Роберт Батуллин, Равил Шәрәфиев, Хәмбәл Закиров, Клара Газизова, Туфан Миңнуллин, Флера Хәсәнова, Фирдәвес Әхтәмова. 1957 ел.*



*Т. Миңнуллин һәм хатыны Нәҗибә Ихсанова туган авылы Олы Мәрәтхуҗада авыл балалары белән. 2001 ел.*



*Шәукәт Галиев, Туфан Миңнуллин, Илдар Юзеев. 1979 ел.*



*Туфан Миңнуллин Татарстан Республикасының җитәкче даирәләре һәм депутатлары белән. Басып торучылар (сулдан уңга): Туфан Миңнуллин, Минтимер Шәймиев, Индус Таһиров, Юрий Камалтынов, Разил Вәлиев, Фәрит Мөхәммәтшин, Ренат Закиров, Марат Галиев; алгы рәттәгеләр: Мидхәт Курманов, Роберт Миңнуллин, Рафаэль Хәкимов, Рөстәм Миңнеханов. 2007 ел.*

Рабит Батулла

# АЗАТЛЫККА ТАБА

## Уяну мәйданы

*1990, 25 август.*

Мин сәясәтче түгел. Мин язучы. Әмма 1990 елның 25 августында башланачак халык депутатлары җыенына бармыйча өйдә утыра алмадым. Язучының, сәгать кешесенең эше урамда, нәмаешларда (демонстрацияләрдә) кычкырып йөрү түгел, аның урыны язу өстәле янында дип акыл өйрәтүчеләр күп булды. Заманында сатира кичәләре оештырып йөргәнемдә дә миңа, «иҗат белән генә шөгыльләнергә кирәк», диләр иде. Гадәттә ул кешеләр йә обкомда, йә КГБ тирәсендә йөрүчеләр була торган иде. Татарстан автономияле җөмһүриятенең Югары Советы сессиясе башланырга бер сәгать чамасы калганда мин Ирек мәйданында идем. Үземнән башка анда адәми зат булмас дип өметсез генә килсәм дә, мәйдандагы халыкның күплегенә хәйран булдым. Йөзләп кеше бар иде. Шушысы да бик олы сөенеч иде, яшел байраклар тоткан, ай-йолдыз сурәтле әләмнәр, маңгайларына «АЗАТЛЫК» дип язылган яшел тасмалар бәйләгән яшь җегетләрне, кызларны күргәч, күземә яшь килде. Яшибез икән әле, үләргә иртәрәк икән әле, дидем. Ә инде болар Чаллыдан, Түбән Камадан килгән җегетләр дигән сүзләрне ишеткәч, уйлап куйдым: Казан әле, Казан уянмаган...

Вәкилләр (депутатлар) килә башлагач, Чаллылар тыкрык ясап, һәр вәкилне шуннан уздыра башладылар. Тәпәч тоткан милиционерлар халыкны кыйнарга әмер көтеп тора сыман. Депутатлар күренүгә, халык һаваны ярып:

—Азатлык! Азатлык! Азатлык!—дип кычкыра башлады.

Бу да минем өчен яңалык иде. Шушы ике-өч йөз кешенең бергә тупланып, йодрыкларын һавага төбәп «Азатлык» кычкыруы маңкортка әйләнеп бетә язган татар халкының кыю күрәше булып тоела иде миңа.

Чаллы җегетләренең җитәкчеләре Зиннур Әһлиулла, Тәлгать Әхмәдиша, Дамир Галимҗан тавыш көчәйткечләр аша сәяси торым хакында, Мәскәүнең Татарстанны сыер урынына савуы турында, шовинист җитәкчеләрнең, аларга сатылган Татарстан коммунистларының татар халкын ат урынына җигүләре, эт урынына сүгеп торулары мәсьәләсендә, «Автономия» дип аталган колониаль өлкә булудан Союз җөмһүрияте дигән дәрәҗә алырга кирәклегенә кагылышлы сүзләр белән әледән-әле халыкка оран сала торалар. Мин дә берничә тапкыр үз фикерләремне әйттем. Мин сөйләгәннәр өч тарафка аталган иде. Беренчесе—милиция хезмәткәрләренә, икенчесе—депутатларга, өченчесе—халыкка.

—Милиция хезмәткәрләре! Сез җинаятьчеләрне, үтерүчеләрне, каракларны, рэкетирларны, көчләүчеләрне тотасы урында, халыкка каршы басып, тәпәчләр белән халыкны кыйнарга боерык көтәсез. Халыкка файда китерәсегез килсә, үз эшегез белән шөгыльләнегез! Халык үзе сайлап куйган вәкилләрне халыкның

үзеннән саклау ул имәнгеч бер хәл! Чыгыгыз безнең якка яки китегез моннан!

—Халык вәкилләре! Сез кемнән куркасыз? Үзегезне сайлап куйган халыктан милиция гаскәре артына яшеренгәнсез икән, димәк, сезне халык сайламаган, сез демократик юл белән түгел, арткы—иске юллар белән вәкил булуга ирешкәнсез! Чыгыгыз, халык белән бергә булыгыз!

—Кадерле туганнар! Милләттәшләр! Якыннарыгызга, күршеләрегезгә әйтегез, җыен беткәнче мәйданга күпләп килсеннәр. Татарстанның байлыгын Мәскәүгә төяп озатырга моннан ары юл куймаска кирәк! Мәйданга чыгыгыз! Һәркем монда булыгыз! Уяу булыгыз! Бу көннәр—безнең соңгы ышанычыбыз!

—Җәмәга-ать, Минтимер Шәймиев килә-ә!—дигән хәбәр яңгырады.

Чаллылар Шәймиевне урап алган. Хәтта милиционерлар да халыкны тыеп тора алмый. Минтимер Шәймиев каушаган, аптыраган. Милиционерлар кешеләрне аннан аерырга маташа, ләкин халык тыгыз дивар кебек каты тора.

Минтимер Шәймиевнең борын төбендә үк зур хәрефләр белән язылган гыйбарә күтәргәннәр:

*«Табеевлар, Усмановлар—Шаһ Гали, ә син кем, Минтимер?!» «Минтимер! Булма камыр—бул тимер!»*

Шушы мәтәвек вакытында мин Минтимер Шәймиевнең кулына сигез язучы кул куйган хатны тоттырдым. Ул милиция сагы астында бинага кереп китте. Шәймиев минем бу хатымны бик теләп кабул иткән иде, әмма икенче тапкыр очрашкач, ягъни хат белән танышканнан соң, ул миңа кул бирмичә төксе генә исәнләште. Хатның тексты түбәндәгедән гыйбарәт иде.

*«Минтимер якташ! Әгәр дә Татарстанның РСФСР, СССРга берьюлы буйсынуын законлаштырачак проект расланса, син олы урыныңны да, бөтен уңайлыклардан файдалану хокукын да саклап калачаксың. Ләкин син татар халкы өчен сатлык, куркак җан булып мәңгегә тарихка керәчәксең. Әгәр дә Татарстанның тулы мөстәкыйльлеген раслата алсаң, бөтен уңайлыклардан файдалану хокукларыңны да, абруйлы урыныңны да барыбер саклап калачаксың. Ләкин бу юлы син татар халкының милли каһарманына әверелачәксең. Сайла, Минтимер якташ! Сиңа Татарстан халкы гына түгел, ирекка, азатлыкка, тигез хокуклыкка омтылучы бөтен халыклар да өмет илә карый. Аларның өметен акла, Минтимер! Татар язучылары: Батулла Рабит Мөхлис угълы, Зөлкарнай Фәиз Мәүлит угълы, Корбан Рафис Харис угълы, Зәйдулла Ркаил Рафаил угълы, Газинур Морат Васик угълы, Хәснияр Зиннур Зыятдин угълы, Хуҗа Мөгъсум Хаммат угълы. 23.08.1990 ел».*

Бу хатның икенче өлешен Газинур телевидениедән дә халыкка җиткергән иде инде. Шөкер, Минтимер Шәймиев алга таба моңа кадәр Татарстан җитәкчеләре башкармаган файдалы гамәлләр кылачак әле.

Минтимер кара эчле Ак йортка кереп китте, халык аның артыннан үкереп калды:

—Азатлык! Азатлык! Бәйсезлек! Бердәмлек!

Вәкилләр килә тора. Һәр вәкилгә:

—Кара аны! Әгәр дә суверенитетка каршы кул күтәрсәң, бел, безнең арада яшисең бар!—дип әйтүчеләр дә байтак иде.

Бу көнне без мәйданда, чама белән, биш йөз кеше идек.

Утырыш башланды. Без «АЗАТЛЫК» кычкырып, көне буе мәйданда йөрдек. Ара-тирә туктап, халык җыеп, ни телэгәнебезне аңлата башладык. Узгынчылар безгә карата төрле сүзләр әйтәләр. Кайберәүләр:

—И балакайларым, бахыркайларым, алып кына китмәгәйләре!—ди.

—Дөрес сөйлисез! Без сезнең белән!—дигәннәре дә бар.

Безне хурлап, рәнҗетеп киткәннәре дә юк түгел. Болары урыс интеллигенциясе яки урыслашкан татарлар инде.

—Вот вам демократия!—дип, әдәпсез хәрәкәт ясыйлар.

—Ишь, чего захотели! Татария всегда была землей Российской, так она и будет и в дальнейшем!—дип тәкерек чәчәләр, йодрык селкиләр, кәҗә тоягы күрсәтәләр. Без исә каршы килергә, аңлатырга тырышабыз.

—Нефть үзебезгә калса, син дә, татар да, чуаш та муллыкта яшәячәк бит,—дибез.—Мөстәкыйльлек бер татар өчен генә кирәк түгел ләбаса, барыбыз өчен дә кирәк,—дибез.

Юк, аларның күзләре акайган, аларның үз туксаннары туксан:

—Вы—националисты!—диләр дә китеп баралар.

Без:

—Долой шовинистов!—дип кычкырып калабыз. Моңа каршы тегеләр:

—Вам Ивана Грознога, Сталина не хватает!—диләр.

Икенче көнне иртүк мәйданга җыелдык. Халык күбәя, кичке якка тагын да күбрәк иде. Чаллы җегетләре Казанны дер селкетә. Мин аларга ияреп йөрим, чөнки тавыш көчәйткечләр аларда, байраклар, өндәмәләр, гыйбарә-тәгъбирләр алар кулында, мәйданга алар хуҗа.

Алга таба вакыйгалар магнитофон язмасында бирелә.

Магнитофонга язылганнарны мин үзгәртмичә, ничек язылган булса шулай кәгазьгә күчердем.

Батулла тавышы. Татар халкының язмышын хәл итә торган Югары дивани мәҗлеснең барышына өченче көн. Бүген бик тә кайгылы көн. Яңгыр пыскып тора. Без яңадан Ирек мәйданына җыелдык, ләкин кеше аз, шулкадәр ямансу, чөнки кичә кичтән Чаллының батыр җегетләре, каһарманнары үзләренең әләмнәрен, тавыш көчәйткечләрен алып кайтып киттеләр. Түбән Камалар да юк. Казаннар ялгыз: мәйданда ятим байрак җилферди. Шулкадәр моңсу ки, кешеләрнең башлары түбән иелгән, «Азатлык» кычкыручы кешеләр юк. Без—ялгыз. Шовинистлар, провокаторлар килеп безне төрткәлиләр, әшәке сүзләр әйтәләр, кычкыралар, яныйлар; авызларында—күбек, күзләрендә татарларга карата нәфрәт очкыннары ялтырый; аларның карашыннан Иван Грозный, Сталин, Ежов, Берия карый. Ул күзләрдән шовинизм чаткылары агыла. Җыелыштан да бик начар хәбәрләр килә. Ямансу, болытлы көндә бер учма кеше йөри. Кичәге мәҗлестә булган шомлы хәбәрләр белән Габделбәр Фәйзерахман таныштыра:

—Кичә Татарстан Югары советы сессиясендә берничә мәртәбә хәтәр ситуация барлыкка килде. Аның беренчесе Фәүзия Бәйрәмова тәкъдименнән соң булды. Эш болай тора. Үзләрен урыс демократлары дип йөртүче ТАССРның күп кенә халык депутатлары Татарстанның суверенитеты мәсьәләсен референдум аркылы хәл итеп, бу эшне җимермәкче булалар. Имеш, референдумга куябыз да *(референдумга халык өзер түгел, татар да аңламый, урыс та аңламый)*, урыс тулысынча каршы чыгар, шуның белән йомылыр дип уйлыйлар. Шуны исәпкә алып, Фәүзия Бәйрәмова тәкъдим кертте: референдум үткәрелә ала, әгәр дә ТАССР халык депутатларының өчтән ике өлеше моны яклап тавыш бирсә, диде. Һәм тәкъдимен катгый рәвештә тавышка куюны таләп итте. Рәислек итүче Шәмгунов моны бераз шикләнеп каршы алды һәм залда бик көчле реакция булды. Фәүзиянең тәкъдименә каршы чыгучылар шактый булды, соңыннан тавышка куелды һәм йөз унөч тавыш кына җыя алды Фәүзиянең тәкъдиме. Залда йөз кырык сигез татар депутаты утыра. Ә менә Фәүзия тәкъдимен яклап тавыш бирүчеләр йөз унөч кенә булды һәм Фәүзиянең тәкъдиме үтмәде. Ул гына да түгел әле, Мәсгут Хафизов, ач торган җегет, хәзер ул депутат: депутатларның өчтән бер өлеше кул күтәрсә, референдум үткәрергә, диде һәм үзенең тәкъдимен тавышка куярга кирәклеген әйтте. Әлбәттә, моның тәкъдиме үтмәде, шулай да татар депутатлары арасында да референдумга өметләнүчеләр бар икәнен күрсәтте. Икенче хәтәр ситуация менә мондый булды. ТАССР халык депутаты Колесникны[1] беләсез, ул «Вечерняя Казань» газетасында өч көннән өч көнгә татар халкының суверенитетлыгына каршы, халыкка каршы, татар халык лидерларына каршы мәкаләләр бастырып тора. Ул «Иттифак» партиясен фашистлар партиясе, татар халкын фашизмга баручы халык дип атады. Һәм шуны экология комиссиясе рәисе итеп тәкъдим иттеләр. Марат Мөлек бу әфәнденең, Колесникның, «Вечерняя Казань» газетасында басылып чыккан мәкаләсен укыды һәм бу кеше бик хәтәр кеше, суверенитетка каршы көрәшүче кеше, татар халкына каршы көрәшүче кеше дип аңлатты. Марат Мөлек шушы «Вечерняя Казань» газетасын укыганда шактый депутатлар, шул исәптән татар депутатлары да, бу монда укылырга тиеш түгел нәрсә, дип ысылдый башладылар. Бер кадәр көрәштән соң Колесникның кандидатурасы тавышка куелды. Ул күпчелек тавыш белән экология комиссиясенең рәисе булып үтте. Аның экология комиссиясенең рәисе булуы әле бер нәрсә: ул автомат рәвештә Югары Совет президиумының әгъзасы булып үтте. Югары Совет әгъзаларыннан хәзер унөч кеше билгеле, сигезе урыс милләтеннән. Биш татарның да татарлыгын анык кына белеп бетереп булмый әле. Татар халык мәнфәгатьләрен саклаучы кешеләрме икән алар? Шулай булгач, Югары Советның әле төзелеше, составы

[1] Дөреслек хакына шуны да әйттеп үтик, референдумны үткәрү барышында ул үзен бөтенләй башка яктан күрсәтте, халык ягына чыкты. — Р.Б.

бик шикле, татар халкы мәнфәгатьләрен яклый алырмы икән дип шикләнәм.

Б а т у л л а. Татар язучы-депутатлары ни хәлдә утыра?

Г а б д е л б ә р. Татар язучы-депутатларыннан зур активлык күрсәтүчеләрне күрмәдем, гомумән, татар депутатларының сессиядәге үзләрен тотышы егылып китәрлек. Урыс депутатларының күзләре ачык, аларның группалары бар. Берсен-берсе бик каты яклыйлар. Ә менә татар депутатлары бик кызып бәхәсләр барган вакытта да газета-журнал укып утыра. Кайберләре йоклап утыра, сөйләшеп утыралар. Һәм рәислек итүче тавышка куярга тәкъдим биргәч тә, нәрсәгә кул күтәрәсен белмичә, кешегә карап, каушап, кеше кул күтәргән якка кул күтәреп утыралар. Татар депутатларының күпчелеге карап утыра, ләкин һәрбер кешенең тавышы кадерле вакытта татар депутатларының шактыеның шулай утыруы бик хәтәр.

Б а т у л л а. Аяныч!

*Разил Вәли мәйданнан узып бара.*

Б а т у л л а. Иптәш депутатлар! Монда безгә хәбәр чыкты: сез гәҗит укып утырасыз икән анда, журнал укыйсыз икән. Уянып кына кул күтәрәсез икән, дигән сүзләр йөри. Дөресме ул, юкмы, иптәш Разил Вәли?

Р а з и л  В ә л и. Төрлесе бар, төрлесе. Районнардан килгән кешеләр анда, бик күп райком секретарьлары һәм башкалар...

Б а т у л л а. Ә язучылар?

Р а з и л. Язучыларның да төрлесе бар. Мөхәммәди[2] кичә бик әйбәт чыгыш ясады, язучы Фәүзия бик әйбәт чыгыш ясады. Мин әле бер сүз дә әйтмәдем. Мин төп сүземне әйтәчәкмен референдумга карата. Һәр атлаган саен сикереп торып, үзең белмәгән нәрсәгә кысылып йөрү дөрес түгел дип саныйм. Мин әзерләндем референдум турында сөйләргә. Чыгышым әзер. Кичә «Вечерняя Казань»да ярты бит мәкалә бастырдым. Референдум турында без атлаган саен сикереп торып чыгыш ясаячакбыз.

Б а т у л л а  т а в ы ш ы. Обком ишеге төбенә барып,тагын тыкрык ясарга өндиләр. Кешеләр, бар булганыбыз йодрыкларыбызны һавада селки-селки «Азатлык» кычкыра башладык. Халык күбәя, шөкер. Һәр депутатны урап алып, ишеккә кадәр озатабыз. Мин Колесник янына килдем.

Б а т у л л а. Товарищ Колесник! Вы за Сталина или же против?

К о л е с н и к. Конечно, против!

Б а т у л л а. А почему тогда утверждаете двойное подчинение сталинское?

К о л е с н и к. А почему вы решили, что я утверждаю двойное подчинение?

Б а т у л л а. По печати... Как вы относитесь ТОЦУ?

К о л е с н и к. Смотря какой его части.

Б а т у л л а. В его программе ничего против русского народа нет. А вы трактуете его по другому.

К о л е с н и к. Есть!

Б а т у л л а. Значит, вы шовинистического толка человек...

Халык кызганнан-кыза, депутатлар тизрәк кереп китәргә омтылса, аны куып җитеп торалар, тыкрыктан узарга кушалар.

Бүген тагын бер сөенечле хәбәр килеп иреште: Чаллы җегетләре кайтып китмәгән икән. Хәлләрнең мөшкел икәнен белеп, Аллага шөкер, безне ташламаганнар, алар кайтып китсә, мәйдан бөтенләй буш кала иде.

Б а т у л л а. Әйдәгез әле, Чаллылар өчен тагын бер «Азатлык» кычкырыйк! Азатлык! Азатлык!

Халык «Азатлык!» кычкыра. Кешеләр мәйданда артканнан-арта бара. Куәт сизелә.

Б а т у л л а. Кичә сез Сөембикә манарасына татар байрагы эләргә, дип киткән идегез. Бу эш барып чыктымы?

Ф ә р и т  Ш ә р и ф. Кичә, егерме сигезенче августта унтугыз сәгать тә унөч минутта байракны кадарга менеп киттек. Унтугыз сәгать кырык биш минутта байрак Сөембикә манарасының иң очында иде инде.

Б а т у л л а. Кемнәр элде?

Ф ә р и т. Мин—Фәрит Шәрифуллин, Әхтәм Сатый, тагын сигез кеше. Шуннан соң төштек, егерме сәгать тә кырык биш минутта азан әйтелде. Аннан намаз укылды. Шунда биш-алты ПМГ машинасына төялеп бик күп милиционерлар килде. Бауман районының замполиты килеп, бик каты әтәчләнеп, безне куркытырга

[2] Сүз Ринат Мөхәммәдиев турында бара.

азапланды. Без аңа бирешмәдек. Байрак кичтән эленеп тора иде әле. Бүген иртәнге сигездә байракны алганнар. Мин манара янына барганда, кече лейтенант, бер сержант тора иде охранадан. Сорадым: нигә алдыгыз байракны, дидем. ТАССРның МВД министры алырга кушты, янгынчыларны чакырып китерделәр, таң алдыннан алдылар, диделәр. Мин әйттем, җәмәгать, сез бу эшегез белән безнең халыкны аяк астына салып таптадыгыз. Сезнең бу эшегез халыкны башкаларга каршы котыртып, кан кою, Карабах ясау өчен эшләнгән, дидем. Без моны болай гына калдырмыйбыз, дидем. Аллаһ боерса, бүген тагын барып, элеп куярбыз.

Б а т у л л а. Сез кем буласыгыз үзегез?

Ф ә р и т. Фәрит Шәрифуллин, Казанда яшим. Транспорт цехы белән идарә итәм... Казан заводларының берсендә.

Б а т у л л а. Андагы байракны гына түгел, шовинистларның кулы тагын кайдадыр безнең байракны ерткалаган түгелме, Фәрит?

Ф ә р и т. Әйе, бүген иртә белән ТИҮнең штабына барганда күрдек, әләмнең бер таягы гына калган ие. Халык сөйләве буенча, шул ук МВД әһелләре, УВД әһелләре ТИҮ штабындагы безнең әләмебезне урлап киткәннәр.

Менә өченче көн инде, безне шовинистлар урап алып, битебезгә төкерәләр, байракларыбызга үреләләр, төкерек чәчә-чәчә «вы националисты» дип үзләренекен тукыйлар.

—Вы Карабаха хотите! Вы националисты! Вас расстрелять надо!—дигәннәре дә бар.

Югары Советта статусны карау башланды. Сәгать икедә вәкилләр тәмәке тартырга чыгачаклар икән. Симергән шовинистлар, куркак татар депутатлары... Хәлем китте. Кан басымым бик нык күтәрелде. Йөрәк шашып тибә. Көчкә утырам. Көчкә йөрим. Чаллылар өчен йөз кырык сум чамасы акча җыйган иде халык. Шуны тиешле кешегә тапшырырга дип кенә утырам, кайтып китәр идем юкса.

Унөч сәгать утыз җиде минут. Бераздан җегетләр Югары Совет урнашкан бина тирәли, мәйдан буйлатып «Азатлык» кычкырып йөри башлаячак. Депутатларның тәмәке тартачак урынына барабыз. Әләмнәрне, лозунгларны күтәреп барырга кеше җитми, кул җитми. Халык әбәткә таралды. Марсель Галигә:

—Син бер байракны алып бар әле,—дигән идем, качты:

—Мин күтәреп йөрергә тиеш түгел аны!—дигәне генә ишетелеп калды...

Халык «Азатлык» кычкыра. Кеше саны әкренләп арта бара.

Заманалар үзгәрә тора. Менә бүген генә, берничә сәгать эчендә генә дә сәяси мохит кинәт үзгәреп куйды. Урамдагы халыкның уянуы, һәр вәкилгә йодрык селки-селки үз таләбен куюы, һәрбер вәкилне урап алып «эшкәртүләре», каршыларына йөгереп чыгулар һәм мәйдан буйлап, элеккеге өлкә комитеты йортының алдында да, артында да мегафон аша «Азатлык» кычкыру, дөреслекне сөйләп тору тәэсирсез калмады кебек—күп кенә чыгышларда депутатлар мөстәкыйльлекне яклый башлады.

Мәйданда халык арта бара. Италия телевидениесе бу хәлләрне төшереп йөри. Ләкин Татарстан телевиденисе, Татарстан кинохроникасы күренми, алар безне төшерергә теләмиләрме? Халыкның тарихи шушы мизгелендә ничек итеп үзенең югалткан хокукларын яклап, урамга чыкканын төшерергә теләмиләр, йоклап яталар. Урам тулы халык. Күп, яхшы сүзләр сөйләнә. Язучылар да уяна. Беренче көннән алып мәйданга йөри торган язучылар бар. Бер мәртәбә дә килеп карамаганнары күбрәк.

Ләис Зөлкарнай, Рөстәм Мингалим, Газинур Морат, Рәшит Әхмәтҗан, Флүс Латыйфи, Рашат Низами, Нияз Акмал, Зиннур Хөснияр лар гел күз алдында. Ләкин, ни өчендер, бүтән язучылар күренми. Бүген Илдар Юзи белән Мәхмүт Хөсәен күренде. Кайда калганнар, нишләп йөриләр? Зөлфәт бер күренде. Мөдәррис бер күренде, Марсель Гали бер күренде...

Мәйданда артистлар да бар. Равил Шәрәфи көн саен килә. Шамкай көн саен килә. Вафирә һәрвакыт монда. Гөлзада һәрвакыт монда. Риф Гатауллин күренә. Мәсгудә Шәмсетдин халык арасында. Рамил Курамша беренче көннән бирле урамда.

Халык тагын да артты. Эшләр бара шикелле. Вәкилләрне каршы алырга ипи кибетеннән алып Зур Урамга кадәр бөтен мәйданны томаладык. Арада тыкрык калдырып, вәкилләрне шул тыкрыктан үткәрәләр. Халык мәнфәгатен яклаган вәкилләргә рәхмәт сүзләре кычкыралар. Ләкин әле татар язучы-вәкилләре җыелышта каты сүзләрен әйтмиләр... Фәүзия Бәйрәмова бер ялгызы телгәләнә,

бәргәләнә. Халык арасына чыга, сөйли.

Мәйданга бик күп әбиләр, апалар килде, алар чиләк-чиләк кайнар бәрәңге, май, чәй, помидор, ипи алып килгәннәр. Ап-ак яулык, матур шәлләр бәйләгән пөхтә, чиста карчыклар. Менә кемнәр көрәшә! Менә кемнәр батыр! Татар ирләре, татар егетләре йоклап ятканда, татар карчыклары азатлык таләп итеп урамга чыккан. Акчалары беткән Чаллы җегетләренең тамагын шушы әбиләр туйдыра. Урам тутырып әбәт ашый халык. Халык үз көрәшчеләрен тәрбияли, ярдәм итә. Моны күреп күңелем тула. Кешегә күрсәтмичә генә җылап алдым. Бу җылау халкымның мескен булып торган елларын искә төшергәннән дә, халыкның аз-маз уяна башлаганыннан да иде бугай.

Әбиләр: «Ашагыз, балакайларым!»—дип икмәк турый, чәй ясыйлар.

Чаллы җегетләрен кунакханәләрдән куганнар: имеш, алар экстремистлар, милләтчеләр икән. Бу турыда мин халыкка җиткердем, халык шундук Чаллыларга ярдәм-иганә акчасы җыя башлады.

Шушы хәлләрне үз күзең белән күреп торып, ничек җыламыйсың инде! Бу бит дүрт йөз ничә елга бер килгән кузгалыш. Дөресрәге, кузгалышның башы.



Караңгы төшкәнчегә хәтле халык мәйданнан китмәде. Бу көн бик нәтиҗәле булды. Вәкилләр тәнәфескә чыккач, мегафоннардан гел кычкырып тордык:

—Сез нинди халыкның депутатлары? Халыктан куркып, милиция артына посып, тәмәке тартасыз!.. Шулмы сезнең халыкка хезмәт итүегез! Чын халык депутаты булсагыз, чыгыгыз халык янына, курыкмагыз халыктан! Алыгыз милиция сагын! Милициянең болай да эше күп, үз вазифаларын башкарырга китсеннәр!

Бер милиция полковнигын халык алдына алып килеп әйттем:

—Әгәр дә депутатлар коллыкка кул куйса, безгә чыгып әледән-әле хәлләрне аңлатып тормасалар, халык үзе депутатлар янына бәреп керәчәк! Танк чакырсагыз да, моннан китмәячәкбез. Йөз кешене сытсагыз да, бер миллионыбызны сытсагыз да, калган алты миллион татар ирек өчен көрәшәчәк!—дидем.

Шулай итеп, без әлсерәп соң гына өйләребезгә таралдык. Бирсен Ходай, иртәгәсе яхшы булсын! Иртәгә хәлиткеч вә соңгы көн. Аллаһы Тәгалә, үзең ярдәм ит!

*1990 ел, 28 август. Ирек мәйданы.*

Иртән иртүк Ирек мәйданына килдем. Чаллы җегетләре инде уянган, әләмнәрен күтәреп, гыйбарәләрен, лозунг-транспарантларын асып, «Азатлык» дип кычкыра-кычкыра Иҗтимагый үзәктән Ирек мәйданына таба киләләр иде. Мин, куанып, аларга каршы йөгердем, сафка кушылып, тавышым карлыкканчы кычкыра-кычкыра обком йортына киттек. Бүген дә тыкрык ясалды. Вәкилләр, өйрәтелгән бозаулар кебек, кумыйча да шул тыкрык аша уза башладылар.

Хәтәр хәбәрләр килеп тора. Урысча газеталар халыкка яла яга торган мәкаләләр бастырганнар. Райкомнар тиз генә җыелышлар җыеп: татарларның хулиган группасы таяклар белән урысларны кыйнап йөри, алар исерек, наркоманнар икән, шәһәр буйлап урысларга террор ясап йөри икән, диган хәбәр таратканнар. Бөтен мәктәпләрдә ата-аналарга: сак булыгыз, татарлар урысларны кыйнап йөри, дип әйткәннәр. Шундый мөшкел хәлләр. Гайбәт, ялган, провокация мохите Казанда. Яшел бәйләгән җегетләр исерек, наркоман дип бер урыс җегете минем үземә дә әйтте. Пөхтә киенгән, утыз яшьләрдәге чибәр генә кеше иде ул. Мин, үземне белештермичә, шундук аның беләгеннән тоттым да Чаллы җегетләре янына алып

бардым, җегетләрне тезеп куеп:

—Вот они, эти парни с зелеными повязками! Покажи, кто из них пьян, у кого зрачки расширены!—дидем.

Җегетләр янына килеп, берәм-берәм әлеге урыс җегетенә күрсәтеп:

—Кайсысы исерек?—дидем.

Җегет нык каушаган иде:

—Извините! Я ошибся!—диде...

Бу адәм китте. Мәйдан халык белән тула язган иде. Митинг артыннан митинг үткәрәбез. Мин алты-җиде тапкыр урысча да, татарча да сөйләдем. Мәйдан аша узган автобуслар, туристлар, интуристларга аңлатабыз, сөйлибез. Язуларыбызны автобус тәрәзәләренә якын ук алып килеп күрсәтәбез.

Гайбәтләр әледән-әле ишетелеп тора. Депутатлар арасында да безне экстремистлар, наркоманнар группасы дип әйткәлиләр икән.

«Вечерняя Казань», «Советская Татария» газеталарында басылган мәкаләләргә каршы митинг оештырдык. «Вечерняя Казань» газетасын яндыру күренеше булды.

Халык арта. Узгынчыларга ни өчен мәйданга чыкканлыгыбызны аңлатырга тырышабыз. Көрәш бара. Ләкин ник бер киноаппарат булсын да, ник бер магнитофон булсын! Халыкның уяна башлаганын телевидение дә, киностудия дә тарихта калдырырга теләми, ахрысы. Үзәк телевидениедән татар халкының мәйданга чыгып, үз хокукын якларга тырышуын күрсәтсәң, бөтен халык аңлар иде, күрер иде, безгә кушылучылар күбәер иде. Татар әле тулаем манкорт ук түгел, шуны күрерләр иде. Телевидение һәм радио тапшырулары комитеты рәисе Илгиз Хәйруллинга әйттем:

—Нигә телевидениедән халыкның йөзен, ап-ак киенгән матур әбиләрне күрсәтмисез?—дидем.—Аларның, яль-яшь җегетләр, матур кызларның урамга чыкканын күрсәткәч, шовинистлар тараткан «экстремист, исерек, наркоман» дигән гайбәт-провокацияләре җимерелер иде,—дидем.—Шушы тарихи мизгелне, бу каһарманнарыбызның йөзләрен бүген төшереп калмасак, кайчан төшерербез?..

Халык арта бара, ләкин күңел тагын да күпне тели. Их, бер ун-унбиш мең кеше җыярга иде шушында, дим. Халык күп булса, һич шик юк ки, халык җиңәчәк икән, мәйданда йөреп мин шуны аңладым. Бу турыда мин Рәшит Ягъфәргә әйттем; ул сабыр гына сүземне тыңлап бетерде дә, тиз генә каядыр китеп тә барды, ярты сәгать чамасы да узмагандыр, ул бер кочак кәгазь төргәкләр күтәреп килеп җитте. Халыкны күпләп мәйданга чыгарга өндәп язылган өндәмәләр иде алар. Без аларны тиз арада халыкка таратып бетердек. Муллалар, мөәзиннәр дә кешеләрне вәгазь-намаз вакытында нәмаешка чакырсын иде дип мин мәчеткә киттем. Анда хәзрәтләр юк иде. Каравылда торучы бер абзый, бер-ике хатын минем ниятемне белгәч, тырнаклары белән чыраемны ерта яздылар.

—Син Карабах телисеңмени, кабахәт! Синдәй әшәке кешеләр, синдәй усал кешеләр халыкны урамга чыгарга котырта!—дип, мине мәчеттән куып ук чыгардылар.

Шул кызулык белән йөгерә-чаба торгач, Камал театрына барып кердем, үз артистларым, сәхнәдәшләрем мине аңларлар дип өмет итә идем мин. Театрда репетиция вакыты иде. Гафур Каюмның «Мирас» исемле пьесасын кабатлыйлар иде. Празат Исәнбәт белән артистларның эшләрен бетергәнен көтеп тордым.

—Ни җаныгыз бар? Берегез дә мәйданда күренмисез! Халык азатлык өчен көрәшергә мәйданга чыкты. Халкыбызның иң хәтәр көннәре. Яшибезме, юкмы дип көрәшкәндә ни гамегез белән йоклап ятасыз? Халык кычкыра, миннән сорыйлар: кайда артистлар, диләр. Халыкның теләген белдерергә килдем! Әйдәгез мәйданга!

Шулчак Празат миңа җикереп:

—Театр политикадан читтә булырга тиеш, артистларның урыны сәхнәдә!—диде.

—Политикадан читтә булгач, нигә политик әсәр куеп ятасыз?—дидем,—Гафурның пьесасы нәкъ менә политика түгелме соң?

Театрдан да куылгач, мәйданга йөгердем. Күңелем кителде. Җитмәсә, мәйданда кеше бик аз иде, нибары йөз илле чамасы. Арыганнардыр, ашарга, әбәткә таралганнардыр дип уйладым.

Их, ун-унбиш мең татар мәйданга гайрәт илә нәгърә орса, депутатлар әллә

кая китә алмаслар иде дә... Татар халкын аны аңламассың. Концертларга егерме бишәр мең җыела ул, Спорт Сараенда дүртәр мең дәррәү килә. Ни өчен соң мәйданга, көрәшкә килми?

Чаллы җегетләренең сорап алган ял көннәре бетте. Аларның кайсысы үз хисабына эштән өч көнлек ял алган, кайсысы кан тапшырып, эштән киткән иде. Аларда—ике мегафон, байраклар. Алар кайтып китсә, без бер уч карчыклар белән монда ничек көрәшербез икән?

Хәлсезләнеп соң гына өйгә кайтып егылдым. Арыган булсам да йоклый алмадым.

*1990 ел, 30 август*

Татар халкының язмышы хәл ителә торган соңгы көн. Нәрсә булачак бүген? Татарстан РСФСРга да, СССРга да берьюлы буйсыначакмы? Шәймиев Ельцинның да, Горбачевның да берьюлы уртак хезмәтчесе булырмы?

Югары Советта бертавыштан шундый карар кабул ителгән:

—Утызынчы август көнне мәйданда бернинди митинг булырга тиеш түгел!

Янәсе, халык үзе сайлап куйган депутатларга бик нык комачаулый икән...

Сәгать унга хәтле халык мәйданнан таралмады. Милиционерлар, ОМОНнар, эт тутырылган автобуслар тыкрык саен постырылган иде.

Б а т у л л а т а в ы ш ы. Ирек мәйданы. Дүртенче көн. Разил Вәли белән сөйләшү.

Б а т у л л а. Кичә нәрсәләр булды, Разил?

Р а з и л В ә л и. Кичә бер төркем депутатлар, суверенитетны яклаган депутатлар, Шәймиев белән очраштык. Без әйттек: әгәр дә безнең хыяллар тормышка ашмаса, дәүләт суверенитеты булмаса, без, татар депутатлары, җыелышып милли суверенитет мәсьәләсен күтәрәчәкбез, диде... 1966 елда Вена килешүенә безнең ил кул куйган. Анда: һәрбер милләт үзбилгеләнергә, үзенә баш булырга хокуклы, диелгән.

Б а т у л л а. Яхшы хәбәрең өчен рәхмәт, Разил.

Б а т у л л а т а в ы ш ы. Бәлки, татарның яңа тарихы шушы көннән башланып китәр? Иншалла, шулай булсын!

Мәйданда халык күп. Халык яклы депутатларга:

—Рәхмәт! Мең яшә!—дип кычкыралар.

Безгә каршы депутатларга:

—Долой!—диләр, аннан соң:—Азатлык!—дип кычкыралар.

Чаллылар ярдәмендә татар язучылары да уяна башлады. Сез мәйданда Ркаил Зәйдулла, Зиннур Хөснияр, Рөстәм Фәйзулла, Рәшит Әхмәтҗан тавышларын ишетәсез: «Азатлык! Азатлык!..»

Чаллы җегетләре мәйданга көлке бер рәсем алып килде. Рәсем зур түгел. Рәсемдә Минтимер Шәймиев камыт киеп, арбага җигелгән; арбада чыбыркы тоткан Горбачев, чыбыркы тоткан Ельцин Минтимерне кыйный-кыйный куалыйлар. Аста язу: «Менә шушы була инде ул ике субъектлы республика!» Бу рәсемне Фәрит Җәләй ике метрга ике метр итеп зурайтып китерде. Җегетләр аны депутатлар юлына бастырып куйды.

Ниһаять, бүген депутат Роберт Миңнуллинның теле ачылды. Мөнбәрдә ул. Аның чыгышы әйбәт иде, сүзләре төгәл. Сүгәрлек түгел, җегет икәнсең әле, дип әйтерлек иде.

Мәйданда торган вакытта минем янга бер ир кеше килде.

—Мин Альберт Минһаҗ булам!—диде ул.

Бөтен Казанның радиоэлемтәсенең башлыгы икән. Ул мәйдандагы тавыш көчәйткеч чиләкләрен эшләтеп, әчтәге утырышның барышын бөтен халыкка ишеттерә башлады. Бу рөхсәтсез эш икән.

—Кичке якта мин сезгә бик көчле микрофоннар китерәм, автобус белән, ләкин депутатлар янына кереп, сез рөхсәт алып чыгыгыз!—диде Альберт.

Фәнзаман Баттал белән без бу эшкә алындык. Керүебезнең нәтиҗәсе булмады. Шәһәр Советы рәисе Камил Исхаков андый эшләр өчен өч көн алдан гариза кертергә кирәк, диде.

Мәйданга чыктык. Минем янга килеп, бер җегет бик тә хәвефле сүз әйтте.

—Мин моторлар төзү заводыннан, егерме җиденче цехта эшлим. Бүген эштән туры монда килдем. Кичә безнең цех дружинасы ДНД буенча дежурствода булды.

Минем иптәшләрем сөйләде: инструктаж вакытында бер майор дружиначыларга: пикетчикларның барысы да исерек икән, наркоманнар икән, сугышып йөриләр, кеше кыйнап йөриләр, дип, аракыга сатылган алар, Чаллыдан, Түбән Камадан аларны аракыга яллап җибәргәннәр икән, дигән.

—Майорның исеме билгелеме?

—Менә шунысын ачыклый алмадым. Үзебезнең цехның җаваплы кешесе аның фамилиясен әйтә алмады. Мин үзебездә аңлатырга тырышып карадым. Моның ялган икәнен әйттем, чакырдым, килегез, анда халыкка аңлатып торалар. Бу безнең халкыбызга тап төшерә, дидем.

Менә, ниһаять, бүген Түбән Камадан күпләп килеп төштеләр. Җитәкчеләре Ильяс исемле ир-егет. Нур өстенә нур булып батыр җегетләр килә.

—Сезне сагындык!—ди халык.

Провокацияләр, ялганнар турында петиция язып, Фәнзаман белән тагын утырышлар йортына кереп киттек.

М. Рокицкий кичә телевидениедән татар халкына яла якты. Имештер, без, мәйдандагылар, Татарстан бары тик татарларга гына, дигән язулар күтәреп йөрибез икән. Бу турыда да президиумга язып керттек.

Унике сәгать егерме минут. Тәнәфес. Халык янына Марат Мөлек белән Фәүзия Бәйрәмова чыкты.

Ф ә ү з и я. Туганнар! Эш менә шунда хәзер. Үзегез ишетеп тордыгыз, безгә ультиматум куйдылар. Әгәр сез чыгып халыкны бераз тынычландырмасагыз, без сессияне өзәбез, диделәр. Һәм моның болай дип әйтүен күп кенә депутатлар шатланышып кабул иттеләр, ягъни сез монда тавышланып торсагыз һәм без сезне шуңа өндәсәк, статус мәсьәләсе көн тәртибеннән төшеп калачак... Сессия барышын тыңлагыз, китмәгез, һәрвакыт әзер булып торыгыз. Ләкин мин уйлыйм, байракларны хәзер алып торырга кирәктер! Дежурныйлар куегыз, провокаторлар кычкырып йөрмәсеннәр, суверенитет мәсьәләсе хәл ителмәгән килеш. Чаллылар бирегә килү өчен кан тапшырды. Өчәр тапкыр кан тапшырып килделәр. Минем мораль яктан хакым юк китегез дип әйтергә. Мин моны беләм, ләкин без сессияне өзсәк, моннан да яман нәрсә булмаячак, туганнар.

З и н н у р Ә һ л и у л л а. Чаллы иҗтимагый үзәге сүз ала. Менә, җәмәгать, күрдегезме инде? Азатлык әзрәк тезләнеп тә куя икән ул. Тезләнә икән инде, ул азатлык була алмый. Ләкин безнең бер тәкъдимебез бар. Кичкә хәтле «Азатлык» кычкырып бер генә тапкыр барырбыз. Ләкин без моннан китмибез. Без монда ничә тәүлек буе ятабыз, теләсә кайда йоклыйбыз. Әгәр дә безне моннан куалар икән, алар сессияне теләсә кайчан өзә алалар, бүген булмаса, башка вакытта; шуңа күрә без тегендәрәк китәрбез, байракларны җыймыйбыз, алар беркемгә дә комачауламый...

Б а т у л л а т а в ы ш ы. Хөрмәтле депутатлар! Сез шуңа игътибар итегез. Депутатлар ягыннан провокацион чыгышлар булды. Мәсәлән, Рокицкий: Татарстан бары тик татарларга гына, дип кычкыралар, шундый язу күтәреп йөриләр дип безне гаепләде. Бу ялган. Олы ялган! Кайда күрәсез сез андый язуны? Кайчан ишеттегез сез андый сүзләрне? Урыс халкына каршы бер сүз дә булмады. Рокицкий яки гафу үтенсен, яки аңлатсын, шуны таләп итәм!

Т а в ы ш л а р. Дөрес! Правильно!

Ч а л л ы л а р. Хөрмәтле депутатлар! Бу—җәмәгать тәртибен бозу түгел, бәлки милли бәйсезлекне сәламләү генә. Сез безгә андый претензия белдерергә тиеш түгел!

—Мин Чаллы җегетләренә җавап бирергә телим. Мин депутат Мөнир Әһлиуллин. «Социалистик Татарстан» газетасының баш редакторы. Менә хәзер генә комиссия төзелде. Мин ул комиссия рәисенең урынбасары. Монда иптәш Мөлеков та, Сафиуллин да, Фәйзуллин да бар, Миңнуллин да бар. Верховный Советның кичәге карарында: сессия барган вакытта митингларны, демонстрацияләрне булдырмау турында. Әгәр дә бу карарга буйсынмасак, Югары Совет ул—югары органыбыз, без аның карарын санламаган булабыз һәм Верховный Совет үзенең эшен туктатырга мөмкин. Инде хәзер җайланып килгән эшне, суверенитет алырга әзерләнеп беткән эшне туктату була, дим. Чаллы иптәшләр, дөрес аңлагыз, без барыбыз да сезнең белән, ләкин хәзер флагларны алып куеп, матур гына, эскәмиягәме утырып ял итәргә кирәк.

Халык Ленин һәйкәле янына китте. Анда үзеннән-үзе төзелгән концерт башланды. Мәсгудә Шәмсетдин яңа җыр язган, шуны бөтен халыкка өйрәтә.

*Уянды бөек татар, җиһан тетрәткән татар.*
*Рәнҗеттермә телеңне,*
*Бу соңгы көрәш, татар...*

Сәгать унсигез дә егерме биш минут. Яңгыр коя. Халык күп. Яңа гына Татарстанга суверенитет бирү турында игълан яңгырады. Халык бу хәбәрне төрлечә кабул итте. Алкышлар да булды, ризасызлар да күп иде. Сөмсере коелганнар да байтак. Шашып-шашып шатланучылар бар. Мин сөенмәдем дә, көенмәдем дә. Чөнки иң начары түгел, шөкер, иң яхшысы да түгел. Әмма зур җиңү иде бу. ТССР дигән җөмһүриятебез бар, булсын, бәлки әле алга таба тагын да рәтләнер. «А»дан котылдык, тагын «Эс-эс»тан да котылу форсаты чыгар әле, Аллаһ боерса, дип үземне үзем тынычландырдым. Ләкин әле суверенитет мәсьәләсе тулысы белән хәл ителмәгән. Сессия җир, тел мәсьәләләрен карый.

Биш сәгать буена халык яңгыр астында җырлап-биеп соңгы нәтиҗәне көтә.

1552 елда менә шушы Арча кыры дип аталган мәйданда, без басып торган җирдә, Ирек мәйданында (ихтимал, ул киләчәктә «Азатлык» мәйданы дип аталыр), Чапкын мирзалар, Япанчалар, Кошчак угланнар бугазга-бугаз, кылычка-кылыч килеп азатлык өчен сугышканнар,—аларның каны сеңгән мәйдан бу. Нәкъ менә 438 ел элек җир өчен, җан өчен, дин өчен көрәш барган. Бүген дә нәкъ шундый сугыш бара. Ә йөрәкләргә сауган канны күреп буламыни? Ничә көн иртүк, шәфәкъ сүнгәнче, көнозын аягөсте йөргән бу әбекәйләрнең, бу ирләрнең йөрәгенә кан саумаган дип кем әйтә ала?

Халык мәрхабә, афәрин, ура кычкыра. Мин максатсыз гына халык арасында йөрим. Шулай моңланганда яныма музыкаль фольклор ансамбле җитәкчесе Ринат Гыйлләҗ килде.

—Хәлең бик авыр бугай, Батулла абый, бераз гына хәл алып тор. Минем машина эченә кереп,—диде.

Мин риза булдым. Без аның машинасына кереп утырдык. Монда Рәшит Әхмәтҗан, Мөдәррис Әгъләм дә бар иде.

—Ни хәлләр, Батулла?

—Бүгенгәчә без «2»дә яши идек. Бүгеннән без кәгазьдән суверенитет алып, «3»нчедә дә яши башлаячакбыз. Әле шушы өчлене дә нинди көч сарыф итеп алдык. Алга таба «5» дәрәҗәсенә җиткезербез, Алла боерса.

М ө д ә р р и с. Кешеләр арыды. Анда утырган дәүләт кешеләре дә арыды, алар халык сайлаган депутатлар дип атала, мондагылар да арыды, барысы да арыды. Халык арыган кадәр берәүнең дә арыганы юк әле. Татар халкы—иң арыган халык, үз дәүләте булмаса, алга таба ул йөкне тартып бара алмаячак. Декларацияне кабул иттеләр, әмма «социалистик» дигән сүз күңелгә ятмый. Нинди социалистик инде ул? Коммунизмга бардык, «развитой социализм» төзедек. Бөтен илләр социализмнан качып барганда, нигә «халык җөмһүрияте» дип игълан итмәскә!

Р ә ш и т. Мин бишенче көн инде монда. Сәгать сигездә киләм, егерме икедә кайтып китәм. Аяклар шешенде. Халыкның да аяклары шешенгән.

*—Кагылулар, сугылулар булса,*
*Дошманнарга каршы чыгарбыз.*
*Без туган тел булып җырларбыз да,*
*Без туган җир булып сугарбыз!*

Шушыннан артык чигенү юк! Юк!

Р и н а т. Милләтебезнең каһарманнарына, шушы зур көрәшне әйдәп баручы егетләренә меңнәрчә рәхмәт. Татар халкы үлеп барган көннәрендә күтәрелде. Шуңа шатланам. Халыкка рәхмәт!

Мөдәррис:

*—Үз дигәнчә бара халык һаман,*
*Үз дигәнчә бара кешелек.*
*Казан өязендә кыссаң аны,*
*Ул Җаектан чыга бүселеп.*



*Бәреп чыга башкорт даласыннан,*
*Себерелеп килә Себердән.*
*Сындырам дип торткан мондагылар*
*Тотып кала бары сеңердән.*

Б а т у л л а т а в ы ш ы. Тагын шомлы хәбәр килде. Имеш, безне алдарга азапланалар икән. Татарстан барыбер РСФСР составында калырлык җай эзли икән шовинистлар. Өстән яңгыр явып тора, халык китәргә теләми. Депутатлар һәр пункт буенча бәхәсләшәләр. Бөтен милек, җирдәге байлык халыкка диган сүзне үзгәртергә тырышалар икән шовинистлар. «Халыкка» түгел, «халыкларга» булсын, янәсе. РСФСР декларациясендә ничектер, анысын мин белмим, «халыкка», ягъни бары тик урыска гына микән, әллә РСФСРда яшәүче барлык халыкларгамы икән?

Урамда халык **«Азатлык»** кычкыра. Бу эш бүген генә бетә алмады. Озакка сузылды. Мин Түбән Камадан килгән ун кешене өемә алып кайтып киттем. Аларның кунарга урыны юк иде. Вакыт бик соң иде. Кунакларны ашатып-эчертеп яткырдык. Мин дә яттым, егылдым дисәң дә була. Көннең ноктасы өчле-тугызлы гына булып бетте. Уртача булды. Без теләгән тулы ирек булмады. Ләкин ике койрыкның хет берсен кисеп аттык.

Төрмә бар. Төрмәнең карцеры бар. Иң тар бүлмәсе. Гомумән, төрмә-зиндан дүрт төрле була ул. Төрмә эчләрендә төрмә... Беренче төрмә—бер кешелек карцер. Карцердан чыкканда кеше чагыштырмача азатлыкка чыга, ягъни киңрәк төрмәгә, төрмәнең ишегалдына чыга. Шартлы рәвештә иреккә чыгарылганнар була. Ул эшли ала, йөри ала. Әмма билгеләнгән арадан читкә китәргә генә хокуклы булмый. Аннан да азат булган кеше «Советлар иле» дип атлаган зур төрмәгә чыга; чөнки Советлар Союзы—ул иң олы төрмә. Тулы иреккә чыгар өчен Советлар Союзыннан аерылырга кирәк. Шушылар белән чагыштырганда, безнең мөстәкыйльлек карцер түгел, без карцердан төрмәнең ишегалдына чыктык. Шуңа күрә, шатланмыйм да, кәеф «тәк сибә».

Бүген статус кабул иттек тә, иртәгә иртүк татарга ирек килде диган сүз түгел. Халыкның коллык рухы шул килеш калачак, бандитизм кимемәячәк, киресенчә арта барачак, шовинистлар үз дигәнен кылачак. Милли изү, сыгу, нефтьне бушлай суыру әле һаман шушылай еллар буе барачак. Милли мәктәпләр шулай хокуксыз, фәкыйрь калачак. Азатлыкның бер кирпечен салдык, алга таба миллионлаган кирпеч саласыбыз бар әле.

* * *

Хөрмәтле «Казан утлары»!

Март санында журналист Ф. Фәтхинең галим И. Габдрәфыйков белән «Без—татарлар!» дигән әңгәмәсе басылган иде. Мин анда китерелгән фактлар һәм фикерләр белән килешәм. Әмма минем өстәп әйтер сүзем дә бар.

«Башкортстан кызы»ның шул ук март санында 2002 елгы җанисәп турында мәгълүмат бирелгән. Андагы саннарга ышансаң, исләрең-акылларың китәрлек. Мәсәлән, безнең төп халык татарлар булган Борай районында яшәүчеләрнең 81,4 проценты башкорт булып чыга. Көлке бу, әлеге сан күпчелек чын башкортлар яшәгән төбәкләрдәгедән дә күпкә артык ләбаса! Эшләр болай барса, киләсе җанисәп алуда райондагы башкортлар саны 100 процентка да җитәргә бик мөмкин. Башкорт милләтчеләре, хөкүмәт яклавына таянып, барлык булган матбугат чараларын, радио, телевидениене эшкә җигәләр. Быелгы җанисәп елында татарлар күпләп яшәгән районнарга аеруча көчле һөҗүм оештырыла. Үгет-нәсыйхәт белән төрле башкорт делегацияләре районнарга сәфәр ясый. Бөтендөнья Башкортлары корылтаен быел үткәрү дә шул максатны күздә тота. Телевидениедән «Родословная малой родины» дигән башкорт телендәге тапшыру авылда яшәгән татарларга сезнең асылыгыз башкорт дип көн саен кабатлап тора. Районнардагы татар авылларының барысын да башкорт авыллары дип исбатларга маташалар. Шәҗәрәләрнең дә тамырларын, ялганлап булса да, башкорт милләтенә илтеп тоташтыралар.

Иң гаҗәпләндергәне шул: бу ялганны урындагы татар интеллигенциясеннән дә хуплаучылар бар. Мәсәлән, Уфа телевидениесеннән апрель аенда Борай районыннан ике иптәш без чын башкортлар дип ышандырмакчы булдылар. Татар телендә язып, иҗат итүче зыялылардан мондый сүзне ишетү сәер. Хакимияткә ярыйм дип үз намусына хыянәт итү түгелме соң бу?

Башкортстандагы татар матбугаты да тулаем Башкортстан хөкүмәте кул астында, шуңа күрә сүз ирегенең булуы мөмкин дә түгел. Дөреслекне язсаң, урындагы матбугатта (район гәзитләре), синең язмаңны чүп савытына гына ыргыталар, чөнки алар да эштән алырлар дип куркалардыр инде.

Хәер, бу темага уйлаучы да аздыр, авыл халкы да битарафлык күрсәтә, янәсе, кем дип язсалар да ярый. Менә шундый кайнардан-кайнар мәсьәлә Башкортстанның татар зыялыларын бер дә борчымый микәнни? Югыйсә белеп-күреп торалар бит. Бу турыда яраткан шагыйрьләребез Фәрит Габдерәхим, Рим Идиятуллин һәм башкалар нинди фикердә икән?

Әлеге вакытта китапханәләрдә тау-тау өр-яңа башкортча китаплар укылмыйча тузан җыеп ята, ә татарча китаплар бармак белән генә санарлык...

Җанисәп алуга санаулы гына айлар калып бара. Бу—тарихка кереп калучы мөһим вакыйга, һәм без үзебез булып калырга теләсәк, бер-бер чара күрергә, вакытны бушка уздырмаска кирәк иде. Әйе, бездә дөреслекне әйтерлек ирекле матбугат басмасы юк. Шуңа күрә, хөрмәтле «Казан утлары», сезнең Башкортстандагы коллегаларыгыз азрак кыймылдасыннар иде, йокыларыннан уянсыннар иде, югыйсә изеп-таптап киталәр бит. Бу эшне ничек башкарырга икән, газета-фәлән чыгарыпмы, листовкалар таратыпмы? Бу бит фетнә күтәрү түгел, бәлки үз хокукларыңны демократик юл белән яклау гына. Минем уемча, агитациянең халык аңын уятуда файдасы тими калмас иде.

Мин үзем инде пенсия яшендәге (1938 елгы) гади авыл кешесемен, махсус белемем дә юк. Сабый чактан ук мәктәптә Габдулла Тукайның «Туган тел»ен өйрәнеп үстек. Менә хәзер безнең балаларыбызны, оныкларыбызны туган телебездән, милләтебездән ваз кичтерергә телиләр. Районның «Алга» гәзитендә быел Г. Тукайның туган көнен дә искә алучы булмады. Аның каравы «асылыбыз башкорт» дигән язмаларга гел урын табыла әнә.

**Ралиф НУРИСЛАМОВ.**

*Борай районы, Бакалы авылы.*

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫ ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Соңгы елларда Төркия барлык төрки телле әдәбиятларның иң гүзәл ядкарьләрен, тарихларын төрек шивәсендә бастырып чыгару юнәлешендә максатчан эш алып бара. Күптән түгел Казанга «Төрек дөньясы әдәбият тарихы»ның *(Анкара, 2007)* 860 биттән торган 9нчы томы килеп җитте. Иң сөенечлесе, ошбу җилддә «Идел-Урал аланы. Татар төрекләре әдәбияты» исемендә күренекле әдәбият галиме, профессор, язучы Тәлгат Галиуллин белән Татар дәүләт гуманитар-педагогик университеты доценты Рамилә Яруллина язган монографиягә (667-736 б.) юлыгу булды. Татар әдәбияты тарихы турында сүз баргач, төрек телен камил белмәсәм дә, «кармалап» барып, сүзлекләргә таянып, хезмәтне каләмдәшләрем, бай рухи тарихыбыз өчен сөенә-сөенә укыдым.

Милли әдәбиятларның тарихи юлы, бүгенге торышы турындагы мәгълүматны үз чикләребездә генә йомдырып калмыйча, башка телләргә, үзгә мәмләкәтләргә ирештерү турында кайгырту—мактаулы һәм җаваплы эш. Бу нияткә бары тик тәрҗемә аша гына ирешеп була. Ә бит башкалар әдәби казанышлары белән бүтән халыкларны таныштыруда оялып, тартынып тормый. Үзенне үзең мактамасаң, башкаларның сиңа исе дә китмәс, дигәнрәк әйтем бар. Борынгы һәм урта гасырларда, бигрәк тә XIX гасырда һәм XX йөз телләре белән тыгыз элемтәдә, хәтта бербөтен булып яшәсә, 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң, бигрәк тә әлифбабыз башта латинга, аннары кириллицага күчерелгәннән соң, дөнья кыйтгаларына чыгуыбыз бары тик урыс лөгате аша гына барды. Әдәбиятыбыз тарихы да татар һәм урыс телләрендә генә яктыртылды. Бу юнәлештә Г. Халит, Р. Бикмөхәммәтов, Р. Мостафин, Н. Хисамов, Х. Миңнегулов, Р. Ганиева, Т. Галиуллин һ. б. галимнәребез форсатны ычкындырмадылар. Үткән гасырның 90нчы еллары башында демократия җилләре исеп, мәгълүм микъдарда иҗат, матбугат иреге килеп, «пантюркизм», «панисламизм» кебек куркыту күсәкләренең шаукымы сүндерелгәч, Көнчыгыш илләре белән элемтәләрне яңа югарылыкта торгызу мөмкинлеге туды. Әлбәттә, рухи дөньябызның кайбер тарафлары кайтарып булмаслык дәрәҗәдә гаип булган иде. Аерым алганда, гарәп, фарсы телле мәмләкәтләр белән мәдәни, рухи, әдәби, фәлсәфи-әхлакый якынлыкларны, мәгълүм сәбәпләр нәтиҗәсендә (тел белү, үзаң үсеше дәрәҗәсе, менталитет һ.б.), элеккеге дәрәҗәдә аякка бастыру мөмкин булмады. Көтелмәгәндә, хыяллана да алмаган мөстәкыйльлеккә ирешеп, дәүләтле булып алган төрки халыклар җитәкчелегендә әлегә эгоизм да көчле, үз мәнфәгатьләрен генә кайгырту беренче нәүбәттә тора. Таянычыбыз булып әлеге дә баягы, дәүләтчелеген беркайчан да җуймыйча, зур рухи һәм матди дәрәҗәсен саклый, үстерә алган Төркия калды. Иншалла, аның хөкүмәте тарихи миссиясен дөрес аңлап, мөмкин булган микъдарда барлык (бигрәк тә изелгән) төрки халыкларны (хәтта телләре бик ерак, тоткан диннәре христиан булган чуаш, якут, хаккас һ.б.) мәдәни берләштерү, якынлаштыру юнәлешендә җитди гамәлләр башкара.

Аерым алганда, төрки халыклар шигъриятенең күп томлы антологиясе (татар поэзиясе өлеше өчен җаваплы профессор Н. Юзиев булды), төрки телле әдәбиятлар тарихын борынгы чордан алып безнең көннәргә чаклы җиткерү (татар өлеше координаторы профессор Х. Миннегулов) шул изгелек һәм ихтыяр җимеше иде.

Тугызынчы жилддә (Г. Исхакыйлар заманында «том» сүзе «жилд» дип йөртелгән) урын алган күләмле мәкалә татар әдәбияты үсешенең иң катлаулы һәм гаять зур уңышларга ирешкән XIX һәм XX гасырларын, ягъни мәгърифәтчелек, романтизм, реализм һәм модернизм чорлары дип йөртелгән (әлбәттә, бу юнәлешләр һәрдаим аралашып, керешеп, диффузия күренеше хәлендә яшиләр) дәверләрне эченә ала. Хезмәт XIX йөзнең беренче яртысы татар әдәбиятын тәкъдир итүдән, Әбелманих Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәки, бигрәк тә Габделжаббар Кандалый иҗатларына төпле бәя бирүдән башланып, түбәндәге бүлекләрдән тора: «XIX йөзнең икенче яртысында иҗтимагый-игътисадый үсеш һәм культура (мәдәни хәрәкәт)», «Эстетик әдәбиятның үсеше», «XX йөз башы татар әдәбияты», «Нәсер» (проза), «20нче, 30нчы еллар татар шигърияте», «20нче еллар әдәбияты», «30нчы еллар әдәбияты», «Икенче дөнья сугышы еллары татар әдәбияты»... Әлбәттә, мондый бүленеш белән бәхәсләшеп, башкачарак өйрәнү кулаерак булыр иде дип тәкъдим кертергә дә мөмкин. Ни өчен, әйтик, хәзерге әдәбият шактый тәфсилле тикшерелсә дә, ул 1941-1945 еллар әдәбиятының дәвамы буларак кына, бер бапта карала. Мондый бүленеш авторлар ихтыяры белән эшләнгәнме, әллә тәрҗемәче үз анлавын алга сөргәнме—кистереп әйтүе кыен. Бәлки, төрек белгечләрен хәзерге татар әдәбиятына Муса Җәлил китереп бәйли торгандыр? Күп булмасалар да, компьютер хаталары да күңелне тырнап уза. Әйтик, беренче профессиональ тарихчыбыз, дин реформаторы, акыл иясе Ш. Мәрҗани фани дөньяда нибары бер ел яшәп киткән икән (1818-1819), З. Һадиның «Җиһанша хәзрәт» әсәре «Фәтхулла хәзрәт» дип бирелгән. Хәер, берничә юл аша ук укучы «Фәтхулла хәзрәт» бәянының чын авторы Ф. Әмирхан икәнне белә ала. Бәхеткә каршы, мондый хаталар хезмәттә күп түгел.

Тугызынчы жилддә татар әдәбияты тарихына багышланган саллы мәкаләнең буеннан-буена сузылган һәм теләсә кайсы милләт горурлана алырлык бай мирасны күрсәтергә мөмкинлек биргән концепция табылган. Бу хәл коры санау алымыннан коткарган. Әлеге концепция түбәндәгеләрдән гыйбарәт. Беренчесе әдәби хәрәкәтне иҗтимагый-сәяси үсешнең аерылгысыз бер тармагы итеп өйрәнү. Җөмләдән, авторлар XIX йөзнең икенче яртысында халык мәнфәгатьләре белән яшәүгә йөз тота башлаган сүз сәнгатен өйрәнүгә керешкәнче, Хөсәен Фәезханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри кебек мәгърифәт йолдызларыбыз эшчәнлегенә аналитик бәя бирәләр, бу бөекләребезнең татар әдәби үсешенә генә түгел, ә бөтен төрки һәм Көнчыгышның фәлсәфи фикере һәм тарихи аңы формалашуга тәэсирен дә урынлы искә төшерәләр. Вәисиләр хәрәкәтенә объектив бәя бирүгә омтылу да уңай тәэсир калдыра. Шул чорда татар сәүдәгәрләренең Казаннан тыш, Уфа, Сембер, Кызыл Яр, Оренбург төбәкләрендә төрле юнәлешләрдә эш йөртә башлауларының милләт үсешенә уңай тәэсире ассызыклана.

Икенчесе—һәр чорның әдәби үсеш үзенчәлекләренә бәя биреп, икенче-өченче «рәттәге» язучыларга ихтирамнарын күрсәтеп үткәннән соң дәвернең, иҗади юнәлешнең сыйфат кимәле чагылыш тапкан авторлар, әсәрләр аерым игътибар белән өйрәнелә. Әйтик, XIX йөзнең беренче яртысында суфичылык шигъриятенең Аллаһны олылаудан яшәү яме тапкан илаһи фәлсәфәсе—Көнчыгыш поэзиясендә калыплашкан жанрлар поэтикасы алга чыгарылса, икенче яртысының төп үзенчәлекләре проза (М. Акъегет, З. Бигиев романнары) һәм драма («Комедия Чистайда», Ф. Халиди, Г. Камалның тәүге әсәрләре) кысаларында ачыла.

Табигый буларак, «XX йөз башы татар әдәбияты» бүлеге хезмәттә иң мөһим урынны алып тора һәм анда әдәбиятның өч төп төре үсешен билгеләгән, әдәби мәктәпләрен калдырган Г. Тукай, Г. Исхакый һәм Г. Камал иҗатларына басым ясала. Әлбәттә, мондый игътибар Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Дәрдемәнд, С. Рәмиев кебек шәхесләрне «рәнҗетү», кимсетү, түбәнсетү исәбенә бармый. Соңгыларының вакыт сынавын узган әсәрләре кабатланмас сәнгати гүзәллекләрен ачу юнәлешендә өйрәнелә. Үткән гасырның егерменче еллар татар сүз сәнгатенең үсеш дәрәҗәсен билгеләгән язучылары буларак Һ.Такташ, Х.Туфан, Н. Исәнбәт, М. Галәү кебек каләм осталары аталса, утызынчы елларның вакыт сынавын узган әсәрләре буларак Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Ә. Фәйзинең «Флейталар», М. Җәлилнең «Хат ташучы», «Алтынчәч», М. Әмирнең «Агыйдел» әсәрләре тикшерелә. Сугыш чоры шигъриятенең сыйфат дәрәҗәсен М. Җәлил,

Ф. Кәрим һәм Х. Туфан әсәрләре билгеләде дигән фикер белән дә килешми мөмкин түгел. Сугыштан соңгы әдәбиятның «сорылык»тан һәм конфликтсызлыктан арына барып, халык яшәешенә һәм рухи тормышка якыная килүенә дәлил итеп С. Хәкимнең «Суд залында», Ш. Маннурның «Кичке моңнар» җыентыклары алына. Шигъриятькә илленче еллар ахырында килгән буынның янача фикерләве ачыла, И. Юзеевның Ш. Галиевның, «Хрущев җепшеклеге» чорында әдәбиятка аяк баскан Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, тагын да соңрак, демократия җилләренә битләрен куеп, шигъриятьтә милилек рухын үстергән К. Сибгатуллин, М. Әгъләм, Зөлфәт, Х. Әюп, Л. Шагыйрьҗаннарның иҗади казанышларына югары бәя бирелә. Татар прозасының үсеше Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ф. Хөсни, И. Гази, Ә. Еники, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Ә. Баян, Х. Камалов, драматургия адымнары Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, Р. Хәмид әсәрләре мисалында күрсәтелсә, әдәбият белеме үсешенә мөһим өлеш керткән Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев, И. Нуруллин, хәзер дә алгы сафтагы Н. Хисамов, Х. Миңнегулов, Ф. Галимуллин, Р. Ганиева, М. Әхмәтҗанов һ. б.лар исемнәре ихтирам белән атала.

Өченчесе—татар әдәбиятының мәгърифәтчелек, романтизм, реализм кебек төп агымнарга таянып үсүе, классицизм, сентиментализм кебек методларны «сикереп» үтсә дә, аларга хас үзенчәлек-сыйфатларга иркен таянып һәм халык иҗаты, язмышы белән бәйләнештә туган милли үзенчәлекләргә өстенлек биреп, Көнчыгышта, гарәп-фарсы әдәбиятларында калыплашкан фәлсәфәгә, жанрлык хасиятенә таянуын искә төшерү дә татар әдәбиятының олы традицияле бай сүз сәнгате булуына ышандыра. Татар әдәбияты «модерн» эзләнүләрдән дә тайчынып тормаган икән. Үткән гасыр башында М. Хәнәфи, Г. Газиз, С. Җәлал иҗатларында чарасызлыктан туган пессимизм мотивлары модернизм юнәлешенә алып килә. Аның аерым чалымнары М. Гафури, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Дәрдмәнд эзләнүләренә дә үтеп керә. Бу эзләнүләр дулкыны яңа модернизм чагылышы буларак Ф. Бәйрәмова, Г. Гыйльманов, Н. Гыйматдинова, М. Кәбиров, өлешчә З. Хәким иҗатларында үстерелә.

Ниһаять, XIX-XX гасыр татар әдәбияты тарихына багышланган хезмәтнең дүртенче концептуаль үзенчәлеге буларак, авторларның үзләренә таяныч ноктасы итеп инде искерә башлаган алты томлык хезмәтне генә алмыйча, Ф. Бәширов, З. Рәмиев, Н. Ханзафаров, Т. Гыйләҗев, Ә. Закирҗанов һәм бигрәк тә татар әдәбиятының XX гасырдагы үсешен бөтенләй «яңа дулкында», фәлсәфи һәм сәнгати яссылыклардан килеп бәяләгән Д. Заһидуллина белән Т. Галиуллинның үткән гасыр шигъриятен иңләгән хезмәтләренә таяналар.

Татар әдәбияты тарихына багышланган язмадан соң башкорт әдәбияты тарихы китерелгән. «Башкорт төрекләре әдәбияты» очеркы биш кешедән торган коллектив тарафыннан язылган. Арада М. Гайнуллин (вафат), Р. Баимов кебек танылган исемнәр бар. Без Ә. Ясәви, Т. Ялчыгол, Г. Чокрый, Ш. Зәки, Р. Фәхретдинов, XX гасырның олы шәхесләре М. Гафури, Ш. Бабич, А. Таһиров, С. Кудаш әсәрләрен башкорт галимнәренең үзләштерүенә инде чарасыздан күнегеп барабыз. Танышуны дәвам итәм. «XIX йөздә Минзәлә башкортлары арасыннан чыккан икенче бер язучы Кашафетдин...» дигән юлларны укыгач, Минзәлә төбәгендә яшәгән татарларның ачудан, гарьләнүдән чалшайган йөзләре күз алдына килде дә, «Егетләр, алай ук ярамый бит инде» дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым...

Аннары, Г. Исхакый, С. Максудилар заманыннан ук татар, башкорт, чуаш һ. б. яшәгән җирләрне «Идел-Урал» төбәге (штаты)» дип атау кабул ителгән. Башкорт әдәбиятына багышланган очеркта исә без яшәгән урын «Урал-Волга» («Урал»ны алга куйгач, башкортның дәрәҗәсе күтәрелә, күрәсең, ә «Идел» дип әйтсәң, татарча була) буларак билгеләнә.

Бәяләмә ахырында гомуми фикеремне әйтим. Татар әдәбияты тарихына багышланган бу хезмәт авторлары әдәбиятыбызның һәм аның нәзарияты үсешенең иң соңгы казанышларын исәпкә алып, башка төрки телле кардәшләребез әзәрбайҗан, Кырым татарлары һ. б. алдында рухи байлыгыбыз белән горурланырлык итеп таныштыра алганнар. Биредә рәхмәттән башка ни әйтәсең!

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН**

Нурмөхәммәт
Хисамов

# ҮЛЕМСЕЗ «КЫЙССАИ ЙОСЫФ»

Урта гасыр ядкярләреннән татар әдәбияты тарихына Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны кебек тирәнтен тоташкан бүтән әсәр, мөгаен, юктыр. Идел буе шигъриятенең XIII йөздән соңгы бөтен үсеш юлы шушы поэма традицияләре белән сугарылган. «Кыйссаи Йосыф»—татар халкы аны «Йосыф китабы» дип йөртә—болгар-татар әдәбиятының безгә исән-имин килеп житкән иң борынгы ядкяре.

Шәһри Болгарда 1299 елда куелган кабер ташында Кол Гали әсәре каһарманының улы «Мамил» исеме теркәлгән. Шунсы кызык, дастанның төгәлләнү елы белән таш куелу датасы арасында уртача бер кеше гомере озынлыгына тиң вакыт ята. Бу исем Идел-Чулман Болгарстанының төрле чорга караган жиде ташында очрый.[1]

Кол Галинең тормыш юлына кагылышлы мәгълүматлар, күп кенә урта гасыр авторларыныкы сыман ук, сакланмаган. Анын Идел буенда туып, Хәрәзм якларында белем алуы һәм мөдәррислек итүе турында кайбер мәгълүматлар гына бар. Болгар дәүләтен монголлар басып алганда һәлак булган дип гөман кылына. Әлеге мәзкүр әсәрен ул 1233 елның 12 маенда, үзе язганча—630 елда рәжәб аенын 30 ында тәмамлаган.

Идел буе төрки әдәбиятының барлык мөһим ядкярләрендә бу дастан теленең һәм фәлсәфи-сәнгатьчә янгырашынын тәэсирен гасырдан-гасырга күзәтергә мөмкин. Яңа дәвер татар шигъриятендә ул йогынты Тукайгача һәм соңгы чор шагыйрьләренәчә сузыла. Әсәр татар күчереп язучыларынын армас-талмас эшчәнлеге һәм Казан басмалары аркасында безгә килеп житкән. Бүгенге көнгә анын табылган күчермәләре саны 300 гә якын. 1839 елдан 1918 елга чаклы ул 80 тапкыр диярлек басылып чыккан. 1983 елда «Кыйссаи Йосыф»нын күренекле тел галиме Ф. С. Фәсиев тарафыннан эшләнгән тулы тексты дөнья күрде.

Кол Гали әсәре гасыр ярымнан артык татар, төрек, урыс һәм Аурупа галимнәренең игътибарын жәлеп итеп килә. Анын теле, язылу ватаны, халыкта таралышы һәм кайбер шигъри үзенчәлекләре Г. Флейшер, В. Перч, Ш. Мәржани, М. Һоутсма, К. Броккельманн, М. Күпрелезадә, Г. Рәхим, А. Самойлович, Е. Бертельс, Г. Таһирҗанов, Ә. Нәҗип, Х. Күроглы һ. б. хезмәтләрендә тикшерелә.

Татар филологиясендә дастанны махсус тикшерү эшен Ж. Алмаз башлап жибәрде. Татар әдәбият белемендә һәм фольклор фәнендә бу теманы эшләүгә Б. Яфәров, М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев, Ш. Абилов, Х. Мөхәммәдов, И. Надиров, М. Жәлалиева, С. Шәйдуллин, Р. Ганиева, Х. Миннегулов, Р. Әмирханов төрле дәрәжәдә өлеш керттеләр. 1979 елда Мәскәүнең «Наука» нәшриятында һәм 1984 елда Казанда безнең дә әсәрне әдәби ядкяр буларак тикшерүгә багышланган монографик хезмәтләребез дөнья күрде.[2] 2001 һәм 2006 елда анын халыкара

---

[1] Кара: Хакимзянов Ф. С. Язык памятников Волжской Булгарии (на материале эпитафий XIII-XIV вв.). Автореферат кандидатской дисс. М.,1976,с.16

[2] Хисамов Н. Ш. Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али. М.,«Наука»,1979; Хисамов Нурмөхәммәт. Бөек ямышлы әсәр. Казан,1984.

кыйммәтен яктырткан яңа монографияләребез[3] басылып чыкты.

«Кыйссаи Йосыф» дөнья әдәбиятында, аеруча Көнчыгыш әдәбиятларында, Йосыф сюжетына язылган күпсанлы әсәрләрнең бер төрдәше санала. Әмма төрки әдәбиятларда ул—Йосыф темасына язылган иң беренче дастан. Бу әдәбиятлар өчен аның гаять зур әһәмияте дә шушы бәрәкәтле сюжетны төрки укучылар өчен дә рухани ләззәт чыганагы итүгә бәйле. Кол Галидән соң төрки әдәбиятларда, башлыча госманлы төрекләре әдәбиятында, әлеге әсәрнең янадан-яна төрдәшләре дөньяга килә.

Идел буе шагыйренең Йосыф сюжетын эшкәртүгә керткән барлык яңалыкларын аның Кече Азиядәге дәвамчылары тулысынча күтәреп алалар. Болгар-татар әдәбиятында исә «Кыйссаи Йосыф» бу темага язылган бердәнбер шигъри әсәр булып кала, һәм ул татар укучыларының янадан-яна буыннарына эстетик тәрбия биреп, зәвыкларын канәгатьләндереп килә. Әсәрнең мондый даны аның халыкчан шәкленә, фикер һәм мотивларның инсанчылыгына бәйле. Анарда халыкның киң катлауларына якын булган тыныч һәм бәхетле тормыш хыялы чагыла.

Әсәр өч тел традициясенә таянып язылган: анда карахани-уйгур, угыз һәм кыпчак телләре катнашмасы күздә тотыла. Угыз-кыпчак катнаш әдәби теле Идел буенда традицион төс ала. «Кыйссаи Йосыф»тан тыш «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә» кебек Алтын Урда ядкярләрендә дә шул ук әдәби тел чагылыш тапкан. А. Н. Самойлович бу мәсьәләне махсус тикшергән. Әмир Нәҗип Кол Гали әсәрен Иделнең түбән агымында язылган дип саный.[4] Бу дөреслеккә туры килә. Испаниядән килгән гарәп сәяхәтчесе Әбу Хәмид әл-Гарнати Саксин шәһәрендә угызлар һәм болгарлар аралашып яшәвен яза[5]. Кыпчаклар белән аралашу да тыгыз булган. Сөләйман ибне Даудның «Зөһрәтер рияз» трактатының Саксиндә язылуы анда әдәби мөхит булганлыгын сөйли. Кол Галинең шигъри фразеологиясе угызча булу, теленең башлыча угыз теле булуы аның угыз мохитеннән чыгуын күрсәтә.

Әлегә кадәр, төрки әдәбиятларда Йосыф-Зөләйха сюжетына язылган башка әсәрләр схемасын механик рәвештә Кол Гали поэмасына да күчереп, аның тематик нигезен егет-кыз мәхәббәте рәвешендә билгеләү хөкем сөрде. Хәлбуки Е. Э. Бертельс үк Фирдәүси поэмасы кебек җитди версияләрдә мәхәббәт сызыгы сюжетның ярдәмче элементы гына[6] дигән фикерне әйткән иде. Соңрак ул Дүрбәк поэмасына карата да шуны язды.[7] Кол Гали әсәренә бу фикерләр тулысынча туры килә, чөнки поэманың исеме үк аның Йосыф хакындагы әсәр икәнен күрсәтеп тора. Ягъни сюжет нигезендә ата—угыл мәхәббәте, Йосыфның Иагъкубка тугрылыгы ята. Каһарман язмышындагы иң зур фаҗига да аның атасыннан аерылуына бәйле.

Шагыйрь әсәрнең үзәгенә хөкемдар һәм халык бәхете проблемасын куя. Калган барлык мәсьәләләр иҗтимагый, әхлакый, эстетик планда шушы үзәк тирәсенә туплана.

Проблема каһарман образы аша хәл ителә. Хөкемдар шәхесе нинди булырга тиеш? Шагыйрь шул сорауга җавап бирү өчен каһарманны бала чагыннан алып төрле сынаулар аша уздыра, шулар аша аның кешелек сыйфатларын ача.

Кол Гали әсәрендә Йосыфның хәлиткеч сыйфаты итеп тугрылык тасвирлана. Сюжетның Көнбатыш версияләрендә каһарман даимән «Гүзәл Йосыф» дип аталса, «Кыйссаи Йосыф»та ул—«Йосыф Сыйддыйк», ягъни Тугры Йосыф.

Тугрылык дигәндә шагыйрь барыннан да элек атага тугрылыкны күздә тота. Бу мотив каһарманның төш юратуыннан башланып, атасы белән янә күрешүенә чаклы үстерелә. Әсәрдәге төрле шартларда аның бу сыйфаты антка, бурычка тугрылык,

---

[3] Хисамов Н. Ш. Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XIII – XV вв. (Проблема версий). Казань, «Идел-Пресс», 2001; Кол Гали һәм төрки йосыфнамә. Казан, Таткитнәшер., 2006.

[4] Наджип Э. Н. О диалектном составе языка Кутба. – В сб.: Вопросы диалектологии тюркских языков, т.4, с.85.

[5] Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131-1153гг.).М., 1971, с.27.

[6] Бертельс Н. Э. Абу-л-Касим Фирдоуси и его творчество. Л.-М., 1935, с. 61.

[7] Бертельс Е. Э. Узбекский поэт Дурбек и его поэма о Иосифе Прекрасном. – Альманах Дар. Ташкент, 1944, с. 171.

ахыр чиктә, туган халкына, аның гореф-гадәтенә тугрылык рәвешен ала.

Йосыф язмышындагы иң кискен очрак—Зөләйхә вәсвәсәсенә бирешми калу да—«Кыйссаи Йосыф»та атага тугрылыкны сынау төсен ала. Йосыфны сатып алгач, бары Кол Гали поэмасында гына Мисыр газизе Кыйтфир Зөләйхәгә: «Безим бу углымыз улсун имди»[8],—ди. Шушы факт Йосыфның Зөләйхә каршында үз-үзен тотышына бөтенләй башка яңгыраш бирә. Хатынның юмарт мактаулары, үгет һәм ялваруына карамастан, каһарман үтә акыллы һәм тыныч итеп: «Бәни ул угыллыкка кабул кылди, Атама нәтә хаин улам имди»,—дип җавап бирә. Бу инде колның хуҗага тугрылыгыннан күп өлеш мәгънәлерәк, кешелеклерәк. Шулай итеп, шагыйрь каһарманның яңа иҗтимагый халәтенә ата-угыл мөнәсәбәтен күчерә. Ә инде Йосыф, Зөләйхә сүзләреннән эреп, елмаеп куйгач, аны хата эшләрдән кисәтеп, күз алдына атасы Йагъкуб килеп баса, һәм егет үзендә янадан ныклык таба. Атасының истәлеге һәрвакыт аның вөҗданы сагында тора. Сюжетка төрки шагыйрь алып килгән шундый нюанслар әсәргә яңачарак, үзенчәлекле яңгыраш бирә.

Тугрылык идеясе—«Кыйссаи Йосыф» поэмасының лейтмотивы. Бу әхлак сыйфаты кешенең бәхеткә ирешүе өчен төп шарт икәнне шагыйрь Зөләйхә язмышы белән раслый. Әсәрнең хатын-кыз каһарманы, кырык ел тугрылык саклап, сабыр итүе нәтиҗәсендә Йосыфка тиң һәм лаек була.

«Кыйссаи Йосыф»—борынгы төрки поэзиянең сюжетлы беренче әсәре. Аның сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләр дә шуңа бәйле. Әле сюжетлы әсәр коруда төрки әдәбиятның мөстәкыйль казанышлары җитәрлек булмаганлыктан, шагыйрь фольклор тәҗрибәсенә таяна. Сурәтләрне эшләү, сюжет борылышларын кору, стилистик ялгамнарны тәэмин итүдә ул тылсымлы әкият һәм каһарман эпос тәҗрибәсеннән файдалана. Аның сәнгатьчә фикерләве дә нигездә эпик поэтика кысаларында бара.

Әсәрнең иң әһәмиятле эстетик мәсьәләләреннән булган каһарман проблемасын хәл итүне алыйк. Монда шагыйрь эпик идеаллаштыру кануннарына буйсына.

Йосыфны уңай герой итеп күтәргән төп сыйфатлар—ул тугрылык һәм зирәклек. Ә инде матурлыгы—аның тумыштан бирелгән һәм дөньякүләм данын тотып торган үзенчәлеге. Мисырда аны кабат сату вакытында базар хәбәрчеләре ун сыйфатыннан берсе итеп батырлыгын да телгә алалар:

*Алтынчы: камулардан бик куәтлү—*
*Кырык ирдән куәти артык имди.*

Әсәр эчендә Йосыфка физик көч күрсәтү бөтенләй кирәк тә булмый. Әмма шагыйрь төрки укучының каһарман дастаннар традициясендә тәрбияләнүен истән чыгармый: ә аларда геройның беренче сыйфаты—батырлык.

Эпик идеаллаштыруның иң мөһим күрсәткечләреннән берсе булып магик көчкә—тылсымга ия булу санала. Эпоста бу каһарманның өстенлеген тәэмин итү өчен кирәк. Кол Гали поэмасында Йосыф та шул сыйфатка ия итеп тасвирлана. Мәсәлән, Кодес (Иерусалим) бәге, Йосыфны алып калу өчен, кәрван артыннан куа чыккач, каһарманның бер күз карашыннан ул 12 меңле гаскәре белән өч көнлек йокыга тала.

Иагъкуб сурәтендә дә эпослардагы зирәк аксакал гәүдәләнә. Бу, барыннан да элек, аның фикер йөртүендә, сөйләмендә чагыла. Үгет бирәме ул, кисәтәме, үз-үзен тынычландырамы—һәр очракта аның сүзләре мәгънәле, гыйбрәтле.

Зирәк аксакалның үлемен тасвирлаганда, Дәдә Коркыт турындагы легендаларга һәм угыз-кыпчак дастаннарына хас мотивлар килеп керә. Йосыф сюжетына Кол Галидән элек иҗат ителгән әсәрләрдә Йагъкубның тере көе үзенә кабер казучыларга юлыгуы тасвирланмый. Бары «Әнисел-мөридин»дә генә аның мәетен бабалары күмелгән мәгарәгә алып килүләре һәм, шартлы сүзләр белән эндәшкәч, мәгарә ишеге ачылып, эчкә кертүләре языла.

«Кыйссаи Йосыф»та исә Иагъкуб, туган җиренә кайтып барышлый, кабер

[8] Кыйссаи Йосыф. Казан университеты табыгханәсе,1839,57 б. Алга таба басманың битләре генә күрсәтеләчәк.

казучы фәрештәләргә тап була, кабернең эчен күрергә дип кереп китә һәм шунда җан бирә. Бу—Дәдә Коркытның үлемнән качып йөргәндә дөньяның дүрт тарафында да үзенә кабер казучыларга юлыгуы хакындагы легендаларны[9] хәтерләтә. Себер татарларыннан язып алынган «Ак Күбәк» дастаны каһарманның атка атланган көе кабергә кереп китүе һәм шунда күмелүе белән тәмамлана.[10] Ак Күбәкнең кабер казучылар белән сөйләшүе гаҗәп дәрәҗәдә Йагъкубның фәрештәләр белән әңгәмәсенә охшаган. Шунсы кызык, кешенең кабер казучыларга юлыгуы һәм тере көе кабергә керүе турындагы легендалар Татарстан авылларында хәзер дә очрый. Күп санлы шушындый детальләр Кол Гали поэмасына төрки колорит бирә һәм сюжетның төрки җирлектәге үзенчәлекле сәнгатьчә яшәешен тәэмин итә. Зөләйхә, мәсәлән, Йосыфның чәчен толымлап үрә. Йосыф сюжетының Кол Галигә кадәрге чыганакларында бу деталь бөтенләй юк, һәм ул булырга мөмкин дә түгел. Чөнки, затлы нәсел күрсәткече буларак, ирләрнең толым йөртүе борынгы төркиләргә хас күренеш.[11] Соңрак Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия»сендә дә Йосыф толымлы итеп сурәтләнә. Бу очракта Кол Гали кыпчак мохитенә якынрак тора.

Эпик башлангыч Йосыф сурәтен тудыруның бүтән якларында да чагылыш таба. Каһарманның үзен рәнҗеткән агаларына карата олы җанлылык күрсәтүе сюжетның тәүге чыганакларында ук урын алса да, төрки поэмада ул герой проблемасын хәл итүнең башка аспектлары белән тыгыз бәйләнештә бирелә, ягъни идеаллаштыруның эпик кануннарына туры килә. Төрки эпосның нинди генә сюжетын алсаң да, каһарманның олы җанлылыгы даими күренеш буларак тасвирлана. Мәсәлән, төрки халыкларда киң таралган «Алпамыш» дастанында, бигрәк тә аның «Дәдә Коркыт» циклына кергән «Бамсы-Бәйрәк» тәрдәшендә шушындый хәлне күрәбез. Кол Гали бу цикл белән таныш булган дияргә нигез бар.[12]

Зинданнан чыккач, Йосыфның, рәхәткә чумарга ашыкмыйча, башта үзенең тоткын иптәшләрен азат итү турында кайгыртуында да эпик каһарман характеры чагыла.

Зөләйхә сурәтенең нигезендә дә эпик башлангыч ята. Кол Гали бу сурәткә мөһим социаль-әхлакый вазифа йөкли, шунлыктан аның иҗат ихтыяры монда аеруча көчле сизелә.

Мәгълүм булганча, Тәүрат белән Коръәннән башлап, сюжетның барлык җитди чыганакларында Мисыр газизенең хатыны (Асенат, Т.Маннда: Мутеменет; «Зөләйхә» исемен башлап Фирдәүси бирә) бары Йосыфка бәла-каза китерүче тискәре сурәт буларак гәүдәләнә. Аны уңай образ итеп иң әүвәл Фирдәүси эшли. Хәлбуки бөек фарсы шагыйрендә дә сурәт каршылыклы кала. Беренчедән, ул үзе, ир хатыны була торып, Йосыф каршында коточкыз әдәпсезлек күрсәтә. Икенчедән, Йосыфның инде аңа өйләнгәндә кәнизәктән ике баласы туган була. Фирдәүси поэмасында Зөләйхә «кыйбти хатын», ягъни Мисыр кешесе итеп бирелә.

«Әнисел-мөридин»дә китерелгән бер риваять буенча, Зөләйхә—башка ил патшасының кызы. Үзенең бу ягы һәм Йосыфка аны төштә күреп гашыйк булуы, сөеклесе артыннан бүтән патшалыкка китүе белән дастаннар традициясендә тәрбияләнгән төрки шагыйрь күңеленә ул хуш килә. Көнчыгыш поэзиясе тарихында беренче буларак, Кол Гали сюжетның мәхәббәт сызыгын гыйшык дастаннары схемасына кора. Кыз Мисырга алдан ук төштә күргән Йосыфы өчен килгәч, соңыннан газиз хатыны була торып, «әрсезлек» күрсәтүе һәм әхлакый, һәм психологик яктан тулысынча аклана. Шул рәвешле, Кол Гали сурәтне эчке каршылыктан тәмам азат итә.

Аның әсәрендә Зөләйхә—Йосыфның бердәнбере. Шагыйрь бу фикерне ассызыклап әйтә. Әсәрнең каһарманнары мисалында мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләсен хәл итеп, ул үз чоры Көнчыгышындагы күп хатынлылыкка каршы чыга.

9 Жирмунский В. М. Тюркский героический эпос. Л.,1974,с.547.

10 Радлов В. В. Образцы народной литературы тюркских племен Сибири и Джунгарской степи. СПб.,1872,ч.4,с.58.

11 Вайнштейн С. И.,Крюков М.В. Об облике древних тюрков. – Тюркологический сборник. М, 1966,с.177-187.

12 Кара: Хисамов Н.Ш. Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али,с.93-95.

Атасы Йагъкуб белән очрашкач, Йосыфның балаларын бабалары каршына китергәндә әйткән сүзләре мәгълүм дәрәҗәдә ата белән угылның тормыш принципларын каршы куюу булып та яңгырый.

*Андин дагый Йосыфның угланлари,*
*Йагъкуб сурдый Йосыфдан һәм анлари,*
*Йосыф әйдер: «Угланларим безим бари—*
*Җөмләси Зөләйхәдән улур имди».*

Зөләйхә вафатыннан соң да шагыйрь аларның мәңгелек тугрылыгына басым ясый.

*Андин соңра Зөләйхә вафат улди,*
*Йосыф аның хәсрәтилә мәгъмум улди,*
*Андин соңра айрук йәнә ивләнмәди,*
*Угланларин башарубән ирәр имди.*

Шул рәвешле, шагыйрь бердәнбер мәхәббәт һәм хатын идеясен алга сөреп, каһарман һәм гомумән Иагъкуб гаиләсе өстенә килгән бәла-казалар, кардәшләрнең ата мәхәббәтен бүлешә алмыйча ызгышулары—барысы да күп хатынлылык бәласе дигән фикерне үткәрә. Поэзиядә Йосыф сюжетын эшкәртү тарихында бу яктан беренче юл ярučы була ул.

Мондый тәвәккәл идеяләрне күтәреп чыгу өчен нинди дер тарихи-иҗтимагый шартлар, яисә, шуна өстәп, эстетик факторлар этәргеч бирергә тиеш. Бу очракта этәргечнең берсе төрки фольклор булса, икенчесе мөселман Көнчыгышы әдәбиятында гуманизмның (инсанчылыкның) чәчәк атуы. Шагыйрьгә бер яктан моногамияне яклаган халык шигърияте тәэсир итсә, икенче яктан Көнчыгыш әдәбиятын яңа баскычка күтәргән Низами иҗаты йогынты ясый. Шушы ике чыганакны искә алганда гына, Кол Гали әсәрендә куелган мәсьәләләрне һәм сюжеттагы мәхәббәт сызыгының хәл ителеш үзенчәлеген аңларга мөмкин.

«Кыйссаи Йосыф» язылган чорда инде Көнчыгыш әдәбиятының йөзен Низаминең мәхәббәт поэмалары билгели. Бу дәвердә мәхәббәттә тиңлекне һәм бер хатынлылыкны эзлекле рәвештә яклаучы бөек гуманист үрнәгеннән беркем дә азат була алмый. Алай гына да түгел, Кол Гали иҗатының гомуми әһәмияте дә төрки шигъриятне Низаминең идея-эстетик казанышларын үзләштерүгә тәмам якынайтудан гыйбарәт. «Кыйссаи Йосыф»ның фактурасында исә Низами әсәрләрендәге детальләрне дә аермачык күрсәтеп була. Мәсәлән, Зөләйхә сараеның эче сандал агачыннан бизәлү Низаминең «Җиде гүзәл» поэмасындагы Бәһрам шаһның Рум патшасы кызына салдырган сараен искә төшерә.

Зөләйхә сарае—автор фантазиясенең байлыгына бик әйбәт дәлил. Сарай бизәлешен тасвирлаганда, Гол Гали үзенең Көнчыгыштагы элгәреләреннән шактый мөстәкыйль эш иткән. Әсәрдә аерым мотивлар Фирдәүсидән һәм «Әнисел-мөридин»нән алынса да, бизәлешнең әхлакый-эстетик һәм башкарылыш яклары гаять үзенчәлекле. Барыннан да элек, шагыйрьнең төрки укучы каршында үтә дә әдәп саклавы күзгә ташлана. Фирдәүсидә Зөләйхә Йосыфны тәхеттә ялангач утырып каршылый, һәм Йосыф, күзен кая төбәсә дә, көзгеләрдә аның чагылышын күрә. «Әнисел-мөридин»дә дә эротик мотивлар ярылып ята. «Кыйссаи Йосыф» авторы исә үсемлек, кош-корт һәм хайван сурәтләренә киң урын бирә.

Сарай нәкышенең композиция һәм фактурасында эпик башлангыч өстенлек итә. Алтын агачларга кунган кошлар, ул агачлар янында иярле алтын ат, көмеш үгезләр борынгы төркиләрнең ышануларына һәм мәҗүсилек чоры сәнгатенә барып тоташа. Бизәлештәге үзәк мотивларга төрки дастаннардагы нәсел агачы тасвире күчерелгәнлеген күрү читен түгел. Казан татарларының чигү сәнгатендә нәсел агачының ике ягына утыртып ясалган алтын яисә көмеш кош сурәтләрен соңгы чорларга кадәр күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, калфакка чигелгән шушындый сурәт бик

кызыклы[13]. Түбәсенә алтын һәм көмеш кәккүк кунган, алтын һәм көмеш яфраклы тирәк төбенә бәйләп куелган алтын төкле ат алтай эпосының борынгыдан килә торган тотрыклы мотивы санала[14].

Сюжетның хәлиткеч буыны—кульминацияне дә шагыйрь үзенчә корган. Бу исә аның әсәрдәге үзәк проблеманы халыкчан хәл итүенә бәйле.

Хөкемдар һәм халык проблемасы башлангыч төстә бу кин таралган сюжетның барлык вариантларында куела. Әмма аңа халыкчан яңгыраш биргән беренче автор Кол Гали була. Аңа кадәрге чыганакларның берсендә дә Йосыф чын мәгънәсендәге хөкемдар түгел. Тәуратта һәм Коръәндә, тәфсир һәм «Кыйссасел-әнбия»ләрдә Йосыф Мисыр патшасының вәзире булып күтәрелә. Фирдәүсидә аның күтәрелүе берничә баскыч үтә: башта ул фиргавеннең якыны була, ачлык чорында үзе үләр алдыннан, фиргавен тәхетне аңа васыять итә. «Әнисел-мөридин»дә Мисыр мәлиге үзенең төшен юраган Йосыфка тәхет һәм таҗ тәкъдим иткәч, каһарман баш тарта. Мәлик аны үзенең хәзинәдары ясый. Бары «Кыйссаи Йосыф»та гына каһарман төшне юрауга ук патша була. Шагыйрь биредә, тылсымлы әкият схемасына таянып, эпизодны «читен мәсьәлә чишү һәм патшалыкка ирешү» мотивы нигезендә эшкәртә[15]. Мәликнең Йосыфка патшалыгын тапшыруы да әкияткә хас стилистик калыпта башкарыла:

*Падишаһлык бәндән сәңа лайык дорыр,*
*Аның әмрин барча кабул дотың имди.*

Йосыфның идарәсен шагыйрь байга да, ярлыга да тигез караучы «идеаль» итеп тасвирлый. Бу—асылда Йосыф Баласагунлыдан башлап, татар әдәбиятында мәгърифәтчеләргәчә дәвам иткән прогрессив-демократик, әмма хыялый-утопик идея. Кол Гали аңа үзенчәлекле төсмер өсти: ул илдәге идарә гадел булсын өчен, хөкемдар түбәннән, халык күргән мәшәкатьләрне үзе кичереп күтәрелергә тиеш дип саный. Бу исә татар мәкалендәге «Карадан чыккан хан яхшы» дигән фикергә авваздаш.

Гадел идарә өчен хөкемдарның түбәннән күтәрелү зарурлыгын шагыйрь вәзир эпизоды белән кабат раслый. Йосыф тәхеткә утыргач, аның вәзире мәсьәләсе килеп баса. Каһарман сәйранга чыкканда беренче очраган кешене үзенең вәзире итәргә була һәм шулай эшли дә. Ул, үтә йолкыш, кыяфәтсез, фәкыйрь бер кешегә юлыгып, шуны вәзир итә. Вәзир исә Йосыфка лаек акыллы һәм гадел булып чыга. Бу эпизод башлап Кол Галидә очрый. Мәсьәләнең хәл ителешендәге әкиятчәлек беренче очраган кешене сайлап алуда чагыла. Моңа охшаш хәлне бик күп татар әкиятләрендә күрергә мөмкин.

Әсәрдәге башка күп кенә детальләрне Кол Галинең үзгәртеп бирүе дә каһарман проблемасын хәл итүгә буйсындырылган. Мәсәлән, сюжетта Йосыфның кардәшләре кылган явызлыкны фаш итүдә мөһим роль уйнаган алтын савыт Кол Галинең элгәреләрендә реалистик планда эшкәртелсә, төрки шагыйрь бу детальгә әкияткә хас фантастик яңгыраш бирә. Әйтик, Фирдәүсидә Йосыф үзенең кардәшләренә аларның яман эшләрен савыт чыңгыравын «тәрҗемә иткән» булып сөйләсә, «Кыйссаи Иосыф»та савытның үзеннән хикәяләтә. Чөнки алдашу аның каһарманына күләгә төшерә. Деталь әкияттәге «каһарманның тылсымлы булышчылары» мотивына[16] корылган.

Әлбәттә, мондый детальләр әдәби әсәрдә аерым-аерым алынса, беркадәр гадилек булып та яңгыравы мөмкин. Әмма әсәрнең проблематик контекстында аларның эчке логикасы бар, шунлыктан сәнгатьчә хакыйкать буларак ышандыралар.

***

«Кыйссаи Йосыф» поэмасы әдәбият тарихының ялгыз бер күренеш түгел, ул үзенә кадәрге әдәбият үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килеп, аннан соңгы төрки әдәбият үсешенә дә йогынты ясаган әсәр. Аның эчтәлеге нинди чыганаклардан алынуын билгеләү һәм сәнгатьчелеккә йогынты ясаган факторларны ачу әдәбият

[13] Кара: Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. Казань,1969,с!02.
[14] Кара: Поэма «Кысса-и Йусыф» Кул 'Али,с. 171-173.
[15] Кара: Морфология сказки. Л.,1928,с.68,71.
[16] Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. Л.,1946,с.173.

тарихында традицияләр формалашуны күз алдына китерү өчен дә мөһим.

Гасырлар буе эшкәртелеп, камилләштерелгән сюжетка төрки авторның үзеннән яналыклар өстәве нинди юллар белән барган? Моны ачу урта гасыр төрки әдәбиятында сәнгатьчәлек тәҗрибәсен туплауның мөһим ысуллары һәм этаплары хакында нигезле хөкем йөртү өчен кирәк.

Геройны иҗат итү, сюжет төеннәрен оештыру, үзенчәлекле эпизод һәм детальләр кертүнең аерым мисалларын инде өлешчә карап үттек һәм шагыйрьнең башлыча эпос һәм тылсымлы әкият традицияләренә таянуын күрдек. Сәнгатьчәлек мәсьәләләрен хәл итүдә фольклорның башка жанрлары да шагыйрь өчен нәтиҗәле чыганак булган.

Мәсәлән, ата белән угыл арасында хәбәрләшүнең үтә драматик моментларын шагыйрь үзенчә хәл итә. Күзгә иң бәрелеп торган Кәнган гарәбе эпизодын алыйк. Аның Мисырга килешли зиндандагы Йосыф белән сөйләшүе «Әнисел-мөридин»дә үк бар. Йосыф сәүдәгәрдән туган җире һәм атасы турында сораша, кайткач сәлам тапшыруын үтенә. Бу сөйләшү анда ачыктан-ачык, бернинди тел яшерүсез эшләнә.

Кол Гали үзенен каһарманын гарәп сәүдәгәре каршында серле зат итеп калдыра. Шагыйрь социаль психологияне һәм момент үзенчәлеген нечкә тоемлап эш итә. Йосыф үз каршында тукталган узгынчыга сорауларын табышмакка төреп бирә:

*Йосыф әйдер: «Кәнгандән кәлүрмусән,*
*Анда бер каба йегач белүрмусән,*
*Чәүрәсендә ботаклари белүрмусән,*
*Ул ботаклар ун икиму тәмам имди?»*

Теге дә төшеп калганнардан түгел—табышмакны тиз аңлап ала.

*Гарәп әйдер: «Аңладым бу сүзеңни,*
*Белдем, фәһем әйләдем бу разыңни,*
*Вәләкин дыңлыйурмән бу сүзеңни,*
*Бу эш ичрә нә хикмәт вар»,—дәйүр имди.*
*Каба йегач дидекең Йагъкуб дорыр,*
*Унбер углы хезмәтендә хазир дорыр,*
*Ун икинчи Йосыф адлу гаиб дорыр,*
*Хакыйкатьдә ани корд йиди имди.*

Бу өзектәге «каба йегач» метафорасы игътибарга лаек. Ул «биек агач» дигәнне аңлата. Борынгы төркиләрдә нәсел агачын шулай атап йөрткәннәр. «Дәдә Коркыт» дастаннарында, мәсәлән, бу метафора тотрыклы рәвештә бик еш очрый. Коркыт атаның имләү-теләкләрендә («каба агачың егылмасын») һәм бүтән шигъри өзекләрдә әлеге гыйбарә нәсел-ыру яшәячәгенә мәңгелек өметне гәүдәләндерә. Кыскасы, нәсел агачы төрки эпосларда даими күренеш булып йөри. Кол Гали дә шушы традициягә таяна.

Табышмаклы аңлашу исә, гомумән, борынгы дәвердә яшерен телнең актив кулланылуын чагылдыра. Дастаннарда, әкиятләрдә, никахлашу һәм туй йолаларында яшерен тел, ягъни метафорик аңлашу зур урын тоткан. «Патша, вәзир һәм тегерменче» дигән татар әкияте дә тулысынча шуңа корылган.

Элгәреге чыганакларда сюжеттагы роле пассив булган персонажларны җанландыру өчен шагыйрь гаять оригиналь алым куллана. Мәсәлән, Йосыфның бер анадан туган кардәше Ибнейәминнең рухани һәм әхлакый дөньясын ул аның балаларының исемнәрендә чагылдыра.

Мәгълүм ки, төрки халыкларда балага исем кушканда ата-ананың изге теләкләре, бала язмышын алдан юрап куюя яисә аны бәла-казадан саклау нияте чагылыш таба. Ибнейәмин балаларының исемлегендә дә шушы хәлне күрәбез.

Кол Галигә кадәрге чыганаклардан беренче тапкыр «Әнисел мөридин»дә бу деталь очрый. Анда Йосыфның, энесе белән күрешкәч, аның гаилә хәле, балалары

хакында сорашуы бирелә. Йосыф аларның исемнәре белән кызыксына. Энесе жиде улы, өч кызы барлыгын, ә исемнәренең «Йосыф, Бүре һәм Кан» булуын әйтә. Чыганакта, шул рәвешчә, өч исем генә аерым атала. Күрәсен, автор шулар белән генә чикләнгәндер дә. Чөнки Кол Гали поэмасына һәм «Әнисел-мөридин»гә таянып эш иткән Шәйяд Хәмзә әсәрендә дә шушы исемнәр генә телгә алына[17].

«Әнисел мөридин»дә Йосыф, энесеннән мондый исемнәр куюның сәбәбен сорагач, тегесе: «Аларны чакырганда, сине дә искә төшерәм»,—дип җавап бирә. Төрки шагыйрь бу детальнен сәнгатьчә мөмкинлекләрен абайлап ала һәм аны тулыландырып, персонажның бөтен әхлагын ачып бирә. Балаларының санын да ул сюжет нигезендәге символик санга туры китереп, 12 итә. «Әнисел мөридин»нән исә ике исемне генә ала: Корт һәм Кан. «Йосыф» исеме аның өчен берданбер, һәм ул үзенең кабатланмас кыйммәтен сакларга тиеш.

Эпик башлангыч поэманың стилендә дә өстенлек итә. «Кыйссаи Йосыф»ны шул сюжетка язылган барлык әсәрләр арасында аерып торган мөһим үзенчәлек—ул сөйләмнең диалогка корылуы. «Йагъкуб әйдер», «Йосыф әйдер», «Зөләйхә әйдер» кебек композицион-стилистик ялгамнар, һичшиксез, төрки халыклар фольклорындагы әйтешләргә һәм дастан поэтикасына барып тоташа.

Диалог шагыйрьгә сөйләмне мәгълүм дәрәҗәдә индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә. Дөрес, урта гасыр әдәбиятында анлы бер сәнгатьчә күренеш буларак индивидуальләштерү бөтенләй диярлек очрамый. Бу—чорның гомуми үзенчәлегеннән килеп чыга: сәнгатьчә фикерләүнең һәр өлкәсендә гомумилеккә омтылу, күренешләрне шартлы символларда чагылдыру, индивидуаль сыйфатлардан бигрәк уртаклыкка, гомумилеккә игътибар итү урта гасыр эстетикасына бик тә хас. Менә шушы шартлар эчендә Кол Гали персонажларны ике гомумилеккә: унайга һәм тискәрегә генә аера. Каһарманнарның унай булуына беренче шарт итеп ул зирәклекне куя. Табигый ки, андый персонажларның теле дә афористик.

Афоризмнар башлыча Йосыф һәм Йагъкуб сөйләменә хас. Зөләйхә күргән төштә каһарманның сабырлык турында биргән киңәше афористик формада Йагъкуб телендә дә, сарай хезмәтчеләренен Зөләйхәне юатуларында да үзгәрешсез диярлек кабатлана: «Сабыр берлә морад хасил улур имди». «Сабыр иткән морадына җиткән» дигән татар мәкале дә башлап Кол Гали поэмасыннан алынган булса кирәк.

Үз-үзен тотышындагы акыллылык һәм афористик тел Йосыфның үзен рәнҗетүчеләр каршында өстенлеген, вакыйгалардан югары була белүен күрсәтә. Мәсәлән, аны коллыкка саткан агалары турында ул сәүдәгәргә: «һәр кеши үз лайыкын эшләр имди»,—дип җавап бирә. Ә Малик Дугырның «әле хатаны төзәтергә соң түгел» дигәненә каршы: «Кәчән сүз кирү кәлмәз»,—ди.

Йагъкуб сөйләмендәге мәкальләр исә зирәк картның, кайгы эчендә югалып калмыйча, улын күрәчәгенә өмет өзмәвен чагылдыра.

Шул рәвешле, Кол Гали үзенең киң карашлары һәм талант көче нәтиҗәсендә гаять җаваплы һәм читен иҗади бурычны хәл кылган: инде Шәрекъ дөньясында күптән оешып җиткән сюжетка яна тормыш көче биргән, оригинальлек дәрәҗәсе югары булган әсәр барлыкка китергән.

---

[17] Hamza Seyyad/ Yusuf ve Zeliha. Istanbul, 1946, 5.106. Әнисел-мюридин вә шәмсел мәҗалис (фарсы телендә). Лондон кулъязмасының фотокүчермәсе. – Г.Ибраһимов исем. ТӘҺСИ мирасханәсе, ф. 69, тасвирл. 1, сакл. бер. 385, 155 нче кәгазь.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Күкшем

Күкшем авылы Апас районында, район үзәге Апастан 37, тимер юл станциясе Кильдураздан—19, Тәтештән 73 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы ни аңлата һәм ничек барлыкка килгән соң?

Бирегә килеп урнашучылар, олылар сөйләвенә караганда, калын урман арасында намаз укып яшәгәннәр. Төннәр шундый караңгы булган, ә күктә ай ялтыраган. Бу яктылыкны халык "күк шәм" дип йөрткән. Шул нигездә авылга Күкшәм дигән атама бирелгән. Тора-бара ул Күкшемгә әйләнгән.

Экспедиция дәфтәрләремдә авылның өлкән кешесе Гаялетдин Бикчәнтәев (1906 елда туган) мина авыл атамасының килеп чыгышын тагын икенче төрле итеп тә сөйләгән. Авыл янындагы басуларда күк чәчәкләр күп үскәнгә авыл Күкшем дип аталган, имеш.

Авыл яныннан Ташлыклы исеме алган инеш ага. Ул суын Бола елгасына коя. Бола суы авылдан ерак түгел генә үтеп китә. Ул Чуаш республикасыннан башлана һәм Тау ягы төбәгенең күп авыллары аша үтеп, суын Зөягә илтә.

Якындагы басуда Хәлил күле бар. Элек ул матур, мул сулы булган, хәзер исә беткән. Чөнки аңа ашлама капчыклары ташланган, каралмаган, игътибар булмаган. Бу тирәдә сазлыклар күп булган, әлегә кадәр дә сакланганнары бар.Авыл янында бик зур урман полосасындагы аланлыкта Изгеләр зираты урнашкан. Бу зиратка, халык сөйләве буенча, авылны беренче килеп нигезләгән кешеләр күмелгән.

Авылдан бер чакрымнар ераклыкта керәшен зираты бар. Зиратның тирә-ягы койма белән тотып алынган. Елга ике тапкыр халык зиратка бара. Зиратка барыр алдыннан һәр кеше мичкә яга, төрле тәмле әйберләр пешерә. Шул ризыкның бер өлешен табакка тутырып, махсус ашъяулыкка төреп зиратка алып баралар, һәр кеше үз туганың аның кабере янында ризык чәчеп-түгеп искә ала. Зиратка барыр алдыннан мунча ягып үзләрен чисталыйлар, чөнки зиратка ак һәм пакь килеш керү зарур.

## Карга

Карга авылы Әлки районында, район үзәге Базарлы Матактан 11 чакрымда, тимер юл станциясе Бряндинодан—84, Болгар пристаненнән 85 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы тарихи белешмәләрдә телгә алына.

XVIII йөз мәгълүматларын эченә алган Д. А. Корсаков белешмәсендә Карга авылы Актай суы ярында утырган дип теркәлгән. Анда 136 йомышлы, 27 керәшен татары көн күргән.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

1898 елда басылып чыккан тарихи белешмәдә Карга авылында ислам динендәге татарлар яшәгәнлеге күрсәтелә. В. П. Семенов нәширлегендә басылып чыккан хезмәттә Карга авылында 2200 кеше гомер кичергәнлеге, анда волость идарәсе, 2 мәчет һәм кибетләр эшләгәнлеге әйтелә.

Авыл оешуы турында олылар болай сөйли.

Борынгы заманда кешеләр, бераз калкурак урынны сайлап, шунда килеп төпләнә башлаганнар, авыл барлыкка килгән. Ләкин аның исеме булмаган. Уйлашканнар да, мондый карарга килгәннәр, имеш: бер ялгыз агач тирәсенә җыелырга һәм шул агачка иң беренче нинди кош килеп куна, авылны шул кош исеме белән атарга. Халык җыелган, аларны көттереп тормыйча, агачка карга килеп кунган, имеш. Шулай итеп, авыл Карга исемен йөртә башлаган. Авылның исеме турында халык хәтерендә сакланып калган бердәнбер риваять шушы.

Авылны икегә бүлеп Актай елгасы ага. Бу елга хәзер саега һәм тарая бара. Карга яныннан Сарсаз елгасы үтә. Бу елга ярында бик тәмле сулы изге чишмә бар. Аны да Сарсаз чишмәсе дип атыйлар. Чишмә-кизләүне авыл кешеләре чистартып һәм карап тора.

Бакый елгасы—авыл читендәрәк урнашкан сазлыклы урын. Анда өч зур карт зирек үсә. Шушы чокырлыклы урыннан өстәрәк Бакый исемле изге кеше яшәгән дип сөйлиләр. Ул фаҗигале төстә үлеп киткән. Әлеге өч зирекне дә Бакый утырткан. Бүгенге көндә ул урын изге дип исәпләнә, халык телендә «тота торган җир» дип йөртелә.

Вәли елгасы. Авылдан 6—7 чакрым ераклыкта Ромодан авылы утырган. Ул урыс авылы, ләкин халык үзара аралашып яшәгән. Ләкин бервакыт Ромодан урысы белән Карга авылының Вәли атлы кешесе ызгышалар. Вәли агай качып китеп урман артындагы елгага яшеренгән. Ләкин Ромодан урыслары аны шуннан эзләп табалар һәм үтерәләр. Шул вакыйгадан соң елганы Вәли елгасы дип атый башлыйлар.

Хәзер авылда якынча 160 хуҗалык исәпләнә. 1993 елда мәчет ачылган.

## Каратмән

Матур һәм бай табигатьле урыннарга урнашкан авылларыбызның берсе—Зеленодол районындагы Каратмән. Ул район үзәгеннән 37 чакрым ераклыкта исәпләнә. Авыл яныннан Каратмән исемле инеш агып уза. Шул ук исемдәге күл дә бар.

Атама шактый гына тарихи чыганакларда урын ала. Д. А. Корсаков белешмәсендә (1866) күрсәтелгәнчә, Каратмән авылында 28 ясаклы татар көн иткән. Авылда агач мәчет һәм мәдрәсә булган. Нәҗия Борһанова мәгълүматларына күрә, Каратмән авылы халкы күршедәге Олы Карауҗа, Кече Җәке, Уразлы, Үтәнгеш, Герешби халыклары белән бергәләшеп июль аеның беренче декадасында Уҗа исемле җыен бәйрәме үткәргән.

Авыл халкы сөйләвенә караганда, Каратмәнгә иң әүвәле Кара Әхмәт исемле кеше килеп утырган. Каратмән халкы башта үз кешеләрен Олы Җәкегә күмә торган булган. 100 еллар чамасы элек алар аерым зират булдырганнар.

Чишмә, Бакыр, Кече, Мәхмүт боты, Дүрмән, Сөсер, Чыршылык, Мүклек һ. б. елга-инешләр тирә-юнь табигатен бизи һәм халыкка хезмәт итәләр.

Каратмән сүзенең мәгънәсенә килик.

Каратмән атамасы—«кара» этнонимыннан һәм «төмән» («мең») компонентларыннан кушылып ясалган катлаулы этнотопоним. Этнонимнар кушылмасыннан торган мондый кабилә-кавем һәм халык исемнәре байтак: каракалпак, каранугай, каракыпчак, каратабын, каракытай, карабүрек, карабаганалы, карасираклы һ. б.

Галимнәребез Һ. В. Йосыпов һәм М. И. Әхмәтҗанов бу авыл зиратында 1419 елга мөнәсәбәтле, нугай татарлары этнонимы «табын» исеме язылган кабер ташы табалар. Каратмәннән ерак түгел Олы Карауҗа, Кече Карауҗа, Карабай, Караби (Караваево) исеме алган авыллар бар. Диалектологлар фикеренә караганда, бу авыллардагы халык сөйләшендә нугай теле үзенчәлекләре ачык чагыла. Бирегә нугай татарларының кара төркеменә керә торганнары килеп урнашкан дип уйларга нигез бар.

Авылда башлангыч мәктәп, китапханә, клуб, балалар бакчасы, мәчет эшли.

## Каракүл

Дөньякүләм мәшһүр янартаулары, шарлавыклары, упкын-тарлавыклары булмаса да, Татарстан табигатенең дә көтелмәгән могжизалары, күңелне сөендерә яки кинәт сискәндерә торган күренешләре юк түгел. Ике катлам хасил итә торган, ягъни күл астында тагын бер күл булган Каракүл, кышның зәмһәррир салкын көннәрендә дә жып-жылы, яисә җәйнең эссе вакытларында да тешенне сындырырлык, сап-салкын сулы чишмә-кизләүләр, рәвешләре дөя өркәченә охшаган таулар, чалбар балагын хәтерләткән елга тармаклары бездә дә бар.

Биектау районындагы Каракүл—район үзәгеннән 48 чакрым ераклыкта урнашкан кечерәк кенә бер авыл.

Д. А. Корсаков белешмәсендә (XVIII йөз) Каракүл авылы Түбән Айбаш дип бирелә һәм анда ясак түли торган 37 татар яшәгәнлеге күрсәтелә. Авылда бер мәчет булган. 1878 елда да авыл Түбән Айбаш дип йөртелгән. Андагы 67 хуҗалыкта 215 ир-ат һәм 191 хатын-кыз көн күргән, авылда гыйбадәт кыла торган бер йорт һәм жил тегермәне булган. И. А. Износков Каракүл авылын Кече Айбаш, Түбән авыл дип тасвирлый. Каракүл янындагы Гәреч сәүдә юлының уң ягына урнашкан авыл халкы Зур Айбаштан күчеп утырган. Авылдагы 78 хуҗалыкта ислам динендәге 229 ир-ат һәм 218 хатын-кыз көн күргән, алар Түбән Айбаш авылы җәмгыятенә кергәннәр. Тормыш-көнкүрешләре уртача булган, тегермән тарту, мич чыгару, умартачылык белән шөгыльләнгәннәр.

«Каракүл» атамасы Каракүл исемле гидронимга мөнәсәбәтле. Ә күл үзе ни өчен шулай аталган икән?

Бу атаманың барлыкка килүе жирнең геоморфологик төзелеше белән бәйләнешле. Татарстанның кайбер районнарында суда тиз эрүчән карст токымнары очрый. Бу токымнар эрү нәтиҗәсендә Упкын күлләр дә ясала. Төбендә мондый токым булган күлләрнең суы үзенә бер кара-кучкыл төс алып тора.

Элекке Дөбъяз районы жирләре геоморфологик яктан шактый үзенчәлекле. Бу районның кайбер төбәкләре, аерым алганда Ашыт суы бассейны, карст токымнарына бик бай доломит-известьташтан тора. Тиз эри торган бу калын катлам жир өстенә якын урнашкан. Карст токымнары эрү нәтиҗәсендә Ашыт елгасы бассейнында жир асты сулары күп. Экспедициядә йөргәндә Дөбъяз районының кайбер төбәкләрендә (мәсәлән, Олы Солабаш һәм Кече Солабаш авылларында) авыл аксакаллары басуда Дингез күзе исемле чыганаклар бар икәнлеген сөйләделәр. Биектау районының Айбаш һәм Яңа Рәс авыллары арасында жир асты сулары байтак. Яңа Рәс авылы жирендәге Упкын чишмәсе һәм карст токымнары эрү аркасында убылып ясалган Чүмәләк суы шушы хакта сөйли.

Каракүлнең дә суы каралып тора. Ләкин күп еллар үткән саен ул саега бара. Аның тирә-юне элек камышлы һәм жикәнле булган. Хәзер исә бу матурлык бетеп бара.

Каракүл авылы тау-калкулыклар арасына урнашкан.

Каракүлдә башлангыч мәктәп, клуб, медпункт, кибет, мәчет эшли.

Ялгыз яши торган олыларга авыл халкы игътибарлы. Күрше-күлән аларны пешкән ризыкларыннан, яккан мунчаларыннан калдырмый. Укучы балалар да аларга булыша. Халык киләчәккә карап яши. Ләкин яшьләр читкә, шәһәргә китү ягын кайгырта. Авылда эш юк...

*Дәвамы киләсе саннарда*

# К

**КОЛШӘРИФ** (Шәриф Хаҗитархани, Мөхәммәд—Шәриф) (?-1552 нең октябре, Казан), дәүләт һәм дин эшлеклесе, шагыйрь. 1546 дан (бүтән мәгълүматларга караганда 1551 дән) Казан ханлыгының дин башлыгы. Чыгышы б-н Әстерханнан булган сәет Мансур улы (татар вариантында соңыннан псевдонимга әверелгән Хаҗитархан). 1551 дә Мәскәүнең Казанга каршы яңа хәрби хөҗүмнәрен булдырмау максатыннан чыгып, Шаһгали хан б-н сөйләшүләр алып бара. Чапкын Отучев б-н бергә Казан тәхетенә чакырылган Ядегәр Мөхәммәд хан хөкүмәте әгъзасы. 1552 дә Казанны соңгы чиктә саклап калырга тырышучыларның берсе. Шәкертләрдән төркем төзи, хан ныгытмасы өчен барган сугышта һәлак була.

К.Ш.нең шигъри мирасыннан соңыннан «Бакырган китабы»на кергән 5 газәле билгеле. «Кыйссаи Хөбби хужа» дастанын да аңа нисбәтлиләр (1889 дә нәшер ителә). Әсәр урта гасыр төркитатар әдәбиятында киң таралган сюжетка нигезләнә. Тасвирланган вакыйгалар 12 гасырда Урта Азиядә бара. Әсәрнең төп геройлары—Бакыргани һәм аның кече улы Хөбби. Төрле могҗизалар (суелган сыерларны терелтү, дингездә суга баткан кешеләрне коткару һ.б.) башкара торган Хөббинең изгелегенә Бакыргани ышанмый. Бөтен игътибарын ул олы уллары Әсхәр һәм Мәхмүдкә бирә. Атасының «Икебез дә акыл иясе булып, бер илгә сыймабыз без» дигән сүзләреннән соң Хөбби, ак кошка әйләнеп, читкә очып китә. Атасының улына карата миһербансызлыгы Бакырганинең рухи остазы Ә.Ясәвигә мәгълүм була. Ул үзенең мөридәнә бер еллык авыр физик эш б-н җәза бирә һәм аңа Аллаһы Тәгаләнең әмерен житкерә. Бу әмер аркасында Бакыргани улы б-н фәкать үлгәннән соң гына очраша ала.

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» (1550) исемле тарихи әсәрнең авторы да К.Ш. Бу чәчмә әсәр тексты эченә 8 шигырь кергән. Аларда 1549-50 еллардагы Иван IV нең Казанга хөҗүмнәре тасвирлана, Казан ханлыгы чоры дәүләт эшлеклеләре исемнәре атала, камалышта Казанны дошманнан алып калган сакчыларның батырлыгы турында сүз алып барыла. Тюрколог Ә.—З.Вәлиди әсәрнең кульязмасын Төркиянең Кутаһия ш. китапханәсендә табып, 1963 тә аны беренче тапкыр бастыра. 1995 тә әсәр Казанда беренче тапкыр татар һәм рус телендә басыла.

Әсәр.: Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр: Газәлләр, кыйсса. К., 1997; Шәрифи Х. Завер-наме-и вилайет-и Казан // Гасырлар авазы—Эхо веков. 1995, май.

Әд.: Подлинная о Казанском походе запись Царственной книги 1552 г. и сказание князя Курбского о покорении Казани. М., 1902; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Исхаков Д.М. Сеиды в позднезолотоордынских татарских государствах. К., 1997; Кул Шариф и его время. К., 2005; Шәрипов Ә. Ничек килеп життен син, борынгы кыйсса? // Аргамак. 1993.№ 11; Togan Z.V. Kazan Hanliginda Islam Turk Kulturu // Islam Tetkikleri Enstitusu Dergisi. 1963. Cilt III. Sayi 3-4; Kaya O. Kul Serifin Ir Hubbi Destani // KOK Arastirmalar. 2000. Cilt II. Sayi 1.

*А.М.Ахунов.*

**КОРБАНОВ** Рафис Харис улы (1.1.1957, Биектау р-ны Кече Битаман ав. туа), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1982-89 да Телевидение һәм радиотапшырулар буенча ТАССР Дәүләт к-тында мөхәррир булып эшли. 1989 дан «Салават күпере» ж-лында, 1990 нан «Идел» ж-лында җаваплы сәркатиб.1991-93 тә «Әдәби жомга», 1993 тән «Заман—Татарстан» газеталарының баш мөхәррире. 1993-95 тә «Әкият» татар курчак т-рында әдәби-драматик бүлек мөдире. 1996дан Татар кит. нәшриятында, 1999дан матур әдәбият һәм балалар әдәбияты бүлеге мөдире, 2007-2008—баш мөхәррир. 2008дән нашрият эше белән шөгыльләнә. Балалар өчен язылган «Буран кайда йоклый?» (1987), «Сөзгәк Болыт» (1991), «Капкорсак» (1992), «Болыт суны болгаткан» (2000), «Алмалы төн» (2002), «Тапкырларга табышмак»

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

(2003) шигырь җыентыкларында туган як табигате, аны саклау, хезмәт сөючән, гадел, мәрхәмәтле булу турында яза. К.ның «Куркуын җингән Куян» (1994), «Бардым күлгә, салдым кармак» (1995), «Керпе малае дуслар эзли» (1995) пьесалары буенча «Әкият», Татар яшьләр т-ры, Яр Чаллы курчак т-ры, «Нур» татар т-ры сәхнәләрендә спектакльләре уңыш белән барды. «Бардым күлгә, салдым кармак» пьесасы буенча куелган спектакль Измир (Төркия, 1999), Канны (Франция, 2000) шәһәрләрендә узган курчак т-рларының халыкара фестивальләрендә дә күрсәтелде. Аның балалар өчен сәхнә әсәрләре «Куркуын белмәс Куян» (2000) җыентыгына тупланган. К. шулай ук «Уян, татар!» (1999), «Яра» (2004) исемле лирик-публицистик шигырь җыентыклары авторы да.

Әд.: Гыйльманов Г. Гөлле шигърият // Заман сүз сорый. К., 1991; Галиев Ш. Сайланма әсәрләр. К., 2002. 4 т.

**КОРОЛЕНКО** Владимир Галактионович (15.7.1853, Житомир ш.—25.12.1921, Полтава ш.), язучы, җәмәгать эшлеклесе. «Макар төше» («Сон Макара», 1883), «Сукыр музыкант» («Слепой музыкант», 1886), «Павлов очерклары» («Павловские очерки», 1890), «Тел белмәү» («Без языка», 1895) исемле хикәя һәм повестьлар, «Замандашым турында» («История моего современника», 1922) автобиографик әсәр h.б. авторы. 1879 да революционерлар б-н элемтәдә тора дигән шик тудырган өчен аны кулга алалар һәм сөргенгә хөкем итәләр. Казанда Якутия ягына сөргенгә барганда (1880) һәм аннан кайтканда (1884) була. 1885 тә «Волжский весник» газетасында язышa. Анда ул «Изге бәйрәм алдындагы төн» («В ночь под светлый праздник»), «Чиркәүдә чаң кагучы карт» («Старый звонарь»), «Дингез» («Море»), «Караңгы почмак» («Глушь»), «Станокта» («На станке») исемле очерк һәм хикәяләрен бастыра. 1888 нең маенда Красновидово а. бергә сөргендә яшәгән М.А.Ромась дустында була. Соңыннан ул «Художник Алымов» (1896) хикәясе төп героеның прототибы була. 1888 нең августында Казанга язучы һәм журналистлар берлеге тәэү нияте б-н килә (полиция рөхсәт бирми). 1895 тә Чистай, Алабуга, Мамадышта булып китә.

Әсәр.: Собр. соч.: В 10 т. М., 1953—56; Собр. соч.: В 6 т. М., 1971.

Әд.: В.Г.Короленко в воспоминаниях современников. М., 1962.

*Ж.Ф.Хәкимева.*

**КОРЧАГИН** Владимир Владимирович (14.10.1924, Казан), геолог, язучы, геол.—минер. фән. канд. (1954), ТР-ның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). 1951 дә Казан ун-тын тәмамлый һәм ш.у. 1987 гә кадәр укыта. «ТАССРның көньяк-көнбатыш өлешендә һәм янәшә районнарындагы югары юра утырмаларының литологиясе» («Литология верхнеюрских отложений юго-западной части Татарской АССР и смежных с ней районов», 1962), «ТАССРның көньяк-көнбатыш өлешендә һәм янәшәдәге Ульяновск Идел буенын түбән акбур утырмаларының литологиясе» («Литология нижнемеловых отложений юго-западной части Татарской АССР и смежных с ней районов Ульяновского Поволжья», 1964) минерология буенча монографияләр авторы. 1988 дән ТРның Язучылары берлегендә: рус әдәбияты секциясе җитәкчесе, 2003 тән әдәби консультант. Иҗаты фәнни-фантастик һәм мажаралы әсәрләрдән гыйбарәт: «Явыз рухлар елгасы сере» («Тайна реки злых духов», 1961) повесте, «Тау сырты аша юл» («Путь к перевалу», 1968, «Астий эдельвейсы» («Астийский эдельвейс», М., 1982), «Курку әсирләре» («Узники страха», 1991) романнары, «Үткәннәр өрәге» («Призрак минувшего», 1993), «Ташландык бала» («Подкидыш», 1998) повестьлары, «Карадан киенгән хатын» («Женщина в чёрном», 2002) романы. Алар төрле спектрдагы мәсьәләләрне яктырталар: кеше акылы барлыкка китергән вакыттан алып термоядер сугышны булдырмау, башка цивилизацияләр б-н аралашу юлларына кадәр.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Шемелова Е. Благославлённый самим Державиным // Детская библиотека. 2002. №2.

*Р.Р.Мусабәкова.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

# БӨЕКЛЕК БАСКЫЧЛАРЫ

*Киләсе елның апрель аенда бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 125 ел тула. Шушы олуг юбилейга әзерлек йөзеннән аның тормышындагы һәм иҗатындагы иң мөһим фактларны искә төшереп барырга булдык. Бу айдан башлап журналыбызның һәр санында шагыйрь тормышының бер елы яктыртылачак. Биредә без Татарстан китап нәшриятында 2003 елда басылып чыккан «Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы»исемле җыентыктан файдаландык.*

## 1905 ел

**13 гыйнвар.** ***(«Безнең әти аягында җыермалы ал читек...»). Шагыйрь бу җырларны кулъязма «Әлгасрелҗәдит»тә түбәндәге искәрмә белән урнаштырган: «Надан бер бай улына чыккан кызлардан берсенең түбәндә китерелгән җырларны матур күзләреннән яшь агызып җырлаганын ишетеп, сынык күнелебезгә бик нык тәэсир иткәнгә күрә, журналыбызда бастырдык».

**26 гыйнвар.** *** («Әхмәтсафа әфәнде—фазыйль әдибтер кәнде...»). Шигырь Тукайның «Мотыйгыя» сабакташы шагыйрь Әхмәтсафа Байтирәковка багышланган. Бу шигырьгә каршы Ә. Байтирәков Тукайны мактап хат язган.

**1 май.** Уральск эшчеләре Ханская рощада халыкара бердәмлек көне—Беренче майны билгеләп үтәләр. Тукай бу бәйрәмгә катнашкан булырга тиеш. Чөнки эшчеләр тарафыннан оештырылган демонстрацияләргә, митингларга ул актив катнашкан. Бу турыда мәкаләләр дә яза.

**12 май.** Г. Тукайның беренче шигырьләрен, мәкаләләрен урнаштырган, аның шигъри таланты ачылуга зур булышлык иткән кулъязма «Әлгасрелҗәдит» журналы 1905 елның 12 май саны белән тукталып кала. Барысы 9 сан чыга.

**Май.** К. Мотыйгый «Уралец» газетасы типографиясен арендага ала. Аның тәкъдиме белән Г. Тукай бу басмаханәгә өйрәнчек булып керә. Монда аны кассадагы хәрефләрне ничек урнаштыру, гомумән, хәреф җыю эшенең техникасына әлеге типографиядә эшләүче рус эшчесе Александр Гладышев өйрәтә. Ул үзенең истәлекләрендә, өч көн шөгыльләнгәннән соң Тукайның хәрефләрне ничек урнаштыру тәртибен белеп алуы, беренче эше итеп «Казанның Габдулла Тукаев» гыйбарәсен җыюы турында яза. Монда ул 1 сум 50 тиен хезмәт хакы ала.

А. Гладышев Тукайның матбагага өйрәнчек булып 1904 елның ахырларында—ноябрь яки декабрь аенда керүен әйтә. К. Мотыйгый, Р. Нәфыйгов күрсәткән даталар дөреслеккә турырак килә, чөнки К. Мотыйгый типографияне 1905 елның май аенда сатып ала.

**Май-июнь (якынча).** Г. Тукай *** («Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран...»)*, ***(«Чөнанча бездә Камил әл-Мотыйгый...») шигырьләрен яза.

**8 июнь.** К. Мотыйгый Г. Тукай актив катнашкан басма «Әлгасрелҗәдит»

журналын чыгаруга рөхсәт ала. 4 июльдә журналнын цензоры итеп Казан Учительская семинария укытучысы Н. И. Ашмарин билгеләнеп куела.

**Җәй.** Г. Тукай якшәмбе көннәрендә «Мотыйгыя»дәге сабакташы Ярулла Морадый белән бергә еш кына Ханская рощада үткәрелә торган халык гуляньесенә чыга. Табигать матурлыгына хозурлана, солдатлар тарафыннан уйнала торган музыканы бирелеп тынлый, су коена.

Тукайнын дусты, сабакташы Ярулла Морадый (соңыннан укытучы) истәлекләрендә шундый белешмә бар: «Беркөнне Тукай иптәш бөтенләй язу эшләренә бирелергә уйлады. Миннән ун тиен акча сорап алды да кәгазь вә карандаш сатып алып, мәшһүр Крыловның басняларын татарча тәрҗемә итәргә тотынды.

Бу басняларның кайсыларының безнең татар тормышына муафыйк урыннарын күрсәтә вә бу хакта үз тарафыннан күп сүзләр дә кушып куя иде. Шушы ук җәйне бер хатында үзенең Крылов басняларын тәмам итеп, «Мәҗмугаи мөфидә» исеме илә Камил Мотыйгыйга нәзер өчен биреп, каләм хакына егерме биш тәнкә алырга муафыйк булганын бик куанып язган иде».

Г. Тукай Лбищенскидан ун километрлар ераклыкта урнашкан казакъ авылы Дуанда кунак була. Авылда казакъ халык җырларын (үлән) җыйный. Кемгә һәм кем белән барганы билгеле түгел.

**29 август.** ***(«Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран...»), ***(«Чөнанча бездә Камил әл-Мотыйгый...») шигырьләре язылган һәм «1906 нчы сәнәсе башында чыкмая башлаячак «Әлгасрелҗәдит» журналынын мөфассал игъланы»нда басылган. Болар—Тукайның беренче басма шигырьләре. Беренчесе чыгачак басма «Әлгасрелҗәдит» журналына, икенчесе анын булачак нашире һәм мөхәррире К.Мотыйгыйга мәдхия-мактау формасында язылган. Шигырьнең беренчесе алдында Г.Тукайның түбәндәге мөрәҗәгать хаты урнаштырылган:

«Уральскида мәдрәсәи «Мотыйгыя»дән,

29 август, 1905 сәнә.

«Мөхтәрәм Мөхәммәткамил әфәнде!

«Күптән бирле көтелгән «Әлгасрелҗәдит» журналын чыгарырга рөхсәт алуыгызны ишетеп, чиктән тыш шатландым. Әгәр журналыгыз битләрендә безнең кебекләргә урын бирелсә, мин, хәлемнән килгәнчә, журналыгызга тезмә һәм чәчмә әсәрләр язып торырга вәгъдә итәм һәм, шул вәгъдәмне ныгыту өчен, журналыгыз турында шушы зәгыйфь кенә бәетләремне яздым. Журналыгызның бер почмагында басылуын өмет итәм».

**2 сентябрьдән соң.** Петербургта татар телендә беренче газета «Нур»ны чыга башлавы белән котлап «Шигырь» («Шималь яктан...») исемле мәдхия-тезмә яза.

«Нур»ның беренче саны 1905 елнын 2 сентябрендә чыга.

**15 октябрь.** Г.Тукай «Шигырь» («Шималь яктан...») мәдхия-тезмәсен түбәндәге үтенеч белән Петербургка «Нур» газетасы редакциясенә җибәрә: Петербург шәһәрендә «Нур» мөхәррире әфәнде хәзрәтләренә. Безнең түбәндәге зәгыйфь кенә бәетләребезне, кимчелекләренә дә карамастан, газетагызның почмагына сыйдырсагыз зур яхшылыгыгыздан санар идем».

**21 октябрь.** Г. Тукай Уральск типографиясе эшчеләре оештырган демонстрациядә катнаша. Демонстрация эш хакын күтәрүне, 8 сәгатьлек эш көне урнаштыруны таләп итеп оешкан була.

**26 ноябрь.** Уральскида Г. Тукай актив эшләгән «Фикер» газетасының беренче саны чыга. «Атнага бер чыгып, соңыннан атнага өч тапкыр чыгачак» дигән белдерү бирелгән (1907 елнын 13 маенда туктала). Мөхәррире Камил Мотыйгый Төхфәтуллин.

Г. Тукайның әлеге газетаның 1 нче санында басылган беренче шигыре «Мужик йокысы» «Мөтәрҗим Габдулла Тукаев» дигән имза белән чыга. Әсәр рус шагыйре А. В. Кольцовның «Что ты спишь, мужичок» (1839) шигыреннән ирекле тәрҗемә.

«Габдулла Тукаев» дигән имзаны шагыйрь беренче мәртәбә шушы шигырьнең ахырына куя.

**Ноябрь.** ***(«Бу көндә бер сарай ачты әһали...») мәдхия-тезмәсен яза. Мәдхия 1905 елнын ноябрендә Уральскида ачылган «Казан миһманханәсе»нә багышланган.

Шигырь «Фикер»дә басылырга тиеш булса да, үз вакытында басылмый калган. Беренче тапкыр «Г. Тукай. Академик басма»нын 1 нче томына (Казан, 1943) кертелгән.

**4 декабрь.** «Шәһәр хәбәрләре» исемле мәкаләсенең беренче кисәге имзасыз басылган. «Фикер» газетасында «Шәһәр хәбәрләре» дигән бүлекне Г.Тукай алып барган. Мәкаләнең эчтәлегеннән чыгып караганда да ул шагыйрьнең ***(«Бу көндә бер сарай ачты әһали...») дигән Уральскида «Казан» миһманханәсе ачылуга багышланган мәдхиясе белән аваздаш, хәтта кайбер гыйбарәләр, сүзләр тәңгәл килә. Бу мәкаләне Тукай язган, дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

**6 декабрь.** «Шигырь» («Шималь яктан...») исемле мәдхия-тезмәсе редакциягә юллаган үтенече белән бергә басыла. Шушы ук санда «Хәят», «Тәрҗеман» газеталарына багышланган дүртьюллыклары да урнаштырылган.

Болар барысы да мәдхияләр. Г. Тукай иҗатынын башлангыч чорында мәдхия язу белән сизелерлек мавыккан.

**11 декабрь.** «Хөррият хакында» шигыре «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган.

Шигырь 1905 елгы «17 нче октябрь манифесты»н тәбрик итеп язылган.

«Шәһәр хәбәрләре» исемле мәкаләсенең икенче кисәге имзасыз басылган.

**18 декабрь**. «Дустларга бер сүз» исемле шигыре чыга. Шигырь 1905 елгы «17 нче октябрь манифесты» унае белән язылган.

*Бу хөррият манифесте-государьдыр,*
*Кадрен белеп, кирәкләрне сорыйк имди,*

—ди шагыйрь.

**25 декабрь.** «Иттифакъ хакында» исемле шигыре чыга. Шигырь дини китап «Бәдәвам»нын ритм-рифма үлчәменә нигезләп язылган.

**Ел дәвамында.** Г. Тукай үз чорынын мәдәни тормышында актив катнашкан журналист, укытучы Сәгыйть Кәримгә (1883—1939) хатлар яза. «Габдулла әфәнде Тукаев белән минем арадагы мөнәсәбәт 1905 елдан башлана. Ул вакыт мин Оренбургта, ул Уральскида иде. Шул вакыт мин «Фикер», «Әлгасрелҗәдит»кә язган нәрсәләремә карата аңардан өч-дүрт мәртәбә хат алдым»,—ди ул.

**Ел ахыры.** «Фикер» газетасы чыга башлагач (27 ноябрь) Габдулла әфәнде, «Фикер» матбагасында бишәр сум вазифа алып, ике ай наборщик булып хезмәт итте.

Наборщик вакытында бәгъзе бернәрсәләрне үзлегеннән төзәтә башлагач, Камил әфәнде анар ун сум жалунье биреп, мөсәххих итеп куйды»,—ди Г. Кариев үзенең истәлегендә.

К. Мотыйгый истәлегендә иң әүвәл айга сигез сумга хезмәт итә башлавы, торабара хезмәт хакын егерме биш сумга күтәрүе турында әйтелә.

Истәлек авторларыннан К. Мотыйгый фикерләре дөреслеккәрәк туры килә. Тукай Казанга килгәч, Шәһер Шәрәф белән очрашкан вакытында Уральскида егерме-егерме биш сум кадәрле вазифа алып эшләве турында сөйли.

Хатыйп
Миңнегулов

# ТАТАРНЫҢ БӨЕК БЕР МОҢЧЫСЫ

Октябрь инкыйлабыннан соң төзелгән «Башкортстан Җөмһүрияте», гәрчә ул бу исем белән йөртелсә дә, чынлыкта Татар-башкорт Республикасы дип атарлык. Чөнки андагы халыкның өчтән берен, ягъни миллионнан артыгын диярлек татарлар тәшкил итә. Шунысы мөһим: алар биредә диаспора түгел, ә шушы туфракта, биредәге башкортлар кебек элек-электән гомер кичергән җирле халык. Мондагы кавемдәшләребез күп гасырлар буе үзләрен милләтебезнең мөһим бер кыйсеме итеп тойган: бер үк телдә сөйләгән, бер үк телдә язган, бер үк моңнарны көйләгән. Башкортстан җирләрендә туып үскән, биредә яшәгән меңнәрләгән талантлар гомумтатар рухи мирасына гаять зур өлеш керткәннәр һәм кертәләр. Безнең әдипләребезнең, мөгаен, өчтән бере бу җөмһүрият туфрагы белән бәйләнешледер. Алар арасында Шәмседдин Зәки, Акмулла кебек элегрәк чор шагыйрьләре дә, Г.Ибраһимов, Дәрдемәнд, Ш.Бабич, Ф.Кәрим, Н.Исәнбәт, М.Әмир, Ә.Еники, Н.Фәттах, И.Юзеев кебек XX йөз әдипләре дә, Ә.Баян, Р.Гаташ, Р.Миннуллин шикелле бүгенге каләм ияләре дә бар. Болардан башка татар сүз сәнгатен, гомумән, күз алдына да китереп булмый.



Башкортстан җирлеге, Урал татарлары биргән иң зур әдипләрнең берсе, әлбәттә, Мәҗит Гафури (1.08.1880—28.11.1934). Күңелендә аз гына татарлык чаткысы булган һәр кешегә бу исем яхшы таныш. Аның уй-кичерешләргә бай иҗаты, милли рухлы, инсани эчтәлекле язмалары инде менә гасырдан артык халкыбыз белән бергә яши, аның күңелен нурландыра; берничә буын мәктәп балалары әдипнең шигырьләрен ятлый, әсәрләрен өйрәнә. Телебезне, милли рухыбызны саклауда, хәтер дәвамчанлыгын тәэмин итүдә бу шагыйрьнең роле искиткеч зур. М.Гафуриның әсәрләре инде йөз ел буена басылып тора, аның тормышы, иҗаты хакында да күпләгән мәкалә-хезмәтләр язылган. Болар арасында Г.Тукай, Г.Ибраһимов, С.Кудаш, А.Таһиров, Г.Рамазанов, Ә.Нигъмәтуллин, Г.Халит, Н.Юзиев, М.Мәһдиев һәм башка бик күп зыялыларның язмалары бар. Бу үзе генә дә әдип эшчәнлегенең зур әһәмияткә ия икәнлеген сөйләп тора.

Г.Ибраһимовның мәшһүр «Кызыл чәчәкләр» бәяны «Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек» дип башлана. Бу сүзләр М.Гафуриның тәрҗемәи хәленә дә туры килеп тора. Чыннан да, ул гадәти татар авылыннан чыгып, яшәеш-мәгыйшәтнең бөтен мәшәкатьләрен, кыенлыкларын күреп, үз көче, үзенең тырышлыгы белән әдәбият сәхнәсенең түренә күтәрелә.

М.Гафури—ихласи шәхес. Аның тормыш юлы, рухи халәте әдәби әсәрләрендә, геройларының эш-гамәлләрендә шактый дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан. Өстәвенә «Тәрҗемәи хәлем», «Баштан үткәннәр» кебек автобиографик язмаларында әдипнең гомер юлы шактый тулы һәм үтемле яктыртыла. Шуңа күрә биредә без шагыйрьнең тәрҗемәи хәлендәге аерым факт-күренешләрне генә атап китәрбез.

Габделмәҗид Нургани улы Гафуров үзенең бер язмасында болай ди: «Метрика дәфтәре минем 1880 елда туганны күрсәтә. Мин кечкенә чакта әни минем: «Син тары утау вакытында тудың»,—ди торган иде. Шуңа караганда мин 80нче елның июнь

числосында туган булсам кирәк ...[1] (IV т., 487 б.). Әмма хәзерге фәндә әдипнең туган вакыты 1880 елның 1 августына (иске стиль белән 20 июленә) нисбәт ителә.

Табигать, тирә-юнь кешенең формалашуына, аеруча иҗат әһелләренең үсешенә зур йогынты ясый. Әгәр дә кечкенә Габделмәҗид олуг Гафури булып өлгергән икән, монда аның кече ватаны да мөһим роль уйнаган. Әдипнең туган авылы Җилем-Каран Уфадан көньяк-көнчыгышка таба «җитмеш-сиксән чакрымнар» ераклыкта урнашкан. Гаҗәеп матур Агыйдел, Җилем сулары, Урал таулары, болынлыклар. Күп еллар үткәч тә әдип «Табигатьнең иң матур бер урынына ташланган шушы Җилем-Каран авылы минем туган бишегем була инде»,—дип сокланып яза (IV т., 354 б.).

[Мина 2005 елның октябрь башларында Башкортстанда М.Гафуриның тууына 125 ел тулу бәйрәмендә катнашырга туры килгән иде. Шул чагында Уфадан шагыйрьнең туган ягына баруларым, андагы табигатькә хозурлануларым әле хәзер дә хәтеремдә]. Шунысы кызыклы: М.Гафури , Дәрдемәнд, Г.Ибраһимов, М.Әмир һәм татарның кайбер башка мәшһүр затлары шушы ямьле төбәктән—элеккеге Эстәрлетамак өязеннән, андагы татар авылларыннан. М.Гафури иҗатында пейзаж, табигать күренешләре, ел фасыллары хакында сәнгати камиллеккә ия булган шактый гына юллар бар. Аларда әдипнең туган төбәге тәэсирен абайлау кыен түгел.

Булачак шагыйрьнең төп йорттагы тәүге еллары, балалык вакыты да чагыштырмача тулы канлы, табигый, бөтен уза. Үзенең «Тәрҗемәи хәлем» әсәрендә ул болай дип яза: «Әти Нургани (1887-1894. Х.М.) исемендә, әни Марзия исемендә булып, мин ун яшьләргәчә шуларның җылы кочакларында тәрбияләндем. Үз-үземне белә башлаган вакытта әни дә, әти дә исән булу өстенә, Нурислам, Мәһди исемендә ике абзам, Әхсән исемендә бер энем, Фатыйма һәм Сафия исемендә ике апам бар иде » (IV т., 356 б.). Күрәсез: алты бала. Бу исә үз чиратында холыкны тәрбияләүдә, үзара аралашу, ярдәмләшү күнекмәләре булдыруда мөһим роль уйный. М.Гафури әнисенең «бик йомшак күнелле булуын», әтисенең «сүзгә оста икәнлеген» искәртә. Нургани хәлфә өендә чын мәгънәсендә китап культы яши. «Әбугалисина», «Хатәме Тай», «Сәйфелмөлек», «Тутыйнамә» һәм Шәрыкның, төрки-татарның башка бик күп әсәрләрен тыңларга кичләрен авылның башка кешеләре дә җыела. Мондый «әдәби салоннар»ның үзәгендә, әлбәттә, Нургани хәлфә үзе. Ул күпвакыт «китапны кулына да алмыйча», «яттан гына сөйли». Шулай итеп, уку, китап белән мавыгу Габделмәҗиднең күңеленә бала вакыттан ук сеңеп кала. Шунысын да әйтик: әсәрләре аша, истәлекләрдән әдипнең укымышлы булуы, аеруча гарәп, фарсы һәм төрки телләрен, әдәбиятләрын белүе, казакъ, башкорт фольклорыннан яхшы хәбәрдарлыгы, төрки-татар рухи мирасында балык кебек йөзүе ачык сизелеп тора. Аның үз иҗатында китапны, белем-мәгърифәтне зурлавы, мәктәп балаларын, сабак укучыларны сөеп тасвирлавы да юкка гына түгел. 1909 елда язылган бер шигырендә ул китапны үзенең «сердәше», «юлдашы», «бәхет чыганагы», «атам, анам, балам һәм остазым» дип атый ( I т., 151 б.).

М.Гафури шәхесе—укуга, белем эстәүгә омтылышның күркәм бер гәүдәләнеше. Ул әүвәл туган авылында—әтисендә, аннан үзләреннән ерак булмаган Үтәш мәдрәсәсендә белем ала. Әмма булачак әдипне болар гына канәгатьләндерми: ул Уфага, «Госмания» мәдрәсәсенә килә. Әмма язмыш аны бу шәһәрдән «20 чакрым ераклыктагы» Кыешкыга илтеп ташлый. Биредә шагыйрь 3-4 ай гына укый. 1897-1898 елларда инде Габделмәҗид—туган авылында хәлфә. Үтәштәге остазы Хатыйп хәзрәт киңәше белән ул 1898 елның көзендә Троицкидагы Зәйнулла ишан мәдрәсәсенә («Рәсүлия»гә) юнәлә. Бу уку йортында шагыйрь 7 еллап белем ала. 1905 елгы инкыйлаб җилләре аны яңа мәдрәсәләр, остазлар эзләргә канатландыра: Иж-Бубига килә, әмма андагы мәдрәсәне ошатмыйча, Казанга юнәлә. Биредә ул бер елга якын «Мөхәммәдия»дә укый, атаклы Йосыф Акчуралардан дәресләр ала.

Мәгълүм ки, 1906 елда күренекле татар мәгърифәтчесе Зыя Камали (1873-1942) «Галия» мәдрәсәсен нигезли. Бу татар уку йортының даны тиз арада төрки-татар дөньясында киң тарала. Шуның бер нәтиҗәсе буларак, 26 яшьлек М.Гафури да 1906 елның көзендә бу мәдрәсәгә күчеп килә һәм биредә өч еллап укый.

1 Мәҗит Гафури. Әсәрләр: Дүрт томда. – К.: Татарстан китап нәшр.,I т. – 1980,II т. – 1980,III т. – 1983,IV т. – 1981. Алга таба бу чыганакның томнар һәм битләр саны җәяләр эчендә генә күрсәтеләчәк.

Күрәсез: әдип 30 яшенә кадәр диярлек төрле мәктәп-мәдрәсәләрдә белем ала. Мондый төрлелек, урын алыштыру матди як белән генә түгел, шагыйрь табигатенең эзләнүе, рухи канәгатьсезлек белән дә аңлатыла. М.Гафури иҗатында мәктәп-мәдрәсә тормышының, шәкерт-мөгаллим образларының зур урын алуы да язучының тәрҗемәи хәленә бәйле.

Әдипнең белем алуын уку йортында хәзерге кебек аннан аерылмыйча уку рәвешендә генә күзалларга ярамый. Уку елы еш кына көз урталарында башланып, апрель айларында ук тәгәлләнә. Елның яртысын диярлек шәкертләр үзләре теләгәнчә уздыра. Габделмәҗид тә моннан чыгарма түгел.

Үтәш мәдрәсәсендә уку елларында, ягъни ана 13-14 яшьләр вакытында бер-бер артлы әти-әнисе үлеп китә. Мона кадәр чагыштырмача көйле аккан тормыш тамырдан үзгәрә. Әле буыннары да ныгымаган үсмер Габделмәҗидкә ятимлек шулпасын эчәргә, үз көнен үзе күрергә туры килә. Мәдрәсәдә уку елларында ул җир сөреп, иген дә игә, баерак шәкертләргә һәм мөгаллимнәргә хезмәтче булып та тора, заводларда, алтын приискларында да эшләп ала, казакъ далаларында хәлфәлек тә кыла..., кыскасы, Идел-Урал төбәгенең төрле җирләрендә булып, төрле шөгыль-һөнәрләрне сынап карый. Болар киләчәктә әдип әсәрләрендәге тормышчанлыкны, тематик һәм географик киңлекне, психологик төрлелекне билгеләгән.

1906 елдан башлап гомеренең ахырына кадәр М.Гафуриның тормышы ул вакытта Казан, Оренбург кебек татарның мөһим мәдәни үзәкләренең берсе булган Уфа белән бәйле. Биредә ул 1917 елга кадәр бертуган Кәримевләрнең «Шәрык» матбагасында корректор булып эшли. 1909 елда М.Гафури гаилә корып җибәрә. Булачак хатыны Зөһрә белән танышуы хакында әдип болай яза: «Ятим үсеп, үзенең кул көче белән тегү тегеп, үзен тәрбия иткән эшчән бу кыз шул заманның үзенә күрә ачык фикерле кешесе һәм ару гына укыган да иде. Аның эшчән һәм шулай аңлы булуы минем дикъкатемне җәлеп итте» (IV т., 474 б.). Зөһрә ханымның татар теле мөгаллимәсе булып эшләве дә мәгълүм. 1910 елда аларның ир баласы туа. Ана Әнвәр исеме бирәләр. [Шунысын да әйтик: Татарстан Фәннәр академиясенең «Мирасханәсе»ндә М.Гафуриның 300дән артык кульязма әсәре саклана. Аны заманында шагыйрьнең улы Әнвәр (1910-1977) тапшырган була. Бу игелекле гамәле өчен аңа кат-кат рәхмәт укырлык !]. Күп кенә факт-мәгълүматлар әдипнең Зөһрә ханым белән бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яшәүләрен күрсәтә. Бу гаилә белән якыннан аралашкан язучы Зариф Бәшири (1888-1962) үзенең «Замандашларым белән очрашулар» исемле истәлекләр китабында (К., 1968) болай дип яза: «Мин Мәҗит Гафуриның Зөһрәдән чиксез риза булганлыгын аның үз сүзләреннән генә түгел, Зөһрәнең Мәҗиткә булган мөнәсәбәтеннән дә аңладым.... Зөһрә Мәҗит Гафури өчен чын бер иптәш, аның рухын, әдәби зәвыгын күтәрүче һәм аның иҗади хезмәтен аңлый торган ихлас ярдәмчесе иде. Ул Мәҗитне тормыш юлдашы иттереп кенә түгел, иҗат кешесе буларак та хөрмәт итә, аны тәрбияли, юк-бар сораулар белән борчымый, аның уе-фикерен әдәбияттан башка якка юнәлдермәс өчен, юкны бар итәргә, барны тота белергә тырыша иде» (177 б.).

Октябрь инкыйлабыннан соң 1928 елга кадәр М.Гафури типографиядә, татар телендәге гәҗит-журнал редакцияләрендә, җөмләдән хәзерге «Кызыл Таң» башлангычы булган «Башкортстан» гәҗитендә эшли. Уфада яшәү чорында ул күп мәртәбәләр Казанга килә. 1927 елда композиторлар В.Виноградов, С.Габәши, җырчы Г.Әлмөхәммәтов, либретто авторы М.Гафури белән берлектә, «Эшче» операсын иҗат итүгә керешәләр. Шушы вакытта шагыйрь берничә ай буена Казанда, Татарстанда була. Шулай ук М.Гафуриның Мәскәүдә, Кырымда, Оренбургта һәм башка төбәкләрдә дә булуы мәгълүм.

Башкортстан җитәкчелеге һәм җәмәгатьчелеге татарның күренекле әдибенә һәрчак диярлек игътибарлы булды. Аның әсәрләре оригиналда, башкортчага һәм русчага тәрҗемә итеп кат-кат басылды. [Әмма шунысы гына аңлашылмый: Уфа тарафыннан әзерләнеп, М.Гафуриның рус телендә басылган аерым китаплары «перевод с башкирского» искәрмәсе белән дөнья күргән. Мәсәлән: Мажит Гафури. Избранное. Стихи. Перевод с башкирского.—М.: Худ. лит., 1980.—270 с.; Мажит Гафури. Черноликие.—На золотых приисках поэта.—Ступени жизни ... Повести. Перевод с башкирского. Уфа: Башкнигоиздат, 1975.—416 с. һ.б. Бу әсәрләрнең бит оригиналы, ягъни татарча текстлары кул астында бар, алар кат-кат басылган. Бу эшләр

Г.Рамазанов, А.Кудашев кебек күренекле әдәбиятчылар катнашында башкарылган, ул китаплар аларның «Предисловие»се яисә «Послесловие»се белән нәшер ителгән. Шулай шул, бу дөньяның акыл белән генә ирешә алмаслык «тәкый гаҗәп хәлләре» бар]. 1923 елда ук М.Гафуригa, иҗатының 20 еллыгы унае белән, «Башкортстанның халык шагыйре» дигән шәрәфле исем бирелә. Әдипнең туган районы, Башкорт Академия театры аның исемен йөртә. Билгеле булганча, мәшһүр татар әдибе Афзал Таһиров (1890-1937) 1927 елдан алып шәхес культы репрессиясенә эләккәнчегә кадәр Уфада житәкче урыннарда эшли (Әүвәл—Башкортстан өлкә комитеты партколлегиясенең җаваплы секретаре, 1931 елдан—Башкортстан Үзәк башкарма комитеты рәисе). Ул бу республиканың язучыларын туплауда, аларның берлеген оештыруда да башлап йөри. А Таһиров М.Гафури турында да тирән кайгыртучанлык күрсәтә. Үз чиратында шагыйрь ана ихтирами мөнәсәбәтен белдереп, «Пролетариат язучысы Афзал Таһировка» дигән шигырен яза (1934). Анда М.Гафури каләмдәшен һәм дәүләт эшлеклесен «егерме биш еллык» иҗат бәйрәме белән тәбрик итә, аның бай иҗатын, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген югары бәяли (II том, 322—324 б.).

Сүз сәнгатен кечкенәдән үк яраткан Габделмәҗиднең әдәби иҗат белән кайчан шөгыльләнә башлавы төгәл билгеле түгел. Мөгаен, күпләр кебек үк ул да яшьтән үк шигърияткә тартылгандыр. Әмма аның тәүге билгеле әсәрләре чагыштырмача соңрак чорга—XX йөзнең башларына гына карый. Бу вакытта инде М.Гафури—егерме яшен тутырган, шактый белем, тормыш тәҗрибәсе туплаган, кеше буларак өлгергән шәхес. Аның укучыларга билгеле беренче әсәре «Ишан шәкертләренә» дип атала. Автор бу шигырен «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыганда, 1902 елда язып тарата. Бу уку йортындагы искелекне, анда тәртипләрне тәнкыйть уты астына алган әлеге тезмә шактый ыгы-зыгы, каршылыклар тудыра. Шушы ук елда М.Гафури «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» дигән тәүге чәчмә әсәрен яза. 1902-1903 елларда аның мәгърифәти, дидактик рухлы, тәрәккъыятьне зурлаган «Вә иннә мин әш-шигъри ли хикмәтин» («Чыннан да, шигырьдә хикмәт бар»), «Гыйлем», «... Себер тимер юлы» кебек шактый күләмле шигъри әсәрләре иҗат ителә. Авторның бу һәм кайбер башка язмалары 1904-1906 елларда Казан һәм Оренбург нәшриятларында аерым китаплар рәвешендә дөнья күрә башлый. Алга таба аның әсәрләре аерым җыентык булып та, көндәлек матбугатта да бер-бер артлы басылып тора. Һәм тиз арада ул күренекле шагыйрь, прозаик буларак таныла. 1910 елда язылган «Татар матбугаты» исемле мәкаләсендә Г.Ибраһимов аны «Тукаевтан кала иң беренче урынны алган» шагыйрь дип атый (Г.Ибраһимов. Әсәрләр. 5 т.—К., 1978.—6 б.). «Морад» (Ризаэддин Фәхреддин) «Вакыт» гәҗитендә (1906) «Габделмәҗид әфәнде милли шагыйрьләремездәндер» дигән сүзләрне яза (I т., 446-447 б.).

М.Гафури, гәрчә әдәби иҗат эшенә соңрак керешсә дә, бик күп яза, гомеренең ахырына кадәр каләмен кулыннан төшерми. Шагыйрьнең үләренә бер ел кала язган «Гомерем йомгагы» дигән мондый шигыре бар:

*Җыеп караганда, алай бик зур*
*Төсле түгел гомрем йомгагы.*
*Сүтеп караганда, чак күренә*
*Аның бер ягыннан бер ягы*

(II т., 311 б.).

Әдипнең мирасы белән танышкач, чыннан да аның биниһая зурлыгы, «бер ягыннан икенче ягы» «чак күренүе» күзәтелә.

1932 елда Казанда «Мәҗит Гафуриның сайланма әсәрләре» дигән җыентык дөнья күрә. Шушы унай белән Г.Ибраһимов «Яналиф» журналында (1933—2-3нче саннар) «Карт шагыйрьнең яхшы сайланмасы» дигән рецензиясен бастыра. Бирелдәге әсәрләр,—ди ул,—М.Гафуриның бөтен гомер юлын, иҗатын чагылдыра. Рецензент китапка унай бәя бирә. Г.Ибраһимов язмасында «карт шагыйрь» дигән төшенчә мәгънәле. Югыйсә бу вакытта әле М.Гафурига 53нче яшь кенә. Күрәсең, рецензент, әдипнең яшеннән бигрәк, аның бай һәм күләмле иҗат мирасын, әдәбияттагы дәрәҗәле урынын күздә тоткандыр.

Шунысы әһәмиятле: М.Гафури һәм шигърияттә, һәм прозада бердәй осталык белән иҗат итә. Аның сәхнә әсәрләре дә бар. Мәсәлән, әдипнең Октябрьдән соңгы еллардагы тормышны сыйнфый көрәш, шул чор рухы белән гәүдәләндергән «Кызыл йолдыз» драмасы (1926) Башкортстан Мәгариф комиссариаты оештырган конкурста беренче урынны ала, бераздан театр сәхнәләрендә дә уйнала. Аның хакында Г.Кутуйның 1926 елда язылган махсус рецензиясе дә бар. «Бу 4 пәрдәлек пьеса,—диелә анда,—кин авыл катлавы, аның революция вакытындагы үзгәреш, көрәшләрен һәм хәзерге еллардагы төзелешен, янаруын укучы күзенә яхшы, чибәр тел белән сәхнәләштерә ...» (II т., 585 б.). М.Гафуриның «Эшче» исемле либреттосы да жанр таләпләрен тирәнтеп тоеп, шигъри-драматик яктан камил тел-стиль белән язылган. Әдипнең «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек», «Үги балалар», «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» һәм кайбер башка чәчмә әсәрләрендә дә драмага хас элементлар (персонажларның турыдан-туры үзара сөйләшүләре, репликалар һ.б.) урын алган. М.Гафури, чордашы Г.Тукай кебек, фольклор, мифологик материаллардан да файдаланып әсәрләр яза. Болар арасында аеруча 1910 елда дөнья күргән «Заятүләк берлә Сусылу», «Болгар кызы Айсылу» язмалары кызыклы. Шулай ук әдипнең Йосыф-Зөләйха темасына да мөрәҗәгать итүе мәгълүм. Язучы мирасында публицистиканың, әдәби тәнкыйтьнең дә матур үрнәкләре бар.

Әйткәнебезчә, М.Гафури төрле мәдрәсәләрдә укып, төрле остаз-мөдәррисләрдән озак еллар буе белем-мәгълүмат алган, мөстәкыйль рәвештә дә күп гыйлем туплаган. Ул үзенә кадәрге татар әдәбиятыннан яхшы хәбәрдар, Шәрык рухи мирасын да, татар, казакъ, башкорт фольклорын да тирәнтен үзләштергән. Шуның нәтиҗәсендә шагыйрь әдәби иҗатта, аеруча тел-стильдә, шигырь техникасында судагы балык кебек эш итә. Аның әсәрләрендә элеккеге сәнгати традицияләрнең иҗади дәвам ителешенә мисаллар гаять күп. М.Гафури интертекстуаль ысул белән үз әсәрләренә рухи мирастагы күп кенә элементларны, образ-детальләрне кертеп җибәрә, нәзыйрәләр дә яза, башка чыганакларга, авторларга ишарә-киналәр дә ясый. Мәсәлән, ул «Бер татар шәкертенең үз хәленнән зарлануы» (1906) шигыренең һәр строфасын нәкъ «Бакырган китабы»ндагы кебек, «Мин егъламый, кем егъласын?» сүзләре белән төгәлли, билгеле шигъри шәкелгә яңа, заманча эчтәлек сала, шәкертләрне хәрәкәткә өнди:

*Вакыт үтә, вакыт үтә, төрле хәлләр инде йитә,*
*Милләт сездән хезмәт көтә. Мин егъламый, кем егъласын?*

(I т., 68-69 б.).

«Мәмләкәтнең барчасы ...» дип башланган парчасын (1907) шагыйрь нәкъ Акмулланың «Хатимә» әсәрендәге кебек шигъри үлчәм, строфа төзелеше, рәдиф белән төгәлли. Аның соңгы юллары түбәндәгечә яңгырый:

*Үз эшен баксын үзе татарның милләте,*
*Аһ-зарга алданып йөргән бу милләт булмасын*

(I т., 108 б.)

Шагыйрьнең 1909 елда күргән «Замана шигырьләре» җыентыгы—Суфый Аллаярның (1616-1713) атаклы «Сөбател гаҗизин» китабын иҗади файдалануның күркәм бер үрнәге. М.Гафури элеккеге әдипләргә генә түгел, үз чордашларының әсәрләренә дә мөрәҗәгать итә, алардан алынган аерым детальләрне шигырь тукымасына иҗади рәвештә кертеп җибәрә. Г.Тукай үзенең «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» дигән мәрсиясен (1908) мондый юллар белән тәмамлый:

*Шунда да исмең синең милләт яшәдекчә яшәр,*
*Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар.*

М.Гафури бу строфаны, бераз үзгәртеп, «Әдәбият кичәсенең соңында укылган шигырь»гә (1909) бу рәвешле кертеп җибәрә:

*Телләре югалмадисә, мәңге югалмас татар;*
*Милләт ашдыкча—ашар, милләт яшьдекчә—яшәр.*
(I т., 195 б.)

М Гафуриның элеккеге сәнгати казанышларны яхшы белүе аеруча шигырь системасында, жанрлар куллануда ачык күренә. Аның күпчелек шигырьләре гаруз белән язылган. Шагыйрь бигрәк тә һәзәж, рәмәл төрләрен ярата. Шуның белән бергә аның иҗатында, аеруча Октябрьдән соңгы мирасында силлабикага, сөйләм интонациясенә корылган шигырьләр дә шактый. М.Гафури газәл, робагый, мәдхия, мәрсия, мөрәҗәгать, багышлама, хикәя, повесть (бәян), нәсер, истәлек һәм башка бик күп классик жанрлар белән эш итә.

Ул аеруча татар шигъриятендә мәсәл жанрының ныклап үсешенә зур өлеш кертте. Аның «Кәлилә вә Димнә»дән, башка чыганаклардан, тормыштан алынып язылган мәсәлләре элек тә, хәзер дә яратып укыла, зиһенне кузгата, гыйбрәт алдырта. Шагыйрь иҗатында, гомумән, сәнгати табышлар, бүгенге әдипләребезне дә кызыктырырлык шигъри чаралар һәм сурәтләр гаять күп. Мәсәлән, аның «Бер гашыйкның сүзләре» әсәре үзенең шигъри техникасы, образ-детальләре, эмоциональ яңгырашы белән мәхәббәт лирикасының классик бер үрнәге булырлык.

М.Гафуриның әсәрләре идея-тематик яктан киң һәм бай. Аларның исемнәре генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Шагыйрь көндәлек тормыш, табигать, яшәү һәм үлем, белем-мәгърифәт, тарих, мәхәббәт, әхлак, бала тәрбияләү, туган җир, Ватан, ил, сәясәт һәм мәгыйшәткә хас булган гаҗәеп күп төрле мәсьәләләр хакында яза. Әмма аларның һәммәсен диярлек үзара ялгый, берләштерә торган бер проблема бар—ул да булса милләт язмышы. Бу мәсьәлә әдипнең бөтен җанын, рухын биләгән, аның барлык яшәеш күзәнәкләренә сеңгән. Татар әдәбиятында, аеруча XX йөз башы сүз сәнгатендә милләт, татар дип язучылар гаять күп. Татарлыкта, миллилектә М.Гафури, мөгаен, бөек Тукайны да узып китәдер. Татар атамасы аның кечкенә генә парчаларында да, хәтта аерым строфаларында да берничәшәр мәртәбә телгә алына:

*Ничә йөз ел изелгәнгә татар юаш,*
*Без татарның юашлыгы дөньяга фаш...*
(I т, 42 б.).

*Черделәр шунда бик нәфис хәссас (сизгер; хисле.—Х.М.) татарның кызлары,*
*Черделәр шунда татар җегетләре михнәт күреп.*
(I т, 371 б.).

*Русияле бер татардыр асыл затым,*
*Габдулла ибне татар—мәшһүр атым*
(I т., 462 б.).

М.Гафури «милләт», «халкым», «туган телем» дип язганда да казакъ, башкорт, чуаш, урысны түгел, ә һәрчак татарны күздә тота, үзен шуның бер вәкиле саный: «Безнең татар, үгәй бала булганы өчен» (I т, 65 б.); «Әле дә шул тел белән укыйм, язам һәм сөйләшәм, Шул татар теле белән көйлим берәр көй көйләсәм» («Ана теле», I т, 254 б.); «Милләтләр арасыннан безем татар» (I т., 404 б.); «Шигырь язды Габделмәҗид—ибне татар» (I т., 34 б.) һ.б.

Чын татар авылында һәм гаиләсендә туып үскән, татар мәдрәсәләрендә белем алган, татарча сөйләшкән, фикерләгән, татарча язган Мәҗит Гафури үз иҗатында, иң беренче чиратта, үз халкының мәнфәгатьләрен күздә тотты, аны укымышлы, хөр, алдынгы, әхлаклы, бәхетле итәргә омтылды:

*Йа татар! Вакыт йитте кузгалырга,*
*Мәгариф шәмгыданын (шәмдәлен.—Х.М.) кулга алырга,*

*Тәфәккерсез (уйламыйча.—Х.М.), гафил булып (пошмыйча.—Х.М.) карап ятмый,*
*Вакыт йитте гыйлем, һөнәр кулланырга!*
(«Өндәү», I т., 38 б.).

«И татар кызы, бүгеннән соң укы, бел, яз, өрән (өйрән.—Х.М.)» «Торма бушка! Үгрән инде тәрбия, гыйлем, әдәп» («Укучы кызга», I т., 79 б.).

Татарларны ярату хисен автор аларны тәнкыйтьләү аша да бирә: «Бу дөньяда безем төсле хәкыйрь һич жирдә милләт юк» (I т., 96 б.):

*Татарда «милләт, милләт!» диюче бар,*
*Вәләкин күбебездә юк икътидар (көч, ныклык.—Х.М.).*
*Бака кебек коры телдән «бак-бак» итеп,*
*Хур кыйлмаек үзебезне, кыл, зинһар!..*
(«Инсаф», I т., 53 б.).

*Әй татар, нишләрсең инде, бар телеңне киссаләр?..*
*... Агызыңны көчләп ачып, бер башка телне тыксалар?*
(I т., 242 б.)

М.Гафури милләткә, халыкка хезмәт итүне, әдип буларак, үзенең төп вазыйфасы дип саный. Бу мотив аның күп кенә әсәрләрендә гәүдәләнеш тапкан.

*Гафури, син онытма милләтеңне,*
*Сарыф ит ушбу юлда һимматеңне (тырышлыгыңны.—Х.М.).*
(I т., 111 б.).

*Безләр, и туган, анадан туган*
*Булырга корбан миллэт юлында*
(I т. 113 б.).

Әдип фикеренчә, һәр кеше, иң беренче чиратта шагыйрьләр үз милләтенең көтүчеләре кебек булырга тиеш (I т., 98 б.).

М.Гафури—нечкә, йомшак, сизгер күңелле, вөжданлы, гаделлекне яратучы бер шәхес. Аның бу сыйфатлары иҗатында төп тенденция рәвешендә гәүдәләнеш таба. Әдип фәкыйрьләрне, ятимнәрне, ялангачларны, авыруларны, мөшкел хәлдә калучыларны чын күңеле белән кызгана, үз укучыларын аларга теләктәшлек кылырга, ярдәм итәргә чакыра:

*Дөньяда азмы газапланды минем бу гаҗиз җаным?*
*Азмы сызланды халык хәлен күреп бу вөҗданым?*
(I т, 314 б.)

*Кайда ярлы, кайда зарлы, кайда моңлы күп була—*
*Мин шулар янында булам, алар белән килешеп була*
(«Мин кайда», I т., 288 б.).

М.Гафури үз халкы өчен генә түгел, авыр хәлдә калган башка кавемнәр өчен дә борчыла. Юкка гына ул «Дөньяда тулган мәзлумнарга күзе төшеп, Габделмәҗид шигырь яза аптырагач»,—дип әйтми (I т, 65 б.). Европадагы аерым илләрнең колониаль сәясәте дә, мөселман дөньясының коллыкка төшүе дә аның күңелен әрнетә.

М.Гафури үз халкының да коллыкта, ирексезлектә яшәвен яхшы аңлый, моңа чын күңелдән борчыла, хөрлеккә омтыла.

*Хөр улмай йөргәнемнән үлгән артык,*
*Үземне кара йиргә күмгән артык...*

*... Бу милләтне сәгадәткә чыкармак*
*Минем чөн гарешкә ашканнан артык*
(I т, 65-66 б.).

*Мохитне уйлаган чакта, дисең шунда: «Бәхетсез без,*
*Күңелсез без, эрәтсез без, тавышсыз без, тәхетсез без*
(«Күңелсез минутлар», I т, 291 б.).

Милләтнең хокуксызлыгы, халыкның авыр хәле, империалистик сугыш, канкоешлар мантыйкый рәвештә илдә үзгәрешләр булуны таләп итә. Моны, башка бик күп адәм балалары кебек, тормышның үзәгендә кайнаган, яшәешнең бөтен ачысынтөчесен татыган М.Гафури дә көтә. Менә илне тетрәткән инкыйлаб-революцияләр башлана. Шагыйрь бу вакыйгалар милләткә ирек, бәхет китерер дип ышана. Шуның нәтиҗәсе буларак «Кызыл байрак», «Татар җегетенә», «Мин—ватанчы» һәм башка әсәрләр туа. Яңа чынбарлык, совет идеологиясе, сыйнфый көрәш тәгълиматы М.Гафурины да үз дулкыннары кочагына ала, билгеле бер эчке эволюциягә этәрә. Диндар табигатьле шагыйрь күңелендә атеистик очкыннар да күренә башлый. Кайчандыр үзе олылаган, хөрмәт иткән Гаяз Исхакыйларны да, вәзгыятьнең асылын аңламыйча, «фаш» итеп ташлый. Әмма совет чорында да М.Гафуриның матур тел-стиль белән язылган, чынбарлыкны сәнгати югарылыкта гәүдәләндергән, инсани рухлы әсәрләре шактый. Болар арасында «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Тәрҗемәи хәлем», «Эшче» кебек әдәбиятыбызның классик ядкарьләре бар. Аларда тормышның төрле яклары, катлаулы язмышлар, инсаннарның холык-табигате, рухи халәте үтемле, тәэсирле итеп күрсәтелгән. М.Гафури яңа җәмгыятьтәге тискәре күренешләргә дә күз йоммый. 1921-1922 еллардагы ачлыкка мөнәсәбәтле язмалары чор фаҗигасен югары кимәлдә гәүдәләндерәләр.

Мәгълүм ки, яшәеш-мәгыйшәтнең нигезен тәшкил итүче хезмәт, эш кешеләре элек-электән безнең әдәбиятта макталган. Йосыф Баласагунлы шөгыль ияләрен төрлечә зурлый. Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендәге (1342) Фәрһад таш эшен дә сәнгати дәрәҗәгә күтәреп башкара. XVII йөз шагыйре Мәүла Колый иген игүне иң «гали» (бөек), изге эш дип саный, игенчеләр тәмуг газабыннан «азад булып», ахирәткә керә»,—ди.

М.Гафури иҗатында да хезмәт мөһим урынны били. Әгәр дә инкыйлабка кадәрге әсәрләрендә хезмәтнең михнәти ягына күбрәк басым ясалса, совет чоры язмаларында, яңа җәмгыятькә нисбәтән, эшнең иҗади, куанычлы ягы ассызыклана, хәтта хезмәтнең романтик асылы да күрсәтелә («Төнге смена», «Туры ат белән соры ат», «Нигә эшлиләр?» һ.б.).

*... Уйлап торам-торам, әмма һичбер*
*Җеп-җиңел эш юк ул дөньяда.*
*Эш—мактаулы—авыр булган өчен,*
*Аның матурлыгы шунда да*
(II т., 378 б.).

Яшәеш никадәр генә авыр, катлаулы булмасын, аны нурлый, ямьләндерә, мәгънәләндерә торган бер сыйфат бар. Ул да булса—сөю-мәхәббәт. Бу мотив М.Гафури иҗатында якты бер нур, балкыш рәвешендә килә. Әдип чын мәхәббәт ияләрен, сөю хисләрен төрлечә зурлый, яклый. «Кара йөзләр»дәге Закир белән Галимәнең фаҗигаи мәхәббәте күңелләрне тетрәндерә, аларның карага буялган йөзләре укучы күз алдында аклин ак, пакьдин пакькә әйләнә. М.Гафури бу изге хисне тасвирлаганда элеккеге шигъри казанышларны мул һәм уңышлы файдалана. «Дөнья сезсез һич төзәлмәс, иң кадерле бәндә сез»,—ди ул кыз баланы тасвирлап (I т., 79 б.). 1907 елда иҗат ителгән бер газәлен шагыйрь «Мәхәббәтсез җиһанда тормак улмас, Бу дөньяны тотып торган мәхәббәт» дигән юллар белән тәгәлли (I т., 110 б.). Шушыңа охшаш мотив түбәндәге строфада да гәүдәләнеш тапкан:

*Мәхәббәт булмагач, тормышта нинди бер кызык бар соң?*
*Болай булгач, кешенең вәхшидән аермасы нәрсә?*
(I т., 287)

Алтын Урда чоры шагыйрьләре Котб һәм Харәзми яшәешне мәхәббәт кануннары нигезендә корырга омтылалар. Шул вакытта гына җәмгыятьтә гаделлек, сәгадәт урнашачак. М.Гафури да мәхәббәтне чын мәгънәсендә абсолютлаштыра, хәтта аны җиһан тәхетенә утырта:

*Чын мәхәббәтнең җиһан тәхтендә булуын мин телим,*
*Сәҗдә итсен шул мәхәббәткә генә янган йөрәк.*
(I т., 321 б.)

Урыны белән татар шагыйре мәхәббәтне егет белән кыз мөнәсәбәтләре белән генә чикләмичә, гомумән кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре рәвешендә дә карый.

Үз чорындагы иҗтимагый, сәяси, мәдәни вакыйга-хәлләргә гаять сизгер булган М.Гафури иҗатында конкрет вазгыять, вакыт белән бәйләнмәгән фәлсәфи, әхлакый рухлы язмалар да күзгә ташлана. Алар, ничектер, шагыйрьнең эчке дөньясын, андагы тетрәнү-газапларны, куану-сызлануларны шартлы, йомык хронотопик яссылыкта гәүдәләндерә. Бу төр парчаларда автор шагыйрь-философ, хикмәт иясе рәвешендә күзаллана [«Мәкъсуд», «Кызык заман», «Яман юлдаш», «Йолдыз», «...гә» («Бетте ул!...»), «Эш» , «Бу да калмасын» һ.б.]. Мәсәлән, «Язмыш...» шигыреннән бер өзек:

*Йөзәбез шаулаган, тау-тау кебек тулкынлы диңгездә,*
*Барабыз зур карабларның арасыннан шулай без дә!..*
(Т. 1, 351 б.)

Аерым затларга багышлап мәдхия яисә мәрсия рәвешендә шигырьләр язу татар сүз сәнгатендә күптәннән килә. М.Гафури да бу традициягә тугры кала. Аның иҗат мирасында дистәдән артык багышлаулар бар. Аларның адресатлары төрле: дәүләт эшлеклеләре (М.Вахитов, В. Ленин, А.Таһиров, Ш.Ходайбирдин...), әдипләр (З.Бәшири, С.Кулибай...), укытучылар (Ф.Сатиев, Һ.Сәгъди...) һ.б.. Болар арасында аеруча Г.Тукайга багышланган мәрсия (I т., 310 б.) игътибарга лаек. Ул бөек шагыйрь вафат булганның тәүге көннәрендә үк иҗат ителә. Бирелә автор Тукайның бөеклеген («гали» рухын), һәр татар өчен «сөекле» булуын, аның үлеме зур «кайгы» икәнлеген» искәртә, шагыйрьнең күнелләрдә сакланачагын ассызыклый:

*Үлмәдең син: чөнки бу көн һәр татар күңлендә син,*
*Бетмәдең син: һәр кеше сүзендә син, телендә син...*

Мәрсия бик тә мәгънәле, эмоциональ юллар белән тәгалләнә:

*Югалуың—бик зур авырлык, һәммәбезгә син әрәм,*
*Бар кешеләрдән дә артык мин җылыйм, хәсрәтләнәм.*

Бөек Тукай вафатының М.Гафури өчен олы шәхси кайгы да булуы аңлашыла. Чөнки алар мәсләктәшләр, фикердәшләр, дуслар. Татар язмышы һәр ике шагыйрьнең дә бәгырь түрендә. Билгеле булганча, 1912 елда Тукай Уфага килә. Бер үк халыкның, бер үк татар әдәбиятының ике шагыйре очрашалар, озаклап гәпләшәләр. Бу хакта М.Гафуриның 1914 елда «Габдулла Тукай Уфада» исемле хатирәсе басылып чыга. Язмада никадәр самимилек, үзара хөрмәт бөркелеп тора! (Ә бит заманында Тукай үзенең каләмдәшен берничә мәртәбә тәнкыйть тә иткән.) Үз чиратында Казан кунагы да «Мәкаләи махсуса» исемле язмасында (1912) Уфада М.Гафури белән очрашуларын бик җылы, күңеленә якын итеп яза. «Ул (ягъни М.Гафури.—Х.М.),—ди Тукай,—миңа караганда да жуашланган вә дөнья тарафыннан басылган кеби күренде. Аның белән безнең мөсахәбәмез (әңгәмәбез.—Х.М.) күп вакыт күзләр аркылы гына кыйлына иде.

Читтән безне караган кеше, икемезне әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кыйнап, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде.

Нишлик соң? Әле генә язмыш ханым кыйнаган; Җылар идек—әле күздән яшемез дә кипкән (ягъни «елый-елый яшебез дә калмаган, кипкән» мәгънәсендә.—Х.М.).

Русиядә хәзер уйнаган җилләр вә Русия һавасы безнең бөтен коллегаларымызны шул халәте рухиягә китергән» *(Г.Тукай. Әсәрләр.—IV т.—К., 1977.—199 б.)*

[2005 елның октябрендә Уфада шагыйрь исемен йөртүче мәшһүр театр сәхнәсендә М.Гафуриның тууына 125 ел тулуга багышланган кичәдә (Башкортстанда андый юбилейларны оештыра беләләр!). Гафури белән Тукайның Уфада очрашулары хакында да бик тәэсирле, мәгънәле күренеш күрсәттеләр. Әмма бер үк татарның уллары, шагыйрьләре булган бу ике мөхтәрәм затны, халыклар дуслыгы шигаренә туры китереп, татар һәм башкорт вәкилләре сыйфатында тәкъдим итү генә күңелдә юшкын калдырды].

М.Гафури иҗаты—XIX гасыр ахыры-XX йөзнең беренче яртысындагы татар яшәешенең тулы бер энциклопедиясе. Анда илнең, кайбер башка халыкларның тормышы да теге яки бу дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан. Үзенең биш дистәдән артык гомерендә әдип инкыйлабларны, төрле сугышларны, иҗтимагый формацияләр алышуны күрә, кичерә, әмма, нинди генә кыенлыклар булса да, үзенең вөҗданына, халкына, иҗатына тугры кала, киләчәккә өмет-ышанычны югалтмый.

*Күпме гамьнәр күрмәдем мин,*
*Күпме яшьләр түкмәдем,*
*Күпме таулар кичмәдем мин,*
*Күпме сулар үтмәдем.*
*Юл авыр булды, шулай да*
*Тик ятып җан түзмәде,*
*Йолдызын, бәхтен табудан*
*Зур өмидне өзмәде*

(I т., 295 б.)

М.Гафури—иҗат әһеленә йөкләнгән бөек вазифаларны намус белән үтәүнең классик бер үрнәге.

Язучы мирасында аерым җитешсезлекләр, чор белән чикләнгән яклар да бар. Әмма гомумән аның иҗаты—һәм идея-тематик, һәм сәнгати яктан бәһаләп бетергесез бер хәзинә. Аның әсәрләре бүгенге укучыны да дулкынландыра. Әдипнең күңелен телгәләгән күп кенә мәсьәләләр, бигрәк тә милләт язмышы, шәхес тәрбияләү, милли мәгариф һәм мәдәният, сыйнфый тигезсезлек, эчүчелек проблемалары хәзерге көн өчен дә актуаль. Без Г.Тукай традицияләренең әдәбиятыбызда ничек, ни рәвешле дәвам ителүе хакында еш сөйлибез. Ә бит бу процесста Гафуриның да роле зур. М.Гафури безгә, бүгенге көн кавемдәшләренә, мөгаен, бераз үпкәледер дә . Ул татар өчен янган, көйгән, барлык көченә тырышкан, олуг әдип дәрәҗәсенә ирешкән. Ә без аның исеменә, язганнарына, башкаларга аркаланып, тиешенчә игътибар итми башладык. Аның тууына 125 еллык та Казанда түбән дәрәҗәдә узды. Шагыйрь хакында без галимнәр дә соңгы вакытта аз язабыз, диссертацияләр дә якланмый.

1980-1983 елларда Мәҗит Гафуриның татар телендә 4 томлыгы дөнья күргән иде. Ә бит әдипнең иҗат мирасы болар белән генә чикләнми. Аның дүрттомлыгына кермичә калган язмаларын тиешле шәрех-аңлатмалар белән бастыру да күптәннән өлгергән мәсьәлә.

* * *

Халкыбыз асылының, татар менталитетының иң төп сыйфатларыннан берсе—моң. Мин бу сүзне көй, музыка кысаларында гына түгел, ә киң мәгънәдә, яшәешкә хас билге рәвешендә алам. Күрәсең, татарның күп гасырлык авыр, газаплы язмышы, ирексезлектә гомер кичерүе аны моңлы-сагышлы иткәндер. М.Гафури—шундый рухи халәтне, моң-зарны сүзләр ярдәмендә гәүдәләндергән татарның бөек бер моңчысы.



# Фирдәвес Хуҗин

*Совет халкының дөньяны фашизм афәтеннән коткаруына 65 ел тулды. Элекке Советлар Берлегендә яшәүче милләтләрнең үзара дус-тату булуы, кирәк чагында дошман каршында тоташ стена булып күтәрелүе Бөек Ватан сугышында Җиңүгә китерде.*

*Билгеле, сталинчыл йогынты астындагы генералитетның корбаннар белән исәпләшмичә, «Ватан өчен!» дип, дистәләрчә мең солдат һәм офицерларын, күп чагында гади пушка «ите» дип карап, үлемгә китереп тыгулары, армиясе-армиясе белән әсирлеккә төшерүләре берничек тә аклана алмый.*

*Әсирлеккә эләгүчеләрне Йосиф Сталин илен сатканнар рәтенә кертте. Миллионлаган совет әсирләренең күп өлеше фашист концлагерьларында кырылды. Безнең якка исән кайтканнарын кабат ачы язмыш көткән булып чыкты—кайберләре махсус бүлек иләге аша үткәндә, гаепләре зур дип, атып үтерелде; кемнәрдер Колымага сөрелде, сугыш ахырындарак әсирлеккә төшкәннәр фильтрацион лагерьларга ябылды.*

*Икенче бөтендөнья сугышының ачылмаган серле сәхифәләре күп әле. Аурупа, Африка, Азия континентларын дер селкеткән авиабомбалар чинавы, туплар гөрелтесе тынганга алтмыш биш ел үткәч тә, ерак үткәннәрнең кайтавазы булып, моңа кадәр архив киштәләрендә үз чиратын көтеп яткан аерым кешеләрнең язма-көндәлекләре гавам хозурына чыгарыла.*

*Шундыйларның берсе—Татарстанның Апас районы Түбән Барыш авылында гомере буена авылдашларыннан үзе турындагы чын хакыйкатьне яшереп гомер кичерергә мәҗбүр булган, 1920 елда туып, нибары 60 яшендә, сугышта алган яраларыннан, туңу-өшүләрдән, әсирлектәге кимсетелүләрдән гүр иясе булган сугыш ветераны, ерак араларга очучы бомбардировщикның укчы радисты Хәлимов Габделхак Хәлим улы.*

*Табигате белән тыйнак Хак аганың (көндәлекләрендә үзе шулай язган—авт.) әсәрдә алты еллык армия һәм канкойгыч сугышларда катнашу вакыты турында гына сөйләнер һәм ул беренче заттан—«мин» дип язылыр.*

*Хатыны Кәримә апаның һәм балаларының гозерен үтәп язылган ошбу әдәби-документаль бәян әсир ителгәннәрнең рухына бер дога булып барып ирешсен. Һәм алар берүк без—исәннәргә рәнҗеп ятмасыннар.*

---

Фирдәвес ХУҖИН (1955)—*журналист; «Агыла болыт илләргә», «Әлмөхәммәт тарихы», «Ун хикәя» һ. б. китаплар авторы. Алабугада яши.*

# КҮКЛӘР ШАҺИТ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## 102нче очыш

1945 елның 11 март иртәсе. Шылт иткән аваз юк. Әлегә күренмәсә дә, көнчыгыш тарафтан ашыкмыйча гына күтәрелеп килүче кояш, нурлары белән горизонтны кызыл төскә манып, тиздән Җир шары тирәли көндәлек сәяхәтен башлап җибәрәчәк. Балтыйк диңгезе тәэсирендә нык суынган һава сулаганда йөзләгән энәләре белән сулыш юлларына, үпкәгә кадала. Офицерлар аерым төркем, без—сержантлар—аерым булып, эскадрильябыз белән ашханәгә иртәнге чәйгә барабыз. Аяк астында кар шыгырдый. Кәефләр күтәренке. Безнең полкка сугышчан боерык кичтән үк җиткерелгән, очасы маршрутлар картага сызылган, бомбага тотасы объектлар билгеләнгән. Бу якларда томансыз аяз көннәр сирәк булганга, сүз күбрәк һава торышы турында бара. Экипажның радисты Захаров:

—Бүген ким дигәндә өч сугышчан очыш ясарга туры килер әле,—ди.—Көн шундыйга охшаган.

Мин аны:

—Алдан сөйләшергә ярамый. «Алдан сөйләшсәң, юраганың юш килми»,—ди торган иде безнең әти,—дип бүлдерәм.

—Мин андый хорафатларга ышанмыйм. Йөздән артык сугышчан очыш ясадык, күпме дошман ныгытмаларын, эшелоннарын җир белән тигезләдек—безгә шайтаным да булганы юк. Бу юлы да исән-сау әйләнеп кайтырбыз,—диде радист күтәренке рухта.

—Күз тидерә күрмә. Исән барып, сау кайтырга язсын,—дидем, алда торган билгесезлектән күңел эчкәресендә үземә дә аңлашылмаган шомлану тоеп.

Янәшәдәге офицерлар төркемендә атлаучы экипаж командиры өлкән лейтенант Куликов безнең әңгәмәгә колак салып барган икән.

—Разговорчики!—дип, кисәтте командир көр тавыш белән,—ну-ка теманы үзгәртегез!

Ашханәгә барып җиткәнче бүтән сүз куертмадык. Һавага һәр күтәрелгән саен очучылар шактый гәүдә авырлыгын югалта, шуңа аларны яхшы ашаталар. Бүген дә иртәнге лимонлы чәй янына өстәлгә күп итеп ак француз булкасы белән ветчина, плиткалы шоколад куйганнар. Ашагач кәефләр күтәрелеп китте. Инде кояш та ярыйсы ук күтәрелгән. Аның нурлары каты элпә белән капланган кар өстендә миллионлаган чаткылар уйнатып җемелди, агач ботакларында асылынып торучы озынча боз тамчыларын алтынсу-кызгылт төскә манып күзләрне иркәли. Тиздән фашист дигән явызны Балтыйк буендагы өнендә дөмектереп, Берлин юнәлешендә хәрәкәт итүче гаскәрләргә ярдәмгә очачакбыз, ул көнгә ерак калмады инде. Шулай да гитлерчыларның каршылыгы көчле әле, пропагандалары дан җырлаган «Дранг наһ остен» ныгытмаларына өметләре зур. Верховный башкомандующий иптәш Сталин әмере буенча Көнчыгыш Пруссиянең төп терәге саналган крепость-шәһәр Кенигсберг апрель башларыннан да соңга калмыйча алынырга тиеш. Бу уңайдан инде «Кенигсбергны алган өчен» медале дә булдырылган диләр. Медаль булдырылгандырмы—юктырмы, анысы безгә караңгы, әти әйтмешли: «Булса—хуп, булмаса—хуп.» Ул көнгә кадәр әле яшәргә кирәк. Казармага кайткач, өсләргә очканда устав буенча каралган җылы киемнәрне кидек, һаваның җир өстендә салкын булуы бер нәрсә, дүрт мең метр биеклектә тагы да салкынрак.

Самолетлар торган аэродромга барып җиткәндә, иртәнге сәгать уннар иде. Килүебезгә техниклар очкычларны кабызып, моторларын җылытканнар, суынмасынга, фюзеляжларын чехол белән каплап куйганнар. Төш туры якынлашуга

карамастан, һава һаман салкын торуын дәвам итә. Әүвәл баскычтан салонга экипаж командиры Куликов, аның артыннан штурман Плюхин, аннан соң мин һәм радист Захаров күтәрелде. Һәркем үзенә тиешле урынга урнашкач, двигательләрне кабызырга команда булды. Алар кабызылып, кирәкле әйләнешләрне җыйгач, Куликов җирдәге команда пункты белән элемтәгә кереп, очарга рөхсәт сорады. Элемтә буенча эскадрильядагы тугыз очкыч белән командалык итүче эскадрилья командирыннан да рөхсәт алынды. Менә инде безнең самолет старт полосасына чыгып килә. Моторлар үкереп, аны һаман саен алга куалыйлар. Ул кардан арчылган бетон полоса өстеннән йөгерде-йөгерде дә, кинәт җирдән аерылып, югарыга күтәрелә башлады. Эскадрильядагы тугыз самолет та шул ук маневрны кабатлап, төркем алдыннан очкан командир машинасы артында үз урыннарын алды. Биеклек арткан саен самолет эчендәге җылылык кими бара, салкынлык инде борын очларын, битне чеметтерә. Җирдән нинди ераклыкка күтәрелүебезне белергә теләп, очкычтагы приборларга күз салам: биеклекне күрсәтүче ук дүрт километрлы билгенең уң ягына чыккан, димәк, очкан чакта тотылырга тиешле югарылыкка менелгән. Җир өстендәге йортлар шырпы кабы зурлыгында, тимер юл буенча баручы эшелоннар бала-чага уенчыгы кебек кенә күренә. Куликов безнең кәеф ничеклеге белән кызыксына. Бакчы, башка чакларда андый сентиментальлеккә бармый торган иде, хәерлегә булсын. Ул борын астыннан нинди дер көй шыншый башлады. Бусы нервыга тия, тик аңа «туктат!», дигән әмер биреп булмый, мин өлкән сержант кына, ә ул—өлкән лейтенант.

Эч пошканнан Захаровтан:—Хәлең ничек?—дип сорашам.—Нигә эндәшмисең? Әле иртән генә әллә ниләр сөйләнгән идең.

—Шайтан белсен хәлне, башка әллә нинди уйлар килә,—диде радист.

—Күңеленне төшермә, без күрәсен башка берәү күрмәс,—дигән булып, Николайга күз кыстым.

Борчылырга сәбәп юк кебек. Ике яктагы моторның тигез гөрләп эшләвеннән башка тынлыкны берни бүлдерми. Иллюминатордан ара-тирә вак болыт кисәкләренең ничек кинәт пәйда булсалар, шулай кинәт артта калулары күренә. Ләкин моның алдавыч тынлык икәнен очучы халкы күптән белә. Чыннан да, полкның бездән алдарак очучы самолетлары арасында зәңгәрсу-кара төтен болытлары хасил була башлады. Бу—дошманның зенитка батареялары телгә килде дигән сүз. Сул канатта очучы бер самолет снаряд тиюдән сикереп, өскәрәк күтәрелгәндәй итте дә, ялкынга уралып түбәнгә омтылды. Аның артыннан кара койрык кына сузылып калды. Парашюттан сикерүче-фәлән күренмәде. Мөгаен, экипаж шунда ук һәлак булгандыр. Тешләр тешкә кысылды, әмма бернишләр хәл юк—без сугышчан иптәшләргә нинди дә булса ярдәм күрсәтүдән мәхрүм идек. Җирдә андый мөмкинлек бар: пехота булса, һөҗүмгә барганда кемдер пуля яки снаряд ярчыгы тиеп егылса, басыпмы, шуышыпмы аның янына килергә, ярасын бинт белән кысып бәйләргә, яралыны санитаркалар кулына тапшырырга була; танкистлар да янган танктан иптәшләрен сөйрәп чыгара ала, ә һавада—юк. Самолет эчендә үк һәлак булмасаң, парашюттан файдаланып, исән калырга тырышу үзеңнән тора. Сикереп өлгерәсең икән, яшәү шансы арта. Тик әле бу котылу түгел, чөнки һавада парашют куполы астында акрын гына җиргә таба хәрәкәт иткәндә, фашист истребителе әйләнеп килеп пулеметыннан атып үтерергә мөмкин. Андый язмыштан котылсаң да, күбесенчә дошман тылына сикерергә туры килгәнлектән, әсирлеккә эләгү куркынычы бермә-бер арта. Ә Верховный башкомандующий әсирлеккә төшкәннәрне илен сатканнар рәтенә кертә.

Безне озатырга тиешле истребительләр торган аэродромны инде үткән идек. Радиоэлемтә буенча аларның һавага күтәрелүе турында хәбәр алдык. Хәбәр алыну белән полктагы эскадрильялар бер-бер артлы сугышчан курска ятты. Дошман

зениткаларыннан ачылган ут самолетның төрле ягында шартлау дулкыннары хасил итеп очкычыбызны як-якка чайкалдыра, әче төтен исе салонга да үтеп керде. Безнең эскадрильяның койрык өлешендә баручы бер самолет туры тиюдән утлы шар булып әллә кайларга чәчелде, бу—аның бортында бомбалары шартлаганнан. Монысы инде җитдирәк, әгәр очкычлар арасындагы ара якын булса, башкаларга да зыян килергә мөмкин. Безнең очкыч чыгымчы ат шикелле бер якка тайпылды, тик командир да, штурман да күп мәртәбәләр сугышчан очыш практикасын үткән кешеләр—машинаны тиешле курска яткыра алдылар.

## Бәреп төшерелү

Зениткалар кордонын да үттек. Нигәдер безне озатырга тиешле истребительләр төркеме генә һаман юк. Алдарак, шактый югары, өч дистәдән артык очкыч пәйда булды. Ниһаять, дип, җиңел сулап куйдык. Тик ул истребительләр якынаймадылар, безнең полк очкан юнәлештә ара ераклыгын саклап бара бирделәр. Кенигсберг өстенә якынаю белән аларның хәрәкәтләре үзгәрде, кинәт кенә дүрткә бүленеп, як-якка аерылдылар да, козгыннар чебешләрне аулар алдыннан күзәтеп әйләнгән шикелле, өстәрәк төрле фигуралар ясарга керештеләр. Алдагы «тугызлык» үзләренә билгеләнгән объектларны бомбага тота башлаганда, тимер «козгыннар» өскә ябырылды. Шунда гына без алдануыбызны аңладык, бу—дошман истребительләре иде. Алар уңайлы позициядә, бомбардировщиклар пулеметларыннан ут ачып каршылык күрсәтә дә алмый, чөнки пулемет өскә таба атарга көйләнмәгән. Люкларын ачып бомбаларын коярга керешкән очкычлар фашистлар өчен менә дигән мишень иде, күз алдында берничә бомбардировщикны бәреп тә төшерделәр. Чират безгә җитте. Билгеле, очкан курстан тайпылып, һава сугышына керешеп китү мөмкинлеге бар иде. Алай иткәндә, куелган бурычны үтәп булмаячак, тиешле объект бомбага тотылмыйча калачак. Бары бер юл кала—һаман алга очып, картада билгеләнгән объектка җиткәч, бомбаларны җиргә кою һәм шуннан соң, әгәр бәреп төшермәсәләр, немец истребительләре белән сугышка керү. Әгәр инде бәреп төшерсәләр... Хәер, монда төрле уйларга бирелеп торырга вакыт юк. Алга, бары тик алга! Шулчак штурман Плюхин: «Бомбалар!»—дип кычкырды һәм люклар ачылып, безнең очкычның үлем йөге аска коелды. Кинәт машинабызның бөтен корпусын нидер дөбердәтеп кыйнап үтте. Ул да түгел, мин утырган кабинаның уң як иллюминаторында ялкын телләре пәйда булды. Тәрәзә пыяласы яна торган материалдан ясалганлыктан, ул дөрләп яна, экипаж командиры утырган өлештә дә ялкын телләре биешә. Куликов үзе ярым үлем хәлендә булып, инде самолет белән идарә итәрлек түгел, хәер, ул инде штурвалны тыңламый да иде бугай. Тизлек югалганнан-югала барып, биеклекне күрсәтүче ук сулга киткән—самолет котылгысыз рәвештә җиргә төшеп килә иде. Сөйләшү аппараты аша радистка эндәшәм, аннан җавап юк. Ул тарафка борылып карауга күзалларым караңгыланып китте. Николайга карарга куркыныч: куллары салынып төшкән, йөзтүбән капланган башы канга баткан, баш капкачы ачылып, миләре күренеп тора. Күпме эндәшсәм дә, Захаровта тереклек әсәре күренмәде, ул үлгән иде. Колагым шаулый. Каяндыр, бик ерактан, әллә командир, әллә штурманның: «Сикерегез!» дигән әмере яңгырады. Мин ничек люкны ачып сикерүемне хәтерләмим. Һавада, парашют гөмбәзе астында, салкынлык тәнне куырганга айнып киттем. Күрәсең, сикерүем дә, парашют бөҗрасын тартуым да, инстинкт буенча эшләнгән. Мин акрын гына чиксез зәңгәр күк биеклегендә тибрәләм. Әнә астарак, шартлаудан төрле якка чәчелеп, җилдә тирбәлгән кәгазь кисәкләре кебек аска омтылучы самолет кисәкләре шәйләнә. Алар күпмедер вакыт күзгә күренеп очалар да, бушлыкта юкка чыгалар. Тирә-якта тынлык хөкем сөрә, миннән башка бернинди тереклек әсәре

юк кебек тоелды. Ләкин бу алай түгел икән, колак яныннан ук выжт-выжт итеп пулялар сызгырып үткәнен ишетәм, шрапнель яңгыры чәчеп ерак та түгел снарядлар шартлавы күренә. Тунган булсам да, куркудан гәүдәмне салкын тир басты, минем өчен яшәү белән үлем арасы каш белән күз арасы кебек кенә калды, чөнки һәр секунд үлем алып килергә мөмкин иде. Түбән төшкән саен аста җәелеп яткан Кенигсбергның йортлары да якынаялар, урамнар, шул урамнар буенча ары-бире чабышкан кешеләр шәйләнә. Туп-туры дошман өненә килеп төшәчәгемне уйлап, эсселе-суыклы, булдым—әсирлеккә эләгәчәгем көн кебек ачык иде. Парашют бауларын тарткаларга мөмкинлегем юк, кулларым тунып өшегән. Әнә, үзәктәге урамнарның берсендә гитлерчыларның зур гына отряды стройга тезелеп баскан. Алларында торган берәү кулларын бутый-бутый нидер аңлата, күрәсең, командирларыдыр. Офицердан күреп стройда торучы солдатлар да минем тарафка карап тора башладылар булса кирәк. Немец офицерының: «зольдатен, ахтунг!»—дигәне ишетелде, үз буйсынуындагыларны уяу булырга чакыруыдыр инде. Каты җиргә аяк басуым солдатлар алдына ук туры килде. Парашютның чүпрәге артымнан төшеп җир өстенә таралырга да өлгермәгән иде әле, немец офицеры чабып килеп сул кулы белән комбинезон якасыннан эләктерде, уң кулына тоткан перчаткасы белән «русин швайн» дип сөйләнә-сөйләнә яңакларыма суккалады. Аннары каты гына этеп җибәреп, солдатларына парашютымны ычкындырырга боерды. Тегеләр мине парашют бауларымнан азат иткәч, өстемдәге җылы комбинезонны салдырып алдылар. Болай да тунган гәүдәм рәхимсез салкыннан тагы да ныграк куырылды. Алар минем белән озак әвәрә килмәделәр, ике автоматчы эткәләп янәшәдәге урамда урнашкан комендатурага алып китте. Анда бер бүлмәгә кертеп бикләп тә куйдылар. Станция ягында авиаполкның бездән соң очучы эскадрильялары ташлаган бомбалардан шартлау авазлары ишетелә. Кайбер сугышчан иптәшләргә фортуна елмая шулай да,—дигән монсу уй күңел әчкәресендә баш калкытты. Их, шулар арасында булсаң иде ул хәзер.

Комендатура бинасының коридоры буенча барганда каршыга очраган немецларның йөзләренә игътибар иттем: аларның чыраена аучы эзәрлекләвеннән качып баручы кыргый җәнлек куркуы чыккан. Димәк, үзләренең соңгы сәгатьләре якынлашуын аңлыйлар, тиздән котылгысыз җәза киләчәген тою аларны шулай чарасыз иткән.

Ярымкараңгы бүлмәдә миннән башка кеше юк иде. Күп тә үтмәде, кабат ишек ачылды. Янә биш әсирне китергәннәр икән. Тик аларны танырлык түгел, комбинезоннары янып титкәләнүе өстенә куллары-битләренә кадәр пешеп кабарган. Кашсыз, керфексез күз кабаклары йомылып, күзләре капланган. Алар артыннан ук тагын бер кешене сөйрәп керттеләр. Никтер аның парашютын да алып кергәннәр иде. Парашютны стена буена ыргыттылар да, яралыны шуның өстенә салдылар. Аның аягына да басып торырлык рәте калмаган. Сызлана, күрәсең. Түзә алмыйча ыңгырашуы болай да киеренке нервыларга авыр тәэсир итә. Мин, аның сызлануларын җиңеләйтергә теләп, янына барып тезләндем.

—Кем син, әй, җан иясе?—дип эндәшүемә яралы очучы көч-хәл белән күзен ачты. Мин звено командирыбыз өлкән лейтенант Бобровны танып, тетрәнеп киттем. Командир да таныды бугай, әрнүле йөзенә елмаю кундырырга теләп, авызының бер читен кыегайтты:

—Синең кебек үк кеше, Хәлилов. Танымыйсыңмени?

—Таныдым, иптәш өлкән лейтенант.

—Тс-с, артык тавышланма. Монда кирәкмәгән колаклар да булуы бар, авызыңны чамалап ач.

—Аңладым, иптәш командир,—дидем мин акрын тавыш белән.—Берәр төрле ярдәм кирәк түгелме?

—Их-х, өлкән сержант, тән генә түгел, менә монда—эчтә януына чыдашлы

түгел. Җиңүгә дә күп калмаган иде бит, кем уйлаган язмыш дигәннәре немец әсирлегенә китереп ташлар дип.

Мин өлкән лейтенант Бобровны юатырлык сүз таба алмадым, үземнен дә эчемдә хисләр кайный, янарга ялкыны гына юк.

Бер сәгать вакыт үткәндерме, сул яктагы ишек ачылып, бусагада ябык йөзле булса да, озын буйлы, киң җилкәле обер-лейтенант формасында берәү пәйда булды.

—Попрофф,—диде ул урысчаны вата-җимерә Бобровны допроска чакырып. Өлкән лейтенант икеләнгән шикелле беравык ишеккә карап торды да, дүртаяклап торып басмакчы булды. Тик аның талпынуы барып чыкмады. Мин командирыбызга ярдәмгә килергә теләп, шунда омтылдым. Обер-лейтенант:

—Отстаффить!—дип кычкырды. Перчаткалы кулын изәп, ияреп кергән автоматчыга Бобровны алырга күрсәтте. Тегесе җәһәт атлап һаман аягына баса алмаган өлкән лейтенант янына килде. Автомат түтәсе белән китереп сугудан Бобров идәнгә тәгәрәде. Аны ничек кирәк алай аягына бастырып, допроска алып киттеләр.

Допростан кайтканын көткәндә, ул яктан илереп кычкырган авазлар ишетелде, күрәсең, өлкән лейтенантны кыйныйлар иде. Аны култыклап алып килеп, камерага кертеп атканда танырлыгы калмаган иде: болай да шешенке йөзе канга баткан, аскы ирене ярылган, маңгаеннан да кан саркып тора.

Башка камерадашларны да чакыра тордылар, берәм-берәм сорау алып, кыйнап, китерә тордылар. Чират мина да җитте. Бу хәлләрне күреп күнел каткан, эчтә нәфрәттән башка һични калмаган, курку хисе дә каядыр олаккан иде. Башта, «барыбер үләсе», дигән уй бөтерелә. Сакчы кабинетка төрткәләп керткәндә, өстәл артындагы ябык чырайлы обер-лейтенант минем кызылармияче кенәгәсен кулында әйләндергәләп утыра иде. Анын янында тәрҗемәче басып тора. Ул обер-лейтенантның колагына иелеп нидер әйтте, тегесе күтәрелеп карады да үзләренчә кычкырды. Тәрҗемәче:

—Фамилияң?—дип кабатлады. Миннән җавап булмагач, немец офицеры аягүрә басып салкын карашы белән мина текәлде.

—Халилофф?—диде фашист вата-сындыра. Көтеп тә җавабымны ишетмәгәч, кайсы полктан, дивизиядән булуым белән кызыксынды. Мин һаман дәшмәдем. Немец офицеры яныма ук килеп басты.

—Телеңне йоттыңмы әллә?—дип, искәрмәстән ияк астына сугып җибәрде. Фашистның кеше кыйнау тәҗрибәсе зур иде, күрәсен, күземнән утлар күренде. Аяк өстендә басып кала алмадым, әллә ничә адымдагы өстәл читенә очып, башым белән килеп бәрелдем. Гитлерчының немецча нидер сөйләнә-сөйләнә котырынып типкәләвен томанлы гына хәтерлим. Аннары шәм кебек лепелдәп торган аңым сүнеп, караңгы бушлыкка очтым.

Аңыма камерада гына килдем. Идәнгә кертеп ыргытканнар, янәшәмдә идән себерке ята. Башым чуен кебек авырайган, күз алларым әлҗе-мөлҗе килә. Торып утырмакчы идем, умыртка сөяге авыртуга чыдый алмыйча ыңгырашып җибәрдем. Ни хикмәттер, стенада сәгать эленеп тора. Камера тынлыгын сәгать текелдәвеннән башка берни бозмый. «Тек-тек, тек-тек». Бу текелдәү тавышы без әсирләргә үлем сәгате якынлашуын искәртә кебек. Төн уртасына кадәр камерага башка аяк басучы булмады. Ишек артындагы сакчының коридор буенча йөренүеннән башка шылт иткән аваз да юк. Бу—һава дивизияләре берсе артыннан берсе килеп бомбага тотучы шәһәр өчен сәер тынлык иде, зур шартлау алдыннан була торган тынлык.

## Пилауга күчерелү

Стенадагы сәгать уникене сукканда кинәт ишек ачылып китте. Ике автоматчы артыннан овчаркалар житәкләгән ике офицер килеп керде. Алар идәндә ятучы әсирләрне типкәләп аякларына басарга мәҗбүр иттеләр. Үзләре

бертуктаусыз: «Шнелле, русин швайн»,—дип жикеренәләр. Һични аңламыйча як-якка, бер-беребезгә каранабыз. Атарга алып баруларыдыр инде дип уйлап, кулларны кысышып, чыгу ягына юнәлдек. Коридорда безне тагын берничә хәрби каршы алды. Урамга алып чыккач, алар жиде кешелек төркемебезне төрле яклап урап алып, төнге урамнан поезд вокзалына таба алып киттеләр. Димәк, әлегә безне атмаячаклар. Фашистларның ниндидер планнары бар кебек. Шулай булып чыкты да. Станциягә килеп житү белән, безнең жидебезне дә бер кечкенә вагонга куалап кертеп, өстән бикләп тә куйдылар. Ул арада паровоз, сызгыртып алганнан соң, артына тагылган вагоннарын дерт итеп сискәндереп, кузгалып та китте.

Таң алдыннан поезд ниндидер бер станциягә килеп туктады.

Ишекләрне ачып, вагоннан төшәргә боердылар. Бер-бер артлы жиргә сикердек. Төрткәләп стройга тезделәр дә, ашыктырып алга куаладылар. Әле юньләп яктырып та житмәгән. Әче жил исә, кар катыш яңгыр ява. Тәүлек буе авызга валчык та капмаганлыктан, аяклар хәлсезлектән бөгеләләр. Юка киемнәр аша юеш жил тәннең иң нечкә жирләренә үтеп кереп, теш тешкә бәрелә. Күбебез баш киемнәрсез. Юешлектән, салкыннан чәчләр бозланып катты. Әгәр озаграк барсак, тиешле урынга килеп житә алмаган да булыр идек. Ярый әле «һальт!» дигән аваз яңгырады. Безне пристаньга куалап керттеләр, анда бер-беребезгә елышып чак кына жылынгандай иттек. Зур гына көймә китергәннәр икән, шуңа утыртып бухта аша каршы ярга чыгардылар. Диңгез ярыннан йөз илле метрлар чамасы ераклыкта урнашкан кызыл кирпеч бинага керттеләр. Бу бина немецларның гауптвахталары кебегрәк нәрсә иде бугай, жиде кешелек төркемебезне икегә аерып, камераларга яптылар. Мин безнең белән бергә туры килгән штурманнан:

—Нинди жир бу?—дип сорадым.

—Пилау каласы диләр моны, туганкай,—дигән жавап ишеттем. Рәшәткәле тәрәзә янына басып озак кына диңгез ягына карап торсам да тышта томанлы һәм яңгыр булганлыктан, су өстендәге хәрәкәт абайланмады. Гәүдәдә нык арыганлык сизелә, сөякләр сызлый. Идәнгә сузылып ятудан башка чара юк иде.

Бу көнне безнең янга кичкә кадәр керүче булмады. Тамакны алдап булмый шул, эчләр аркага ябышкан кебек, күзләр эчкә батып, яңаклар суырылып калды. Кич белән шулай да һәрбер әсиргә берәр стакан жылымса су өләштеләр. Әмма су эчү тагы да ныграк ашыйсыны китерде. Шулчак ничектер мәктәптә укыган елларымда, пионер лагерена ял итәргә барганда, колхозның бүләк итеп әллә ничә бөтен икмәк биреп жибәрүе искә төште. Ул икмәкнең тәме һаман да авызда торган кебек...

Ул жәйне пионер лагеренда беренче сменада ял итәргә яхшы укучылардан Лотфи, Нәфыйк һәм мине сайлап алдылар. Әниләр фанер чемоданнарга кирәк-яракны тутыргач, безне колхоз кәнсәсенә кадәр озата килделәр.

—Хәмидулла, берүк юлда барганда оланнарга күз-колак була күр инде, бала-чага бит, шаярып, тәгәрмәч астына керә күрмәсеннәр,—дип, ат жигеп безне илтүче Хәмидулла агайга гозерләрен житкерделәр.

Хәмидулла агай кулына бер капчык күтәреп кәнсә баскычыннан төшеп килә иде. Ул капчыкны яшь бала тоткандай кочаклаган, зур саклык белән аны арбага куйды.

—Ярар, жиңгәчәйләр, бер дә аптырамагыз, шайтаным да булмас ташбашларыгызга. Мин үзем алар күк вакытта юл тузанында тәгәрәп үстем. Ул чагында лагерь дигәннәре дә юк иде әле,—дип сөйләнде.

Безне капчыктан килгән тәмле ис әсәрләндерде. Бу—борыннарны кытыклап, магнит кебек үзенә тартучы яңа пешкән арыш ипие исе. Авыздан сулар килә, түземсезләнеп капчыкны карыйбыз. Гел ач булмасак та, алабута яки бәрәңге кушмыйча пешерелгән «чын» ипи ашау ул елларда азларга гына тәти иде шул.

—Ял иткән урыныгызга баргач житешерсез,—диде Хәмидулла агай, безнең ымсынуны күреп. Шулай да арбада урын алганда, һәркайсыбыз ипиле капчыкка якынрак утырырга тырышты. Сабыйлык диме ни диярсең инде.

Яшеллеккә чумган калкулыклар, тугайлар аша бара торгач, ашау кайгысы онытылды. Апас урманында туктап ял иттек. Ат сөзгәк юл буйлап аска юыртканда Хәмидулла агай еракта биниһая озын тасманы хәтерләтеп ялтырап яткан манзарага төртеп күрсәтте:

—Зөя елгасы шушы була инде, оланнар.

Исебез китеп агай күрсәткән якка карыйбыз. Без якынайган саен тасманың үлчәмнәре дә арта, кояш нурларына коенган су өсте көмеш түсенә кереп елкылдый.

Тау тәмамланугa, болынлык башланып китте. Болынлык елга буйлап сузылган, елга ярлары күп урында куе таллар белән капланган. Төн ягына борылып, ярты чакрымнар баргач, елга аша салынган күпердән чыгышлы. Күпернең аргы ягында Дәвеш авылы башлана. Дәвеш артык зур булмаган гажәеп матур нарат урманы янәшәсендә генә. Төз урамның ике ягы буйлап гади генә, чын авылча итеп төзелгән өйләр тезелеп киткән. Хәмидулла агай урам башына чыгып житәрәк дилбегәсен капылт уңга тартты.

—Тпру-уу, малкай,—дип, атын озынчалап салынган йорт янына китереп туктатты.—Балалар, сезнең лагерь столовае шушы була инде. Килеп җиттек, төшегез,—диде үзе җәһәт кенә арбасыннан җиргә сикереп.

Атының аркалыгын бушатып, алдына печән салгач, ашханәгә кереп китте. Анда озак тоткарланмады, чыгып:

—Барыгыз, карынгыз ачкандыр, анда сезне көтәләр,—дип безгә эндәште.

Чыннан да, ерак юлдан килеп ачыккан идек, кабат әйткәнне көтмәдек, йорт эченә үттек. Хәмидулла агай безнең арттан кеткелдәп:

—Менә хәзер рәхәтләнеп ашасагыз да була инде колхоз пешерткән ипине,—дип калды.

Ашханәдә башка авыллардан килгән пионерлар да бар иде. Юл тузанына баткан бит-кулларны кулюгычта әйбәтләп юганнан соң, күнелле гөрелдәшеп, мул табын артына утырыштык, маңгайдан бөрчек-бөрчек тирләр чыкканчы, Хәмидулла агай әйткәнчә, рәхәтләнеп сыйландык.

Менә хәзер, немец әсирлегендә ятканда, үтереп ашыйсы килүдәндерме, минем хәтеремә шушы борчаклы аш белән күпереп пешкән арыш ипиен ашаган чак искә төште. Бу турыда онытырга тырышып күзләремне йомдым. Авызда барыбер арыш ипие тәме. Шул килеш онытылганмын...

Төн тыныч үтте. Тышта томан булганлыктан, безнең һава дивизияләре фашистлар ягына үлем йөге ташымады. Көн яктырып, кояш күтәрелгәч, дингез өсте дә ачылды. Ара якын, су өстендәге бар хәрәкәт аермачык. Төрле зурлыктагы пароходлар, хәрби катерлар әрле-бирле йөреп тора, сирәк кенә суасты көймәләре күренә.

Һава тревогасы башланды. Дингез ягыннан совет штурмовиклары пәйда булды. Алар су өстендәге корбаннарына ташландылар. Пароходлар, катерлар тилгәннән качып котылырга тырышкан чебешләр кебек, тәртипсез рәвештә бухтадан ачык дингезгә омтылды. Очкычлардан ташланган бомбалар әле анда, әле монда су баганалары күтәрә, очучылар пушкаларын да эшкә җигәләр—бомба сызгыруы белән пушкадан аткан тавыш аерыла. Менә бер пароход бомба эләгүдән күз алдында кисәкләргә аерылып, башта һавага күтәрелде дә, агач-тимер-төтен-су массасына әверелеп төпкә китте. Икенче йөзгеч белән дә шул хәл кабатланды. Эскадрильяларның берсен-берсе алыштырып берничә сәгать туктаусыз дәвам иткән һөҗүме нәтиҗәсендә фашистларның өч пароходы һәм ике бронекатеры юкка чыгарылды. Әле болары без күргәннәре генә, ә күрмәгәннәре ничә булгандыр, шайтан белсен. Штурмовиклар дингез өстен генә

түгел, пристаньны һәм шәһәрне дә бомбага тоттылар. Гаупвахта тәрәзәләре беренче шартлаулардан ук коелып төште. Якын-тирәдәге йортларның чүлмәк түбәләре әллә кайларга чәчрәп очканы күренә, кайбер биналар бомба туры килеп, картон уенчыклар кебек җимерелә. Безнең хәл тәбегә эләккән тычканныкыннан әлләни аерылмый. Фашистларның диңгез суднолары, ныгытмасы, җанлы көчләренең күз алдында юкка чыгарылуы куанычлы булса да, үлем һәр мизгелдә үзебезгә дә яный. Шуна да сәер тойгы астында калдык: сөенеч белән курку янәшә. Хәер, беренчесе көчлерәк бугай. Әсирлектән барыбер котылып булмаслыкны уйлап, үзебезнекеләр бомбасыннан һәлак булуың яхшырак дигән фикергә киләсең.

Гауптвахтадан егерме метрлар тирәсендә генә бомба шартлады. Стенадан штукатурлар коелды, берничә урында зур ярыклар хасил булды. Менә ул—үлем, очучы йөген егерме адымнар сулгарак бушатса, без якты дөнья белән хушлаша идек.

Ниһаять, тынлык урнашты. Тик караңгы төшеп килгәндә генә төнге бомбардировщиклар эшкә кереште. Бусы психикага тагы да катырак тәэсир итә икән. Чөнки көндез тәрәзәдән тышкы яктагы мәхшәрне өлешчә күрү мөмкинлеге булса, төнлә үзеңне бөтенләй ярдәмсез хис итәсең. Очкычлардан ташланган бомбалар әче сызгырып нәкъ синең өскә төшкәндәй тоела. Бөтен тирә-як сызгырудан, шартлаудан тетрәп тора: Җир генә түгел, йорт стеналары да чайкала кебек. Төне буе коридорда эт өргән авазга охшаган тавышлар чыгарып фрицлар чабышып йөрде. Алар куркудан үз-үзләренә контрольләрен югалтканнар иде бугай.

Иртә беләнгә бар да тынды. Бүген әсирлеккә эләккәнгә өч көн. Шулай булса да, ашарга бер сынык икмәк биргәннәре юк. Хәер, ашау кайгысы гел онытылды. Гитлерчылар кайчан кереп атарга алып чыгарлар икән дип көтәбез. Барысына түзәргә була, тик тартасы килүгә чыдар әмәл юк. Аптырагач, кайчандыр тәрәзәгә маскировка өчен ябыштырылган сары газета кисәкләрен ертып, тәмәке урынына көйрәтәбез. Тартасы килүне киметмәсә дә, төтене чыккач нәфес азрак басыла тагын.

## Үндүртенче март

Бөтен җирне томан каплаган. Диңгез ягында да берни күренми. Ул тарафтан бары тик су өстендәге судноларның авыр уфылдавы гына ишетелә. Без ябылган бинаның тәрәзәсе төбеннән бертуктаусыз диярлек автомашиналар, сугыш техникасы агыла. Машиналарның әрҗәсе күбесенчә брезент белән капланган—авыр йөк төялгән булырга тиеш, чөнки моторларының үкереп эшләве моңа дәлил.

Томан чак кына таралу белән, берничә автоматлы сакчы ияртеп камерага немец офицеры килеп керде. «Шнелле»,—дип ашыктырып, урамга куаладылар. Инде тәүлектән артык башка камерадагыларны күргән юк иде. Мин танып белгәннәрдән алты кеше, шулар арасында экипажыбыз штурманы кече лейтенант Плюхин да бар иде. Ул элек тә буйга кечкенә, чандыр иде. Әсирлеккә эләккәч, бөтенләй кечерәеп, үсмер малайларга охшап калган. Аны исән килеш күргәч, куанычым эчемә сыймады, янына килеп иңнәреннән кочтым. Владимирдан экипаж командиры турында да сораштым. Штурманның йөзенә кайгы билгесе чыкты.

—Юк инде безнең командир, парашют белән сикергәндә фашист истребителе пулеметтан атып аны теткәләп бетергән,—диде ул башын аска иеп.

—Яхшы кеше иде, и-их, сугыш диген. Безнең дә язмыш аныкыннан әлегә исән булуыбыз белән генә аерыла.

—Күңелеңне төшермә, өлкән сержант, бәлки, берәр рәте чыгар. «Нинди рәт чыгарга мөмкин фашистлар өнендә, бүген булмаса, иртәгә юк итәрләр

дип җанынны учка кысып күтәргә генә кала», дип уйладым мин. Тик кычкырып әйтмәдем, чөнки моннан берәүгә дә җиңеллек килмәячәк, авыррак кына булачак иде.

Кече лейтенант ничек немецларга эләгүен дә сөйләде. Үзе бер мажара. Ул сикергәч, диңгез ярыннан ерак түгел агачлыкка килеп төшә. Парашют баулары карама ботагына эләгеп, һавада асылынып кала. Күпме тырышса да, үз көче белән агач башыннан төшә алмый. Берничә сәгать шул хәлендә эленеп тора. Нык тунудан аяк-куллары берни тоймый башлый. «Бетүем шушы икән», дип уйлый Володя. Вакыты белән аны томалана. Бермәлне чит авазлар ишетеп күзен ачса, ул эләгеп торган агач төбендә үк берничә фриц тәгам җыеп утыралар, имеш. Учак та якканнар. Тушенка банкасы ачып, көлешә-көлешә ашыйлар. Никтер берсе дә өскә күтәрелеп карамый, югыйсә, совет очучысын һичшиксез күрерләр иде. Учактан күтәрелгән җылылык, тәмле булып таралган ит исе Плюхинны тәмам айныта. Ул немецларны сискәндереп төчкереп җибәрә. Тегеләр дәррәү сикереп торып коралларына ябыша. Берсе инде атарга дип автоматын төзи, тик икенче берәве автоматны читкә борып өлгерә, көпшәдән чыгып очкан ядрәләр янәшәдәге агач ботакларын кыеп төшерә. Очучыларны әсирлеккә алу зур мәртәбә саналганлыктан, дошманнар иренми, Плюхинны агач әсирлегеннән азат итеп, немец әсирлегенә алып кайта.

Ничаклы гына ач булсак та, әлегә анысына түзәбез. Ә менә тартасы килүдән башлар әйләнә башлады. Юл аша чыкканда аунап яткан тәмәке төпчекләре күреп, шунда ташландым. Бер-ике төпчекне кесәмә салырга өлгермәдем, арттан килеп кемдер аркама каты итеп оруга тәгәрәпләр киттем. Янәшәмдә авызын ямьсез кыйшайтып сакчы басып тора, үзенчә көлүедер инде. Автомат түтәсе белән суккан икән. Болай да сызлаган умырткам тагы да ныграк авырта башлады. Конвоирларга ияреп безнең төркемне озатып йөрүче тәрҗемәче алай эшләргә ярамаганны аңлатты. Инде бүтән чагында саграк кыландык: күзәтүчеләр күрмәгәндә, тычканга ташланган мәче җитезлеге белән төпчекне эләктерәбез дә эчке кесәгә шудырабыз. Хәлсез әсирләргә көч каян килгәндер, анысын бер Ходай белә. Хәер, тартасы килү тойгысы барысыннан да өстен иде шул.

Төштән соң, томан таралуга, тагын үзебезнекеләр очып килеп җитте. Җир өстен кабат дәһшәтле кукрәү авазлары күмде. Безне ашыгычлык белән төрмә ролен үтәүче бинага алып кайттылар. Кичкырын, авиаһөҗүм туктагач, эшкә яраклыларны бер якка, яраланып яисә имгәнеп эшкә чыга алмаучыларны икенче якка тезделәр. Ике арада автоматчылар озатуында немец офицеры йөренә, әсирләргә эчке тәртип кагыйдәләрен, качарга омтылыш ясалса, шунда ук атып үтерәчәкләрен аңлата. Тәрҗемәче урысчага аударып, сүзен сүзгә җиткерә. Сафта торганда селкенергә дә ярамый. Ике төркемдә барлыгы егерме кеше. Каршы яктагылар ишлерәк. Кайсысының бөтен йөзе бинткә уралган, кайсының кулы чүпрәк бәйләп муенына асылган, тәннәре каты пешүдән чиләнеп, киеменә ябышканнары да бар. Минем каршыда ук төнлә ерак араларга оча торган Н номерлы полк командиры подполковник басып тора, аның аягы имгәнгән. Мескенкәй аксак аягын бераз бушатып кыймылдатып куйды. Исемлек буенча барлау уздыра башлаган офицер аның хәрәкәтен күреп, янына йөгереп килде. Юкка фашист димәгәннәрдер—бар куәтенә күн итеге белән подполковникның тез астына китереп типте. Ир уртасы ыңгырашмаска тырышып, ике куллап тезен тоткан килеш алга иелде. Аның чыдамлыгына җене котырган гитлерчы арттан баш чүмеченә сугып яралы җиргә екты. Әсирләр немецның подполковникны таптый-таптый изүен күрмәскә тырышып, йөзләрен читкә борды.

Безне камераларга куалап керттеләр. Караңгы төшкәндә җан башына җитмеш грамм пычкы чүбе кушып пешерелгән икмәк һәм берәр стакан җылы су өләштеләр. Бу—тәүлеклек норма. Аннан соң тагын һәр әсиргә ярты литр чамасы болганчык су бирделәр. Табак-савыт юганнан калган су икәнлеге исеннән

сизелә иде. Икмәкне болай гына тешләп ашарлык түгел, шакраеп каткан. Җаен таптык: юынтык суга ипи кисәкләрен ташладык та, болгата-болгата җебеткәннән соң, шулпага охшый башлаган баланданы азлап-азлап эчәргә керештек. Ана чак кына нindидер тәм кергәндәй сизелде. Ач тамакка анысы да ярап тора.

Нык арылган. Идәнгә сузылып яттык. Шулай да күзгә йокы кермәде. Уйларым мине ерак үткәнгә, 1940 елның октябрь аена алып китте.

## Казан—Пенза арасы

Кырыгынчы елның унҗиденче октябренә каршы төндә без—некрутларны завод клубы яныннан бөркәүле машиналарга утыртып Казан тимер юл вокзалына алып киттеләр. Гарифҗан абыем белән беренче мәхәббәтем Мәхмүзә мин утырган машина артыннан текстиль фабрикасы мунчасына кадәр йөгерделәр. Менә алар ераклашканнан ераклашып, урам чатындагы багана төбендә басып калдылар. Ут яктысында кул болгаулары аермачык күренә. Мәхмүзә башындагы ак яулыгын салып, изи дә изи. «Хуш, туган абыем, хуш, сөеклем Мәхмүзә»,—дип пышылдый иреннәрем. Монсу булып китте. Машина әрҗәсендә күнелле гөрелдәшеп барган иптәшләремнең әнгәмәсенә дә катышмадым. Безгә кирәкле поезд иртәгәсе көнне иртәнге сигездән соң гына буласы икән. Кем каян бушрак эскәмия таба, шунда җайлашып баш төртте. Пензага кадәр озата баручы төркем җитәкчеләребез сүз әйтмәде.

—Әллә кая китеп югалмагыз гына,—диде алар. Тәүлек буе йокламаган яшь-җилкенчәкнең хәлен анлый иде алар.

Вокзал иртәсен сискәндереп «Подъем!» янгырады. Торып аякка басуга, фамилияләп исемлек барладылар. Мин җиде йөз уникенче номерлы төркемгә эләктем. Бу төркемгә һава флотына билгеләнүчеләрне җыйдылар. Залга өр-яна хәрби киемнән, озын буйлы, кыска калдырган чәчле вокзал коменданты килеп керде. Төркем башлыклары ана үрә катып честь бирделәр. Һәрберсенең рапортын тыңлаганнан соң комендант башындагы фуражкасын салып өстәлгә куйды. Ашыкмыйча, салмак тигез тавыш белән булачак кызылармиячеләргә вокзалдагы тәртипләр, станциядән рөхсәтсез чыкмау, эшелонда барганда үзенне ничек тотарга, спиртлы эчемлекләр кулланудан тыелырга тиешлекне һәм башка кагыйдәләр турында җентекләп анлатты. Шуннан соң саубуллашып залдан чыгып китте.

Тышкы якта паровоз гудогын кычкыртты. Призывниклар өчен состав биргәннәр икән. Төркемнәрне бер-бер артлы утыру платформаларына алып чыктылар. Һәр төркемне алдан билгеләнгән вагоннарга тараттылар. Паровоз янә монсу итеп кычкыртты. Шунда яшәп иялнелгән кала белән саубуллашуы кыен иде. Поезд тимер тәгәрмәчләре белән рельска «дрык» итеп бәрелеп, урыныннан акрын гына кузгалып китте. Паровоз безнең хәлне анлагандай авыр пуфылдап куя, рельс белән рельс ялганган җирдә вагоннар чак кына сөрлеккәндәй акрынаялар да, кабат алга тартылалар. Без дә шул унайга алга-артка чайкалабыз. Тизлек арткannan-артып, перронда басып торган кешеләр, соры монсу биналар артка йөгерә. Казан инде артта кала. Җылы хатирәләр белән бәйле калада сөйгәнем Мәхмүзә, әлегә авылга кайтып китәргә өлгермәгән абыем, инде икенче өемә әверелгән заводым һәм хезмәттәш дусларым кала. Күрешкәнчегә кадәр хушыгыз, газизләрем. Сез мине онытмагыз, мин сезне онытмам!

Казан—Пенза арасы ерак түгел. Эрерәк шәһәрләрдә озаграк, ә кечерәк торак пунктларда кыска вакытлы тукталышлар ясап барса да, безнең эшелон күз бәйләнгәндә инде Пенза вокзалында идек. Монда озак тоткарламадылар, хәрби һава көчләре өчен очучылар әзерләүче авиамәктәпкә тиешле санда курсантлар җыелу белән Орел ягына озаттылар. Ике тәүлек дигәндә Орелга барып җиттек.

## Авиамәктәптә

Биш көн карантинда тотканнан сон, чәчләрне кыркып, мунча кертеп, хәрби киемнәр кидерделәр. Бер-беребезгә карыйбыз да елмаябыз. «Синме сон бу? Танырлык та түгел»,—дип шаян сораулар бирешәбез. Гражданскийдан хәрби формага күчү килеш-килбәтләрне нык үзгәрткән: бу хәл күпләребезгә ошый, бераз сәер дә тоела. Хәер, бер-ике атнадан ияләнеп җиттек тагын. Бертөрлерәк курсант тормышы башланып китте. Минем белән утыз алтынчы авиамәктәпкә эләккән Казан егетләре байтак иде, күпчелек—татарлар. Никтер, татар милләтеннән булганнарны тигез санда бүлеп, төрле төркемнәргә тараттылар. Урысча ярыйсы ук сукаласак та, дәреслекләрдәге терминнарны аңлау авыр булганга, уку программасына төшенү җинел түгел иде. Берсендә, әле укулар яңа башланганда, минем белән мәзәккә охшаш хәл дә булып алды. Взвод командиры—лейтенант—һәр курсант белән аерым сөйләшеп бланк тутырганда, чират мина житкәч:

—Фамилиян?—дип беренче соравын бирде. Мин:

—Хәлилов,—дигәч, анысын теркәп куйды да, исемен ничек диде. Урысча ул: Как зовут була бит» Мин:

—Хак,—зовут,—дип җавапладым. Лейтенантнын ачуы килде бугай. Бу юлы катырак итеп:

—Я тебя спрашиваю: как зовут?—дип кычкырды.

Мин «нишләп бу лейтенант әйткәнне бер дә аңламый икән?»—дип сәерсендем.

—Хак, зовут,—дидем тавышыма тимер чыны кертеп.

Лейтенантнын күзләрендә ачу чаткылары биеште. Ул кулындагы каләмен өстәлгә атып бәрде дә:

—Вон, вон отсюда!—дип җикеренде.

Тәмам аптырашка калып, бүлмәдән чыгып китәргә ашыктым. «Нигә шулай килеп чыкты соң әле?»—дип уйладым үз гамәлләремдә офицернын ачуын китерерлек берни дә тапмыйча. Уйлана торгач, башыма барып житте: лейтенант үзен үчекли, әйткәнне попугай шикелле кабатлый, дип уйлагандыр. Тизрәк кабинетка кереп взвод командирына:

—Мине чыннан да Хак зовут,—дип аңлаттым, ул менә болайрак языла дип, хәрефләп тә язып күрсәттем. Эшнең асылына төшенгәч, икебез дә шаркылдап көлеп җибәрдек. Шул хәлдән сон төркемдәге иптәшләр уку курсы тәмамланганчы мине еш кына: «Как зовут—Хак зовут», дип үчекләп йөрттеләр.

Мәктәптә укулар көннән-көн катлауланды. Бигрәк тә радиостанциянең принципаль схемасына һәм морзе әлифбасы буенча сигналларны кабул итү—җибәрүгә бәйле нечкәлекләргә төшенү авыр иде. Тырыша торгач, бусына да күнектек. Язга кергәч, самолетта һавага менеп, практик күнекмәләр үткәрергә кереште. Анда инде эскадрильядагы очкычлар арасында гына түгел, бер үк вакытта җирдәге команда пункты белән дә элемтәне тәэмин итүгә, мишеньгә атып тидерергә дә кирәк булды. Атнасына бер каравыл ротасында кизүлек итү дә безнен өстә.

Уку, практика, спорт белән шөгыльләнү—график буенча көн шуларга бүленгән. Көннәрне атналар, атналарны айлар алыштыра. Мәхмүзәдән, яки Тәскиядән хат килсә, ялыктыргыч бертөрлелеккә башка төсмер кертеп җибәрә. Мин әле кызларның кайсына өстенлек бирүемне анык кына аңлап бетермәсәм дә, атналар буена кош тоткандай сөенеп йөрим. Күңел күтәренкелеге авырлыкларны җиңел кичерергә ярдәм итә.

Җир өстендә карлар эреп, яшеллек борын төрткәч, төркемнәрдә укыту-өйрәтүләрне бик нык ашыктыра башладылар. Безгә ел ярымлык укыту программасын сигез ай ярымда үзләштерүне максат итеп куйдылар. Самолетларны ангарлар-

дан чыгарып, урман кырыйларындагы җәйге тору урыннарына тезеләр. Таң яктысыннан төн караңгылыгына кадәр вакыт, ашханәдә туклану һәм төшке бер сәгатьлек ялны санамаганда, өйрәнүләрдә үтте. Унбишенче июнь көнне дәүләт комиссиясе чыгарылыш имтиханнары кабул итте. Курсантларга сержант дәрәҗәсе бирелеп, укчы-радист таныклыклары өләшенде.

Хәрби башлыклар да адәм баласының мөмкинлеге чикле булуын аңлый. Шуларны күздә тотып булса кирәк, авиамәктәпнен чыгарылыш курсантларына ике атналык ял бирделәр. Төркемнәр өчен табигатьнен хозур җирендә, урман буендагы чирәмлектә, палаткалар корылган. Янәшәдә генә салмак сулы елга ага, елга буенда комлык. Рәхим итеп су коен да, комлыгында сузылып ятып, кояш астында кызына бир. Тик мондый рәхәтлекләр озакка бармады: 22 июнь таңында гадәти булмаган тревога безне палаткалардан йөгереп чыгарга мәҗбүр итте.

—Нәрсә булды?—дип, бер-беребезгә сораулар яудырабыз, тик беркем бернәрсә белми. Сафларга тезелергә команда яңгырады. Взвод командирлары һәр төркем алдында бер-ике адым алгарак басып, үрә каткан. Рота командиры палаткасыннан чыгып туры безнең сафларга юнәлде. «Смирно!» әмере яңгырады. Капитанның чырае гадәттәгедән житдирәк тоела, борчылуы йөзенә чыккан. Ул төркем житәкчеләре—лейтенантларның рапорт бирүләрен дә тыңлап тормады, сафлар каршына басып нык тавыш белән сүз башлады:

—Бүген, иртәнге сәгать дүрттә фашист илбасарлары илебезнең көнбатыш чикләренә бәреп керде. Шәһәр һәм авылларыбызны бомбага тоталар, үзләренә каршы корал тотып сугышкан гаскәрләрне генә түгел, карт-карчыкларны, хатын-кыз һәм бала-чагаларны да үтерәләр, кайберәүләрне коллыкка алып китәләр, байлыкларны талыйлар. Без бу ерткычлыкларга чик куярга, дошманны илебез территориясеннән куып чыгарып, үз өнендә тукмарга тиешбез. Ә хәзер ашыгыч рәвештә казармаларыбызга кайту сорала...

Авиамәктәптә паникага охшашрак хәл туган иде. Төш турында Пензадан яна курсантлар төялгән эшелон килеп төште. Аларны аерым казармаларга урнаштырдылар. Аэродромдагы очкычларны саклау максатында төрле урыннарда пулеметлар белән коралландырылган ут нокталары булдырдылар. Ашханәдән ике йөз-ике йөз илле адымнар ераклыктагы шундый бер ноктага якташым Хәбир Сәлимуллин белән мин туры килдем. Аэродромда СБ тибындагы самолетлар иде. Аларның кайберләре командование карары белән туры фронтка озатыла, алар урынына башка аэродромнардан икенче очкычлар төшеп куна. Алары да озак тоткарланмый—очып китә.

Сугыш башланганның икенче көнендә көньяктан яна төркем самолетлар очып килгәне күренде. Алар инде түбәндә, шассиларын чыгарганнар. «Үзебезнекеләр», дип җиңел сулап куйдык. Болар—СБлар иде. Эскадрилья аэродром өстендә берничә төркемгә аерылды. Үз күзләребезгә үзебез ышанмадык: беренче очкычтан бомбалар аерылып аэродромдагы машиналар өстенә очты, аннары—икенчесеннән. Бомбалар шартлый, җирдәге самолетлар яна. Берничә һава лайнеры үлем йөкләрен әле кичә генә китерелгән Пенза курсантлары яши торган казармаларга ташлаган иде. Шактый өлеше җимерелгән бина астында калып, һәлак булучылар, яраланучылар аз түгелдер—ул тарафтан ачыргаланып кычкырган авазлар ишетелә, кемнәрнеңдер урам якка йөгереп чыкканы күренә. Совет самолетларын кулларына төшергән фашистлар берничә минут эчендә аэродромдагы берничә СБны, җанлы көчләрне юк итеп, китеп тә барды. Бу шулкадәр көтмәгәндә эшләнде ки, без исебезгә дә килергә өлгермичә калдык. Мәкерле дошман белән, үлем белән күзгә-күз очрашу шулай башланды...

Арыганлык үзенекен итте—хәтер төпкелендә иң соңгы булып сугышның беренче көн вакыйгалары чагылып үтте дә, мин чынбарлыктан аерылып, йокы дигән серле дөньяның илаһи кочагына чумдым.

## Унбишенче март

Иртә белән уянганда камерада өченче кеше юк иде. Ул очучы-штурманны кайчан һәм кая алып чыгып киткәннәрдер, мин сизми калдым. Янәшәмдәге танкист лейтенант та һични әйтә алмады. Танкист белән кичтән калган баланданы чөмердек. Ишек ачылды, безне алырга керүләреме? Алай түгел икән, лейтенант Плюхинны керткәннәр. Җинелрәк булып китте. Арканы аркага терәп утырып, соңгы көн вакыйгалары, үткәндәгеләр турында сөйләштек. Запас аэродромда торган чакларда ничек итеп күрше авылдагы кызлар янына кич утырырга йөрүләрне, кызларның бездән бик авырлык белән аерылуларын искә төшердек. Күпме генә сөйләшсәк тә, ахыр чиктә сүз барыбер бүгенге хәлебезгә әйләнеп кайта, билгесезлек йөрәкне сызландыра иде. «Өметсез шайтан гына», диләр, әмма фашист әсирлегендә ятканда, исән калырга өметләнү камил акыллы кеше өчен чынга ашмастай хыял, фантазия җимеше. Фашистларның Көнчыгыш Пруссия группировкасы тар-мар ителүгә күп калмады һәм алар үзләре беткәндә бернәрсә алдында да туктап калмаячаклар. Әгәр могҗиза туса гына инде.

Бу көнне безне эшкә алып чыкмадылар. Әллә инде элеккерәк елларда әсирлеккә төшкән солдатлар белән аралашып, аларга фронттагы соңгы яңалыклар турында җиткерерләр дип курыктылар, әллә башка сәбәбе бар иде. Ярымкараңгы камераның тынчу һавасын иснәп яту да туйдыра, тик бернишләр хәл юк. Үтереп тартасы килә. Төпчек чүпләгәндә җилкә тамырына мылтык түтәсе белән берне тондырсалар да, анысына гына түзәсең. Тилмереп, урамга чыгаруларын көтсәк тә, өметебез акланмады, бу көнне безне камерада гына калдырдылар. Төнлә кабат күзгә тиз генә йокы кермәде. Мин кабат хатирәләргә бирелдем.

## Сугышчан авиаполкта

Июльнең бишләрендә чыгарылыш төркемендәге Запорожьедагы авиаполкка җибәрделәр. Мондагы сугышчан полкларда СБ маркалы очкычлар түгел, ә ТБ-3ләр иде. Аларның кайбер параметрлар буенча аерымлыклары булса да, идарә итү системасында охшашлыклары күп. Август урталарына кадәр бу төр самолетларда очу һәм сугышу күнекмәләре алдык.

1941 елның 18 августы. Табигать үзенең җете яшеллеген югалтып, көз сагышына өртелә башлаган. Агач яфраклары, җирдәге үләннәр сизелер-сизелмәс сарылыкка манылып, салмак җилдә «эх, үтте шул ямьле җәй айлары», дигән шикелле әкрен генә лепердәшә. Бүген минем дә гомеремдә беренче мәртәбә сугышчан йөкләмә алып, дошман тылына оча торган көн. Күңелдә тирән дулкынлану, башта уйлар өермәсе. Кайбер иптәшләрнең берничәшәр очу практикасы бар. Алардан сорашу бер нәрсә, ә үзенә дошман белән йөзгә-йөз килү бөтенләй башка. Һавада иң хәлиткеч мизгелдә каушап, югалып калмаммы, кирәк чагында очкыч пушкасыннан ут ачып өлгерерменме? Минутлар түгел, секундлар хәл итә язмышны.

Экипажның башка әгъзалары белән инде таныш идем. Сугышның беренче көннәреннән үк дошман объектларын, эшелоннарын бомбага тотуда катнашкан, тәҗрибәле экипаж командиры да, штурман да беренче күрүдә үк миндә унай тәэсир калдырды. Хәер, башкача була да алмыйдыр. Экипажда җылылык атмосферасы туып, бер-береңне бер ым, бер хәрәкәт, күз карашыннан аңлау мөһим. Киресенчә булса, бәхетсезлеккә тарыйсыңны көт тә тор. Алар бер анадан туган игезәкләр кебек булырга тиеш. Хәтта якынрак та. Һавада командир сүзе закон, штурман да, радист һәм укчы да аңа берсүзсез буйсына, кирәк чакта тиешле карар да кабул итеп өлгерсә, уңыш киләчәк.

Радист белән мин—«яңалар»—командирның очар алдыннан соңгы киңәшләрен тыңлый-тыңлый, аэродромдагы безгә билгеләнгән самолетка таба атлыйбыз. Килеп җитәргә берничә адымнар кала экипажны техник каршы алды. Командир

каршына басып очкычның һавага күтәрелергә әзер булуы турында рапорт бирде. Һәрберебезнең кулын кысып, унышлар теләгәннән соң, лейтенант артыннан ияреп кабинага менде, штурман да аларга иярде. Экипаж командиры белән штурман җайлап урнашкач, радист белән миңа чират җитте. Без дә урыннарыбызга менеп утырыштык. Мин пушка һәм пулемет установкаларының торышын тикшердем. Аларны канәгатьләнерлек дип таптым. Күз кырыем белән радистка карыйм, ул элемтә приборлары белән мәш килә. Күрәсең, үз «хуҗалыгыннан» канәгать—җинел сулап кулы белән мангаендагы тирен сөртте.

Техник кабинадан чыгып түбәнгә төшүгә, баскычны алдылар. Самолет моторлары эшли башлады. Пропеллер әйләнүе тизләнгәннән тизләнеп, ул инде тоташ түгәрәк хасил итеп бөтерелә. Әллә ничә очкычтан чыккан тавыш колак тондыргыч гүелдәүгә әверелде. Башлап эскадрилья командирының самолеты стартка чыкты, аның артыннан башкалары. «Өчлек» звенолар бер-бер артлы старт мәйданы буенча йөгереп китәләр дә, билгеле тизлеккә җиткәч, җирдән аерылалар. Без дә шул ук хәрәкәтне кабатладык. Очкычыбыз инде һавада.

## Беренче сугышчан очыш

Эскадрильяда тугыз очкыч. Һәр «тугызлык» һавада үз урынын белә. Биеклекне күрсәтүче стрелка «икеле» цифр өстендә. Димәк, без җир өстеннән ике мең метр биеклектә очабыз. Сәгатькә күз салам: вакыт ун тулып унберенчене күрсәтә. Аста урманнар, болыннар җәелеп киткән; авыллар, шәһәрләр күзгә чалына. Бу күренешләрне манзара кылу башта күнелле тоелса да, соңрак кызыгы бетте. Дошман тылына очабыз шул, күңелдә тынычлык булмагач, матурлык күзгә күренми.

Штурман:—Дошман линиясенә якынлашабыз,—дип белгертте. Ул да түгел, тигез сафлар арасында зәңгәрсу-кара бүрекләр пәйда булды, шартлау тавышлары ишетелде. Түбәндә немец зениткалары ут ачкан иде. Бусы инде җитдирәк, һәр мизгелдә дошман снаряды машинага эләгергә, якты дөнья белән хушлашырга мөмкин. Ин яхшы дигәндә дә парашют белән сикерергә туры киләчәк, әле анда исән каласыңмы-юкмы, анысын бер Ходай белә. Кайбер снарядлар очкычыбыз янәшәсендә үк ярыла. Андый чакта дары исе кабинага үтеп керә. Бераз алдарак очучы эскадрильяның бер самолетына снаряд тиде. Ул ялкынга уралып, түбәнгә омтылды, артыннан кара төтен эзе сузылды. Без машинаның түбәнгә төшеп шартлавын да, экипажның сикерүен дә күрмәдек, чөнки бу урынны инде очып үткән идек.

Түбәндә тимер юл станциясе. Ул танклар, туплар, автомобильләр һәм башка сугыш кирәк-ярагы шыплап төялгән эшелоннар белән тулы, читтәрәк цистерналарына ягулык тутырылган состав сузылган. Немецның бөтен фронтлар буенча һөҗүмгә күчеп, ашкынулы алга барган айлары. Ул җирдә генә түгел, күктә дә хакимлек итә. Әнә ич, радист элемтә буенча югарыда дошман истребительләре күренүен белгертә:

—Бездән өстә фашист «мессерлары» пәйда булды, әзер торыйк.

Фриц хәйләкәр, үзләренең зениткалары атканда, снарядлары зыян китермәслек биеклеккә менә, алар туктау белән совет бомбардировщикларына һөҗүмгә ташлана. Йөрәк уч төбендә, гәүдә шабыр тиргә баткан. Әлеге мәхшәрдән исән килеш чыга алырбызмы? Чигәмдәге кан тамыры шулай дип тукылдый. Алдагы эскадрильялар түбәнрәк төшеп станцияне бомбага тотарга керешә, каршы як истребительләре аларга ташланды. Ике арада һава сугышы кабынып китте. И-их, кая соң бомбардировщикларны озатырга тиешле истребительләр? Юк шул алар. Аста ягулык тутырылган цистерналар яна, танклар, машиналар өстендә ялкын телләре биешә. Безнең берничә бомбардировщик та бәреп төшерелгән. Бу вакыт станция өстеннән очып әйләнеп, кабат объектка якынлашабыз. Наушникта командир тавышы:

—Түбәнәябез, бомбаларны ыргытырга әзерләнегез!

ТБ-3Фебез пикегә керде, бомба люклары ачылды, үлем йөге аска коелды. Машинабыз җиниләеп калып өскә омтылды. Шулчак фашист стервятнигының пулеметыннан ут ачып безгә ябырылуын күрдем, унайлы мизгелне ычкындырмаска кирәк иде—мин дә гашеткага бастым. Командирның һава машинасы белән бик оста идарә итүе коткарып калды, ул очкычны дошман ядрәләре артык зыян китерә алмаслык ягы белән куеп өлгерде. Берничә пуля шулай да кабинаны тишеп кергән иде, штурман җиңелчә яраланган. Ә мин фрицка атып тидерә алмадым бугай. Сонарып булса да безнең истребительләрнең ярдәмгә килүе күренде. Алар дошман ягы белән һава сугышы башлап җибәрде. Берничә очкычын югалткан авиаполкыбыз сугышчан йөкләмәсен үтәп, аэродромга әйләнеп кайтты. Мин нык арыган булсам да, самолетыбыз төшеп утырганнан соң да кабинаны ташларга ашыкмадым, дошманга каршылык күрсәтүдә төп ярдәмчебез—пушканы җентекләп тикшердем, киләсе бәрелешләр өчен әйбәтләп чистартып куйдым. Инде ял итәргә кайтырга да була. Казармага кайтуыма өстәл өстендә минем өчен әзерләнгән фронтовой йөз грамм тора, янында кабымлыгы да бар. Экипажның башка әгъзалары мине көткәннәр. Экипаж командиры кулларыбызны кысып:

—Молодцы, егетләр, сынатмадыгыз. Мондый команда белән дошманны кыйнарга була,—дип котлап, киләсе яуларда уңыш теләде. Стаканнар стаканнарга бәрелеп чекелдәде, зәһәр сыеклык бугазны яндырып үтте. Тынычланып, зур канәгатьлек кичергән хәлдә ятакларга сузылып яттык һәм тирән йокыга чумдык.

## Төнге очыш

Көндезге очулар бер нәрсә, ә төннәрен ерак дошман тылына үтеп, билгеләнгән объектларны бомбага тоту бөтенләй башка. Озак та үтми, безнең полкны төнлә очу серләренә өйрәтә башладылар.

Төнлә очу искиткеч катлаулы. Күзгә төн караңгылыгын сискәндереп, самолет куе болытлар арасыннан алга ашыга. Анда берни шәйләнми. Визуаль күзәтү мөмкинлегеннән мәхрүм шартларда һәр минут саен очкычның нинди биеклектә, кайсы курс буенча очуын билгеләргә, кайсы район өстендә икәнлегенне белергә кирәк. Фронт линиясеннән яки дошманның аеруча саклаучы объектлары өстеннән үткәндә күк йөзен тасмалар белән бүлгәләүче прожекторлар утына эләксәң, үзеңне тозакка эләккәндәй хис итәсең. Тенкәгә тиеп, күзне чагылдыручы прожектор эзәрлекләвеннән котылу шактый катлаулы, күп нәрсә һава карабының штурманы һәм командирының һөнәри осталыгыннан тора. Әлбәттә, дошман яктылык кайчыларын ялт-йолт уйнатып, ычкындырмаска тырыша, зениткаларыннан дәррәү ут ача. Очкычка снаряд эләгү ихтималы бик нык арта. Андый чакта болытлар булса, алар арасына качып котылу мөмкинлеге бар.

Көзге төннәрнең берсендә экипажыбыз ерак дошман тылына очып, мөһим объектын бомбага тотарга боерык алды. Берничә сәгать очканнан соң, кирәкле урынга җитеп, бомба удары ясадык. Әмма шулчак прожекторлар утына эләктек. Фашистлар котырынып зениткаларыннан атарга кереште. Бер снаряд самолет янәшәсендә үк ярылды. Штурманыбыз лейтенант Путник каушаудан ориентировканы югалтты. Шулай да куркыныч зонадан чыгу әмәлен тапты. Төнлә юнәлешне югалту хәтәр нәрсә, бөтенләй әллә кая килеп чыгуың бар. Үзебезнең аэродромнан күтәрелеп киткәнгә дә җиде сәгатьтән артык вакыт үткән, бензобаклардагы ягулыкның менә-менә бетәчәген искәртеп, прибор уклары биешә. Яшәү белән үлем арасында эленеп торган шундый бер вакытта штурман тигез болынлык табып, очкычны исән-имин шунда төшертә алды. Әле немецлар басып алган җирдәме, әллә фронт сызыгының бу ягындамы

икәнлекне белмәсәк тә, Путникка рәхмәтле идек. Чөнки без исән идек. Таң беленүгә үзебезнең якта булуыбызны күреп куандык. Тик частька кадәр ара ерак, экипаждан кемдер анда кайтып, хәлне аңлатырга һәм очкычка ягулык китертү чарасын күрергә тиеш. Рация сафтан чыкканлыктан, элемтәгә кереп булмый иде. Бу эшкә штурман белән радист егет алынды, мина экипаж командиры белән һава карабын саклап калырга туры килде. Ярый әле һәр экипажга сугышчан йөкләмәгә очар алдыннан биш көнлек коры паек бирелә, бу паек аэродромга әйләнеп кайтканчы тукланып торырга таман гына булды. Безне полкта инде һәлак булганга санаганнар, штурман белән радист, юлда туры килгән машиналарга утырып, кайда җәяүләп, штабка кайтып кергәч, башта ышанмаганнар, аннары тизрәк полуторка әрҗәсенә бензинлы мичкәләр төяп, ярдәм җибәрү ягын караганнар.

Самолет белән исән-имин аэродромга төшеп утыргач, безне каршыларга эскадрилья командиры үзе килде.

—Тагын берничә көн күренми торсагыз, хәбәрсез югалганнар исемлегенә кертә идек. Болай булгач озак яшәрсез, бөркетләр,—дип сөйләнде капитан житкән сакал-мыеклы битләребездән үбеп. Аның күзе дымланган иде...

## Унҗиденче март

Иртән торуга, җир һәм дингез өстен куе томан каплаган иде. Тозлы, аксыл төстәге җылымса баланда керттеләр. Бер кешегә җитмешәр грамм икмәк өләштеләр. Немец бушка ашатып яткырмый, барлы-юклы азыкны йотып та бетермәгән идек, урамга эшкә куаладылар. Урамдагы күренеш тетрәндергеч иде. Моннан ике көн элек кенә зур матур йортлар, ангарлар торган урында ватык кирпеч өемнәре генә калган, кан катыш әче төтен исе борыннарны ярып керә. Безне бу урамда туктатмыйча икенче урамга алып чыктылар. Анысында сирәк кенә җимерелмичә калган биналар күзгә ташлана, яртылаш җимерелгәннәре шактый. Шундый йортларның берсе янында «һальт!» дигән аваз яңгырады. Туктарга кушулары. Тәрҗемәче килеп нәрсә эшләргә кирәклекне аңлатты. Ватылган, чәчелеп яткан кирпечләрне урамның каршы ягына ташырга тиеш икәнбез. Кайбер урыннарда һаман төтен пыскып утыра. Дингез култыгының аргы ягындагы еракка ата торган безнең туп эше икән. Эре калибрлы снаряд тиюдән бинаның яртысы ишелеп төшкән. Монда фрицларның штаблары булырга охшаган. Актарган саен төрле кәгазьләр күбрәк чыга. Немецлар аларны берәмтекләп җыялар, һәрберсен тикшереп, кирәк булмаганнарын ыргыталар. Кирпеч ватыклары арасыннан язу машинкалары да чыккалый, кайберләре черт тә итмәгән. Күрәсең, снаряд тигәндә эш вакытының иң кызган чагы булгандыр. Җимерекләргә басылып калган фашист мәетләренә тап булабыз, аларны сөйрәп чыгарып бер читкә ташыйбыз. Менә полковник дәрәҗәсендәге бер хәрбине табып алдык, аны да башка үлекләр янына илткәч, хәрабәләр чистартуны туктаттылар. Кабат төрмә ролен үтәүче бинага кайтырга әмер булды. Иң күңелгә тигәне бер генә төпчек тә табылмау иде. Ачлыкка да түзәргә күнеккәнбез, ә менә тартасы килүгә чама юк.

Ишекләрне ачканчы камераларга кертми тордылар. Мин Бобров, Бондаренколар белән сүзгә мавыгып, керергә команда бирелгәнне ишетми калганмын. Комендантның әче тавышы борылып карарга мәҗбүр итте. Коридор буенча бире таба ашыккан комендант таягын селти-селти ямьсез итеп сүгенә иде. Мин аның артыннан үткәндә кулындагы карама таяк ике тапкыр җилкә тамырына менеп төшәргә өлгерде. Ишектән керүчеләргә иллешәр грамм икмәк белән бер стакан баланда тоттыралар икән. Тик мина баланда урынына таяк белән суктырылу гына тәтеде. Әсирләрнең эчке тәртип кагыйдәсен бозуы өчен шундый җәза каралган икән. Ярар, моннан соң белеп торырбыз. Болай да кечтеки паек-

тан мәхрүм кала башласаң, ачлыктан җан тәслим кылу да ерак түгел. Шартлар начар булса да, яшәү барыбер тансык иде.

Төштән соң томан күтәрелүгә Кызыл Армия артиллериясе телгә килде, күктә бомбардировщиклар пәйда булды. Кабат аллагы көннәр мәхшәре башланды. Кичке якта снарядларның берсе без ябып тотылган бинаның уң канатына эләкте. Түшәмдәге штукатурлар шыбырдап идәнгә коелды. Снаряд эләккән якта ачыргаланып кычкырган авазлар ишетелгәндәй булды. Тик алар ничек кинәт ишетелсәләр, шулай кинәт тындылар да ярты сәгатьләр чамасы үтүгә тәрәзәдән ике немец солдатының Н.нчы полк командиры, подполковникны ике култыгыннан сөйрәп ярга таба алып киткәннәрен күреп калдык. Фрицлар һәлак булган совет офицерын яр кырыендагы чокырга ыргыттылар. Подполковникның гауптвахтадагы ин кырый номерда ялгызы гына тотылуын белә идек. Димәк, снаряд анда эләккән. Әкренләп бу йортны да җимерә башладылар. Болай булса, чират безгә дә житмәгәе. Күнелгә кергән шомнан ярты төнгә кадәр йокларга ятмыйча утырдык.

Коридорда тавышлар ишетелде. Ишектәге кечкенә тишек аша дүрт әсирне алып кергәннәре күренде. Биш-алты көн эчендә фронтта зур үзгәрешләр булгандыр. Безнекеләр кайсы тирәдә икән, беләсе иде. Төнге уникеләрдә бәдрәфкә чыгардылар. Шул чагында яна китерелгәннәр белән аралаштык. Очучылар күрше дүрт йөз кырык бишенче полкныкылар булып чыкты. Алар безнекеләрнең бөтен фронт буенча һөҗүмгә күчүләрен, көннән-көн Кенигсберг тирәсендәге боҗраның кысыла баруын әйттеләр. Көнчыгыш Пруссия башкаласының алынуына күп калмаган инде. Шушы ике-өч атна эчендә, әгәр гитлерчылар юк итмәсә, әсирләрнең дә исән калу-калмавы хәл ителә. Чөнки туктаусыз барган арт һәм авиаударлардан исән калу шулай ук икеле. Совет гаскәрләре Пилауга да бомба, снарядларны янгыр урынына яудыралар.

Камерага кертеп япкач та тиз генә тынычлана алмадык. Башка төрле уйлар килә. Ничек кенә булса да исән каласы иде. Күпләребез өчен тормыш яна башлана гына, арада кызлар кулы тотып карамаган егетләр дә бар...

## Дягилево аэродромы

Самолет белән югалып торганнан соң күп тә үтмәде, безнең сигез йөз кырыгынчы авиаполкны Сталинград юнәлешендәге Дягилево аэродромына күчерү турында фронт командующиенең әмере булды. Тик бу вакытта тоташ янгырлар башлану сәбәпле, әлеге боерык тиз генә үтәлмәде. Беренче кырпак кар төшеп, җир өстен каты боз элпәсе каплап алгач кына андый җай чыкты. Звенолар бербер артлы эскадрильялар, ә эскадрильялар полк хасил итеп күккә күтәрелдек тә, һаваны иңләп Рязань ягына очтык. Бөтен полк, ә кайчагында дивизия белән бергә очу тәэсирләндерә торган күренеш. Күнелдә үзен хезмәт итә торган хәрби берләшмә, туган илең өчен горурлану хисләре туа, дошманга нәфрәт хисләре арта. Йөзләгән самолетның тиешле дистанция саклап, җепкә тезгән шикелле тигез очулары җирдән күзәткәндә, бәлки, тагы да тәэсирлерәктер.

Авиашәһәрчектән бер чакрымнарда гына Дягилево дигән авыл бар. Аэродром да шул исемне йөртә икән. Монда күчкәч, безнең экипаж өчен бик тә күнелсез хәл булып алды. Командир белән штурман рөхсәтсез авылга киткәннәр иде. Шулчак эскадрильябызга сугышчан йөкләмә житкерелде. Радист белән икәү генә булганга, очкычыбыз һавага күтәрелә алмады. Тикшерү китте. Полк особистлары килеп, «югалган» экипаж әгъзаларын Дягилево авылы кызлары янынннан табып алып кайттылар. Сугыш вакыты законнары коры шул: командирны да, штурманны да судсыз-нисез генә штрафбатальонга озаттылар. Көтмәгәндә радист та авырый башлады. Шулай итеп, бер гаилә булып укмашкан экипаждан ялгызым гына торып калдым. Күпләр көн саен эскадрильялары белән фронтка якынрак аэродромнарга күтәрелеп очканда, минем өчен бер дә күнелле хәл түгел иде бу.

Полк яна килгәннәр белән тулылана торды. Арада сугышчан тәҗрибәм зур, яшем ягыннан да өлкәнрәк булганга, мине укчы-радистлар арасында старшина итеп билгеләделәр.

Бертөрлерәк казарма тормышы башланды. Старшина күбрәк частьтәге хуҗалык эшләре өчен җаваплы, ә бу нәрсә минем күңелгә ятмый. Ярый әле монда калганнарны төнлә еракка очып бомбага тотучы һава дивизиясенә өйрәнүләргә күчерү турында әмер алынды. Баш күккә тиде. Тизрәк китәсе иде.

Килде ул көн. Полк аэродромы Григорьев дигән авыл янында урнашкан. Көннәр өйрәнеп үтә. Кичләрен сафка тезеп кинофильмнар карарга алып баралар. Беркөнне клубта Соня исемле кыз белән таныштым. Сары чәчле, оялчан гына. Күңелгә хуш килешле. Моңа кадәр марҗа кызлары белән йөргәнем юк иде, жае чыкканда аны өенә кадәр озатып куя башладым. Табигатьтә кыш айлары үтеп, ямьле язга кергән чак. Өстә гимнастерка гына. Соня да җинелчә кофта, юка күлмәктән. Капка төбендә гөнаһсыз үбешүләр. Тәннең тәнгә тиеп кызышуын тою рәхәт иде, тик бер-беребезгә тартылуда үбешүдән артыгына керешмәдек. Мин яшь кыз баланы рәнҗетүдән курка идем, ул, бәлки, күңелендә булып та, теләген белдерергә кыймагандыр.

Ока елгасы очучылар казармасыннан ерак түгел. Төшке ял сәгатьләрендә күнелле гөрелдәшеп шунда су коеныргa китәбез. Төннәрен кайчагында аерым эскадрильяларга дошман тылына үтеп, разведка ачыклаган объектларны бомбага тотарга дигән боерык алына. Мина да яна экипаж составында берничә шундый операциядә катнашырга туры килде.

## Лазаретта

Кырык икенче елның егерменче июнендә полкка кабат Дягилево аэродромына кайтырга кушылды. Мин автомашинага утырып штаб җиһазларын озата барырга тиеш булып чыктым. Мәскәү—Рязань шоссесы. Күктә бер болыт әсәре юк, кояш кыздыра. Юлның ике ягында иген басулары җәелеп киткән. Тулышкан арыш башаклары башларын иеп моңсу гына озатып калалар. Иген кырларын хәтфә болыннар алыштыра. Яшеллектә күзгә кебек ялтырап яткан күлләр чагылып кала. Зур һәм кечкенә елгалардагы күперләр аша чыкканда да машинаның тизлеге салмаклана. Андый чакта каршыга искән тыгыз җил дә йомшарып, битләрдән назлап иркәли. Юлда очраган авыллар, шәһәрләр аша бара торгач, ниһаять, алда безгә кирәкле торак пункт күренде. Бу авыл район үзәге санала. Анда икешәр-өчәр-дүртәр катлы биналар да бар. Әнә, котельныйның морҗасы озын муенын күккә сузган. Электән таныш булгангамы, туган авылым Түбән Барыш кебек якын тоелды Дягилево мина. Машина аның төп урамыннан тузан туздырып узганнан соң, авиашәһәрчеккә юл алды. Шулчак бөтенләй көтелмәгән хәл минем һәм тагын берничә сержантның язмышын үзгәртеп ташлады. Хәер, тормыш очраклыклардан торадыр инде ул. Эш менә болай булды. Инде штабка да ерак калмаган. Машина туп-туры шунда җилдерә. Тик казармаларга борылган юл чатына килеп житкәч, шофер янәшәсендә утырган эскадрилья адъютанты кинәт машина йөртүченең кулына ябыша.

—Уңга борыл,—дип әмер бирә. Каушап калган шофер тизлеген киметмичә адъютант әйткән якка борыла. Мин машина әрҗәсенең уң борт кырына ук баскан идем, тотынырга өлгермәдем, баштүбән җиргә очтым. Минем арттан тагын берничә сугышчы мәтәлде. Берни аңламыйча җирдә аунап ятабыз. Берәмләп хәрәкәткә киләдек. Мин җалт кенә аягыма басарга теләп, торырга талпындым. Тик торып баскач туры кала алмадым, ток суккандай авырту сыгылып төшәргә мәҗбүр итте. Башкалар белән дә шуңа охшаш хәл иде: кайсының аягы, кайсысының кабыргасы имгәнгән. Адъютант белән шоферның алдан килешеп эшләмәүләре әнә нәрсәгә китерде. Ел буе диярлек күктә очып, дошман самолетлары

белән сугыштан, зенитка снарядларыннан исән калып та, бернинди атышсыз тылда үзебезнекеләр илтифатсызлыгы аркасында күпмедер вакытка сафтан чыгу гарьлек, билгеле. Тик нишлисең, лазаретка ятарга туры килде. Беренче ярдәм күрсәтеп, тез капкачын кысып бәйләрләр дә җибәрерләр дип уйлаган идем. Алай булып чыкмады. Кечкә таба бот сөяге дә авыртырга кереште, баш белән нык бәрелгәнмен—ул да шешеп, сызлый башлады. Медсанчастьның баш табибы миңа катгый рәвештә ятып кына торырга кушты. Шулай итеп, яңа гына бер гаилә булып оешкан экипаж члennарыннан, юньләп оча да алмыйча, аерылырга туры килде. Мин ай буе диярлек лазарет койкасында аунарга мәҗбүр булдым...

## Унсигезенче март

Бүген иртә таңнан вак яңгыр сибәли. Тирә-юньдә шылт иткән тавыш юк. Самолетлар оча алмый, еракка ата торган артиллерия дә тынып калган. Әйтерсең әле кичә генә һава дивизияләре диңгез өстен, яр буендагы кала ныгытмаларын һәм хәрби объектларны бомбага тотмаган, йортлар өстендә снарядлар шартламаган. Үле тынлык. Коридорда ара-тирә йөреп үткән надзирательләрнең аяк тавышларыннан башка берни юк. Без бер камерада өч әсир. Көн саен бомбалар шартлауга күнеккәч, тынлыкка ияләнүе дә авыр икән. Хәтта сәеррәк тоела. Үзара сөйләшәсе дә килми. Һәрберебез авыр уйларга чумып эчкә йотылган. Кемдер туган җирен исенә төшерә торгандыр, сугышка кадәр эшләп йөргән чакларын күз алдына китерә; кемдер әти-әнисен, йә булмаса сөйгән кызын сагынып уфтанадыр. Гел уйланып утыру да алҗыта икән, баш миләре сызлагандай кебек тоела башлый. Мин, балачага шикелле, үземә шөгыль таптым, «иректән» бер кечкенә чыбык кисәге табып кергән идем, шуның белән камерадагы мич учагының әллә кайчангы көлен актара башладым. Актара-актара төпкә кадәр төшеп җиткәндә тәмәке төпчеге килеп чыкмасынмы! Иптәшләр дә уңышымны күреп алды, «мәрткә»кә китеп утырган җирләреннән җанланып, янәшәмә килеп чүмәштеләр. Көл арасыннан тагын байлык чыкмасмы дип инде бер пар гына түгел, өч пар күз түземсезләнеп күзәтә. Чыкты тәки, көл арасыннан янә өч тәмәке төпчеге табылды. Менә шатлык! Беребезнең кесәсендә сакланган кульъяулыкка зур саклык белән төпчекләрдәге тәмәке бөртекләрен тараттык. Аны өч өлешкә бүлеп, берсен озын нечкә итеп кәгазьгә төрдек. Аның белән генә эш бетмәде, янган шырпы бөртегенең корымлы башы белән төрелгән тәмәкегә билгеләр салдык. Бусы, чират буенча тартканда, кая кадәр суырырга икәнлекне белер өчен. Кадерле табылдыкның табучысы мин булганга, камерадашларым башлап бәхетле мизгелләр татуны миңа бүләк итте. Кадерле секундларның тәмен мөмкин кадәр озаккарак сузарга тырышып, сагындырган әче төтенне никотин сорап ярсыган үпкә күзәнәкләренә тутырам, аларны бронхларда озаграк, һаман озаграк тотасы килә, инде сулыш органнары тончыга башлый, ютәл буып ала. Юк, төтен алай гына таралмасын әле: ике борыннан зәңгәрләнеп чыккан зәһәр исне кабат авызым белән йотарга тырышам. Тәмәке пыскып яна, корым белән билгеләнгән минем өлеш һаман кечерәя шул.

—Житте, үзеңә тиешлесен тартып бетердең!—дип беравыздан кычкыра иптәшләрем. Беткәнен алар әйтмәсә дә күрәм. Үтереп тартасы килү алай гына басылмады, иптәшләрнең бәхетле мизгел кичерүен карап өтәләнмәс өчен тәрәзә кырына ук китеп бастым...

## Старшина вазифасы

Мина лазареттан савыгып чыккач та озак вакытлар сугышчан йөкләмәләргә очарга рөхсәт итмәделәр. Эскадрилья комиссары капитан Коган үз янына чакыртып:

—Старшина Трофимовка кайбер хуҗалык эшләрендә булышырсың!—дип боерды.

Минем вазифага сугышчыларны строй белән ашханәгә алып бару, алып кай-

ту; мунча көннәрендә аларның мунча керүен контрольдә тоту; килгән хатларны, газеталарны тиешле адресатларына тарату керә. Буш вакытым күп булганлыктан, еш кына ашханәдә савыт-саба юучы Маруся исемле кыз янына кереп утырам. Озак вакыт күренмәсәм, ул үзе каптеркага кереп хәлемне белешә.

Старшина Трофимов чирләп киткәч, аның бөтен вазифалары мина өелеп калды. Старшинаның эше читтән карап торганда гына күренми икән, ә эченә керсән, тавык та чүпләп бетермәслек.

Мен тугыз йөз кырык өченче елның 21 июлендә полк башка аэродромга күчәргә боерык алды. Тик мина әле һаман да элекке урында калырга туры килә, өч ел буе эскадрилья белән база арасында юньләп бернинди кәгазь-хисап эшчәнлеге алып барылмаган, одеял, простыня, тагын әллә нәрсәләр—үлгәннеке дә, исәннеке дә җыелып килгән. Искесе гамәлдән чыгарылмаган, янасы теркәлмәгән. Бу хәл инде өч ел дәвам итә икән. Һәм менә хәзер барысы өчен мина җавап тотарга туры килү ихтималы эчне пошырды. Бәхеткә күрә, әллә минем гаеп юклыкны аңлап, әйберләрне тапшырганда артык вакланмадылар. Егерме өченче июльгә аэродромда лейтенант Межевов экипажыннан башка полктан бер очкыч та калмады. Межевов самолетының кайбер җирләренә ремонт кирәк икән. Экипаж әгъзалары техниклар белән көнозын аның янында мәш килә, кичләрен алар белән казармада гәп куертам. Көндез штабка йөри идем, анда мин хезмәт күрсәткән эскадрилья өчен яңа аттестатлар тутыралар. Кирәкле кәгазьләр әзер булу белән мин аларны алырга тиеш.

Берсендә Межевов экипажының радисты һәм укчысына ияреп Хирин дигән авылга киттем. Үзебезчә, кызлар урамга чыкса, алар белән күнел ачарга исәп. Барып җитүебезгә һава тревогасы башланды. Кичке күнел ачарга чыккан кызлар өйләренә ашыкты, без дә, командирлар сизгәнче дип, казармаларга йөгердек. Моннан соң рөхсәтсез беркая бармаска булдым, янәшәдә Маруся бар ич, сөйләшеп утырырга ул да бик житкән.

Ниһаять, аттестатлар әзер. Инде Межевов экипажы да очып киткән иде, мина американнарның «Дуглас» дигән дүрт моторлы дәү генә пассажир самолетында очып барырга куштылар. Аның салоны иркен, ни әйтсән дә безнен бомбардировщиклар ише түгел, гражданский бит. Очкыч артык югарыга күтәрелмәде, дүрт моторын да гүелдәтеп күптән түгел генә сугыш булып узган кырлар, янган урманнар, җимерелгән авыл һәм шәһәрләр өстеннән очты. Самолетның өскә күтәрелүе кирәк тә түгел, чөнки дошманнан чистартылган районнарда аны зениткалар сагаламый. Аста елгалар, зур күлләр күзгә чалынып кала. Күл өстеннән узганда кинәт һава бушлыгына туры килеп, аска омтылган очкыч су дәрьясына чумар төсле. Икенче мизгелдә инде «Дуглас» өскә күтәрелә. Акрын хәрәкәтләнүче һава карабы шулай берничә сәгатьләр очканнан соң, тиешле урынга төшеп туктады.

## Җаваплы йөкләмә

Иртә беләнгә һава чалт иткән аяз, күктә ник бер болыт әсәре күренсен. Очучылар телендә мондый күренеш «летная погода», дип атала. Иртәнге аштан соң аэродромга киттек. Салкынча саф җил битләрне иркәли. Тик табигать хозурлыгы күзгә күренми, җанны алда торган гаять мөһим бурычны үтәп чыгу җаваплылыгы биләп алган. Һәркемнең чырае житди, үзара аралашканда иң кирәкле сүзләр тыенкы тавыш белән генә әйтелә.

КПдан чыгуга, һавага ак ракета аттылар. Бу—экипажларга очкычларында урын алырга кирәклекне аңлата. Эскадрилья командирының: «По машинам!» дигән боерыгы һаваны ярып үтте. Башка төркемнәрдә дә шундый ук хәл. Йөгереп барып һәркем үз урынына урнашуга күк йөзенә зәңгәр ракета чөелде. Ул әле югары ноктасына менеп, түбәнгә төшәргә өлгермәде, дисталәгән очкыч моторлары дәррәү кабынып, тирә-юньне тоташ гүелдәүгә, дөбердәүгә күмде. Өченче—кызыл ракета

һавада пәйда булуга «тимер кошлар» бер-бер артлы кузгалып старт мәйданчыгына чыга башлады. Инде полк буенча җаваплы кизүнең кулындагы флагчыклары хәрәкәткә килгәнне генә көтәсе калды. Ниһаять, кизү офицер ак флагын алга, ә кызылын аска юнәлтте. Очкычлар да тылсымлы кизәнүгә буйсынып старт полосасы буйлап йөгерә-йөгерә бер-бер артлы зәңгәр күк биеклегенә омтылды.

Һәр төркемдә тугызар тезелеп көнбатыш тарафка очабыз. Разведка бер зур торак пункт янында дошманның күп санда бронетехникасы, башка сугыш кирәк-ярагы туплануы турында хәбәр иткән. Шунда ук гитлерчыларның фронт штабы да урнашуы ихтимал дигән мәгълүмат алынган. Димәк, ул тирә зениткалар, истребительләр тарафыннан нык саклана. Алдагы бомбага тоту, фашист очкычлары белән һава сугышына керүне уйлап, гәүдәне салкын тир басты. Тиешле урынга якынлашканны белдереп, алда-артта-янда зенитка снарядлары ярылудан зәңгәрсу-кара төтен болытлары пәйда була башлады. Безнең төркемдә очучы бер самолетка эләкте, ахры, ул түбәнәеп, каядыр читкә юнәлде. Җиргә төшеп шартлаганы күренмәде. Бәлки, мәҗбүри берәр кая төшеп утыргандыр? Бәхет елмайса, билгеле. Фашист кулына эләкмәү дә кирәк бит әле.

Зениткалар кордонын да үттек. Өчәрләп-өчәрләп пике ясап, билгеләнгән нокталарга бомба йөкләрен коябыз. Түбәндә коточкыч шартлаулар маскировкаланган танкларны тимер өеменә әйләндерә, автомашиналар шырпы кабы кебек дөрләп яна, паникадан ары-бире йөгерешкән фрицларның теткәләнгән гәүдәләре йомычка кебек оча. Җаен туры китереп, исән калганнарын без—укчылар—пулеметтан атып чалгы белән чапкандай кырабыз. Хәзер кырык беренче ел түгел, кырык өченче ел шул! Без дә өйрәнеп життек сугышырга, үтте фашистның җирдә дә, һавада да хакимлек иткән заманнары!

Төркемдә тигезлекнең саклануы укчылар өчен унайлы, ул прицеллы утка тоту һәм дошман истребительләрен строй эченә үткәрмәү мөмкинлеге бирә. Шул турыда уйлап бетерергә өлгермәдем, бер кырыйда немецларның «фокке-вульф»лары пәйда булды. Алар—унике. Чак кына икеләнеп торгандай иттеләр дә, икешәрләп безнең эскадрилья өстенә ташландылар. Безне озатучы истребительләр алтау иде, алар «фокке»ларның юлына аркылы төшеп ярдәмгә килде. Фашистларның искәрмәстән һөҗүме барып чыкмады. Алдан килүче ике дошман очкычы, ут кабып, түбәнгә мәтәлде. Һава сугышы кызганнан-кызды. Дошманга совет истребительләре ата, без дә атабыз. Бер—советныкы, бер немец очкычы кара төтен эзе калдырып җиргә төшеп шартлады. Нәтиҗәдә, үлем уенында фрицлар җиде самолетларын югалтты. Безнең якта—өч.

Сугышчан бурычны үтәп, аэродромга әйләнеп кайткач, мин очкычыбыз бортын тишкәләп үткән дошман ядрәләре эзен санадым, алар егермедән артык иде. Безне язмыш аяды, әгәр фашист пулеметыннан ясалган чират бензобакларга тисә, исән әйләнеп кайтмаган булыр идек.

Иптәшләр белән сугышчан бурычны үтәгәндә һәлак булганнар рухын фронтовой йөз грамм күтәреп искә алдык. Алай гына җинеллек килмәде, әле бүген иртән генә безнең белән янәшә атлаган, сөйләшкән, ашаган-эчкән полкташлар хәтердән китмәде. Бүгенге көн мәхшәре күз алдына килеп йөдәтте. Фатирга кайтып урынга яткач та тиз генә йоклап китә алмадым. Күзне йомуга, өскә фашист «фокке»лары үкереп килгән кебек тоела. Төшме, өнме икәнлеген һич аерышлы түгел. Сонлап булса да йокы патшалыгы барыбер үз куенына алган...

## Унтугызынчы март

Иртә белән көндәлек баланданы эчеп куюга камерага комендант килеп керде. Бу юлы ул тәрҗемәчесез, бер кораллы сакчы гына иярткән иде. Аның саф урыс телендә эндәшүеннән сискәнеп куйдык. Үзенең урыс кешесе булуын әйткәч, гаҗәпләнүебез тагы да артты. Утыз алтынчы елны Германиягә экскурсиягә

барган жиреннән яшәргә шунда төпләнеп калган. Әле өч-дүрт көн элек кенә әсирләр белән мөгаләмәдә үзен эт кебек тоткан кешенең йомшап-юашланып калуының сәбәбе—совет гаскәрләре Пилауны алгач, аларга мөнәсәбәт начар булудан курку икән. Ул бу турыда кызыксынып:

—Советларга әсирлеккә бирелгән очракта безгә нәрсә булачак?—дип сорады.

—Һәркемгә кылган гамәлләренә карап җәза бирерләр,—дип җаваплаучык. Комендантны бу канәгатьләндермәде булса кирәк, ул тагын сораулар бирде. Тик әсирләр булганлыктан, хәтта котыла калсак та, особый отделдан карашның үзебезгә дә үзгә буласын чамалый идек, фашист ялчысын ни дип юатыйк соң.

Комендант шушы көннәрдә генә Гитлерның Пилауга карата махсус әмере ирештерелүен әйтте. Пилауны Кызыл Армиягә бирмәскә, соңгы солдатка кадәр сугышырга диелгән ди анда.

Бу инде дошманның атаудан табан ялтыратырга өмете киселгән, сугышып үләргә яисә әсир төшәргә генә тиешлеген аңлата.

Утыз алтынчы елда ук илен саткан адәмнең тагын ниндидер мөһим соравы бар иде кебек. Ул гадәти сораштырудан башка нәрсәнедер ачыкларга теләп бер-ике тапкыр талпынып авызын ачты, тик иннәрен җыерып кулын селтәү белән чикләнде. Ахырда:—Сезнең белән соңгы сөйләшү булмас әле,—дип чыгып китте.

Комендантның, исән калган очракта, үзен нәрсә көткәнен беләсе килүе аңлашыла. Аны советлар ягында, Ватанга хыянәт итүе, фашистларга хезмәт итүе һәм кылган явызлыклары өчен үлем җәзасы көтә. Иң ким дигәндә дә—егерме биш ел төрмә. Гаебен бераз булса да йомшарту нияте беләндер, кулындагы таягын «югалтты» ул, әсирләр белән кешечә сөйләшә башлады. Шул көннән башлап әсирләргә бирелә торган җитмеш грамм икмәкне йөз грамм иттерде, баланданың сыйфаты да чак кына яхшырды, чәйнең тәүлеклек нормасы ике мәртәбә артты. Ул, камерага кереп, ашау якларыннан немец солдатларының да кысынкылык күрүләрен, ә безгә паек арттыруның ватандашларына яхшылык эшлисе килүдән икәнен аңлатты. Шулчак башка, телдән менә-менә ычкынам дип: «гаебенне юар өчен шулай тырышасыңмы, фашист эте?» дигән сорау килде. Тик аны кычкырып әйтергә ярамый шул, мангаеңа пуля алуың бар.

Егерме икенче мартка кадәр безне камералардан беркая да чыгармадылар. Совет самолетларының шәһәрне бомбага тотулары да нык кимеде, еракка ата торган туплар да нигәдер тынып калды. Тик бу тынлык давыл алдыннан була торган тынлыкны хәтерләтә иде. Күрәсең, Кызыл Армия киң фронт буенча зур һөҗүмгә әзерләнә.

## Тәскиядән хат

Мин йокыдан уянуга йорт хуҗасы өстәлдәге конвертка төртеп күрсәтте:

—Солдат, сиңа хат килгән анда,—диде ул аталарча җылы тавыш белән.

Мин рәхмәт әйтеп, конвертны кулыма алдым. Хат Тәскиядән иде. Аның белән хат алышу мин армиягә алынганнан соң да тукталмады. Тик менә Мәхмүзә генә... И-их, Мәхмүзә! Мин лазаретка эләгеп озак вакытлар дәваланып ятканда һәм аннан соң бу кызга тиз генә хат язып сала алмадым. Аннан да хат килүләр тукталды. Соңрак ишеттем—Мәхмүзә башкага тормышка чыккан. Кызларга ышанычым бетте. Аерылышканда: «Габделхагым, мин сине мәңге көтәрмен!» дип антлар итте, күкрәгемә капланып елады. Һәм менә сиңа, мә. Мин моны аңламадым. Иптәшләремнән берсе: «Ул синең турыда «үлде», дигән хәбәр ишеткәч, сораучысы барында, кияүгә чыгып калыйм, дип уйлады»,—дигән эчтәлектәге хат та язып салды. Мәхмүзәнең, әгәр мин гафу итсәм, иреннән аерылырга нияте барлыгын белгертте. Миндә дә горурлык бар: бернәрсә ишетергә дә, аңларга да теләмәдем, Мәхмүзә белән араны кырт өздем.

Тәския хатын кырык өченче елның бишенче июнь көне белән даталап, болай дип башлаган: «Йөрәк дустыма! Онытма мине, онытмам сине. Хак дустым,

сиңа меңнәрчә, миллионнарча сәламнәремне җибәреп калам. Бүген җиденче сыйныфларга татар теленнән имтихан үткәреп кайтуыма, капка төбендә бригадирым (мин беренче бригаданың агитаторы да бит әле) көтеп утыра. Аның белән бергәләп кырга сукачылар янына киттек. Басудан кайтсам, өстәл өстендә ике хат ята: берсе—синнән, икенчесе—энекәштән, ике хатны да бер тында укып чыктым. Нык арылган булса да, сиңа шунда ук җавап язарга утырдым. Хатың белән фотонны да җибәргәнсең, хәрби кием бик килешә икән үзеңә. Рәхмәт. Дошманны армыйча кыйнагыз, сез үзегезне аямыйча, җиңүгә зур өлеш кертәсез. Ул көн ерак түгел инде. Бүген радиодан Орел юнәлешендә зур бәрелешләр булачагы турында хәбәр иттеләр. Канкойгыч сугышлардан исән килеш чыгарга насыйп итсен.

Мактаулы һәм батыр бул,
Туган илең каршында.
Фашистны дөмбәсләп ныграк,
Ирек бирмә качырга.

Дустым, мин сиңа кичә тагын посылка итеп кәгазь төргәге җибәргән идем. Моннан алдагысын «алмадым»,—диден. Шәт, бу юлы барып ирешер. Неужели инде һәр җибәргәнне үзләштереп барырга намуслары җитәр? Үзем дә җаен туры китереп, Апаска барып фотога төштем, сиңа бер карточкамны җибәрәм. Сагынганда алып карарсың.

Үткәнендә «Түбән Барыш белән бәйләнеш», дип язган идем бит әле—син аны дөрес анламагансың. Минем анда беркем белән, бернинди бәйләнешем юк. Чит-ятларга күз дә салмыйм. Ә синең башкалар белән хат алышуыңа исем китми, чөнки һәркем җаны теләгән кешесе белән хат алышырга хокуклы. Алай кызыклырак та әле ул, тормышта күп нәрсәләрне чагыштырып карарга өйрәнәсең.

Авылда хәлләрне җиңел дип әйтеп булмый. Чәчү һаман бетмәгән. Бәрәңге утыртырга хәле булганнар да, бәрәңгесен утыртмаган. Иген турында әйткән дә юк, бәрәңгенең поты алты йөз—алты йөз илле сум тора. Аңлыйбыз инде: фронт өчен күп кирәк. Без монда ничек тә түзәрбез, сугышта тагын да кыенрак ич. Тәския хатын шигъри юллар белән тәгәлләгән иде:

—Тиңсез шатлык туа йөрәгемдә,
Рәсемеңне алып карасам.
Кош баласын өзелеп сагынгандай
Мин дә сине өзелеп яратам.
Сөешү ул безнең өчен бәхет,
Яшәү бәхете сөешә белү дә.
Яшь чагында сөя белеп кенә,
Сөя белеп яшик гомергә.

*5.06.43 ел*

Тәскиянең ак кәгазьгә төшергән чиста хисләре, миңа карата күңеленнән ташып чыккан мәхәббәте мине дә әсәрләндергән иде. Фотосын зур саклык белән кулыма алып, үз итеп озак кына карап утырдым. Ачык йөз, гөнаһсыз туры караш мине тәмам әсир итте. Тыйнак кыз баланың йөрәген ачып салуы күп нәрсә турында сөйли: ярата ул мине, өзелеп ярата. Үзем дә сизмәстән бармакларым белән Тәскиянең фотосурәтен сыйпадым. Иреннәрем үзләреннән-үзләре: «Көт кенә, кайтырмын»,—дип пышылдады.

Ашханәгә кичке ашка барганчы әле ике сәгатьләп вакыт бар иде, Тәскиягә җавап хаты язып салырга булдым.

Берникадәр ничек башларга микән дип утырганнан соң башына: «Кадерле-

мә» дип язып куйдым. Бу сүз артыннан шигъри юллар тезелеп китте:

—Хат язарга менә утырдым да
Матур сүзләр эзләп карадым.
Ләкин матур итеп язар өчен
Иң кирәкле сүзне тапмадым.
Яшь күңелгә ышанып булмыйдыр шул,
Төрле уйлар килә күңелгә.
Кайчагында ялгыш алдана ул,
Ни буласын алдан белми дә.
Жил исмидер—жилләр хасил була,
Һаваларда кошлар кагынса.
Һәркем үз иленә хатлар яза,
Аны сөйсә, аны сагынса.
Дөресен әйтәм: синсез авыр мина
Авыр таш бар кебек күңелдә.
Мин сөямен сине шунын өчен
Аерылмам синнән мәңгегә.

Соңгы хәлләр турында бәян иткәннән соң, аны күрергә зар-интизар булуым турында әйттем. Язганнарымны зәңгәр конвертка салып, ашханәгә барышлый хатны почта әрҗәсенә салдым.

## Егерме икенче март

Егерме икесе көнне иртән иртүк безне камералардан чыгарып коридорда тезделәр. Стройда унтугыз кеше. Шулардан өчесе генә сержант: мин, Мазин һәм Метелкин дигән иптәшләр. Ун—очучы-офицер, калган алтысы танкистлар. Подполковник дәрәҗәсендәге комендант үзенең ярдәмчесе һәм тагын ике немец офицеры белән безнең төркем каршында басып тора. Анын дулкынлануы йөзенә чыккан. Дүрт автоматчы автоматларын корсакларына терәп, бер-берсеннән тигез ара калдырып, тезелеп басканнар. Алар әмер янгыраса, кичекмәстән ут ачарга әзер.

Элекке урыс эмигранты, немец жандармериясе подполковнигынын дулкынлануы юктан булмаган икән. Менә ул әсирләр тезелеп баскан төркем алдыннан атлап китте һәм һәрберебезгә текәлеп карап акрын тавыш белән сөйли башлады:

—Сез бүген бу атаудан портка чыгарылачаксыз. Бирегә бомбалар астында калып һәлак булуыгыз ихтимал. Немец командованиесе гуманлылык принципларыннан чыгып, исәнлегегезне кайгырта. Портта пароходка утыртып бөек Германия жирләренә жибәреләчәксез. Сезне исән-имин илтеп житкерүне мина ышанып тапшырдылар. Алдан ук кисәтеп куям: качарга теләгәннәр, тотылган урыннарында атылачак. Андый очраклар булгалады инде, качып ерак китә алмадылар. Үзегезне тәртипле тотсагыз, сезнең белән дә мөнәсәбәтләр нормаль булыр...

Комендантнын сөйләгәннәре бер колактан кереп икенчесеннән чыга. Башта сораулар бөтерелә. Немецлар ни сәбәпле үзләренә артык йөк итеп совет әсирләрен Германия жирләренә чыгарырга уйлаганнар. Шушында юк итү алар өчен жайлырак түгелме? Моның әллә берәр сере бармы? Болай булса, яшәүгә өмет бетмәгән ич. Юлда әллә нинди хәлләр килеп туарга мөмкин, бәлки, качып котылып булыр.

Комендант нотыгын тәгәлләгәч, сакчыларга алып чыгарга кушып кул изәде. Шуны гына көткән автоматчылар безне урамга куалады. Жир өстенә, бинһая зур савытка салынган аксыл кесәл кебек, куе томан сарылган. Күп тә үтмәде,

томан, кар катыш вак яңгырга әйләнеп, юка гимнастеркаларыбыз аша арык тәннәребезгә үтеп керде, яланбаштагы чәчләрне учма-учма укмаштырды. Тунудан тешләр тешкә тими. Немецларга нәрсә, алар өсләренә плащ-палаткалар бөркәнгән. Дүрт солдат һәм дүрт офицер ике яклап тезелеп, эт һаулаган тавышлар чыгарып безне дингез ягына ашыктыра.

Кичүдә халык күп җыелган. Әйләнә-тирә кычкырыш-талаш, елау тавышларына күмелгән. Күпләр бу тиранe совет гаскәрләре басып алганчы, тизрәк ташлап китәргә ашыга, күрәмсең. Тик качып кая бара инде болар, бер җәһәннәмнән котылып, икенчесенә эләгәләр түгелме? Бу уйлар анда озак тоткарланмыйча тиз сызылып уза. Чөнки үз хәлебез—хәл. Туну тәмам багырьгә үтте. Паром һаман күренми. Ул берничә сәгатьтән соң гына килде. Ачык паромда да бернинди ышыкланыр урын юк. Карлы яңгыр юешлегенә дингез салкынлыгы өстәлде, без—унтугыз әсир—катып үлмәскә тырышып, күшеккән сарык бәрәннәре шикелле бер почмакка бөялдек. Өлкән лейтенант Бобров телгә килеп:

—Мөгаен, бу этләр безне атмыйча, шулай туңдырып үтерү ысулын сайлагандыр,—дип куйды. Аның һәм кайбер тоткыннарның пешеп эренләгән яраларын бәйләгән чүпрәкләре җебеп, урыннарыннан кучкән, ачылган яралар кызгылтшәмәхә төскә кереп, коточарлык булганнар.

Атаудан каршы якка чыккач, паром яр буенда туктады. Бу әле порт түгел иде. Бөтен халык чыгып беткәч, безгә чират җитте. Аяклар туң агач кебек каткан, юньләп атламыйлар. Аларны чак сөйрәп, яр буенча өстерәлә торгач, ничек кирәк алай пристань-портка килеп җиттек. Монда да безне көтеп тормыйлар, тиешле пароход килеп җитмәгән иде. Ярый шулчак кояш чыкты. Сакчылар порттагы зур бер бина янында тезелешеп утырырга рөхсәт иттеләр. Рәхимле кояш нурлары! Ярый әле сез бар. Акрынлап тәннең дерелдәп калтырануы басылды, эчкә җылы керде. Кайберәүләр хәтта изрәп йокыга оеды. Өстәге гимнастеркаларны, чүпрәк-чапракны кояшта киптерергә җай чыкты, кичкә таба һава янә суытты. Тик монысына гына түзәргә була инде, өстән явып тормый иде.

Пароход кичке уннар тирәсендә генә килеп җитте. Трап буенча зур дингез пароходына күтәрелгәннән соң, әсирләр төркемен судноның борын өлешенә, юан тимер чылбырлар урап куелган урынга кысрыкладылар. Берничә тәүлеккә сузыласы «сәяхәтне» без шушында үтәргә тиеш булып чыктык. Тик әле дингез корабы якорь ташлаган җиреннән никтер һаман да кузгалырга ашыкмады. Төнге сәгать икеләр тирәсендә генә портны ташлап киттек. Безнең кораб дингез сәфәрендә ялгызы түгел икән. Әсирләр каян ишетеп белгәндер, кемдер әйтүенчә, янә биш пароход суднолар төркемендә йөзәсе, аларны дүрт суасты көймәсе саклап барырга тиеш, имеш. Бардыр, анысы да булыр.

Пароходлар кузгалып ерак китәргә өлгермәде, Кызыл Армиянең еракка атучы дингез буе артиллериясе телгә килде. Снарядлар башта шактый читтә шартласалар да, торган саен куәтле су баганаларының өскә күтәрелүе якынайганы сизелә иде. Менә инде кайбер снарядлар янәшәдә үк фонтаннар хасил итә. Күккә чөелгән зур су массасы шаулап дингезгә коела да, пароходның ныклыгын сынарга теләп, як-якка чайкалдыра. Бу вакытта басып торсаң, аяк өстендә калуы кыен. Күңелгә курку хисе үтеп кергән. Үлем янәшәдә генә, һәр мизгелдә зур җимерү көченә ия снаряд тиеп, юкка чыгу куркынычы бар. Пароход шунда ук батмаса да, барыбер котылу юк—төпкә китеп, балыкларга азык буласыңны көт тә тор. Көн яктысы беленгәч, эскадрадагы алты корабльдән икесенең су астына киткәнлеге ачыкланды. Дүрт су асты көймәсенең берсе юкка чыккан иде...

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Рәхмәт, Сәйдәшне онытмагансыз!

«Казан утлары журналы» йөрәкләрне дулкынландыра алган һәм тирән эчтәлеклеге белән аерылып торган әдәби әсәрләрне үзенең битләрендә бастырып чыгаруын дәвам итә. Шул рәттән быел, 2010 елда, журналның 1нче һәм 2нче саннарында «Сәйдәшнең соңгы елы» дигән кыйсса басылып чыкты. Бу әсәрнең авторы—Рашат Низами. Сүз уңаеннан әйтим, моңа хәтле «кыйсса» минем өчен таныш сүз түгел иде. Шуңа күрә татар теленең аңлатмалы сүзлеген алып карарга булдым: киң форматта язылган һәм бер генә темага багышланган әсәр икән ул.

Бик тә кирәкле һәм вакытында язылган әсәр булган бу. «Казан утлары» журналы редакциясендә дә өлгер егетләр эшли икән—сөекле композиторыбызның тууына 110 ел тулу уңаеннан язылган әсәрне вакытында бастырып чыгаргансыз. Халыкта шундый әйтем бар: «Кунак ашы тәмле була вакытында өлгерсә, авызны пешермәсә һәм тозы таман булса» . Бу кыйсса да вакытында өлгертелгән. Салих Сәйдәшевнең тормыш юлларын, композитор булып үсеп җитү елларын укучының күңелен җәлеп итеп алырлык тасвирлавы белән дә, барлык язылганнар тарихи яктан төгәл бирелүе белән дә үзенчәлекле. Өстәвенә күп кенә яңа фактлар китерелгән һәм җиңел укыла торган әсәр булган бу.

Әйе, күптән көткән идем күңелем белән бөек композиторыбызга багышланган саллы әдәби әсәрнең язылуын һәм басылып чыгуын. Рәхмәт язучыга, рәхмәт «Казан утлары» журналы редакциясенә.

Безнең буын Салих Сәйдәшевне бик яхшы белә. Үземнең узган гасырда балачак, яшьлек вакытым, урта мәктәптә укыган еллар Сәйдәш яшәгән чорга туры килде. Композитор язган Совет Армиясе маршын уйнаган оркестр яныннан төз сафларда басып елына ике тапкыр, Казаныбызның Ирек мәйданы аша 13нче мәктәпнең демонстрация колоннасында уза идек. Классташларым белән Камал театрына бик тә матур яңгырашлы, халыкка якын һәм аңлаешлы күркәм музыка белән бизәлгән «Казан сөлгесе» спектакленә дә барган идек. Залда, бәлкем, безнең класс килгән кичке спектакльдә оркестр белән Салих Сәйдәшев үзе дирижерлык иткәндер дип тә уйландым сезнең күңелгә ятышлы әсәрегезне укыган минутларда, Рашат әфәнде.

**Мансур ҖӘЛӘЛИЕВ**

## Шигырь—тәмәке түгел!

Сталин лагерьларыннан кайткан Хәсән Туфанның тәүге визиты, әлбәттә инде, Матбугат йортына булды. Язучылар берлеге идарәсендә булганнан соң, иркенләп утырырга дип, ул 5нче каттагы Тукай клубына менде. Мин анда, китапханә мөдире Әминә апа Бикчәнтәева үтенече буенча, китапларны системага салу белән мәшгуль идем. Исәнлек-саулык сораштык. Шагыйрь яшь егетнең кемлеге белән кызыксынды. Нык кына якынаеп киттек Хәсән ага белән.

Бер килүендә Хәсән аганың иҗаты белән кызыксындым. Болай да аз сүзле шагыйрь бик үк җәелеп китәргә ашыкмады.

—Ничек инде, ике дистә елга якын берни дә язмадыгызмыни анда?—дип сорыйм.

—Яздым. Исән калган 200 шигыремне папирос мөштеге эченә яшереп алып кайттым,—диде шагыйрь.—Ни хикмәт, тентүчеләр шигырьләремне тәмәке итеп суырмадылар.

## Пәһлеван шагыйрь

Ниһаять, Муса Җәлилнең әсирлектәге халәте, аның кемлеге беркадәр ачыклана төште шикелле. Шагыйрьнең туууына 50 ел тулуны зурлап үткәрделәр. Казанга күп кунаклар чакырылды. Килүчеләр арасында Әзәрбайҗанның халык шагыйре Сәмид Вургун да бар иде. Кичәдә ул Моабит каһарманына багышланган ялкынлы шигырьләрен укыды.

Хикмәт Сәмид Вургунның үзендә. Беренче көнне үк аның пәһлеван гәүдәсен, мул итеп бәйләнгән арыш көлтәседәй әкәмәт зур, ап-ак чәчләрен күреп хәйран калган идек. Татарстанда Вургун белән чагыштырырлык затның бүгенгәчә күренгәне юк. Шулай да шагыйрь Нури Арсланда бераз гына кавказлы чалымнары бар иде шикелле.

Мәскәүгә китәр алдыннан Кавказ пәһлеваны, коллегалары белән саубуллашу өчен, Татарстан Язучылар берлегенә сугылды. Идарәдәге әңгәмәдән соң, 5нче каттагы Тукай клубына күтәрелде. Анда эшләүче китапханәче егеткә, ягъни миңа сүз кушып, ничек эшләвем, кайда укуым белән кызыксынды. Шунысы кызык: әңгәмә өч телдә дәвам итте—татарча, әзәричә һәм урысча. Шагыйрь әңгәмәбезне болайрак түгәрәкләде:

—Барысы да яхшы. Сиңа җинелрәк, егет. Ә мин 13 яшемдә Бакудан Мәскәүгә поезд вагоннары түбәсендә бардым. Бер кабым ризыксыз. Урыс агае (ул аны брат диде) куса да, типкәләсә дә, түздем... Һәм менә Сәмид Вургун булдым. Бу җирдә үз исемеңне табарга тырыш, егет!

Шагыйрьнең әлеге сүзләре чәчем агарып беткәч, кабат искә төште...

## Кыска гомер, кыска җыр

Болак буендагы 2нче урта мәктәп бинасына эшче яшьләрнең кичке 19нчы мәктәбе урнашкан иде. 7нче сыйныфта укырга дип шунда бардым. Кая ул?! Соболев дигән усал директор алмады, 6нчыны бетергәнгә белешмән дөрес түгел, диде. Шулай булгандыр анысы. Яңгырга эләгеп бозылган ул, дип тә карадым, юк икән, юк инде. Рәхмәт Һади Такташның Маһруй исемле апасына (үз улы кебек ярата иде), уку-укыту бүлеге мөдире Галина Анаемовна белән сөйләшеп, тәки мәктәпкә урнаштырды үземне. Мин каян белим: баксаң, Галина Анаемовна дигән завучыбыз шагыйрь Һади Такташның хатыны Гөлчәһрә ханым булган икән. Ул арада мәктәптәге 7нчеләр 2 урынына 4 сыйныфка җыелды. Бүлеп, шәһәр мәктәпләренә

тараттылар. Мин Казан киез һәм киез итек фабрикасы подвалына урнашкан кичке мәктәпкә эләктем. Болак буенда Ташбулат Шакиров калды, әнә, Татарстанның сәүдә министры булгач, «Победа» машинасында гына йөри.

Калучылар тагын да булган икән. Еллар узып, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшли башлаган яшь талантлы җырчы Таһир Якуповны «Социалистик Татарстан» газите редакциясенә кунак итеп чакырдык.

— И-и, син мондамыни? Теге чакта әллә кая китеп югалдың,—дип гаҗәпсенде Таһир. Аннары шаяртып әйтеп куйды:

— Безнең мәктәптә калган булсаң, минем күк җырлап йөрер идең менә. Хәзер язарга туры килә инде сиңа.

Яздык та. Ул гына озак җырлый алмады—Ходай биргән моңын үзе белән алып китте.

## Бурят үкенүе

Бүген ана йөз унбиш тирәсе булыр иде. Цеден Цебудиев—пәһлеван гәүдәле (бәлки, кыпчак токымыннандыр?) бурят, карт бәлшәвик, республика газитенең, ул замандагыча әйтсәк, җаваплы редакторы, Бурятия партия өлкә комитеты бюросы әгъзасы. Үзләрендә Совет хөкүмәтен урнаштыруда алтатар уйнаткан. Шуңа күрә дә башкала җитәкчелеге «Социалистик Татарстан» газитенең 50 еллык юбилеена Ц. Цебудиевны чакыруны кирәк тапкан. Җаваплы мөхәрриребез Ш. Хамматов кунакларны: бурят Цеден Цебудиев, үзбәк Мөхетдин Җәләлов, әзәри Асиф Мамедовларны минем кулга тапшырды. Кунакларны шәһәр гиздердем, Ленин белән бәйле урыннарга алып бардым. Кичен Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында «Зәңгәр шәл» спектаклен карадык. «Казан» рестораныңа кайткач, Цеден агай әйтеп куйды:

— Сәнгать өлкәсендә без татарлардан йөз елга калышабыз. Бәлки күбрәктер дә?..

— Аның каравы, сездә шаманлык куәтле,—ди Мөхетдин әкә, юмор беләнрәк.

— Шулай шул, коллега. Октябрь революциясенә дә 50 ел менә. Мин инде бурятларны үзгәртә алмаячакмын!..

Инкыйлаб эшләп бетерә алмаган нәрсәләр өчен үкенә иде бугай карт бурят.

## Алтатар заманы

«Социалистик Татарстан» газитендә эшләгәндә хәбәрчеләрем арасында карт бәлшәвик, фамилиядәшем Ләбиб абзый Гомәров та бар иде. Урта буйлы, төп шикелле базык гәүдәле, яше җитмештән узса да, көчен-куәтен, гайрәтен саклаган бер инсан. Кыяфәтеннән ниндидер хакимлек бөркелә. Алга китеп әйтим, күрсәткән «батырлыклары» өчен аны Татарстанның җир эшләре комиссары иткәннәр. Әмма чын түрәлек инде күптән киткән үзеннән. Кайчандыр җирдә аның заманы булган... Бер галимнең мәкаләсеннән укып, Ләбиб агайның яшьлегендә дөньяны шактый тугылаганын белә идем. Әйтик, ул милләтебез азатлыгы өчен җан атып көрәшкән сәясәтче, патша армиясе офицеры, прапорщик Ильяс Сәетгәрәй улы Алкинны соңгы тапкыр (унынчы мәртәбә!) кулга алуда катнашкан. Алга китеп әйтим, бу каһарманыбызны 1937 елда Сталин зинданында атып үтерәләр.

—Ничек килеп чыкты анысы?—дип кызыксындым мин Ләбиб абзыйдан шул хакта.

—Без ул чакта алтатар тагып йөрдек,—диде элеккеге НКВД вәкиле.

—Алтатарың Алкинны коткара да алгандыр ич?

—Коткару түгел, утырту иде безнең бурыч.

—Атып үтерү, диегез.

—Анысын мин эшләмәдем...

Кылган гамәлләре турында Ләбиб абзый бик ансат җавап бирде. Ә намусы белән нишләгәндер, анысы миңа караңгы. Ул вакыйгаларның үзе шикелле...

**Госман ГОМӘР**

## «МАТБУГАТ.РУ»ДАН БЕЗНЕ УКЫГЫЗ

### Рәфикъ Юныс. «Татар батырмы?» 2010, май

Чын сугышта булганнарның сугыш турында сөйләмәүләре сәер тоела иде. Сугыштан бик гарип булып кайткан үз әтием дә сөйләми иде. Анын Бөек Ватан сугышы ордены бар, шуны ничек алганы турында ике-өч сүздән артык әйткәне булмады беркайчан.

**Иркә**

Бүгенге татарлар куркаграк дигән фикер белән килешеп була. Сәбәбе– батырларның башын һаман кисеп тордылар шул. Гитлер гына түгел, башкалар да. Куркактан куркак тумыйча, батыр тумас бит инде. Әле ярый, геннар сакланып калганмы, батырлар да туралаштыра.

**Кигәвен**

Татарның батыры да, куркагы да булгандыр. Сугыш вакытында илен дошманнарга саткан татарлар аз булганмыни? Рәфикъ Юныснын мәкаләсенә килгәндә, саллы язма. Иң мөһиме–дөреслектә тикшерелгән фактлар кулланган, ачыклыклар керткән.

**Лилия**

Ул батыр ирләр кемгә хезмәт итәләр соң? Маржага өйләнгән «батырлар» турында әйтәсезме? Ана телен белмәгән «батыр» татарлар турында әйтәсезме? Нуриевларны, Гобәйдуллиналарны әйтәсезме? Алар безгә үрнәк татарлар түгел!!!

**Мин**

Әйе, үткән тарихта булган ул татарның батырлары. Гомумхалык эше өчен гомерләрен дә жәлләмәгәннәр. Хәзер бармы икән алар? Юктыр, дигән фикердә мин. Түрәләр алдында, бигрәк тә урыс түрәләре алдында куркак булмасак, милләтебезгә, телебезгә куркыныч килер идеме?! Үз сүзебезне әйтергә, дөрес эшебезне эшләргә батырлыгыбыз житми, куркаклыгыбыз жиңә. Читтә-чотта гына сөйләнәсен, татарым. Кирәк жирдә син юк. Куркак син хәзер, татарым, куркак.

**Гардан**

Беркөнне «Кара-каршы»да өлкән буын кешеләре хакында сөйләшү булды. Хәлләрен сорашкач, бер-берсен уздырып пенсияләренең күплегенә шатландылар. Подъезд төбендә сөйләшкәндә ул акча–аз, ә кулда микрофон булганда, тиешле урында әйтергә мөмкинлек булганда–пенсия зур! Шуннан карамадым да. Мескенлек ташып, бәреп, аңкып тора.

**Күке**

Татарда батырлар юк! Казан ханлыгы чорында булгандыр, бәлки. Чөнки анда катнаш халык булган, бер диндәге, төрле менталитет вәкилләре бер-бере белән кавышкан. Ханлык жимерелгәч андый әйбер бетте. Бүгенге татар сатлыкжан, хөсетле, астыртын, мәкерле, ышанычсыз. Ачуланмагыз, кардәшләр. Кызганыч, барыбыз да шушы сыйфатларга ия. Бер татарның ирек, тел даулап кычкыруы психик авыру дип кабул ителә. Кем тарафыннан? Башка татарлар тарафыннан! Милләтебез

психик якан сәламәт түгел... Һәркем үз каланчасыннан чыгып кына карый дөньяга. Бер татар – юк татар! Бер максатка юнәлгән 5 татар – инде көч. Ләкин шул биш татарга бездә 5 мең татар таш атып аяк чала...

Тагын шунысы: бүгенге татар надан!!! Сәяси яктан да, юридик, икътисади яктан да надан. Бүген китапханәләргә килеп китап алучы юк. Кемнәрнен танышлары китапханәдә эшли? Сорашыгыз. Йөрмиләр бүген анда. Авылы да, шәһәре дә йөрми китапханәгә. Ә ул китапханәне беркем дә япмады. Йөрүче булмагач кына кыскарту эше башланды. Монда да житәкчеләребез гаепле микән? Юк, безнен һәрберебез битараф бәндә. Үз омтылышы булмаган, башкалардан көнләшкән, туганынын мантуын теләмәгән мескен бәндә.

**Мин әле бу**

Татарнын батырлары бүген дә туып тора. Элегрәк туганнарынын берничәсен сезнен (безнен) кайнап торган фикер казанына ыргытам, көйдермәгез генә! Начар ис чыгып борыннарыбызны томаламасын. Зәки Зәйнуллин, Фәндәс Сафиуллин, Марат Мөлеков, Фәүзия Бәйрәмова... Тагын бер батыр татарны аерып калдырдым – М.Ш Шәймиев. Вакытында ул да зур батырлыкка(ин зур!) барды. Аннан сон чигенде, сәбәпләрен анлаучылар бардыр инде.

**Кигәвен**

Кстати, апрель аенда еврейлар оешмасы Казан Кремлендәге манежда Холокостка багышланган мероприятие уздырды. Молодцы, искиткеч оештырылу, бернинди пафос, кычкырыну юк, тыныч кына итеп барысын да киштәләргә тезеп анлаттылар. Милләт бөеклеге, изелгәнлек турында ник бер сүз булсын! Бу каләр дә акыллы халык булыр икән! Акрынлап үз эшләрен эшлиләр.

**Авылдаш**

## Туфан Миңнуллин. «Бәләкәй Туфан». 2010, май

Мөхәммәт Мәһдиев һәм Туфан абый Миннуллиннын язган һәрбер язмасын бөтен татар баласына укытыр идем. Туфан абыйнын оныклары бик бәхетле балалардыр. Алар бабайларыннан үзе гади, үзе анлаешлы телдә сөйләнгән хикәяләрдән тормыш әлифбасын өйрәнәләрдер.

**Зелпе**

Туфан абыйнын сары маржалар үбәргә күрше авылга барулары кызык булды. Аулак өйләр, кичләрен урамнарда өелгән бүрәнәләрдә, мунча ише жирләрдә жыйналып утырулар... Баштан үткән матур хатирәләрне кабат янарттым. Рәхмәт барыгызга да!

**Монсылу**

Да-а, Туфан ага!!! Мин сезне төзелмәгән коммунизм, тирән үсеш алган социализм жырчысы дип кенә белә идем. Укымаган да идем. Монсылу ападан сон укып караган идем, бер сорау туды: «Ник эротикадан тукталып калдыгыз?» Икенчедән, ирләрнен «балыкчы әкиятләрен» ачып салгансыз, анысы өчен тагын бер кат рәхмәт! Бик матур, жинел укыла! Язгыз! Бер яшьлектә, бер картлыкта ди. Нәжибә апан беркая китми инде ул хәзер!

**Иркә**

## Халикъ Садриның тууына 120 ел

Габделхаликъ Гариф улы Садретдинов (Халикъ Садри) 1890 елның 4 августында Самара губернасының Богырыслан өязе (хәзерге Самара өлкәсенең Келәүле районы) Иске Ярмәк авылында игенче гаиләсендә туа. Ул бик яшьли ятим калып, чит кешеләр кулында тәрбияләнә һәм кечкенәдән үк үз көнен үзе күрә башлый: башта авылда, аннан соң Уфа, Бакы, Самара, Оренбург кебек шәһәрләрнең төрле остаханәләрендә, нефть промыселларында эшли, көтүче малайдан югары квалификацияле эшче-машинист, механик булып житешә. Уфада чагында бераз вакыт «Галия» мәдрәсәсендә дә укып чыга.

Февраль революциясе вакытында Халикъ Садри, большевиклар ягында торып, революцион көрәш хәрәкәтенә кушыла. Октябрь көннәрендә Самара шәһәрендә Совет властен урнаштыруда һәм Идел буен акгвардиячеләрдән азат итүдә катнаша, 1918 елның маенда Самарада татар телендә чыга башлаган «Кинәш» исемле газетада эшли, аннан соң, 1919-1922 елларда—партиянең Самара губерна комитетында татар-башкорт секциясе рәисе хезмәтендә. 1920 елда ул, татар халкы вәкилләреннән берсе буларак, Мәскәүдә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан итү турындагы тарихи Закон проектына кул кую тантанасында катнаша.

1925-1928 елларда Халикъ Садри Казанда Татар коммунистлары университетында (ТКУ) укый, аны тәмамлагач, озак еллар Казанның «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында һәм башка сәнәгать оешмаларында житәкче урыннарда эшли, актив жәмәгать эше алып бара. Бу чорда ул уйлап табу һәм хезмәтне рациональләштерү өлкәсендә дә нәтижәле эшли, шул мәсьәләләр буенча фәнни-популяр характердагы дистәгә якын брошюра язып бастыра («Электромонтер», 1926; «Электрик серләре», 1928 һ. б.).

Ватан сугышы елларында Халикъ Садри, полк хәрби комиссары буларак, фронтның алгы сызыгында сугыша, яралана, сугыштагы батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, II дәрәжә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Халикъ Садри СССР Әдәби фондының Татарстан Язучылар берлегендәге вәкиле булып эшли. 1950 елда ул «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә.

Халикъ Садриның әдәби ижат эше Октябрьгә кадәр үк башланып, 1913 елда Уфа матбугатында аның «Тегермәндә» исемле беренче хикәясе басылып чыга. Ижатының башлангыч чорында ул әдәбиятның барлык жанрларында диярлек каләм көчен сынап карый: шигырьләр, сәхнә әсәрләре, очерк һәм хикәяләр яза. 1919 елда ижат ителгән «Унике ел төрмәдә» исемле пьесасы шул елларда сәхнәләрдә дә куелып йөри.

Утызынчы елларда Халикъ Садри әдәби ижат эшчәнлегендә төп урын тоткан проза әсәрләрен—«Ил батырлары» (1934), «Тимерче малае» (1935) һәм «Безнең тан» (1937) исемле повестьларын яза.

Әдипнең сугыштан соңгы әдәби ижаты «Йөзмә госпитальдә» исемле очерк-хикәя (1950), драматург Әнәс Камал белән берлектә язган «Юллар» дигән сәхнә әсәре (1950) һәм курчак театрлары өчен «Камал бабай әкияте» дигән пьесадан (1951) гыйбарәт.

Халикъ Садри 1939 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Ул 1955 елның 8 мартында Казан шәһәрендә вафат була.

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ ДАНИЯ

### Мин—Казан кызы

Әйе, мин—Казан кызы. Әй ул без үскәндәге Казанның матурлыклары! Хәзер дә гүзәл Казаныбыз. Үзгәреп, зураеп китте. Инде мин белмәгән урамнар барлыкка килде. Казан күккә дә ашты, ингә дә киңәйде. Булсын шулай, ул бит безнең мәркәзебез. Бар татарның—өмет-хыялы, мәккәсе-кыйбласы! Нурлы Казан, моңлы Казан!

Тик шулай да менә мин үскәндәгесе якынырак, назлырак, ягымлырак сыман. Ул Казанда мин сөеп һәм сөелеп үстем. Мин әле Казан кызы гына түгел, аның легендалар белән тулы күленең—Кабанның да кызы. Ник дисәгез, безнең йортыбыз Кабан кырыендарак, СКА һәм Искож заводлары тирәсендә—Калинин бистәсендә иде. Җәебез дә, кышыбыз да Кабан өстендә үтте дисәм, дөрес булыр. Балыгын да тоттык. Әллә нинди матур-матур балыклары бар иде шунын. Суы да хәзергегә караганда чистарак иде бит. Ышанасызмы? Ярлары комнан иде Кабанның—әйе! Шунда самавырларны, табаларны, кәчтрүлләрне, керосинкаларны чистартабыз. И күңелле иде, иптәш кызларым белән шул эшне яратып та эшли идек инде! Әни үтә дә чиста, пөхтә кеше иде. Гомере генә кыска булды шул. 13 яшьтән ятим калдым. Исеме—Бибикамал. Матур бит! Бибикамал!

И еладым да инде әни үлгәч. Хәбил абый белән икәү генә калдык. Әти өйләнде. Аннан абый да башлы-күзле булды. Бүтән абый-апалар күптән тормышлы. Әнине сагынам. Сарайга чыгып елыйм. Укуларым бик авырлык белән генә бара. Әти дә мина карап көенеп йөри. Ничекләр генә юатырга соң бу кызын дип уйлана, ахрысы. Тотты да дагана ясады, берне генә түгел, өчне. Иптәш кызларым белән шунда атынып рәхәтләндек. Атынабыз, атынабыз да Кабан күленә чумабыз. Рәхәт бит эссе җәйдә су керүләре. Үзебез белгән малайлар да безнең белән бергә коена. Коенабыз, коенабыз да күлнең икенче ягына чыгып кәбестә, кишер урлыйбыз. Ул якта колхоз кыры—умырылып уңа иде яшелчәләр. Бер заман мина малайлар майка бәйләделәр, шуңа дынгычлап кишер тутырдылар. Мин аны-моны уйлап тормыйча өебез ягына йөзеп киттем. Кая ул бату турында уйлау? Монда кишер мөһим! Батмадым. Шәп йөзә бит апагыз!

Шул Кабанда тагын бер хәл булды. Кыш көне су ката бит инде. Итеккә бау белән бәйләп беркетелгән кәнки белән шуабыз. Кая инде ул вакытта ботинкалы кәнкиләр. Начеслы чалбар киеп ызгыртам гына боз өстендә. Бәкеләр бар иде. Сизмәгәндә, абайламаганда чумдым мин боларның берсенә. Ике терсәгем белән тәпкә китмичә бәке кырыена терәлеп калдым.

«Абый, абый!»—дип кычкырам. Абый әллә кайда. Күренми. Кирәк түгел чакта гел янымда. Ә менә хәзер шундый хәлиткеч мәлдә әллә кая олаккан. Янәшәмдә шуып йөргән малайлар тавышымны ишетеп, тартып чыгардылар. Өстемнән шыбырдап су ага, туңу турында уйлау юк. Бар хәсрәтем: «Әнигә әйтмәгез!»—дигән сүзем иде. Мич башында байтак жылынып утырдым. Әни алай каты бәрелмәде тагын.

Ходай саклагандыр, югыйсә, Кабан башындагы Камал театрында эшләячәк Данияне белмәгән, күрмәгән булыр идегез.

Менә шундый истәлекләр белән матур ул минем Казаным. Кичләрен яшьләр, тату гаиләләр үз көймәләренә утырып Кабанга чыгалар иде, Болакка үтеп, Кремль тирәләренә хәтле йөзеп күңелле сәяхәтләр ясыйлар иде. Кайберәүләр гармуннары белән чыгалар, җанга сихәт иңә торган үзебезнең татар җырларын яңгыраталар иде.

Ничек шундый Казанны сагынмыйсың да, яратмыйсың да ди!

## Төштә күргән кебек

Иң беренче кечкенә вакытымны әти-әнием белән бергә: урталарында, караватта итеп хәтерлим. Иркәләнәм. Әле берсенә, әле икенчесенә сырпаланам. Алар да мине сыйпыйлар, назлыйлар, матур сүзләр әйтәләр. Иң рәхәте шул: алар бер дә иренмичә минем белән уйныйлар. Сабый балага ни кирәк тагы? Алар шулай итеп җиде бала үстергәннәр. Иң татлысы мин булганмындыр инде, чөнки апагыз—төпчеге. Әтием Нургаяз кулында «Үчти, үчти!» дия-дия күкләргә чөелгәнем истә дә кебек әле.



Безнең зур мичебез бар иде. Минем йокы урыным—караватым һәрвакыт шунда булды. Анда рәхәт. Берәү дә комачауламый. Кәҗә бәтиләре дә сикереп менә алмый. Әни мичтә коймак пешерә, ә мин өстә—җылыда. Аннан чәй эчәбез. Әти келәшчә белән шикәр вата, кайчагында ватканда утлар чыга әле аннан. Мина инде ин зур кисәген бирә. Төпчек бит!

«Нәнә абый» дип йөртәм бер абыемны. Ул мина һәрчак морожный алып бирә. Ни өчен мин аны «нәнә» дим—ул минем алда туган. Шул абый бик тә футбол уйнарга ярата, ә мина кәҗәбезне карарга куша. Мин кәҗә саклыйм һәм шуның өчен морожный белән бүләкләнәм. Яратам шул мин тәмле-томлыны. Кәҗәне күпме кирәк көтәр идем әле, бирсеннәр генә морожныйларын.

Кәҗә генә түгел, казлар да көттем. Ишек алдыбыз чирәмле, бакчабыз зур, анда бәрәнге утыртабыз. И ул кура җиләкләре!

Уналты яшендә нәнә абыем вафат булды. Кемнәр инде мина морожный алып кайтыр?... Әй, абыем, хәзер дә сине бик еш искә төшерәм. Үзем сыйлар идем әле. Тик нишләтәсең, шулай язгандыр инде.

Әти-әнинең туганнары бик күп. Бездә бик еш мәҗлесләр уза. Әни тәмле-тәмле камыр ризыклары белән сыйлый үзләрен. Сөйләшәләр, көлешәләр, җырлыйлар, бииләр. Ишек аллары ду килә. Көз көне җыелсалар мин табакка су алып галушларын, ботинкаларын юа торган идем кунакларыбызның. Сөртеп тә куя идем әле. Мактыйлар иде. «Ай, кем юып куйган аяк киемнәребезне!»—дип шаккатуларын яратып, көтеп тора идем.

Бездә проигрыватель бар иде, Зифа Басыйрова, Фәридә Кудашева, Рәшит Ваһапов пластинкаларын куя идем дә, кунакларыбызча бии идем, алар киткәч.

Әни кунакларны белеп чакырган. Ул аларга «Бер-берегезне онытмагыз!»—дип гел әйтеп торды. Мина ул вакытта җиде-сигез яшь булгандыр. Хәзерге вакытта да кунаклардан өзелеп торганыбыз юк, Аллага шөкер.

## Артистлыкка беренче адымнар

Әйткәнемчә, проигрыватель уйнатып, җырлаучыларның җырларына хәрәкәтләр ясап, кыланып йөрүләр бушка китмәгән, күрәсең. Башкача мөмкин дә түгел, чөнки кичләрен һәр йорт каршында бүрәнәләрдә апалар, әбиләр утыра. Тирә-юнь халкы җыелышып сөйләшәләр, дөнья хәлләрен, күрше-тирә яңалыкларын «чәйнәп» бетергәч, түгәрәк сәнгати төс ала иде. Ягъни җыр, бию, мәзәк куерту башлана. Мин инде алгы рәттә—концертта иң актив катнашучы. «Әртист булырсың син!»—дияләр иде.

Аннары әни күрше әбиләрне өйгә чакыргалый башлады. Чаршаулы караватта аларга да концерт куям. Чаршауны ачып җибәрәм дә: «Хәзер башлыйм!»—дим. «Сәхнәдә танылган артист Дания!» Җырлыйм, сөйлим, биим. Шунда, сиділе караватта, каз мамыклы мендәрләр дә сикерешә. Мактыйлар. Мактаган саен азынам. Конфет бирәләр, алкышларга күмәләр. Әбиләр: «Бибикамал, бу кызың, менә күр

дә тор, артист булачак»—диләр.

Кем ул артист? Үзем әле юньләп белмим. Әнием дә күрми, белми калды киләчәгемне.

Шулай да йоклар алдыннан комган тоттырып, тәхарәтләр алдырды, догалар ятлатты. Жомга көнне тәсбих тарттырып, дини тәрбия дә бирергә иренмәде. Үләр алдыннан күрше әбидән «Исме әгъзам» догасын яздырып алган. «Бүтән нәрсә бирә алмыйм мин сина, сине шушы дога сакласын!»—диде.

Әнием, бәгърем, синен догада яшим.

## Театр җене

Бишенче класстан бию түгәрәкләренә йөрдем. 114нче мәктәптә укыдым. Шуннан театр училищесына килдем. Әле сигезенче классны гына тәмамлаган идем. Кабул итү комиссиясе, нишләптер «татарчасы начаррак» дигән фикергә килеп, мине алмадылар. Нигә алай булды икән? Югыйсә сиптерәм генә бит инде татарча!.. Кремльдә имтихан тоттык. Театрнын шунда булган чагы да бар иде. Комиссиядәге Галия Булатованы, Ширияздан Сарымсаковны, Празат Исәнбәтне хәтерлим. Әле бит дәрестән качып килгән идем. Нинди хурлык!



Жә, ярый, рәттән сөйлим.

Ниһаять, керергә чират мина житте. Кәккүк белән әтәч турында мәсәл сөйләдем. Комиссиядәге озын буйлы абый туктатты... Чыгып торыгыз, диде. Сонyннан бер ханым (исемнәрен язмыйм инде, югарыдагы исемлектән күреп белерсез) чыкты да, укырга керүчеләрнен исемнәрен укыды. Мин елап жибәрдем. Теге озын абый чыкты.

—Абый, нигә мине алмадыгыз!—дим.

—Үсеп кил, яме, үскәнем!—диде.

Инде 9нчы классны тәмамлагач, чәчләрне кисеп, болай да бөдрә чәчемә бөдрәләр өстәп, буйлы-буйлы аклы-зәнгәрле, өрелгән итәкле матур күлмәк киеп, янадан Горький клубына, кабул итү имтиханнарына килдем. Комиссиядә Ширияздан Сарымсаков, Асия Хәйруллина, театр училищесы директоры —Шапиро.

Чират мина житте. Мин хәзер батыр—ничек керергә кирәклеген беләм. Теге озын абый юк. Мәктәптә татар теле укытучы белән байтак өйрәндек. Мәсәлнен икенчесен укыдым. Әйбәт кенә килеп чыкты. Ширияздан абый: «Жырлап күрсәт әле»—диде.

Бер кыз әйткән иде: «Жырлаганда туктатсалар да туктама!»—дип.

Киттем жырлап:

*«Сәхрәләрдә ялгыз йөргән чакта*
*Мин яратам чәчәк исләрен*
......

Анда нинди тавышлар чыккандыр инде. Ширияздан абый зур кульяулыгын чыгарды: әллә елый, әллә көлә.

Дөресрәге, бөтенесе көлә. Ширияздан абый һаман күзен, борынын сөртә. «Тукта!»—диләр. Туктамыйм. Шулай куштылар бит. Жырлап бетергәч:

—Булды, абый!—дидем.

Шәп жырладым. Ярый, монысы үтте. Хәзер этюд. Гүзәл исемле кыз этюднын нәрсә икәнен өйрәтте.

Ширияздан абый:

—Менә син жәй көне, ачыклыкта кызынып утырасын... Менә сина нәрсәдер куна... Аягын буйлап өскә менә... Менә... Менә... Күлмәгенне күтәрәсен...—ди. Шулай иттем.

Хәзер уйлыйм: алар минем аягымны караганнардыр инде. Ә бездә аяклар Аллага шөкер! Биюче аяклары алар—сөбханалла! Юкка гына бит мин Казаннын бөтен клубларына биюгә йөрмәдем.

Күрәсез, әрсез, кыю булганмын.

## Матур буласым килде

Беренче курста биек үкчәле (шпилькалы!) туфли алдым. Ничә сумга диегез? 14 сумга—ике стипендияне бергә кушып. Шуны кибеттән үк киеп кайттым. Трамвайдан төшеп атлый гына башлаган идем: кыса, кыра. Салдым да, җәяүгә калдым. Кибеттә таман кебек иде бит. Киясе килгәч алдым. Менә хәзер нишләргә? Аягым тузәлгәч туфлиләремнең үкчәсен кистердем.

«Сәнгать корбан сорый» дип дөрес әйтәләр икән.

## Чарасын таптым

Мәктәптә гимнастика белән дә шөгыльләндем бит әле мин. Шпагатлар ясыйм. Дусларым белән бергәләп пирамидалар корабыз. Республика, район, мәктәп ярышларында гел катнаша идем.Ул грамоталарның чуты-исәбе юк. Тик менә—спорт кәчтүмем генә юк әле. Анысын да җайладым. Өскә ак кофта таптым, аска абыйның өйдә киеп йөри торган трусигының балагына резин кертеп, чыгышлар ясый башладым. Дус кызларым: «Каян таптың, каян алдың?»—дип йөдәтеп бетерделәр.

Кулыңнан эш килгәч, җаен чыгарасың аның.

## Кулинар тәҗрибә

Ничә яшьләр булгандыр үземә, чама белән—ундүрттер. Беренче тапкыр токмач кисеп, аш пешерәсе иттем. Әллә нигә камырым йомшак булды. Йомырка да сыттым югыйсә. Оны азрак булды, ахрысы. Бөтен җирем онга батты. Оештыра алмадым. Ябышып беттем. Уклау кырам, куна кырам. Ах-вах килеп, интегеп беткәннән сон, камырны табыкларга чыгарып салдым. Рәхәтләнде табыкларым.

Камыр басарга күрше Газзә апа өйрәтте. Рәхмәт анарга.

## Юкка хафалану

Минем күкрәгем озак чыкмыйча торды. Иптәш кызларыма соклана торган идем. Алар житкән кызлар кебек, горурланып, күкрәк киереп йөриләр. Ә минеке юк та юк. Үсәр микән ул? Кемнән сорарга да белмисең бит. Хәзер табибка барыр идең дә, белеп кайтыр идең. Сәбәбе ни? Кайчан була? Булмаса да булдыралар аны хәзер. Ул вакытта минем кебек кызга трагедия бит бу.

Түшемә ике бәләкәй туп куям да, билемне кысып, көзге алдында көязләнеп торам. Их, аңламыйсыз хәлемне... Соң өлгерешле кыздыр инде мин.

Ә инде театр училищесында укыганда!.. Кайбер хәйләкәр ир-ат укытучылар сиздермәслек кенә итеп сыпыргалап китәләр иде. Сизәбез... Дания апагыз хәзер бала-чага түгел—София Лорен күкрәкләре бер кырыйда торсын!

Унжиде яшь чүтеки...

## Төшләремдә өнәрем

Мин яшь чагымда төннәрен саташкалап йөргәнмен. Урыслар әйтмешли—лунатик. Белештерми урынымнан торам икән дә, ишеккә барам, тышка чыгам. Шунда йөрим икән. Әни мине һәрвакыт күзәтеп торган. Бисмиллаларын укыган, мине әкрен генә, җайлап урынга яткырган. Мин тынычлап йоклап киткәнмен.

Шул биюгә йөрүләрем, гимнастика белән шөгыльләнүләрем, хыялый булуым саташтыргандыр инде. Мин төшемдә тауларга менә идем. Гомер буе мендем тауларга. Әле күптән түгел генә менеп җиттем. Өстә тигезлек, яктылык. Авыр булса да мендем. Хәзер андый төшләр керми. Тынычландым.

**Дания НУРЛЫ**

***Редакциядән:*** *әле быелның июнь аенда гына Дания Нургаяз кызы Нуруллинага «Россиянең атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде. Котлыйбыз!*

*Казан университетының татар бүлеген тәмамлаган Илшат Сәйфуллин дистә елдан артык милициядә эшләде. Буш вакытларында ул балалар өчен шаян хикәяләр, шигырьләр яза иде. Узган ел Илшатның Татарстан китап нәшриятында беренче китабы дөнья күрде. Шаян шигырьләрдән торган икенче җыентыгын да әзерләгән иде ул, Язучылар берлегенә дә керергә хыяллана иде...*

*Язмыш аяусыз. Чечняга, хезмәт командировкасына киткән милиция капитаны кире туган ягына әйләнеп кайта алмады. 39 яшендә аның гомере өзелде.*

*Илшат Сәйфуллинның редакциябез папкасында сакланган бер хикәячеген бүген сезгә тәкъдим итәбез.*

# СӘЯХӘТ

ШАЯН ХИКӘЯ

Бу хәл бик-бик күптән, моннан 7-8 еллар элек булды. Мин яшьтәшем Сәрия белән укырга да кермәгән, ә Милис беренче сыйныфны тәмамлап килә иде. Безгә, әле борын асты кипмәгән, еламыйча ашый да белмәгән сабыйларга Милис ул вакытта зур акыл иясе, галим булып тоела иде. Монарчы колак ишетмәгән нәрсәләр, яналыкларны ул сөйләде. Шуңа да Милиснең мәктәптән кайтканын һәркөн зарыгып көтә идек. Ә беркөнне ул, гадәттәгечә безне күргәч:

—Беләсегез килсә, жир тү-гә-рәк!—дип кычкырды. Безнең ачык авызлар, шакмак күзләр Милискә яхшы тәэсир итте булса кирәк, ул тагын:

—Жир шары тү-гә-рәк,—дип, куллары белән һавада зур түгәрәк сызды.

—Һы, алма кебекме?—диде Сәрия, кулындагы «антоновка»га аптыраулы караш ташлап.

—Әллә туп кебекме?— дип өстәдем мин, кулымдагы әти туган көнгә бүләк иткән кызыллы-зәңгәрле тупны әйләндерә-әйләндерә.

—Алма кебекме, туп кебекме, без моны, теләсәк, белә алабыз!—диде Милис, серле караш ташлап. Шул вакытта без Милиснең башында яна план туганын сизеп алдык.

—Ничек белә алабыз?—дидек Сәрия белән бертавыштан.

Фәүзия апа әйтте, без авылның бер башыннан чыгып китсәк, икенче башыннан кайтып керергә тиешбез.

—Безнең кызыл сыер кебекме?—диде Лилия, кулларын чәбәкләп.

—Причум монда сезнең сыер?

—Ул да иртән авыл башына таба китә дә, кичен икенче яктан арып-талып кайтып керә.

—Димәк, көне буена бөтен дөньяны әйләнә, әле ул акрын гына чирәм ашап барадыр—дип, Милис уйлана башлады...—Һәм, димәк, без дә бер көндә дөньяны әйләнә алабыз!—дип кычкырып ук жибәрде.

Шулай итеп, без өчәүләп жир тирәли ике көн эчендә сәяхәт кылырга булдык. Ни өчен ике көн, сыер бер көндә әйләнеп кайтканны, диярсез инде сез. Милис бит, йөргәч-йөргәч башкаларга да файдасы булсын, Африка дигән илне узганда сабантуй бәйрәме оештырып алырбыз, диде. Бәйрәмнән соң куна калмасак, андагы кешеләр үпкәләр, дип тә өстәде. Моңа шатланып риза булдым. Бер яшькә олырак булса да, көрәштә Милисне жинәм мин. Тегеләрнең татарча көрәшә белмәгәннәрен истә тотып, батыр калып, Африка тәкәсе алырга ниятләдем...

Якшәмбе көнне юлга чыктык. Әмма күпме генә барсак та, авылыбыз тиз генә күздән югалмады. Кояш баеп, тирә-юнь карангылана башлагач кына бер басуга килеп чыктык. Милис тиз генә басу кырыендагы эскерт башына менеп китте дә, кулын каш өстенә куеп еракка күз салды.

—Нәрсә карыйсың, карангы бит,—диде аяклары авыртуга түзәлмичә еларга житешкән Сәрия.

—Бездә төн булганда, аларда көн була. Димәк, африкалылар безне күрмәсә дә, без аларны күрергә тиеш,—диде Милис белдеклеләнеп, һәм:—Тик нигәдер күренмиләр,—дип, үз сүзенә үзе каршы килде.

Сәрия елый ук башлады. Бик кызгандым үзен. Сәяхәт кылырга аны мин күндергән идем шул. Сабантуй батыры буласым килсә дә, кызны кызганып, авылга кайту турында уйлана башладым.

Ничек эскерттә төн кунуыбызны, һәр кыштырдаган тавыштан куркуыбызны сөйләп тормыйм. Икенче көнне авылның кайсы ягыннан чыгып китсәк, шул ягыннан кайтып та кердек. Әти-әниләребездән, көне-төне эзләгән авыл халкыннан, милициядән безгә ничек эләккәнен үзегез дә чамалыйсыздыр...

...Әйе, вакыт тиз үтә. Сәрия белән жиденче сыйныфка життек. Күп нәрсәләрне үзебез укып, ишетеп беләбез. Вакытыбызны кызыклы һәм файдалы итеп үткәрергә тырышабыз. Төрле кешеләр белән очрашабыз, сәяхәт кылырга яратабыз. Африкага ук барып житмәсәк тә, үткән жәйдә генә укытучылар белән күрше мари авылы мәктәбендә сабантуй уздырып кайттык. Бик күнелле булды.

Тик теге күптән булып узган вакыйгалар Милиснең күнелендә тирән эз калдырды. Күп фәннәрне яхшы гына укыса да, география укытучысы белән гел бәхәсләшә.Үз тәжрибәсеннән чыгып, жирнең түгәрәк булуына әле дә ышанмый.

---

# ПАРЧАЛАР

## Балыктан—балык

Бала чактан ук балык тотарга ярата торган идем мин. Тынычлык: беркем дә комачауламый, син үзең дә беркемгә дә кирәкмисен. Үзен дә син табигать белән берлектә, һәр тавышны ишетәсең, жилнең тыныч кына исүен сизәсен.

Кыш көне дә тотам мин балыкны. Салкын, суык. Урамда буран булгангамы, әллә тагын нәрсәгәдерме, белмим, ләкин күнелдә ниндидер борчу, жанга тынгы табып булмый. Ялгыз агачларны көчле жил як-якка иелдерткән төсле, баштагы уйлар бүлмәнең бер почмагыннан икенче почмагына әрле-бирле йөрергә мәжбүр итә. Шулчак өстәлдәге аквариумга күзем төште. Кечкенә генә балык су чирәме арасыннан салмак кына йөзеп йөри. Аның бер кайгысы да юк, ана рәхәт. Шушы бәләкәй генә мәхлукка карап жәйге бер мәлне искә төшердем.

Ул вакытта таң сызыла гына башлаган иде. Бар тирә-якны уятучы моңлы әтәчебез дә йоклый әле, мин исә барлык әйберләрне жыеп күл буена, балык тотарга төшеп киттем инде. Иртәнге тынлык. Салкынча һава йокыдан тәмам айнытып бетерә, яшел үләндәге чык аяк киемен чылатып тәнне талгынлата, сафландыра сыман. Күл өстеннән күтәрелгән томан болынга ак пәрдә сыман жәелгән. Әйтерсең лә хәзер шушы пәрдә жыелыр да, күл, андагы балыклар, үсеп утыручы камышлар күренер сыман. Ләкин томан ашыкмый, көндезге спектакльне башлар вакыт житмәгән әле. Тынлык. Хәтта кайвакыт чирәм арасыннан елан яки кәлтә барганын да ишетә аласың.

Әмма ашыгырга кирәк. Борынгы бабаларыбыз әйтүенчә, нәкъ менә шушы мәлдә чуртан шәп каба икән. Тынычлыкны бозарга теләмичә, әкрен генә кармакларны сүтәм. Күл өстендә чыбыр-чыбыр килгән һәрбер тавышны ишетәсең. Әйе. Балыкның тамагы ачкан. Хәзер абыең ашата сине, көтеп кенә тор. Тәләкә суны икегә аерып сабантуендагы колга сыман су өстендә төп-төз басып тора. Шушы вакытта башындагы булган барлык юк-бар уйларны чыгарып ташларга кирәк. Фәкать балык турында гына уйла... Бер тапкыр үзем дә шулай бүтән әйбер турында хыялланып утырганда, шушы ук урында олы бер чуртанны ычкындырдым. Бүген алай булмас, хәзер мин дә өйрәнеп життем шул...

Чү, тәләкә батты. Аннан шундый ук тизлек белән кире калыкты. Шул хәл бернечә тапкыр кабатлангач, балыкның ләккәненә шигем калмады. Менә ул мизгел. Иң рәхәте! Балык чыгару! Качарга теләгән мескен балык йә тегендә, йә монда йөзә, бәргәләнә. Кармак сабы кинәт жинеләеп китте, аннан соң шунда ук тагын авырайды. Бу вакытта

башта бер генә уй: ычкындырмаска, ничек тә булса тартып чыгарырга. Ун минут көрәшкәннән соң чуртан җинелде. Судан күтәреп алганда соңгы тапкыр сикереп куйды куюын, ләкин беренче тапкыр тоткан шундый олы балыкны мин җибәрмәдем инде.

Тик нишләптер, шушы чуртаннан соң мина бүтән бернинди балык та ләкмәде, хәтта чиртеп тә карамады. Ләкин кәефем барыбер күтәренке иде, чөнки ул вакытка иң олы чуртанны мин тоттым. Өйгә кайтып кергәч, әти мактады. Соңыннан гына балыкның эче кабаруына гаҗәпләнде ул. Гадәттә чуртаннар ашагач кына шулай «тазаралар». Ә иртә таңнан нинди ашау ди инде. Шулай да эчен ярып карарга булдык. Яруым гына булды, идәнгә кечкенә балыклар сибелде. Сенлем шундук табак алып килде. Бәләкәй табан балыкларын җыеп шул табакка салдык. Игътибарлабрак карасам, өчесе әле тере икән. Банкага су тутырып шунда салган идем, бер яктан бер якка әйләнгәләделәр дә, йөзеп киттеләр. Соңыннан мин ул балыкларны аквариумга күчердем. Ике-өч атнадан соң икесе үлде. Әллә су килешмәде, әллә чирләделәрме, белмим. Ләкин өченчесе әле һаман да яши.

Инде олы булды хәзер, үзе дә нәкъ теге чуртан төсле. Күлгә алып барып җибәрергә телим мин аны. Димәк, яшәү теләге менә нинди олы көчкә ия икән!

## Сырлыйлар!

Урамда яз. Кар эрегән тизлек белән кешеләрнең башлыклары да каядыр югала башлыйлар. Күмер төсендәге чем-кара чәч кояш нурында алтындай ялтырый. Шуларга карап бер үзенчәлеккә игътибар иттем. Бу инде замананың тәэсиреме, әллә тагын берәр нәрсәнекеме, белмим, ләкин яшь егетләр башларында төрле-төрле рәсемнәр, сырлар ясый башладылар. Нинди генә бизәкләр очратмыйсың. Кибеттә йөргәндә күрдем, берсенең чәчен хәтта шахмат тактасы сыман кискәннәр. Уйлап-уйлап тордым да, үзем дә шундый сырлар ясатырга булдым. Тик бу дөнья дигәнең майдан пычак белән үткәргән сыман гына бармый шул. Башны «матурландыру» өчен әти-әнинең дә орышуларын, дусларның: «Син нәрсә, акылдан яздыңмы әллә»,—дигәннәрен дә йөрәккә якын китермичә тыңларга кирәк булды.

Монарчы чәчнең арт өлешен калдырып үстерә идем. Чәчең озын булу шәп ул. Кыш көне муенга салкын кертми, дәрестә утырганда да аркага карандаш яки каләм белән төртмиләр, чәчтән генә тарталар иде. Сырлар булгач чәчне кыскыртмаслар дип уйладым мин, әммә чәч кисүче апаның бер кулында кайчы, икенчесендә тарак күргәч, ник килгәнемә үкендем. Урындыкка утырткач: «Күзеңне йомып тор. Эш тәмамлангач әйтербез»,—диде ул. Белгән бар догаларымны укып «карангылык дөньясы»на чумдым. Артта кайчының «Чырт!» иткән тавышын ишеткәч, йөрәгем «Дөп!» итте. Булды бу! Хәзер инде чәч белән теләсә нәрсә эшләсәләр дә ярый иде. Гел пеләш калдырсалар да исем китмәс булдым. Алты ай буе карап, көн саен тарап үстергән чәченне бер мизгелдә кисеп атсыннар әле!

Машина, кайчы тавышлары тынгач күземне ачтым һәм үземне танымадым. Бер карасаң, берни дә үзгәрмәгән сыман, башның авырлыгы да шул ук, икенче яктан карасаң, колак өстендә өч сыр матурланып тора. «Озын чәч үстерү модадан чыкты инде. Кызлар хәзер «сырланган» егетләргә карыйлар!»—диде чәч кисүче апа. Чыннан да, дусларымның фикере үзгәрде, урамда очраган кешеләр дә борылып карый башладылар. Хәтта әти белән әнигә дә бик ошады.

Егетләр! Үз чәчегезне төрлечә итеп кистереп карагыз, бизәк, рәсем ясатулардан курыкмагыз.

**Динар ВӘЛИЕВ,**
*КДУ студенты*

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@telebit.ru.*

## «Казан утлары» архивыннан



*Язучыларның Тукай клубында җыелыш. Сулдан уңга, беренче һәм икенче рәтләрдә—Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Габдулла Шәрәфетдинов, Рәис Даутов. 1985 ел.*



*Мөдәррис Әгъләмов (1946-2006). 60 нчы еллар башы. Урта мәктәп тәмамланган. Алда зур хыяллар...*



*Язучылар Фатыйх Хөсни һәм Риза Ишморат. Аккош күле иҗат йорты верандасында. 1958 ел.*



*Әдәбият-сәнгать әһелләренең укучылар белән очрашу мизгеле. Сулдан уңга—композитор Ганс Сәйфуллин, җырчы Миңгол Галиев, язучы Рәфкать Кәрами,артист Равил Шәрәфи. 1984 ел.*



*Аксакаллар. Сулдан уңга—Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники, Мидхәт Шакирҗанов (әдәбият-сәнгать кешеләрен фотоелъязмада калдыруда зур хезмәт куйган фотограф), Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов. Язучылар берлеге бакчасында. 1996 ел.*



*Замандашлар. Сулдан уңга: Ренат Харис, Фоат Садриев, Дамир Гарифуллин.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### «ЯҢАРЫШ»—ИЛ КҮЗЕНДӘ

Казанның «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә узган Төбәк һәм милли массакүләм мәгълүмат чараларының IV Конгрессының пленар утырышында ТРнын Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты. Конгресс кысаларында республиканың «Яңарыш» дип аталган Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу республика фонды тәкъдир ителде. «Болгар шәһәрчеген һәм Зөя утравын төзекләндерү проектларына алынуыбыз халкыбызның рухи ныклыгы җитлегүен дәлилли. Татарстанда хәйрия белән шөгыльләнүнең матур тәҗрибәсе бар инде. Болгардагы һәм Зөя утравындагы тарихи ядкарьләрне торгызуга да җәмәгатьчелек, эшмәкәрләр, дәүләт структуралары, муниципаль район хакимиятләре бергәләп алынды, Россия Президентының да ярдәмен сизәбез»,— диде Минтимер Шәймиев.

Бүген Болгар шәһәрчегендә һәм Зөя утравында эш тулы куәткә гөрли. Дәүләт Киңәшчесе сүзләренә караганда, Болгарда яңа мәчет төзеләчәк, киләсе елга биредә чатырлар лагере барлыкка киләчәк, республиканың 20ләп авыл хуҗалыгы предприятиесе быелдан Икмәк музеен төзүгә тотыначак, ислам динен кабул итү хөрмәтенә һәйкәл куелачак, шулай ук Болгарда да, Зөя утравында да сәяхәтчеләрне заманча елга вокзалы каршы алачак.

Конгресста Россиянең 40 төбәгеннән килгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты. Пленар утырышның икенче көнендә кунаклар Болгар шәһәрчегенә һәм Зөя утравына да сәфәр кылды. Аннан соң алар «Федор Шаляпин» теплоходында Идел буенча сәяхәт иттеләр. Биредә Россиянең телевидение, радио һәм басма мәгълүмат чараларында эшләүче танылган кешеләре катнашында мастер-класслар һәм түгәрәк өстәлләр узды.

Конгресста катнашучылар белән ТРның Премьер-министры Илдар Халиков очрашты. Очрашуда шулай ук ТР Президент Аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов, республиканың Дәүләт Советы Рәисе урынбасары—Татарстан Журналистлар союзы рәисе Римма Ратникова белән Басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы җитәкчесе Марат Моратов та катнашты.

### БОЛГАР ҖЫЕНЫ

19 июньдә ел саен үтә торган олы бәйрәмнәрнең берсе—«Изге Болгар җыены» узды. Спас районының Болгар шәһәрендә ата-бабаларыбызның 922 елда рәсми рәвештә ислам динен кабул итүе билгеләп үтелде. Болгарларның тарихы, мәдәнияте, ә иң мөһиме дине—һәр татар кешесе, Россиянең һәрбер мөселманы өчен, һичшиксез, иң кадерле мирас. Шуңа күрә менә инде 21нче тапкыр Изге Болгар җирендә, явып торган яңгырга карамастан, Татарстаннан гына түгел, Россиянең бик күп почмакларыннан меңләгән кунак җыелды. Җыенга килгән һәркемнең бер максат—болгар ата-бабаларыбызны искә алу, алар өчен дога кылу, иманны ныгыту, дин кардәшләре белән аралашу берләштерә иде.

Чараның быелгы программасы тагын да кызыклырак һәм мәгънәлерәк булды. Бәйрәм, әлбәттә, Коръән аятьләрен уку белән башланып китте. ТР Президенты Рөстәм Миннеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Илдар Халиков, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Россия үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил Гайнетдин да чараның иң кадерле кунаклары иде. Болгарга шулай ук чит илләрдән—Төркия, Болгария, Израиль, Венгрия һәм Кувейттан югары дәрәҗәле кунаклар да килгән иде. Җыенда катнашучылар Идел Болгарстанының ислам динен кабул итүе истәлегенә билге-таш салдылар. Олы манара янында оештырылган сәхнәдә ТРның танылган артистлары башкаруында мөнәҗәтләр, нәшидләр һәм шигырьләр ишетергә була иде.

### «СӘЛӘТ»ТӘ—СӘЛӘТЛЕЛӘР

9-12 июль көннәрендә Алексеевск районының Биләр саклаулыгы биләмәсендә республика яшьләренең XIX «Сәләт-Биләр» фестиваль-бәйгесе узды.

Бәйрәм быел да «Изге чишмә» мемориаль комплексында, ягъни «Хуҗалар тавы» янында үтте. Фестиваль хәрәкәтендә 700дән артык мәктәп укучысы, студент һәм укытучы катнашты.

«Сәләт» фестивале интеллектуаль яктан сәләтле балаларны һәм яшүсмерләрне барлау, аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерергә шартлар тудыру, яшүсмерләрдә

һәм яшьләрдә туган җиргә, аның тарихына, гореф-гадәтләренә хөрмәт уяту, шулай ук рухи-әхлакый һәм физик тәрбия бирү, сәламәт яшәү рәвешен сайлау максаты белән үткәрелә. Биләр фестивалендә катнашу «Сәләт» оешмасының «Раушан» (Казан), «Рухият» (Әлмәт), «Бөгелмә» (Бөгелмә), «Байлар Сабасы» (Байлар Сабасы), «Кол Шәриф оныклары» (Чаллы) аланнарының да программасына кертелгән.

Фестивальне Алексеевск муниципаль районы, Татарстанның Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, ТР Фәннәр академиясе белән берлектә «Сәләт» фонды оештыра. Бәйге быел да ТР Министрлар Кабинеты ярдәме белән үтте.

Фестиваль-бәйгенең ачылу тантанасында ТР яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Рафис Борһанов, шулай ук депутатлар, галим-язучылар, төрле дәүләт оешмалары һәм министрлыклардан вәкилләр, Татарстандагы эре компанияләрнең җитәкчеләре катнашты.

Фестивальгә Россиянең төрле шәһәр һәм төбәкләреннән—Чувашия, Удмуртия, Башкортстан, Киров өлкәсе, Самара, Саратов, Санкт-Петербургтан, республикабызның 10 район-шәһәреннән махсус делегацияләр килде. Быелгы фестиваль хәрәкәтендә Чехия кунаклары, Казанга татар телен өйрәнергә килгән Америка студентлары да катнашты. Географик киңлек тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән шәхесләр—Рабит Батулла, Әнвәр Хәйри, Фаяз Хуҗин белән очрашулар бик җанлы узды. Фестивальдә катнашучылар «Изге чишмә» тарихи-мәдәни комплексында да булды. Шулай ук Борынгы Биләр шәһәренең археологик казу эшләре алып барылган урыннарын да үз күзләре белән күрде алар.

### КФУ—СТУДЕНТЛАР «ОЯ»СЫ

Казан (Идел буе) федераль университеты ректораты хәбәр итүенчә, 2011 елның 1 гыйнварына кадәр КФУга берничә уку йорты кушылырга тиеш. Нәтиҗәдә, анда 45 меңнән артык студент белем алачак. Ректор И. Гафуров: «Белем бирүнең сыйфатын арттыру өчен чит илләрдән дә укытучылар чакырырга уйлыйбыз»,—ди. ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте академиясе инде бетерелде дә. Академия студентлары укуларын КФУда, яки башка уку йортларында дәвам итә алачак.

### АРЧАДА—ИСКЕ КАЗАН ТҮГӘРӘК УЕНЫ

Арчада республикабызның фольклор коллективлары катнашында «Иске Казан түгәрәк уены» фольклор фестивале булып узды. Анда 25 районнан җәмгысе 400гә якын кеше катнашты. Свердловск өлкәсенең Аракай авылыннан бөтен Россиягә танылган «Сырдарья» фольклор ансамбленең кунак итеп чакырылуы нур өстенә нур булды.

Мәртәбәле жюри фольклор-этнографик чыгыш, фольклор-хореография, җыр, халык уен коралларында уйнау, бәет, мөнәҗәт жанрлары буенча бәя бирде. Әлеге чараны ачу тантанасына Татарстан Мәдәният министрлыгының эшләр идарәсе җитәкчесе Кадрия Идрисова да килгән иде. «Бу бик тә изге, илаһи, мөкатдәс, чын-чынлап үзебезчә булган бәйрәм,—диде ул.—Халкыбыз фольклор хәзинәсенә ифрат бай. Ләкин хәзинә тиз генә табылмаган кебек, бу төр хәзинәне дә барлау зур тырышлык, сабырлык сорый. Тапкан хәзинәне саклый белү дә мөһим».

Әлеге чараны оештыручы, Татарстан Мәдәният министрлыгы каршындагы Татар фольклорын җыю, саклау һәм өйрәнү үзәге директоры Фәнзилә Җәүһәрова әйтүенчә, татар фольклорын туплауга игътибарны арттырырга кирәк.

### БӘЙГЕ КАБАТ ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ

Татарстан Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры «Яңа татар пьесасы-2010» конкурсын игълан итә. Авторлар конкурска сәхнәдә куелмаган һәм матбугатта чыкмаган пьесалар тәкъдим итә алалар. Әсәрләрнең тәхәллүс белән имзалануы һәм автор турында белешмә булуы шарт. Пьесалар быелның 31 декабренә кадәр кабул ителә. Быел дүрт номинация: «Балалар һәм яшүсмерләр өчен пьеса», 35 яшькә кадәрге яшь авторлар өчен аерым номинация, «Башка формат» махсус төре, проза әсәренә нигезләнеп язылган инсценировка өчен бүләкләр. Моннан тыш, Татарстан Мәдәният министрлыгы тарафыннан махсус бүләк булдырыла. Конкурс ике этапта узачак. Аларны М. Госманов җитәкчелегендәге жюри бәяләячәк. Җиңгән пьесалар махсус җыентыкка кертеләчәк.

### ИСЕМЕ ҮЗГӘРӘ

Быел «Алтын мөнбәр» мөселман киносы фестивале исемен үзгәртә. Ул «Казан халыкара мөселман киносы» фестивале дип аталачак. Хәзер фестивальне Казан Мәскәү катнашыннан башка гына оештырачак. Җиңүчеләргә тапшырыла торган мәчет мөнбәре рәвешендәге сынны башка төрле бүлгегә алыштыру күздә тотыла. «Татаркино» дәүләт учреждениесе директоры В. Батраков әйтүенчә, ул Казан, кино, ислам белән бәйле булачак. Оештыру комитеты белән Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева җитәкчелек итәчәк. Алтынчы фестивальгә катнашырга теләүчеләр шактый җыелырга өлгергән. 50 илдән катнашырга теләк белдергәннәр. Быелгысында беренче мәртәбә Гамбия режиссерлары да катнашачак. Фестиваль 15-19 сентябрьдә узачак.

## ТАТАРЧА ИСЛАМ САЙТЫ

«Инфо-ислам» медиа төркеме үзенең татарча сайтын ачып җибәрде. Аның белән www.tatar-islam.ru адресы буенча танышырга була. Сайт Татарстандагы, Россиядәге, дөньядагы ислам яңалыкларын яктыртып бара. Шулай ук анда фикһ мәсьәләләре, үгет-нәсыйхәт, Мөслимәләр сәхифәсе дә бар, вәгазьләр урнаштырып баруга зур игътибар бирелә, чөнки бу авыллардагы хәзрәтләргә мәгълүмат табуны җиңеләйтер дип көтелә. Сайтта шулай ук сәхабәләр, татарлар тарихы турындагы «Инфо-ислам» газетасында чыккан язмаларны да укырга мөмкин.

## МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ—АКШ ЧЕМПИОНЫ

Халыкара гроссмейстер Гата Камский быел да шахмат буенча АКШ чемпионы булды. Ә ел ахырында ул халыкара бәйгедә катнашырга җыена. Әлеге турнирда җиңүче исә дөнья чемпионы исемен дәгъвалау хокукына ия булачак.

Гата Рөстәм улы 1989 елдан бирле АКШта яши. Ул беренче тапкыр Америка чемпионы исемен 1991 елда яулады һәм төрле дәрәҗәле халыкара турнирларда катнашып, танылуын дәвам итте. Әмма 1996 елда кайбер сәбәпләр аркасында шахматтан китеп торды. 2004 елда исә кабат спортка әйләнеп кайтты. Бүгенге көндә Гата Камский дөньядагы иң көчле 20 гроссмейстерның берсе булып тора. Декабрь аенда Бакуда узачак «дәгъвачылар бәйгесе»ндә без Гатага кабат җиңү теләп калабыз.

## 95 УЛ ӘЛЕ ЙӨЗ ТҮГЕЛ

95 яшькә җитеп сәхнәдә җырлаган артист—ул уникаль күренеш. Шагыйрь әйтмешли, «Ул әле йөз түгел». Татарстанның атказанган артисты Усман Әлмиевнең гомер бәйрәменә килгән тамашачы моның шаһиты булды.

Кичәне Мәдәният министрлыгы һәм Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе оештырды. Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева җырчы хакында: «Усман абыйның ветераннар советы рәисе буларак башкалар турында да кайгыртып йөрүе сокландыра. Әгәр берәр мәгълүмат кирәк булса, без аңа мөрәҗәгать итәбез. Ул безнең «җанлы энциклопедия»,—дип билгеләде һәм У.Әлмиевкә Премьер-министр юллаган Рәхмәт хатын тапшырды.

Җырчыны Г. Камал, М.Җәлил, Качалов исемендәге театр коллективлары, филармония директоры Кадим Нуруллин тәбрикләде. Юбилярны котларга Яшел Үзән районыннан якташлары да килде. Сәхнә ветераннары аңа үзләренең рәхмәтләрен ирештерде. Россия Театр әһелләре берлеге рәисе А.Калягин да Усман агага Мактау кәгазе юллаган.

Юбилярны котларга күренекле сәхнә осталары Зилә Сөнгатуллина, Рөстәм Маликов, Флюра Сөләйманова, Руслан Дәминов, Клара Хәйретдинова, Равил Шәрәфиев һ. б. килгән иде.

## ХӘЛИМ ҖӘЛӘЛЕВ КИЧӘСЕ

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләлевны хөрмәтләү кичәсе узды. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова актерга Президент Указы нигезендә «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды. Юбилярны Президент аппараты каршындагы мәдәниятне үстерү фонды җитәкчесе Нурия Вәлиуллина, артистның Балык Бистәсе районыннан килгән якташлары тәбрикләде.

Хезмәттәшләре Равил Шәрәфиев, Ринат Тажетдинов, Нәҗибә Ихсанова, Наил Дунаев, Әзһәр Шакиров, Илдус Әхмәтҗанов, Наил Шәйхетдинов үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар.

Шунысын да өстәп әйтергә кирәк Х. Җәләлев—каләм иясе дә. Ул—Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## ТАШ РАПСОДИЯСЕ

«Казан Кремле» дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгының табигать тарихы музеенда «Таш рапсодиясе» дигән күргәзмә ачылды. Анда Татарстанның беренче Президенты, бүген ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә бирелгән бүләкләр фондыннан үзенчәлекле әйберләр урын алган.

Экспозиция гамәли сәнгатьтә кулланыла торган асылташларга багышлап оештырылган. Күргәзмәдә нефрит, төсле мәрмәр, малахит, гәрәбә, гранит кебек ювелир һ.б. ташлардан эшләнгән әйберләрне күрергә була. Тамашачылар хозурына үз вакытында Илбашка бүләк ителгән кыйммәтле ташлардан шахматлар, М.Шәймиевнең бюсты, борынгы риваятьләргә нигезләнеп, фил сөягеннән эшләнгән төрле сыннар тәкъдим ителгән.

Күргәзмә киләсе елның февраленә кадәр эшләячәк.

## ГАСЫРЛАР АВАЗЫ

Күптән түгел «Гасырлар авазы—Эхо веков» журналының яңа саны дөнья күрде. Ул, журналның чыга башлавына 85 ел тулу уңаеннан, Татарстан Президенты Рөстәм Миннехановның котлавы белән башланып китә. «Гасырлар авазының бу санында Бөек Җиңү темасына зур урын бирелгән. Басманы укучылар Идел-Урал тәбәгенең 825нче батальонынннан белорус партизаннары ягына күчкән хәрбиләрнең яңа исемлеге, ТАССР халкының дәүләт органнарына ярдәм сорап язган хатлары, Муса Җәлилнең

әлегә кадәр билгеле булмаган батырлыклары белән таныша ала. Журналда ТАССР оешуга—90, Буа шәһәренә 230 ел тулуга багышланган язмалар да бар.

### УКУЧЫЛАРЫ ДА КҮП БУЛСЫН!

Казанда өченче тапкыр Бөтенроссия ислам китап күргәзмә-ярминкәсе уздырылды. Китап күргәзмәсе Россиядә ислам темасына китаплар нәшер итүне цивилизацияле рәвештә үстерү һәм китап укучыларны илдәге мөселман китапларын чыгаручы нәшриятлар белән якыннан таныштыру максатыннан оештырыла. Бу эшне Казан мөхтәсибәте башкарды. Билгеле булганча, Казанда мондый ярминкә 2008-09 елларда уздырылган иде инде.

### ЯБЫЛГАН БАСМАЛАР

Татарстанда 12 мәгълүмат чарасы ябылган. Роскомнадзорның Татарстандагы идарәсе әлеге басмаларның эшен туктатуны сорап судка мөрәҗәгать иткән. Мондый карарга килүнең сәбәбе—әлеге мәгълүмат чараларының бер елдан артык дөнья күрмәве. Моннан ары «Милли ризыклар», «Медицина для всех», «Бизнес-афиша», «Доживем до понедельника», «Торги. Аукционы. Конкурсы» газеталары, «АвтоЛидер Казань», «Казанок», «Казанская афиша», «Криминал-антикриминал в Казани», «Делаем ремонт. Журнал об идеях и материалах» журналлары һәм «Желтые, белые и голубые страницы Казани» еллык басмасы нәшер ителмәячәк.

### ЯҢА КИНОТЕАТР

Күптән түгел генә Казанда ачык һавадагы кинотеатр барлыкка килде. Ул Баскетхолл янындагы мәйданчыкта урнашкан. Оештыручыларның әйтүенә караганда, әлеге кинотеатр кино карарга автомобиль белән килүчеләр өчен бигрәк тә уңайлы икән. Дөрес, җәяүлеләрне дә онытмаганнар, алар өчен урындыклар тезелгән. Фильм үзе зур стенада күрсәтелә, ә тавышны урамдагы динамиклар аша яки машина радиоалгычын билгеле бер ешлыкка көйләп тыңларга мөмкин. Биредә бары тик комедияләр һәм мәхәббәт романнары гына күрсәтәләр.

### ГОМӘР ГАЛИГӘ БАГЫШЛАНДЫ

Буа районы Иске Тинчәле авылында быелгы Сабан туе күренекле язучы, публицист, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе Гомәр Галинең тууына 110 ел тулуга багышлап үткәрелде. Олуг шәхеснең исемен мәңгеләштерү җәһәтеннән авылда язучының музее ачылды, Иске Тинчәле мәктәбенә Гомәр Гали исеме бирелде. Бәйрәмгә җыелган халык алдында Казан кунаклары—«Татпищепром» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры Марс Алиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, үзе дә шушы төбәктә туып-үскән шагыйрә Йолдыз Шәрәпова, Г.Галинең туганы Мөбарәк Мусин, милләтпәрвәр Рәүф Ибраһимов һәм башкалар чыгыш ясады.

### АЙГӨЛГӘ БҮЛӘК

Айгөл Хәйри—милли җырларны башкару традицияләрен уңышлы дәвам итүче талантлы җырчыларның берсе. Күптән түгел ана Мәскәүдә СССРның халык артисты Б. Покровский исемендәге бүләк тапшырылды.

### «ЯНДЕКС» БЕЗНЕҢЧӘ СӨЙЛӘШӘ

«ЯНДЕКС» интернет-компаниясе мәгълүматларны татар телендә дә бирә башлый, ягъни ул татар телендәге сорауларга да җавап бирәчәк. Порталның төп бите, эзләү интерфейсы һәм «Яндекс.Почта» интерфейсы ике дәүләт телендә—рус яки татар телендә эшли. Монда татар теле морфологиясе дә исәпкә алынган. «Яндекс» үзенең кулланучылары өчен бушлай булдырган мондый мөмкинлектән дөньяның теләсә кайсы төбәгендә гомер итүче милләттәшләребез файдалана алачак.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМ

«Татмедиа» ААЖ филиалы—«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы»ның план-производство-технологик бүлеге начальнигы **Курамшина Люция Мөгамбәр кызына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



2010 елның 26 июлендә татар әдәбияты зур югалту кичерде—озакка сузылган каты авырудан соң 87нче яшендә күренекле балалар язучысы, әдәби тәрҗемәче, публицист **Ләбибә Ихсанова** вафат булды.

Ләбибә Фәез кызы Ихсанова 1923 елның 23 августында Киров өлкәсенең Нократ Аланы районы Түбән Шөн авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. 1941-43 елларда Татарстанның Кукмара бистәсендә тәрбияче, колхоз бригадиры булып эшли. 1943-48 елларда ул Казан дәүләт университетында белем ала. Студентлык чорында Л.Ихсанова әдәби иҗат һәм журналистлык эше белән шөгыльләнә башлый, республика матбугатында балалар өчен язылган беренче хикәяләре, мәкаләләре басылып чыга. 1948-78 елларда әдибә Татарстан радиокомитетында, Татарстан китап нәшриятында, «Ялкын» һәм «Казан утлары» журналларында җаваплы вазифалар башкара.

Ләбибә Ихсанова үзенең иҗат гомерендә утыздан артык китап бастырып чыгара. Аның «Якты уйлар», «Нияз мәктәптә», «Робинзоннар лагерында», «Саралан малайлары», «Гөлләр кояшка карый», «Ил кызы» һәм башка повестьлары, күпсанлы хикәяләре татар балалар әдәбиятында лаеклы урын алды. Язучы үзенең һәр әсәрендә балаларның уй-хыялларын, белемгә, батырлыкка омтылышларын романтик чаралар белән сурәтли, яшь укучы күңеленә гуманистик хисләр сеңдерә.

Ләбибә Ихсанованың аерым әсәрләре рус, украин, эстон, чуаш, башкорт телләренә тәрҗемә ителде. Ул үзе дә рус язучысы Л.Кассиль һәм чуаш язучысы А.Талвир әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итте.

1998 елда әдибәнең «Кемгә сөйлим серләремне» дигән автобиографик повесте дөнья күрде.

Ләбибә Ихсанова 1958 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә, 1965 һәм 1973 елларда ул халык депутатларының Казан шәһәр Советына депутат итеп сайлана. 1996 елда Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге әдәби бүләгенә лаек була. 1972 һәм 1983 елларда ана Татарстанның һәм Россия Федерациясенең «Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Күренекле балалар язучысы Ләбибә Ихсанованың бай иҗаты һәм аның якты истәлеге күңелләребездә һәрвакыт сакланыр.

**Татарстан Мәдәният министрлыгы,**
**Татарстан Язучылар берлеге.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Казанда Мулланур Вахитовка һәйкәл.

*Дүртенче биттә:* язучы-галим **Искәндәр Гыйләҗев**.

# Яңа китаплар




**Туфан Миңнуллин.** «Утырып уйлар уйладым». Көндәлекләр: Дүртенче китап. Редакторы Асия Юнысова. Казан: «Мәгариф—Вакыт» нәшрияты, 2010.—463 б. Тиражы—1000 данә.

Шушы араларда гына Туфан Миңнуллинның янә бер саллы китабы «табадан төште». Бу—күренекле әдипнең көндәлек язмаларыннан тупланган инде дүртенче китап. Чираттагысы дип әйтү дә дөрес булыр. Чөнки басманың йомгаклау сүзендә үк: «Туфан Миңнуллин каләменнән төшкән китапларның соңгысы түгел әле бу. 1997 елда дөнья күргән «Утырып уйлар уйладым» китабы да шул исемдәге бердәнбер китап булыр дип уйланылгандыр»,—диелә.

Заманында «Кызыл тышлы дәфтәрдән» исеме астында «Казан утлары» аша укучыга таныла башлаган гыйбрәтле кыйссалар бу юлы да гамьле уй, җитди юмор, җан җылысы һәм ихласлык белән тулы.




**Зиннур Мансуров.** Срез: стихотворения и поэмы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2010.—415 стр. Тираж—1500 экз.

Рус телендә чыккан бу китапка күренекле шагыйрь Зиннур Мансуровның әдәби җәмәгатьчелектә уңай бәя алган шигырьләре һәм поэмалары туплап бирелгән. Җыентык күптән түгел генә дөньядан киткән мәшһүр әдип Рөстәм Кутуйның кереш мәкаләсе белән ачыла. Шагыйрьнең әсәрләрен русчага Рөстәм Кутуй, Мария Аввакумова, Сергей Малышев, Геннадий Иванов, Наил Ишмөхәммәтов, Лилия Газизова һ.б.лар тәрҗемә иткән. Китапны бизәүдә рәссам Хәмит Латыйп эшләре файдаланылган.



Искәндәр Гыйләҗев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)